# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Гөлүсә БАТТАЛОВА. Дала исе килә кырдан... *Шигырьләр*. ........................................................3

Камил КӘРИМОВ. Исемсез хат. *Роман-элегия*. ..............................................................................8

Шәүкәт ГАДЕЛША. Яшен атарга тиеш... *Шигырьләр*. ..................................................................50

Әхәт САФИУЛЛИН. Кытай Гайфулла. *Повесть*. ............................................................................54

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ. Нугай йорты. *Садактагы ун кыйсса*. ..............................................................76

Фоат САДРИЕВ. Алмалы күлгә китү. *Хикәя*. ................................................................................93

Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ. Бар ул хаклык... *Робагыйлар*. ..............................................................114

Гәүһәр ХӘСӘНОВА. Кадер. *Хикәя*. ..............................................................................................117


КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ


Шаһизадә ӘБДИКӘРИМОВ. Хәсрәтләнә халкым өчен күп сүзем... *Шигырьләр*. (*Казакъчадан Рафис КОРБАН тәрҗемәләре)*. ...........................................................................121


ЯҢА ИСЕМНӘР


Азат ВАХИТОВ. Уйлар дәрьясында йөзгән чагым... *Шигырьләр*. ..........................................126

Миләүшә ГАФУРОВА. Көн дә дога... *Шигырьләр*. .....................................................................129

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ..........................................132


«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ


Сәмига СӘҮБАНОВА. Диагноз. *Повесть*. .....................................................................................134


«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ


Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Бер горурлык хисе. ......................................................................151

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ. «Кая әле, үзем!». ..................................................................................156


ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ОЕШУГА 85 ЕЛ


Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Өмет-хыялларга юл ачылган чаклар бар иде. ..................................162

Фотоархив *(Р.Фәйзуллин, Л.Хәмидуллин, Язучылар берлеге архивларыннан)*. ......................124


ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ


Рифә РАХМАН. Уйлы сәгатьләрне кайтарган шагыйрь. ..........................................................168

*Китап күзәтү:* Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Казан ханлыгы турында яңа хезмәт. ......................170

*«Төрки әдәбиятлар һәм заман»:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ...................172

*«Якутлар табыладыр вакыт белән...»:* Кәрим СӘГЫЙД. Атаклы татар әдибе Фатих Әмирханның авыруы, үлүе, күмелү мәрәсиме *(Илһам Гомәровның кереш сүзе белән)*. ..............................174

*Музейларыбыз*: Гөлгенә АБИЛОВА. Бакый Урманче музеена 20 ел. ......................................186

*Шаян сәхифә:* Алмаз ГЫЙМАДИЕВ. Уены-чыны бергә. .........................................................187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..........................................................................................190

КАЗАН УТЛАРЫ
*(«Огни Казани»)*
*№ 9 (1163) 2019*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**

*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**

*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Мөдәррисова** (өлкән бухгалтер)**.**

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.08.2019, график буенча 27.08.2019, басылып чыгу вакыты 12.09.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-2359. Тираж 4390.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2019 ел



Гөлүсә
Батталова

# ДАЛА ИСЕ КИЛӘ КЫРДАН...

## Сораулар күп

Милләт йөзе нинди була?
Сакаллымы, кершәнлеме?
Җил-давылы алдан йөргән
Атлар инде өшәндеме?

Сызгырамы, аһылдыймы
Җәяләрдән аткан уклар?
Таушалганмы, ташланганмы
Ата-баба салган утар?

Милләт теле нинди була?
Карусызмы, агусызмы?
Әрсез диеп кагалармы
Тәкъдиренә талымсызны?

Ак кирмәннең йөзе ак дип,
Җуелдымы уяулыгы?
Кемгә – туган, кемгә – дошман,
Кемгә исә... кульяулыгы...

Бөеклектән боеклыкка
Ничә шәһит, ничә корбан?
...Дәрья кебек дымлы инеш,
Дала исе килә кырдан...

Гөлүсә БАТТАЛОВА (1982) – *шагыйрә; «Бер йотым бәхет» исемле китап авторы. Әтнәдә яши.*

## Мин бары тик яшим

Кесә тулы – давыл! Дөнья тулы
Дәрвиш җанлы бәндә...
Йөрәк белән йөрәк ничә кабат
Ызан бүлгән мәлдә...
Мин бары тик яшим.

Рух зинданы – шыгрым. Шом көткәнгә
Дәҗҗал инде сафта.
Тере көе җеназаңны укып,
Күмеп куйган чакта...
Мин бары тик яшим.

Ашык-пошык ак ямаулык тегеп,
Күңелдәге кергә,
Җиденче кат күк дип белгән
Йолдыз тулы җирдә...
Мин бары тик яшим.

Шытмаган гөл, юш килмәгән төшнең
Мең кат алып үчен,
Йөрәгемә ачкыч табалмыйча,
Ваз кичкәннәр өчен...
Кабатлыймын:
Мин бары тик яшим!

## Балтырганнар

Җәлләмәде... Күмерләнгән җаны
Аз, дидеме әллә?
Тәнне өтте агу. Җәй офыкка
Тәгәрәгән мәлдә.

Үч алдыммы, көч алдыммы сездән,
Йолыкканда сабак?
Елый-елый дөньясына рәнҗеп,
Әрни-әрни кабат.

Җәрәхәтләр тәндә тирән иде.
Төзәлмәсе – җанда.
Белештермәс булып үз-үземне,
Төн ялгадым таңга.

Күзләр Күккә төбәлделәр кинәт...
Һәм тетрәнде кыйбла:
Балтырганнар ласа кул күтәреп,
Кыла икән дога!

Тармак-тармак бармаклармы димен,
Болытларга тоташ...
Җирдә – агу – җан сакларга корал,
Уч төбендә – кояш!

Кулларымны мин дә Күккә суздым –
Догамны ит кабул!
Баш имәслек көч-куәт бир, Раббым,
Һәм бер тамчы... агу!

## Кәрлә җаннар иле

Ул илдә куркыныч шәүләләр
Бөртекне кибәккә чыгара.
Кояштан өненә кача да,
Табына Алласыз чырага.

Ул илдә кадерсез тибеләә
Халыкның баһадир уллары.
Алкышлап, мөнбәрдән тыңлана
Төн ката этләрнең улавы...

Ул илдә мәдхия җырлана
Фәхешкә, хөсетлек, хәрәмгә.
Без – хуҗа, кагылма, дияләр,
Хакың юк тамчы да галәмгә!

Мыскаллап вөҗданын сатудан
Һәр мәхлук – танылган сәүдәгәр!
Ул илдә бер гамьсез көн күрә
Нәкъ безгә охшаган шәүләләр...

## Тапкырлау җәдвәле

Ике икең дүрт. Дүрт икең сигез –
Корасы иде үзеңне шулай.
Төп-төгәл. Ачык. Артык хисләрсез.
Син – җайлы кеше. Заманга кулай.

Кемне борчый соң синең дөньяңда
Ике икең биш икән чишелеш?!
Дөрес адәмнәр төзәтер җайлап:
Кагыйдә, канун, тәртип бар, имеш!

Беркем ышанмас, синең илеңдә
Елгалар акса үрләргә табан.
«Алай булалмый! Ике икең дүрт!» –
Диеп тукырлар җаныңа һаман.

Куып кертергә бердәм кысага –
«Тиеш! Ярамый! Яхшы түгел лә!»
Һәм аның саен минем Күкләрем
Офык артына ташып түгелә!

Ике икең биш! Кояшым – яшел!
Чирәмем – зәңгәр, чиксез галәмем!..
Кисәткән идек, дияр күргәннәр
Җирдән сөрүен мине гавамның.

Качып бетәрләр дөрес иптәшләр,
Ваз кичәр, бәлкем, бүгенге дус-иш.
Үзгәрер гәүдә. Үзгәрмәс иман.
Бигайбә, дөнья, ике икең... биш!

***

Карама тәрәзгә. Карама сәгатькә.
Календарь битләрен ертып ат. Җәлләмә!
Дөньяның үзе күк борынгы бу сөю
Төс бары, беләсең, җандагы җәйләргә.

Әнә бит – шул килеш ямь-яшел ихласлык!
(Булса соң март башы, булса соң бураны!)
Җилләргә ияргән кап-кайнар тыныңнан
Баш җуеп, җәйләргә сыенмый буламы?!.

Әле бит бүген дә бик күпләр күшегеп,
Миченә ныгытып яккандыр иртәдән.
Кем әйтер: сөюнең өрфия күлмәген
Гөнаһмы бер гомер салмыйча кигәннән?

Гөнаһмы ярату: җәйләргә ышанып,
Фасыллар алмашын искәрми, белмичә?
Баемас кояшың, йөрәккә яшереп,
Бар дөнья туңганда өшедем, димичә?

Гөнаһмы кемнедер кар күмеп киткәндә,
Яктыдан түгелсә, җәй үргән тырысың?
...Исәр дип җәлләүче табылса, әйтегез,
Календарь битләрен яксын да җылынсын!

## Көтәбез

Көтәбез. Әйтерсең, бу гомер – зур вокзал.
Көтәбез язларны, ялыгып ак кардан.
Хафалы җаннарга бер файда булырмы,
Мәңгелек Иделдә боз эреп акканнан?

Көтәбез җомганы. Көтәбез таңнарны.
Көтәбез көн тугач, җиткәнен кичләрнең.
Дөньяга килергә көттергән балаңның
Телибез күрергә бишектән төшкәнен.

Көтәбез бәхетне. Менә ул очрар дип,
Йә теге чаттамы, йә явар күкләрдән.
Түземлек калмагач, өметне йомарлап,
Сорардай булабыз үткәннән-сүткәннән.

Көтәбез... Ул Серне кем бездән яшергән?
Югыйсә, менә бит – учыңда бәхетең!
Ашкынган йөрәкне тезгенләп чак кына
Той гына, күр генә яшәүнең рәхәтен!

Февральнең карлары кетер ак, карасаң,
Болыты, бураны әкият түгелме?
Һәр иртәң – кояшы күренгән җомга ул,
Кадерли белгәндә бердәнбер бүгенне.

Яп-якты язларың кап-кара көзеңдә,
Бер шартсыз, гап-гади көннәрдә булалса!..
Күзгә дә күренмәс рәшәне бәхет дип
Көтмәгез. Бу гомер болай да бер вокзал.

## Хыянәт

Ак биләүдән калган ал яулыкны
Кыса төшеп маңгай тирәли,
Бии-бии ардык. Ә аннары...
Җил йөгерде җаннан үтәли.

Иреннәрдән күкрәк сөте тамган,
Җәннәт исе истә чагында,
Кем уйлаган гайрәт чигәр диеп,
Дөньясыннан еллар чатында?

Без килгәндә, юкса, мәхәббәттән
Тулган иде һәрбер күзәнәк!
Гамьсезлеккә алыштырдык барын
Һәм... Күкләргә иттек хыянәт...

Эзләнгәндәй булдык, вөждан, дидек...
Салкын идек җиһан өшерлек.
Бер ятланган сүзләр кабатланды...
Ә тансыгын... ерак яшердек.

Үз балтабыз чапты тамырларны
Ярым шашкан идек... ярым ач...
Шул халәттә кире кайтырбыз бер...
Күкләр инде ләкин танымас...

## Кояш исе!

Бу дөньяның төксе чыраена
Ияләнгән идем! Күптәннән...
Арган идем, Кеше тапмый йөдәп,
Карашларын җирдән күтәргән...

Вак җаннарның эре адымына,
Түбәннәрнең биек үренә...
Күнеккән дә кебек иде күңел,
Юшкын яткач бәгырь түренә.

Иртәләре гадәтләнгән иртә,
Җайлы ласа атлау бер эздән!
Кояш исе!
Кояш исе керде! –
Тансык тамчы тамды күземнән.

Кояш исе! – читән-коймаларда,
Черем иткән киртә очында!..
Ышанмыйча тезгеннәрен тарттым:
Рәшәдер ул, күңел, очынма...

Кояш исе!.. Керде һәм туктады
Егыла-тора чапкан дөньясы.
Колакларга тынлык пышылдады
Фани җирнең бакый догасын.

Чуар уйлар эңгерләрдә калды,
Гамь йөгерде кинәт каныма.
Рәхәт бәхет: күнегәсем килә
Кояш исе кергән җаныма!



К а м и л
К ә р и м о в

# ИСЕМСЕЗ ХАТ

РОМАН-ЭЛЕГИЯ

*«Тургайлы болытлар» романының ахыры ачык калган иде («К.У.» 2015, 2-3 сан.).*

*Төзелеп бетмәгән шәһәрләр, ярты юлда калган сәяхәтләр, төгәлләнмәгән әсәрләр бар.*

*Һәр шәхес – үзе бер архив. Бәхетле кеше үз биографиясен үзе язып калдыра, даһиларның үткән юлын башкалар яза. Бүгенге татар әдәбиятында «Даһи язучы» дигән вакансия бар... Бөекләрнең каберенә басып, йолдыз чүпләүчеләр дә күбәйде...*

*Автор белән бүгенге укучы арасында ачу китергеч каршылык ята – ул синең ярты гасырлык иҗатыңны ярты сәгатьтә укып чыгарга мөмкин. Бүгенге проза диетада, ул сынга үсми, санга үсә.*

*Ашыгып яшәдем, ашыгып сөйдем. Бер хатаны төзәтәм дип, икенче хата ясадым. Бер кат үлчәп, җиде кат кистем. Ләкин ашыгып яза алмадым.*

*Хезмәт кенәгәсенең Мактау кәгазьләренә кергән чорын еллар белән түгел, юллар белән саныйм. Бүлмәдәге байрак җилфердәми. Ерак юлга чыккач, кешенең чын йөзе ачыла, зиһене арта. Үкенүләр минем өчен «тукран тәүбәсе» генә.*

*Хатлар ялгызлыктан коткарды, җанымны асрады. Язмышымның сюжеты хатлардан килә.*

*Китап сөючеләр өчен язучылар бар, язучылар укысын өчен генә язучылар бар... Әгәр мин зур язучы була алсам – кызлар гына гаепле... Алар мине хат язарга өйрәтте. Талантлы язучы булыр өчен талантлы укучы кирәк.*

*Романны фотолар белән бизәргә исәбем бар иде, соңрак бу уйдан кире кайттым. Яшермим, 1975 елның маенда, «Идел» халыкара яшьләр лагеренда, яшьләр иҗатына багышлап үткәрелгән атналык семинарда, фотоаппарат күтәреп килгән авторлардан бер мин генә идем... Бүгенге классикларның яшь чагы әле дә архивымда саклана. Фото – каты бәгырьле хәтер инде ул, һәм позитив булган җирдә негативы да бар. Гафу итегез, еллар үткәч, сынаулар кичкәч, ул рәсемнәрдән кемнәрнедер кисеп ташлыйсы килә башлый, ә күмәкләп*

---

Камил КӘРИМОВ (1950) — *прозаик; «Ком сәгате», «Игезәкләр йолдызлыгы», «Тургайлы болытлар» романнары һәм күпсанлы повесть-хикәяләр авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

*төшкән фотолар әкренләп «туганнар каберлеге»нә әверелә. Соңгы утыз елда кулыма гупчим фотоаппарат тотканым юк. Кеше саен ике-өч камера күргәч, чыраеңны кая яшерергә белмәссең...*

*СССР язучысы дигән билет алган көнемнән (1983) бүгенгәчә, оешмабызда җиде председатель алышынды. Язучылар оешмасы Менделеев таблицасы кебегрәк бит ул: затлы металлга тиңләрдәйләре дә бар; чамадан тыш авыр, инерт, тиз кабынучы язучыларыбыз да җитәрлек. Ул таблицада әле исемнәре ачылмаган буш урыннар да күп. Оешмабызның «Менделеевы алышынса, әлеге таблицаның күп кенә элементлары югала, алар урынына яңалары ачыла. Шөкер, нәсел кушаматым «Корыч» (Fe) булгач, прозада минем урыныма кызыгучы кеше юк. Ә бит әдәбиятның валюта курсын проза билгели!*

*Парнастан «бөекләр» егылып төшә башлады... Әнә, тагын бер йолдыз атылып, атмосферага кереп янды. «Х ә с ә н т у ф а н» йолдызы гына булмаса ярар иде! Җир шарыннан 250 миллион чакрымда пыскып торган 3 мең метр диаметрлы ошбу балкышны татар күгенә күпсенмәсәң иде, Раббым!..*

*Шекспирмы әле әйткән: «Тормыш – ул театр, ә кешеләр – актёр!» – дигән. Чынлыкта исә, безнең гомер шушы уенның бердәнбер репетициясе генә. Ни кызганыч, аның премьерасы юк... Булса да, теге дөньяда гынадыр.*

*Фикер сөрешемдә афоризмнар, канатлы сүзләр, «мөгез чыгарулар» очраса, кылтаю дип кабул итмәгез, безнең буын партия элгән лозунглар, ялтыравык шигарьләр йогынтысында үсте.*

*Без – социализмның соңгы малайлары.*

*Кызлар егет сөя башлагач, көндәлек яза. Кияүгә чыккач, андый юк-бар эш белән мавыкмыйлар. Көндәлек язып калдырган берәр хатын-кыз язучыны белсәгез, миннән сәлам әйтегез.*

*Культура-агарту эшендә чәчем агаргач кына, автобиографик әсәргә тотындым.*

*Шундый сәер кешеләр инде без – ирләр! Гомернең сөеп-сөелеп үткән көннәрен генә Яшәү дип атыйбыз.*

*Яшәлгәнен яза торам...*

## Хат ташучы курчаклар

Яңа машинага утырганнан бирле хат-хәбәрнең өзелгәне юк. Урамнан килеп керүгә, лифт чакырырга ашыкмыйм, диварга кат-кат итеп эленгән «почта ящиклары» арасыннан дөм караңгылыкта да үземнекен абайлыйм. Көннекен-көнгә карап бармасаң, юктан гына кызык эзләп йөргән малай-шалайлар алданрак өлгерә. Баскыч төбендәге лампочкаларны сәгать саен алыштырсаң да, барыбер ут яктысы күрмәссең...

Бу әрҗәләр «СССР почтасы» заманыннан калган истәлек, нәзберек йозаклары күптән коелып беткән, шуңа күрә дә ишекләре шыр ачык. Тышкы дөнья белән элемтәсе өзелгән әби-бабайларның аларга исе дә китми, Йортлар идарәсеннән килгән исәп-хисап кәгазьләрен дә аларның фатир ишегенә кыстырып китәләр.

Бу арада мин хат-хәбәрне көнгә икешәр тапкыр карарга тырышам, бәйрәм сылтавы белән Нуриәхмәт кызының туган авылына – Әгерҗе ягына кайтып килдек. Якын ара түгел, барып килү дигәнең җиде йөз чакрымга җыела. Гомеренә бер машина йөртеп карамаган шагыйрьләр аңлый алмаслык бер халәт бар, ераккарак барган саен, юл кагыйдәләрен чикләү-кисәтү билгеләренең күбәюе

ачуны кабарта, аларны санга сукмыйча узып китү рульдәге кешенең күңеленә әйтеп бетергесез ләззәт бирә башлый. Ә аннан соң... Үзебезнекеләргә өстәп, Удмуртиядән дә штрафлар килә торгач, атналар буе ГАИдан «бәхет хатлары» көтеп ятасың. Өйдәгеләрнең: «Йөри белмәгәч, шулай инде ул...» – дигән үртәүләрен ишетмәс өчен генә дә хат ташучыларны урамда көтеп утырырсың, билләһи.

Әйе, менә тагын бер хәбәр килгән...

Чакыру ярлыгының артына үзем турында белешмә тутырганда, артык җентекләп тормаганмын, юкса адресатка күз салырлык кына вакытым бар иде... «Бәхет хаты» урынына түгәрәкләп төрелгән бандероль тоттырдылар! Әдәби журналда эшли башлаганнан бирле, калын кулъязмаларны, идән астында басылган китапларны җибәрүчеләр күп булды, әлбәттә. Ләкин почтаның безнең редакциягә турыдан-туры хезмәт күрсәтүче бүлекчәсе бар, ул – эш урынына якын гына. Икенчедән, мине «сөендерүче» кешенең исем-фамилиясе бөтенләй таныш түгел, һәрхәлдә, моңарчы хәбәрләшеп торган авторга охшамаган.

Аптырагач, бандерольне кысып карыйм – кәгазь түгел; селкеп карыйм, эчендә нидер шыкылдый – мәгәр тимер түгел... Каян алган, шунда кире кертеп тапшырыр идең, аңламаслар – сюрприз төгәл миңа атап җибәрелгән. Әйдә, ярар, сабырсызланып, урам уртасында төргәк сүтеп тормам инде. Авыру төрле-төрле булыр, ди китап... Яз-көз көчәя торган чирләр бар. Тагын берәрсе яза башлагандыр, күрәсең. Хәзер бит укучыга караганда, шагыйрә булырга хыялланучылар күбрәк. Адресының язылу рәвешенә караганда, бу яшь автор ким дигәндә инде саллы гына ике юбилеен үткәрерлек яшьтәдер, бәлки. Эш урыныма барып җиткәч, барысы да ачыкланыр.

Каләмдәш дусларымның кәефен күтәрер өчен, ниләр генә сөйләмәдем дә, нинди генә маҗараларга юлыкмадым инде мин: өйләнергә акча эшлим дип, Чирәм җир сөреп кайттым; Актаныш кызы өчен Агыйделнең бозлы ташкынын яланаяк ерып чыктым; Шәле кызы белән кавышыр өченгә дөнья чите – Магаданга барып җиттем, ә ул килмәде; сынган долотаны эләктерер өчен баштүбән скважинага да чумдым; ун яше дә тулмаган чия-кызыл «Жигули»емны үз хуты белән тимер-томырга илтеп тапшырдым; стипендиядән алимент түләдем... Кыскасы, акыл туплап, адәм көлкесенә калмыйча, тыныч кына картаерга иде инде исәп...

Бандерольнең кәгазь сүрүен ерткач, 147 нче бүлмәдә беркавым тынлык урнашты, чөнки анда чәчәкле-чуклы бизәк төшерелгән, һәммәбезгә дә бик таныш уенчык – «Матрёшка» иде. Агач курчак, әлбәттә, көмәнле марҗага ишарәләп ясалгандыр – аның эче тулы «бала»... Өченче курчакны ачып өлгермәдем, дүрткә-бишкә бөкләнгән хат кисәге килеп төште, һәм бүлмәдәге тынлык шартлады! Мондый көлүне бары тик хаттагы «сер» генә туктата ала. «Нәрсә язганнар?» – дигән кызыксыну бу көлүдән көчлерәк иде. Ләкин мин кычкырып укымадым.

«Нихәл, дип сорамыйм, үзеңне бик һәйбәт хис итәсең бугай.

Кая югалдың? Хатынны ташласам да, сине ташламам, дигәниең... Сиңа ышанып өйдә утырсаң... Җиләк корты бит син. Аерылышырга лицензия бирмәделәр бугай. «Адәм белән Һава» тапшыруында күреп үртәлдем. Хатының белән алай ук мактана торган кеше түгелиең бит син, нәмә булды? Бөтен ялгыз хатыннарны да бәхетле итәрдәй телең барые. Сиңа кемне яратсаң да, барыбер бугай – яратырга гына булсын. Губной помада ялап агуланырсың әле бер... «Кларунчигың» белән яшәп ятасың алайса... Олыгаясың, ахрысы. Кеше өендә кунып кала алмыйсыңдыр, үз мендәреңне күтәреп йөрмәссең ич... «Матрёшкалар»ны сервантыңа тезеп куй, кинаямне аңларсың шәт – мәхәббәттән җыр да туа, бала да туа... Кызганыч, бу хат кыска чыкты, төпчек

матрёшканың көмәне бик кечкенә. Язучылык һөнәрен ташладыңмы, соңгы елларда бик күренмисең...

Мин. Апрель, 2018 ел.»

Апрель. Апрельдә 1 апрель дә бар, апрельдә – 26 апрель дә бар... Апрельдә – башыма килгән беренче сөенеч «Юмор көне» булды. Үзен тел остасы дип йөрүчеләр бер мин генәме?! Һәр шаян кеше үзенчә көлә.

Бандерольнең тузгыган сүрүеннән мөһерен эзләп табам, бер дә көлке түгел – почтага космонавтика көнендә кергән. Ягъни Г.Тукай премиясен бирү турындагы Указ чыгарга ун көн кала оештырылган... Алай дисәң, кандидатлар хакында низаг чыгару өчен хәзер интернетның «көфер почмагы»на бер әләк ыргытуың җитә, профессиональ гайбәтчеләр шундук чәйнәп ташлый... Юк, иҗади көрәш алымы түгел бу, исемсез хат һичшиксез минем гаиләне җимерер өчен язылган. Теле, фикер сөреше, кинаясе һәм уйнаштан туган «матрёшкалар»га ишарәләве белән – мондый ясалма бомбаны бары тик ялгыз калудан коты алынган хатын-кыз гына ыргыта ала...

Кайтып җитәрәк кухня тәрәзәсендә ут балкыса, ир кешенең борыны чөелә, иңбашлары канатлана, башы әле уңга, әле сулга каерыла – янәсе: бармы берәрегез, күрегез – әнә, көтә, пешә, кайный, дөрли бәхет учагы. Бүген тагын берәр сәбәбе табылгандыр: гаилә бәйрәменә җиләк анасыдай төпчегем, Нуриәхмәт кызына «Әни!» дип өзгәләнеп торган киленем, инде миңа акыл өйрәтә башлаган улым, тәти күлмәкләрен киеп күргәзмәгә тезелгән оныкларым көтә торгандыр. Хәзер, хәзер, урам ишеген шапылдатып ябам – ишетсен, ачкыч бәйләмен кыңгырау итеп, өй ишегенең өске йозагын ачам – Нуриәхмәт кызы чәчен-башын төзәтсен, икенче йозакны ашыктырам – каршы алсын.

«Кларунчик, мин кайттым!» – бу минем елга 365 кат әйтелергә тиешле догам.

Ул зәйтүн мае сеңгән кулын өстәл сөлгесенә сөртә-сөртә каршыма килеп баса. Баштанаяк күзәтеп чыга, алай гына да түгел, күземә туп-туры карамакчы була – тик карашымны тота алмый.

«Алай икән, тагын остаханә утырышы үткәргәнсез», – дияр дә азык-төлек цехына әверелгән аш бүлмәсенә ашыгыр.

Акланмыйм. Мактанмыйм. Каршы дәшмим, дөрләп китәргә әзер торган учакка каен тузы өстәмим. Гаилә бәхетенең шушы вариантын кыл өстенә куйган исемсез хатны агач курчаклары белән чүп савытына ташлыйм.

Шөкер, эш урынымда «онытып» калдырганмын икән...

Мәктәп елларыннан бирле: «Киләчәккә хатлар» (Һ.Такташ), «Хат ташучы» (М.Җәлил), «Тапшырылмаган хатлар» (Г.Кутуй), «Соңгы хат» (Х.Вахит) әсәрләреннән рухланып үзем дә хатлар эчендә яшәргә өйрәнгән «Корыч малае» никтер почта әрҗәсендәге хатлардан сискәнә торганга әверелдем. Һәр яңа әсәрем басылып чыккан саен, мине хатлар эзәрлекли. Күпме хат юлда югалган һәм күпмесе җавапсыз калган?!. Хатлар кавыштыра ала һәм шул ук вакытта кырык ел буе корган җылы-көйле ояңны туздырырга да бер хат җитә...

***

– Почтаны карадыңмы?

– Эштән кайткан кешене, «нихәл», дип каршы алалар иде, нишләдең син бүген? – дигән булдым мин, җаваптан качып.

– ??!

Нуриәхмәт кызының күз карашында тагын шул ук сорау. Минем белән яши-яши әүлиягә әверелде, тәки, көн саен: «сатабыз», «көтәбез», «арзан гына»,

«иң түбән бәяләр бездә» дигән рекламалардан арыны күрмәгән әрҗәдә, бүген, нәкъ менә бүген минем исемгә хәбәр килгәнне каян белә ул?!

– Җимешем, кемнән хат көтәсең соң син? Штрафларга гел үзем түләп торам, сиңа мәшәкате юк; авылдагы әти-әниләребез күптән гүр иясе инде; кесә телефонында, ачуым килмәгәе, көн саен туксан тугыз хәбәр; мәктәп елларың төшеңә кереп интектерә мәллә?.. Иртән уянуга хатыны: «Картым син мине яратасыңмы әле», – дип сорагач, ире нәрсә дип җавап биргән? «Ну, карчык, әче таңнан кара тавыш чыгарма инде», – дигәнме?!. Кайтып керүемә, нихәл син, дип сөендерәсе урында, хат эзләтеп интектермәгән булсаң...

– Абау! Үскән саен вакчыллана барасың син. Бер сүз белән генә: «Юк!» – дип җавап бирсәң ярамыймы?! Бөтен иҗатың сүзгә күчте. Өч ел бит инде бернәрсә язганың юк. Прозаиклар гомер буе язарга тиеш, дигән кеше син түгелме соң(!)?

Нуриәхмәт кызы иң авырткан җиремне – җан тамырымны чеметеп алгандай итте, «язмыйсың» дигән гаепләүдән минем уйларымда кыска ялганыш яшьнәп ала... Бер үк шелтә белән өч ел буе битәрләсә дә, хак сөйли үзе. Акланырдай сәбәпләрем һаман да шул: күңел төшенкелеге; яшәешнең бертөрлелеге; күптән инде мине урап алган офыкның теге ягына чыкканым юк. Әллә инде, соңгы кырык елда, никах кичендә биргән вәгъдәләрем акланып, социалистик йөкләмәләрем үтәлеп, барча хыялларым гамәлгә ашып беттеме – үзем дә аңламыйм, никтер кулдан каләм төште.

Нуриәхмәт кызы, мине Дәүләт бүләге алып кайткан көнемдәгечә сыйлый: өлеш тәлинкәләрен шалтыратмыйча гына тезә; тамгалы кашыкларны ашыкмаенча тарата; гадәттәгечә, бисмилласын әйтеп, үз кулыннан икмәк телеп бирә һәм минем тарафтан хосусыйлаштырылган пыяла шүрлектәге рюмкаларга ихтыяри карап куя... Елмаймыйча, әмма шул ук вакытта чыраен да сытмыйча, төпле тынгы белән ашауга күчә. Бу – аның озакка, әгәр юату сүзеңне кызгансаң, сәгатьләр буена сузылачак тынлыгы. Аның эндәшмичә утыруы әрләвеннән дә яманрак. Җан өшеткеч тынлыкны җылыту миңа кала.

– Хәтерлисеңме, студентларның төзелеш отряды белән киткәч, минем сиңа 27 хат язганымны? Син 1 курста китапханәдә практика үтеп калдың. Ә мине Әчтерхан өлкәсенең Володар районына помидор җыярга җибәрделәр. Беренчесеннән башлап, һәр хатка саннарын куеп бардым... Ә егерме бишенчесе югалган иде. Укулар башлангач кына килеп җитте ул сиңа, ике ай буе кайдадыр качып яткан... Адашып йөри торган хатлар да бар дөньяда, – дип түгәрәкләдем фикеремне, бүгенге исемсез хатка ишарәләп. Шуның белән Нуриәхмәт кызының «йомык авыз» уены өзелде.

– Ул хатлардагы матурлыкның әчмухасын да ишеткәнем юк хәзер, һәр җөмләңдә сагыну белән ярату үрелеп бара иде. Менә дигән әсәр!

– Әйе, бер повестьлык чимал әрәм булган!.. – дидем мин артык хафаланмыйча гына.

– Ник әрәм булсын, исән алар. Синең соңга калып кайткан төннәреңдә укып ятам. Ул хатларда хыянәт юк, яшь язучы хисләре генә.

– Белмим, җимешем, хыянәт дип нәрсәне әйтәсеңдер. Өйгә кайтмыйча кунып калганым бармы – юк!

– Сайланма әсәрләреңне чыгарсаң, йөзәрләгән хатын-кыз үзен эзләп табачак. Шул түгелме хыянәт?!

– Иҗат итү – ул әсәрләрдә кеше тудыру кебек. Рәссамнар портрет ясаганда, шәрә натурага да сокланып утыралар әле, аңа карап берсен дә хатыннары куып чыгармый.

– Суң, хатыныгызга сокланып кына иҗат итеп булмыймы?

– Көлдермә инде, җимешем! Күрсәт, әйдә...

– Нәрсә?!! – Нуриәхмәт кызы мине сугып егардай җенен көчкә тыеп тора.

– Хатларымны, дим...

– Ә-ә-ә... Юк инде. Җыртып атар идең бугай. Ә бәлки шулайдыр да...

Мин өч бүлмәле фатирыбызның сер саклардай почмакларын күз алдыннан кичердем... Һи, гомер буе табып, алып, кирәк-кирәк дип яшәлгән өйдә бер вагон хат яшерергә була ич.

Унсигез яшьлек кызга язган хатларны дәү әни каршында укып утыру өчен сабырлыгым җитмәс... Мәхәббәт ул тән сусавы, тән дигәнең – материя. Материя югалмый ич ул, бер халәттән икенче халәткә күчеп үзгәрә генә. Инде яшьлектә әйтелгән сүзләрнең күбесен кабатлау килешми дә, оят кебек хәтта. Гомер бакый бергә яшәп, тән тәннән, мендәр мендәрдән, караватт караваттан ерагая башлый. Аның каравы җан җанга кушылып, аерылгысыз бөтенгә әверелә. «Сиңайтәм, ниме?» дигән чагында җавап кайтаручы булмаса, уйларың кинәт туктап кала, җылы өең суына, җаныңның яртысын ялгызлык, югалту шомы биләп ала. «Әү?!» Нинди кадерле һәм тирән мәгънәле сүз бу! Исемен сорарга оялып йөргән көннәр, «яратам»ны бик җиңел әйттерә торган төннәр, икебезнең каникулны бер иткән студент җәйләре, гаилә кору сөенечләре, сынаулары-көенечләре – бөтенесе сыйган бу сүзгә! Шушы барлыкны югалту өчен бер ялгышу җитә. Әлеге дә баягы, исемсез хат алып килгән курчаклар түгелме ул?

## «Нух көймәсе» егетләре

Әйе, әби-бабайларыбыз һәм дә әти-әниләребезнең язмышы белән мактанып, әдәби мирасыбызны китапханәләргә сыймаслык дәрәҗәдә баеттык. Инде дә килеп, үзебез турында язар вакыт җитте...

2018 елның 15 февралендә, мәркәзебез Казанның газета-журналлар нәшриятында гадәттән тыш хәл булды. Юк, янгын-шартлау да түгел, су да басмады, шөкер, үлем-китемсез генә...

Олы урамнан туктаусыз узып торган транспорт пассажирлары өчен әлеге вакыйга МЧС уйлап чыгарган эвакуация уены булып күренгәндер, бәлки. Эреле-ваклы йөк машиналары, түрәләрне генә йөртә торган «иномаркалар» тирәсендә күпләгән – бик күпләгән кеше аркылы-торкылы йөгеренә. Һәркайсының кулында чаты чатка сүтелгән җиһазлар, авырлыгы тышыннан ук сизелеп торган кәгазь тартмалар, тәрәзә пәрдәсенә төренгән төенчекләр... Әлеге ыгы-зыгының котылгысызлыгы алдан ук билгеле иде инде. Өч катны колачлаган тугыз редакцияне күчереп, бүлмәләрне заманча ремонтлыйсылар икән, дигән хәбәр белән инде ярты елдан бирле, төшке ялда бөтен ашханә эче пышылдап торды. Ләкин күченү мәрәкәсенең февраль буранына туры килүе метеосизгер чирләшкәләр өчен генә түгел, ә кырык ел командировкаларда йөреп, чи каешка әверелгән абзыйлар өчен дә җан тынычсызлыгына әверелде. Безнең илдә бер генә хезмәткәр дә үзенең җитәкчесен сөйми, ләкин хөрмәт итә!.. Хөрмәтле түрәләребезнең карары катгый иде: дүрт сәгать эчендә «Нух» көймәсенә төялергә! Чордашларым хәтерлидер, «Нух»ның Икенче көймәсе инде бу. 1986 елның җәендә элеккеге Бауман урамындагы «Язучылар союзын» төягән идек. Ул вакытта да татар әдәбиятының алтмыш ел буе бөртекләп җыелган архивы, элеккеге Комлев урамына килеп җитә алмыйча, юлда югалган иде.

Менә хәзер дә без, сүз тыңлаучан татар матбагачылары, дүрт сәгать урынына

өч сәгатькә сыештык! Ошбу үтә күренмәле бинада кырык ел буе җыелып килгән мәдәни катламны бик вак иләктән үткәреп, Кәҗә бистәсеннән «Байлар бистәсе»нә күчендек. Калды инде... Исемнәре халык теленнән төшмәгән шагыйрьләрнең кульязмалары; шәхси култамгалар салынган калын-калын томлыклар; Мансур Вәлиевтән рецензия өметләнеп бүләк ителгән китаплар өеме; Роберт Миңнуллин заманыннан ачылмыйча калган хатлар – барысы да китте, Самосыровога түгел, яңа ачылган полигонга...

Ремонт эшләре ике айдан арыга сузылмас, тәрәзә каршындагы алмагачлар чәчәк атканда, «Майның унбишләрен» җырлап кайтып керерсез, диделәр... Әйе, билләһи, шулай, диделәр. Тик кемнәр әйткәнен генә тәгаенләүче булмады.

Дөрес инде анысы, өеңне тузан күммәсен өчен, исәнлегеңне сиздереп торыр өчен, гел кыймылдап, җырлап һәм уйнап торырга кирәк. «Татар үлгәнме, йоклый гынамы, әллә мәрткә киткәнме», димәсеннәр! Казан футбол чемпионатына әзерләнә. Чит илдән үткен күзле, көйсез журналистлар килеп торыр. «О, коллеги!» – дигән булып, безнең белән күрешергә теләрләр. Ә монда – Чемпионат «фан-зонасы»ның борын төбендә стеналары җыерчыкланган, җиһазлары таралып төшкән, идәннәре абынып егылырлык бүлмәләрдә ике «КамАЗ» «макулатура» өелеп яткан...

Күченгән эш көне әллә ни хәтердә калмаган, яңа «өебезне» эзләп тапканчы, әйләнчек бәрән шикелле бер тирәдән шактый урадым. Бүлмә ачкычын кул куеп аласың, минутына кадәр язып тапшырасы икән (ә без электрон пропускка күнеккән идек инде). Коридорның ике башында видеокамера чекерәеп тора – кергәнеңне-чыкканыңны, бәдрәфкә ничә барганыңны вахтада күзәтеп утыралар. Бигрәк кәттә егетләр эшләгән икән бу йортта.

Эшкә кул бармый. Утны бер кабызып, бер сүндереп, бер кабызып, бер сүндереп уйныйм... Кабызсам, энергетиклар байый, сүндерсәм... Уйный торгач, лампа янып төште, үземә сатып алырга туры килер...

Ияреп килгән дүрт-биш яшьлек кульязмаларга ачу чыга. Кайчан шедеврлар килер?!.

Яңа эш урыныннан сигез сәгатькә картаеп кайттым...

Иң хәтәре – өйгә кайткач та язып булмый. Яз көне бакча эшләре, җәйге челләдә кәгазь кулга ябыша... Җиләк тутәледәй авылыма кайтам. Мишә буен урман булып каплап алган шомыртларның пешкәнен көтеп йөрим. Шәвәли комлыгында әле бер, әле икенче ягына әйләнеп яткан кала күмәчедәй кызларга сокланам да... Язу кайгысы бетә... Күзне көтәм. Кулдан каләм төште. Марсель Галиевнең хезмәт кенәгәсе чаклы гына булса да, бер роман язып ташлыйсы иде бит инде...

Көз дә җитә. Җәйнең бөтен хәзинәсен тагын келәткә, базга, суыткычларга тутырып куябыз... Тик ак кәгазь һаман мине үртәп ята. Өч сәгать эчендә укып чыгардай романны да өч ел буе язам бит әле мин...

Депрессия дип аталырдай күңел төшенкелегенә өстәлеп, әллә каян гына шушы күченү мәрәкәсе килеп чыкты. Тәнем Вишневский урамында йөри, җаным – Кәҗә бистәсендә...

Ике айдан ремонт эшләре бетә, кире кайтырсыз, дигәннәре биш айдан соң искә төште. Үз күзләрем белән күреп кайтыйм әле, минәйтәм, безне югалтмадылар микән...

Җир шары футбол чемпионатына әзерләнә. Гавам телендә – туп тибеш. Шәһәрдә карт-коры юкка чыкты, урам халкы кисәк яшәрде. Кая карама – спорт киеме кигән төзүчеләр, волонтёрлар, кунаклар. Казанны кәләш урынына бизиләр.

Йа Хода! «Идел-пресс» тирәсе яктырып калган – өй түрендәге алмагачлар

делянкасы юкка чыккан. Чистай урамыннан Казансу ярындагы «фан-зона»га чаклы арага, купшы бакча өстенә, евротакталар җәеп, киң сукмак кына түгел, йөк машиналары узарлык юл сузганнар. Таш паркеты үтүкләнгән тротуарда адым саен чүп термослары, алар шифоньер шүрлеге кебек итеп, шома такта белән тышланган. Мин, ирексездән, берсе янында туктап калдым. Безнең халык мондый сервиска күнекмәгән әле, әйләнеп узалардыр шәт – эче чиста. Кызыктырып тора үзе. Үч иткәндәй, чүп-чар итеп ыргытып китәрдәй конфет кәгазем дә юк ичмасам... Кесә төбемдә кирәксезгә аунап яткан ун тиен акчаны томырдым – мая булсын.

Пышылдап кына әйткәндә, Казансуның уң ярыннан уңмадык без. Әле кайчан гына... «Чаян» журналында төшке ял җитте исә, Мөслимнең йөзек кашы – шагыйрь Зөлфәт белән комлыкка чыга идек. Анда шәһәр челләсе коргаксыган халыкны су буена җыйган. Ерактан караганда, аяк төртерлек тә урын калмагандыр кебек, ә якынрак килсәң, бөтен редакцияң белән рәхим ит – урын җитәрлек. Ни хикмәттер, ирләр икешәрләп-өчәрләпме, йә аягүрә, йә утырып кына кызыналар иде. Ә Казан кызлары... чәчәкле-чуклы җәймәләр җәеп, мөмкин кадәр чишенеп, хәзинәдә барын балкытып, сусыл тәннәренә нур җыеп ята иде. Һәммәсенең дә башлары төньякта, аяклары Кремль ягына сузылган. Зөлфәт белән без, вакыт әрәм итмичә, тиз генә коенып чыгабыз да рәт арасыннан да йөренәбез, буш урын эзләмибез. Шушы хөррият атавы гүя көн саен «Су анасы-95» конкурсына әверелә. Һәм без Зөлфәт белән икебез дә мәртәбәле жюри рәисләре! Ә ком җылысында күпме җиңүче әрәм ята... Без эшләгән елларда «Чаян» сәхифәләрендә хатын-кызга карикатура ясаулар бермә-бер кимеде. Эрнест Дышаевны гына тыя алмадык, ул гел үз хатынына охшаш сурәтләрне китерә торды.

Ә көннәрдән бер көнне, «Идел-Пресс» комлыгына күз тиде. Санэпидемстанция әлеге пляжда кызынуны тыя, суда ниндидер таякчыклар тапканнар, Идел суы эчәргә генә ярый, ә коенырга ярамый, ди. Бу хәбәр шәһәр телевидениесендә кат-кат кабатлана торгач, ниһаять, катгый рәвештә рәсмиләште. Яр буена челтәрле биек койма күтәрелде. Комлыкка кеше атлап чыга алмаслык буразналар сыздылар. Халык ияләнгән урыныннан бизде, әкренләп комлык суынды. Боз тартылгач, дистәләрчә «КамАЗ» берсен-берсе этә-төртә, яр читенә ком китерә башлады. Ә без, иң югары каттагы ян тәрәзәдән ошбу гарасатны күзәтеп, үзебезчә нәтиҗә ясыйбыз: әйе шул, меңъеллык Казанның үзәгенә үтүче җан тамырыдай транспорт дамбасы – ике яктан да миллион кеше сыешлы пляжга әверелгән булган. Юл өстендә мыжгып яткан татарны күреп, чит ил туристлары көләргә тиешме, әллә кызганып еласыннармы? Югары каттан барысы да күренә... Әнә, ул комлык күңел ачу мәйданына әверелде. Кайчангыдыр пляж урынында, берьюлы өч сылуның чәчен бәйләрлек «Чаша», өч мөдирле «ЗАГС» бинасы хәзер. Бик кызынасың килсә, язылышып чыгасың да туп-туры диңгез буена китәсең...

***

Килгән-килгән, ремонт барышын күреп китим инде, хезмәттәшләргә кайтып сөйләрлек яңалык бардыр, бәлки. Киткәнебезгә биш ай үтсә дә, шөкер, вахтадагы апалар безнең чырайны онытмаганнар: «Керегез, кер», – дип каршы алдылар.

Без бушаткан этажларда билгесезлек тынлыгы. Тәрәзәләр юылган, идәннәр сөртелгән, коридорлар ялт иткән! Ремонт эшләре генә башланмаган...

Киткәнебезгә ярты ел үтте... Бер ел... Ел ярым... Кайтыгыз, дип чакыручы гына юк. Булмас та... «Информбюро» хәбәрләре шулайрак сөйли. Күчену

фронт кебегрәк бит ул, киттеңме – йә яраланып кайтасың, йә хәбәрсез югаласың... Киткәннәр урынына яхшырагы килгәне юк әле... Зарплатасы кечкенә кеше телгә үткен инде ул, димәгез. Тормыш тәҗрибәмнән әйтәм. Матур сүзләр әйтергә өлгерербез. Мактау сүзләренә без бит юбилейларда һәм дә бәхилләшкәндә генә юмарт.

Исемсез хатлар гына үзгәртә алмас инде безне...

## Салам түбәле академия

Әнә, якасы бөгәрләнә торган, кыска җиңле яшькелт сатин күлмәген вельвет чалбарына кыстырып, салам түбәле өйнең ишексез болдырыннан ундүрт яшьлек бер малай чыгып киләме? Аягында брезент ботинка, балак очыннан көрән юка оегы күренеп торыр. Апасыннан чәлдереп кенә сибелгән «Кармэн» хушбуеның җете исе капка җиленнән үк очып бетәр. Өй түрендәге чирәмле сукмак, өйләнергә яше җиткән дәртле абыйлар, урланырга әзер торган купшы апалар таптаган такыр юлга килеп кушыла. Мең хуҗалыклы Шәленең бөтен такыр юллары клубка илтә... Бабайларның да яшьлеге шушыннан килә, алар клубны авылның иң аулак урынына – тар инешнең киң ярына җәелгән үзәнлеккә салганнар. Өйләр кашлакта. Ак морҗаларда шәфәкъ нуры сүнгәч тә, клуб аланы серле эңгергә чума. Бәхет дигән билгесезлекне без, гадәттә, сөйгән ярың белән кавышу дип әйтәбез икән – димәк, авыл кешесенең бәхете дә, бәхетсезлеге дә караңгылыкка чумган менә шушы агач клуб тирәсендә инде. Үз ярыңны эзләр өчен сиңа көн саен өч-дүрт сәгать вакыт бирелә. Бәхет эзләүнең ял көннәре юк.

Талымсызлар эзләгәнен үз авылында ук таба. Ә инде сайланырга яраткан егетләр Күн, Тау Иле, Пәрәү клубларына чаклы килеп җитә. Алай да барып чыкмаса, Казанга китеп урнаша да, үзе кебек сайланыбрак йөргән берәр кызны килен итеп алып кайта.

Вельвет чалбарлы, брезент ботинкалы малайга Казанга китәргә иртәрәк: аның тагын ике ел укыйсы бар әле... Ул клуб ишегалдында исән калган бердәнбер лампочкалы багана янында үзенең төркемен эзләп табар. Якты түгәрәккә бик кермәскә тырышыр. Ник дисәң, тамак астында җөе бар, аны кеше күзеннән яшерер өчен, бөгәрләнгән якасын тарткалап, муенын уң якка кыегайтыбрак йөрер. Караңгыда ул тураеп бераз үсеп киткәндәй тоелыр. Каян беләмме боларны, ул малай – мин үзем бит инде!..

Бүгенге кызкуарлар өчен генә аңлатып үтәм, «Салам Түбә» – узган гасырның илленче елларына чаклы яшәп килгән архаик сүз. Күз алдына китерегез: әйтик, кыр читендә бер салам чүмәләсе онытылып калды, ди һәм ул салкын яңгырлы көзләрне, кышкы бураннарны кичеп чүгә, карала, язгы җылыда муртая да, аның чит-читләрендә алабута яшәрә башлый... Бу чүмәлә өстенә тагын яңа салам өстәлә... Әкренләп ул тирес өеменә әверелә һәм аны актарып, кошлар җим эзли. Менә шундый була инде ул салам түбә! Салам түбәле өйләрнең күп кенә фаҗигаләре, нужа-кәсепләре охшаш.

Гадәттә без «революциядән соң», «колхозлашу елларында» «сугыш вакытында», «шәхес культы чоры», диебрәк сөйләшергә күнеккән. Болар – тарихи язмышыбыз сәхифәләре.

Әти 1906 елда туган. Ул – биш балалы гаиләдә уртанчы малай. Аның олы абыйлары, гражданнар сугышыннан кайткач, яңа җәмгыятьтәге мөлкәт тигезсезлегенә каршы көрәшкә кушыла. Һәм икесе дә кулаклар тарафыннан шәһит китә. Әти Армиядән ветфельдшер һөнәрен үзләштереп кайта. Авылда

үзлегеннән укып, «мал врачы» булып эшли башлый. Җиденче класстан ук авыл сәхнәсендә җырлап йөргәнемне әйткәнем бар инде... Арттагы рәттә утыручыларның берәрсе: «Атаңның җырын җырла!» – дип кычкыра торган иде. Бик таныш җыр ул, әти чыгармаган аны:

Без агайне – өчәү идек,
Айгырлар печә идек.
Айгырлар печкән акчага
Җырлашып эчә идек...

Рас әйтелгән инде анысы. Әти үлгәннән соң, өч ветврач алышынды. Айгыр печкән җирдән алар да җырлашып кайталар иде. Бу җыру сугыштан соң җырлангандыр, әлбәттә. Ләкин әтинең хезмәт елы 37 нче елларга килеп терәлә бит әле.

Көннәрдән бер көнне, җыеннан соң (Сабан туе), Шәле халкы, кача-поса гына, хуҗасыз болыннардан печән чабарга керешә. Авыл – чамасыз зур, өлгергәнен көтеп торсаң, печәнсез калуың бик ихтимал. Колхоз малы көтүгә чыгып киткәч, әтинең дә кулы бушый, мал врачының кирәге чыкса, көтүчеләр ат чаптырып эзләп табалар. Әти каен җиләге кызарган аланны каезлаган арада, «Шиһап чүнниге» юлындагы күлгә сугарырга килгән Гарифулла көтүенең бер әрсез сыеры эчкәрәк кереп, су эчәм дигәндә, батып кала. Ходай акыл өләшкәндә, үшән сыер соңарып килгән шул: түше суга тигәч, аягын күчерә-күчерә ярга таба борылмый, киресенчә, эчкәрәк керә, кергән саен ныграк бата, ярдан ерагая.

Гарифулла гомер буе көтү көтеп, мондый хәлләрне күргәләгәндер, күл сазына чумган сыерны берүзең сөйрәп чыгару мөмкин түгел, дилбегә бәйләсәң дә, ат, тоягы белән җирне казып, быкырдык ярда үзе батачак.

Көтүче Гарифулланың башы эшли – ни дисәң дә өендә җиде тамак – балалар көтүе әтисез калачак, турыдан гына өч чакрымда Колай авылы бар, тагын берәр ат эзләп шунда чаптыра.

Ләкин, гөнаһ шомлыгы, ярдәм килгәндә, сыер инде тончыккан, су өстендә мөгезе генә тырпайган. Аны-моны уйлап тору юк, ике дилбегә урап, ике ат белән кибәндәй сыерны урман читенә сөйрәп чыгаралар. Колай урысының арба төбендә солы чиләге бар икән, күлдән су ташып, сыерны юалар болар. Яр буеннан сөйрәлгән эзне көтү белән кат-кат таптаткан арада, мәрхүм мәхлук ялтырап кибә.

Кешегә сөйләп йөрмәслек әҗерен килешеп, Колай урысын тиз генә озата да Гарифулла... мал врачын, ягъни әтине эзләп китә.

Әтинең инде мал-туар өлкәсендә бераз тәҗрибәсе бар – үләт базына илтеп аткан хайваннарның сәбәбен күргәләгән кеше. Бу сыер күбеккә батмаган, эче күпмәгән, күзе чиста, җилене тулган, баш җәрәхәте юк. Гарифулланы гаепләрлек сәбәп күренми... Теле кабарып, сулыш юлын бумады микән, дип, тешләрен каерып ачса – сыерның авызы-борыны тулы күл ләме... Мөгез төпләре җәрәхәтләнеп канга каткан...

Әти җикеренеп, Гарифулланың өстенә килә: «Син бит моны күл төбеннән алып чыккансың, паразит! Мине ник эзлисең, колхозга хәбәр итәргә идең!»

Гарифулла, әтинең кирза итеген кочаклап өзгәләнә.

«Әдһәм, җиде баламны харап итмә!»

Әтинең дә гаепсездән гаепле буласы килми.

«Ә минем Габдрахманның әнисе үлде. Ул ятимне кемгә калдырыйм?»

Җәйге челләдә исләнә күрмәсен дип, сыерны тизрәк Казанга – сабын заводына төяп җибәрәләр. Ашыгыбрак котылалар... Районнан вәкил чакыртып, урынында ук акт төзетәсе булган икән шул...

Икенче көнне әтине районга чакырталар. Шундук кулга алалар. Һәм ул «колхоз милкенә корткычлык эшләгәне өчен» биш елга хөкем ителә... Гарифулланың аңлатмасында язылган бер җөмлә харап итә: «Сыер авырып егылгач, мал врачы Әдһәмне эзләп киттем, таба алмадым. Ул килгәндә, колхоз сыеры үлгән иде инде», – дигән.

Ул хөкем ителгән елны Финляндия белән безнең ил арасында кораллы бәрелеш башлана. Әти, үзе теләп, төрмәне сугышка алыштыра. Ул сугыш озак бармый, 1940 елның мартында СССР җиңә. Әтине яңадан төрмәгә кайтаралар. Ә инде Бөек Ватан сугышы башлангач, әти тагын сугышка китә, әлбәттә, штрафбатка, әлбәттә, иң алгы сызыкка... 2 нче Украина фронтына...

Җиңү көнен бәйрәм итәргә ирек бирмиләр, штрафбатны эшелонга төяп Ерак Көнчыгышка – Япон милитаристларына каршы көрәшкә җибәрәләр. Ни хикмәттер, анда җиңүне тиз тоталар. 1945нең августында әти орден-медальләрен гимнастёрка күкрәгенә тагып, ике кулын селкеп кайтып керә. Шинелен булса да алып кайтмаган ичмасам, әтиемнеке, дип ябынып йоклаган булыр идем. «Сиңа шинель бирмәделәр мәллә?» – дип сораган аннан әни. «Барые, ник булмасын, аны бер вокзал мәйданында Менжинский һәйкәленә кидереп киттем», – дигән. Әти дә бераз сатирик булгандыр инде...

«Без Днестр елгасын кичкәндә, өч көн буе бозлы суда коендык, мин үземнең күпме гомерем калганын беләм», – дигән әти... Гел әти дә әти дим, Әдһәм Кәримович минем әти булмаган әле ул вакытта.

Шул ук 1945нең августында әнине җитәкләп, авыл советына алып бара да язылышып кайта ул. Туып-үскән йортында әтинең өйләнгәнен көтеп, тәк кенә ятмаганнар, шактый гына үрчегәннәр, шулай итеп, үзенә аерым куыш корырга кирәк була аңа. Кая барсын әти, якын-тирәдә Шәледән кала зур авыл – Колай гына. Берәр иске бура булса да, ярап торыр дип, чыгып китә ул. Урамнан урамга күчеп, сорашып-киңәшеп йөргәндә, теге урыс танып ала бит әтине. Үзен бик гаепле итеп сизсә дә, сөйләп бирә сыер вакыйгасын (ышанасызмы, юкмы – ул күл авылда бүгенгәчә, «Сыер күле» дип йөртелә). Сугыштан җиңүче булып кайткан фронтовикның нәфрәтсез-үчсез тыңлап торуын күреп соклана бит Колай урысы, келәткә дигән 4кә 4ле бурасын биреп җибәрә. Колхозның бердәнбер «полуторка»сы белән ике рейс ясыйлар.

Әзер бураны бик тиз өяләр. Урам ягына ике, ә ишегалдына бер тәрәзә уйгач, урыс келәте җыйнак кына өйгә охшап кала. Әрәмә куаклары белән тезмәләнгән кыекны арыш саламы белән каплыйлар. Бусаганы атлап, туп-туры урамга чыкмас өчен, бурага терәп, сөян кабыгыннан өйалды сыман корылма да әтмәллиләр.

Сугыш аркасында Шәле авылында ирләр кулы 172 кешегә кими. Әтине кабат элеккеге эшенә куялар. Биш ел буе батырларча сугышканы өчен Аллаһы Тәгалә әтигә тагын биш ел гомер бирә һәм ул, мин тугач кына, «әттә-әннә» дип телем ачылганны да көтмичә, 44 яшендә үпкә авыруыннан китеп бара. Җиңү бәйрәмендә туксан яшьне узган ветераннарны күрсәм, алар өч көн буе Днестрның бозлы суын кичмәгәннәрдер, дип уйлап куям. Зинһар, гафу итегез! Әти искә төшкән саен Җир шарына нәфрәтем көчәя...

Урыс келәтеннән салынган өйнең түбәсенә без 1965 елга чаклы салам өстәдек. Әнинең колхоз эшеннән кайтканын өч бала тәрәзәгә ябырылып көтә идек.

Ул елны халык рәссамы Харис Якупов үзенең шәкертләре белән килгән иде. Алар җәй буе безнең авылда яшәп, миллионер колхозыбызның эшкә уңганнарын, көнкүрешен, табигатен сурәткә төшергәннәр иде. Әни дә уңган колхозчы, җәен-кышын ял итмичә, елга 650 шәр хезмәт көне эшли. Харис абый шәкертләренең берсе, миллионер колхозның соңгы салам түбәсе, дип, безнең өйнең дә аклы-каралы сурәтен ясаган. Ул, Шәле үсә, хәерчелекнең иң соңгы истәлеге булып, бер генә салам түбә калган, дип горурланырга теләгәндер, бәлки... Ләкин, әле бит һәр авылның «Чишмә башы» дигән югары Мәхкәмәсе бар! Гаепләүче-гаепләнүчесе, яклаучысы-прокуроры да шунда ук... Иртән суга килгәч, әнине елатып кайтаралар. Юк, әни өйгә кайтмый, Правлениегә китә. Буш чиләк-көянтәсен рәшәткәгә элеп, дежурный Гайшә түткәйнең ай-ваена карамыйча, туп-туры колхоз рәисе бүлмәсенә килеп керә. Ә анда – идарәнең иртәнге утырышы бара...

Сүз биргәннәрен көтми әни, «Чишмә башы» карарын үзе аңлаганча әйтеп бирә: «Минем өйне бөтен дөньяга рисвай иткәнче, ятимнәремә ярдәм итәр идең, ичмасам. Сугыш ветераны балалары алар. Әдһәмнең рухы рәнҗер, каргышым төшәр. Художникларыңа эш тапмасаң, әнә – Үктәбринәңнең портретын ясат!» – ди дә ашыкмыйча гына чыгып китә. Ни өчен ашыкмыймы? Тын алырга да куркып утырган унөч кешелек идарә «Үктәбринә» дигән чибәр исемнән, ындыр табагыннан күгәрчен көтүе очып киткән тавышлар чыгарып, «пырхылдап» куя. Ул апа белән председатель арасында нинди сер барын белергә теләсәгез, Чишмәгә суга килегез. Анда гайбәт сатсалар да, ялган сөйләмиләр. «Корычныкыларга пекарняга утынга дип китерелгән очлардан бура буратканнар. Колхоз ике мең сум ссуда бирә икән» дигәннәре дә дөрескә чыкты. Күзгә чаклы биш тәрәзәле өр-яңа өйгә кердек. Түбәсен шифер белән яптылар. Ләкин ул авыл халкы өчен һаман да шул салам түбәле урыс келәте булып күренде. Авылның ятимнәргә хәтере шәп... Әйтерсең лә, шифер түбәдә, акшарланган яңа морҗа тирәсендә, әле һаман да тавыклар черек салам актара...

Кешенең бәхетсезлеге бәхет эзләүдән башлана...

Кичләрен өйдә утырмасаң да ярый, клуб тирәсен әйләнеп кайтыр чагың җиткән инде, дип, берәр ата-ананың үндүрт яшьлек малаена әйткәне бар микән? Юктыр... Офыкның кояш баеган ягыннан килә ул ым – чакыра, үрти, ашыктыра, өметемне кытыклый. Табындагы кайнар аш суынып кала, син төн түреннән җан азыгы эзлисең. Дәреслекләргә язылган «җирнең тарту көче» инеш буендагы агач клуб тирәсендә генә... Уяну инде бу... һәм малайлык йокысы таң алдына күчә... Беренче хикәяңә исем булырлык «Үндүрт яшь». Көн саен могҗиза көтәсең... Бүген... Юк... Иртәгә... Менә күрерсең... бүген! Иртәгә, әлбәттә, иртәгә, дия-дия, сиңа унбиш тула... Кайда туганын, кем икәнен белмәгән-күрмәгән, ләкин синең өчен генә үскән җан иясен эзләү башлана.

Сигезьеллыкның имтиханын тапшырдык. Тугызынчы класска (гафу итәрсез, сыйныф дип язсам – сыйнфый көрәш кебек килеп чыга) барырга теләүчеләр бермә-бер азайды. Көчкә-көчкә «өчкә» сөйрәлеп барган сигез укучы, колхоз эшенә китәбез, диделәр. Теге Гарифулланың төпчек малае белән «Моряк» кушаматлы Гайшә өч ел күчми калып, соңгы елны безнең класска эләккәннәр иде, аларга да, ниһаять, сигезьеллык белем турында таныклык бирделәр. Безнең класста күчми калганнар өчен махсус парта тора. Ул имәннән эшләнгән, бераз киңрәк тә, утыргычы да биегрәк, ел буе икесе бергә утырдылар. Гайшә инде гәүдәгә хәйран калку, яшь киленнәр чаклы. Тәненә сыланып торган тельняшкасының күкрәк өлеше ертылырга җитеп тартылган.

Әллә ел буе салмыйча киде инде ул аны? Борын астында мыек сыман «бала җоны» тырпайган, «Моряк» кушаматын аңа без куштык. Тәнәфескә чыкса, башлангыч класс балалары, аны укытучылар белән бутап: «Исәнмесез, апа!» – дип дәшеп калалар иде.

Шәле – кыз урлаучылар авылы, дигән яманат белән тарихка кереп калса да, шөкер, анда мәктәп балаларын урлау очрагының булганы юк. Гайшәнең дә «сигезне» бетергәнен көтеп йөргәннәр. Кичке уенга чыгып, атна-ун көн биеп калды микән, белмим, урладылар үзен. Беренче көннәрдә, мин әле клубка керү белән, зур кызлар арасындагы Гайшә янына килеп баса идем дә: «Нихәл?» – дия идем. Ул дәшми-нитми генә иңбашы белән миңа төртеп куя да елмая торган иде. Әйе, безнең авылда күрешүнең шушындыйрак төре дә бар... Кавышкан парлар никах укыткан көнне үк клубка йөрүдән туктый. Гайшә-моряк та хәзер үзенең кушаматын үрчетә. Мин яңадан үземнең яшьтәшләр арасына елыштым.

Безнең авылда кушаматсыз өй юк. Мин үзем – мең кушаматлы Шәле малае. Ә нәрсә соң ул кушамат? «Блатнойлар» телендә ул «кликуха» дип атала. Сөекле тарихчыбыз, милләтпәрвар галим Марат Мөлеков Зөфәр Мифтахов белән «Шәле таңнары» дигән китап яздылар, ул нәшриятта 1977 елда басылып чыкты. Китапны укыганнан соң, бер горурлык хисе кичерәсең: соңгы биш гасыр эчендә ил-җирдә нинди гарасат булса, Шәле халкы шунда барып кергән... Ләкин авыл исеменең атамасы ни мәгънә аңлата соң? Моңа төгәл җавап юк... Шәле кәҗә мамыгы эрләп «шәл бәйләү» белән бәйледер инде, дибез дә елмаябыз... Юк! Мин моңа каршы. Шәл бәйләмәгән авыл юк, ә Шәле авылы бер генә! Галимнәргә, минем авызны ябар өчен бер табак чиста кәгазь калдырып, шуны әйтә алам: туган авылымның исеме – «Шальной», «шалиш», «не шали» сүзеннән алынган булырга тиеш. Үземнән беләм һәм якташларымның холкына, фигыленә, батырлыгына, шуклыгына, тапкырлыгына таянып әйтәм. Биш гасырлык үткәнне күз алдына китереп карагыз... Ул чакта халыкны киендерерлек тә, туендырырлык та зур шәһәрләр юк. Бөтен эшче көч җирбиләүчеләр кулында. Алпавытларның изүенә, хәерчелеккә, өметсезлеккә түзә алмыйча, батрак гаиләләр урманга кача. Әле Идел белән Нократ арасы тоташ карурман була. Бер якта – Мишә елгасы, аңа ун кизләүле инеш агып төшә, тирә-юньдә биш күле бар – качкыннарга килеп төпләнер өчен менә дигән урын! Халык ишәйгәч, өйләр күбәйгән, авыл зурайгач, әкренләп, карурман да киселгән. Качкын халык юлбасарлык итмәгәндер, димим, иясез малны кулга ябештерү, печәнне-утынны рөхсәтсез генә алып китү, бүгенгә килеп, кыз урлау гадәтләре феодализм чорыннан калган чирдер... Халкының төрлелеге дә минем теорияне раслый. Без укыганда, Шәле мәктәбендә алты йөз дә сиксән бала иде. Арабызда: табак битле, кысык күзле, калын кара кашлы, шулай ук, озынча яңаклы, җирән чәчле малайлар да; сөтсел чырайлы, зәңгәр күзле, шулар арасында бит уртасында «мәхәббәт чокыры» уелып торган түгәрәк йөзле, чем-кара күзле кызлар да бар иде. Бар иде чегәнгә охшаганы, балан кагы төсендәгеләре дә... Кемнәр генә булмагандыр качаклар арасында?!. Куенга кергәч, этник төркемнәр буталып бетә бит ул.

«Дуслык» дигән «Яңа план»да Илсөяр исемле кызны куып йөргәндә, элеккеге карурманнан калган төпләргә абынып егылгалаганым булды... Авыл карурманны кисеп зурайган.

Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е безнең Шәледәге вакыйгаларга таянып язылмады микән, дигән шигем бар: карурман аланында гап-гади качкыннар тормышы; үзара мөнәсәбәтләре; тел-диалект стиле; җырулары, вакыйгалары

– нәкъ бүгенге Шәледәгечә! Тинчурин исемендәге театрның ел саен Шәле авылына кайтып, театраль сезон ачып җибәрүе минем фикерне көчәйтә генә!

Явыз Иван гаскәрләре дә Шәлене үзенә берләштерә алмаган. Чукындырырга дип килгән отрядны авыл капкасыннан кертмичә: «Үзегезне сөннәткә утыртабыз!» – дип каршы алганнар. Нәтиҗәдә опричниклар юл читенә кара багана утыртып киткәннәр – нәкъ кырыгынчы чакрымда. Татар авыллары Казан каласына 40 чакрымга якын килмәскә тиеш, дигән Указ безнең кара бағананы исәпкә алып чыгарылган. Шулай итеп, Шәле урыс һәм керәшен авыллары уртасында яшәп калган. «Кара баганалы» дигән кушаматы бүгенгәчә ияреп килә... Утыз ел элек таркалган күмәк хуҗалыкның да «Миллионер колхоз» дигән «кликуха»сы телдән төшми. Бәхәскә хирыс каләмдәшләр: «Төньяк Кавказда да Шәле бистәсе бар!» – дип минем авызны ябарга маташалар. Юк инде, агайне, Кавказ Шәлесендә дә шәл бәйләп ятмыйлар! Анда да бик «шальной» халык яши!..

Шәхсән үземә килгәндә, нәсел агачының нык тармагында «Корыч» кушаматын горур саклыйм. Мактанырга рөхсәт итегез, «кликухам» белән горурланам мин. Корычның ничек чыныкканын да беләсез. Тимер организм өчен бик кирәкле... Безнең нигездә, ни гомер узып, «корычларның» берсе дә алмагач утыртмаган... Адәм абый белән Һава апаны искә төшерегез... Абыебыз, апа кулыннан алма ашагач кына... Җир шарында халык котырып үрчи башлый. Чөнки алмада тимер бар! Ә «корыч» нәселенә тимер ашауның кирәге юк... Ул болай да шәп үрчегән... Әтинең салам түбә астында өч баласы... «Три пишем, два в уме» дигәндәй, язмыш арифметикасы бар бит әле. Сугышка кадәр, ягъни әнигә өйләнгәнче, әти ике тапкыр өйләнеп өлгергән булган: ике ел гына яшәп калган беренче хатыны ураза гаетендә вафат була; икенче хатыны белән дүрт ел яшәп өлгерә, анысы Корбан гаетендә үлеп китә. Әти: «Атна саен гает, гает саен мәет, твою мать!» – дип елый торган булган. Алардан ике малай читкә киткән... Минем үземнең калай түбә астында икәү, читтә үземнән унсигез яшькә генә кече бер малаем һәм... исемсез хатлар җибәрерлек серләрем бар. Организмда тимер-томырның күплегеннән килә бу... Безнең тавыкларның да хәтта бер чуары ел саен бәрәңге алыр чак җиткәндә, буразна арасында качып чыгарган бер оя чебиен ияртеп кайта торган иде... Үстереп тә өлгерә бит үзе... Тимер тузанын кайдан гына чүпли торгандыр.

Ярый, яңадан унбиш яшемә кайтам...

Җәйге каникулның иң озын көннәре, таң алдыннан гына караңгы төшеп ала. Клубка бик әкрен җыелалар. Мин генә ашыгам. Клуб мөдире бүлмәсендәге көйсез пианиноны азаплап утырам. Исемсез бармак белән, сыңар куллап, «Салкын чишмә» көен чүплим... Ишек ачылды. Кемдер керде. Игътибар итмәдем. Ишек ябылды. Клавишларны санап көйне дәвам итәм: «Тау ас-тын-да сал-кын чиш-мә»... Бөтенләй таныш булмаган кеше – кырык яшьләрдәге бер ир мине дөрес итеп уйнарга өйрәтмәкче: «Көең матуррак чыксын дисәң, уң кулың белән баскан ноталарны сул кулың белән икенче октавада кабатлап бар.»

Ишек ябылды. «Укытучым» юк булды.

Тагын ишек ачылды. Абзый яныма ук килеп басты, пианино тавышын җиңәрлек итеп, сорауга охшаш тонда әйтә куйды:

«Монда минем родной братишкам бар, диделәр!»

«Бүлмәдә миннән башка кеше юк ич...»

«Мин Каримов Файзрахман Адгамович..»

«Мин Кәримов Камил Әдһәм улы!»

«Мин әтинең олы малае...»

«Мин төпчек улы...»

Әгәр алдан сөйләшенгән, көтелгән очрашу булса, бәлкем, мин әни белән киңәшеп, матур-матур сүзләр дә сайлап куйган булыр идем. Ә монда – 45 яшенә җитеп, беренче тапкыр үзенең кан туганын, төпчек энекәшен эзләп тапкан абыем алдында каушап калдым. Кул бирергә дә онытып торам, күрешмәкче идем – ул мине кочаклап алды, маңгаема маңгаен терәп, бер мәлгә тынсыз торды... Аннан тирән, бик тирән итеп сулыш алды да кисәк читкә борылды... «Уф...» дигәнен генә ишетеп өлгердем...

Әти белән әнинең салам түбәле өй каршына басып төшкән фотосы бар. Ике тәрәзә арасына җәймә тарттырып, авылның бердәнбер фотографы «Бабай» Мөхәммәт каршына басканнар. (Мөхәммәт – колхозның баш инженеры. Яңа техникага бик һәвәс кеше. Шәҗәрәсе буенча Г.Кариев исемендәге театрның баш режиссёры Ренат Әюповның әтисе ягыннан дәү абыйсы). Фотога төшкәндә, кеше үзенең иң затлы киемнәрен кия торгандыр. Әни бәби итәкле, озын җиңле аксыл күлмәктән; чигүле күкрәкчә өстеннән киң канатлы көрән алъяпкыч кигән; калын толымнарын яшермичә, кәшемир яулыгын калфаксыман итеп бәйләгән... Әти солдат итегеннән; галифе чалбардан; җиңе кыскарган гимнастёркадан; ул да минем кебек гел кепкадан йөрергә яраткан икән.

Әгәр... Әтинең күкрәгенә «Сугышчан дан ордены» һәм «Сугыштагы батырлыгы өчен» медале тагылган гимнастёркасын Фәйзрахман абыйга кидерсәңме?! Ул нәкъ шушы фотодагы әтиемә охшап калыр иде...

Фәйзрахман абыем Красноярск краеның Богучан районы, Невонки бистәсендә яшәгән. ГЭС төзелешендә эретеп ябыштыручы булып эшләгән... Аның белән ике ел буе хат алыштым. Мәктәпне тәмамлауга минем янга киләсең, Богучан районының комсомол комитетына эшкә урнаштырам дигән иде. Ике ел үтмәде – хаты кинәт өзелде. Эш урынында авария булды, дигән хәбәре килде. Ике кызы белән хатыны шунда яшәп калды... Фәйзрахман – әтинең ураза гаетендә үлгән хатынынннан калган малай.

Абыйларым да, апам да, мин дә – салам түбәнең соңгы балалары...

Корбан гаетендә үлгән хатыны да әтигә Габдрахман исемле бер ятим калдырып китә. Шулай итеп, әти белән язылышкан көнне, әнинең инде ике зур малае була. Габдрахман абыем да ай үсәсен көн үсә, солдат яшенә җитә... Армия хезмәтеннән соң, туп-туры Төмән өлкәсенең Ялутор бистәсенә урман кисүчеләр артеленә китә. Шунда ук ашханәдә эшләүче Светлана исемле татар кызына өйләнә, тиз арада бер малайлары туып өлгерә. (Сугыштан соңгы елларда татар кызларына Светлана исеме кушу аңлатып булмаслык гадәткә әверелә. Юлбашчы нәселен, аның балалары исемен мәңгеләштерүдер инде бу.)

Габдрахман абыем хат язарга бик ялкау була, исәнлеген сиздереп, ике айга бер хәбәре килсә дә, әни сөенгән инде. Әни әйтә: «Хат саен «менә күрерсез, тимер юл вагонына төяп, эченә салам түбәле өегез сыярлык Себер бурасы җибәрәм әле мин сезгә!» дип яза торган иде», – ди. – «Корыч» нәселе үҗәт, уйлаганын чынга ашырмыйча туктамас, тәки сүзендә торган булыр иде», – ди... Иде... Ләкин Светланасы белән җиде генә ел яшәп өлгерә... Делянкадан аударган наратны тягач сөйрәгән чакта Габдрахман абыем ике агач арасына кысыла... Ятимнән ятим туа, ятим белән дөнья тула...

Йөри-йөри «корыч» шомара, мәгәр шома корыч тиз күгәрә...

Бертуган абыем Шамил дә гомер буе юлда йөри... Казанның 2 нче номерлы училищесын тәмамлап, су бораулаучы һөнәрен сайлый. «Ростов капкасы»ннан

кереп китә дә Төньяк Кавказ итәгендә ун ел буе «шифалы су» бораулый. Балачактан эчеп үскән туган як чишмәләре сагындырган, күрәсең. Хат ташучы Маһикамал апа Нальчик шәһәреннән җибәрелгән акча кәгазен әнигә тапшырган көнне, кояш баеганда, Шамил абыем үзе дә кайтып керә. Бөтенләйгә... Һәм Татарстан буйлап каладан калага, саладан салага йөреп, су бораулаучы булып, пенсиягә чыкканчы эшли... Шөкер, мин ошбу юлларны сырлаган көнне исән-имин генә сиксән яшенә якынлашып килә... 150 яшькә җитсә дә, күпсенмәгез, безнең нәселдә дә кемдер озын гомерле булырга тиештер бит!..

Балачакта өйгә ашарга да, йокларга гына кайтасың бит инде, көннең калган өлеше гел урамда үтә. Әнинең: «Балалар, олы юлда уйнамагыз, юл алып китәр!» – дигән сүзе гел дога булып ишетелә иде. Миңа шулай... Ә Тәнзилә апам ишетмәгән. Без инде, ниһаять, салам түбәдән котылгач кына, аны саман диварлы өйләрдән торган Караком чүленә алып киттеләр... Хәер, вакыйгаларны ашыктырмыйм... Кеше әкрен үсә, тиз картая. Яшь арткан саен язмыш тыгызлана... Сүз башында, ялан-тәпиләп, инеш читенә дип кенә баскан идем... Ә ул инде Караком чүлен телеп ага торган Амударья суы булып чыкты... Әйе, поэзия буйга үсә, ә проза аркылыга җәелә...

...Миңа бит әле 15 кенә яшь!

Борынгылар җыен вакытын шултиклем белеп сайлаганнар: печәнгә иртәрәк; җиләк пешеп җитмәгән; бәрәңге төбенә өяр идең – сабагы кыска; техника белән утынга керер идең – урман эче көпшәк, җир таптала... Гарифулла малае мал-туарның исемлеген төзеп чиратка салган. Кемнең күпме түлисен хәл итә торган берәмлек ул чират! Әйтик, 1 сыер – 1 чират; 2 кәҗә – үзе бер чират; 4 сарык – бер чират. Бозаулар, бәрән-бәтиләр саналмый. Безнең капкадан 2 сарык һәм 1 кәҗә чыгып китә... Җәй үткәнче, көтүче дә безгә бер генә тапкыр кереп ашый... Әйе... Гарифулла малаеның чыбыркысы ерагайгач, авыл эчендә көпә-көндез йокы тынлыгы урнаша. Эшсезлеккә күнекмәгән Шәле халкы кунак җыю мәшәкатенә чума... Өйләнергә теләүчеләр уяна. Туй арты туй китә... Бу бәйрәмнәр барысы да бергә кушылып, Сабантуйның куәтен арттыра, мәйдан бәйгеләрендә җиңүләргә чиратлар ишәя.

Шушы яшемә җитеп, җыенга җиде-сигез тапкыр гына булса да чыкканмын инде мин... Өлкән яшьтәге агай-апайлар, аркылы киртәгә сөялеп, черт-черт көнбагыш ярыр өчен генә көтеп алганнармы соң бу бәйрәмне? Яшь җилкенчәкнең гармун күргән саен туктый алмыйча биюләре дә сәер... Нигә инде ул кашыкка пешкән йомырка гына салып йөгермиләр?.. Колга башындагы күнитекне ел саен Афзал апа малае Миңнулла алып төшәсен беләләр бит инде, сабынлы баганалар утыртып, бәйрәмгә килгән малай-шалайның майка-ыштанын пычратмыйча гына күнитекне баштук Миңнуллага бүләк итеп булмый микәнни?!. Кыскасы, башка елларны кулга тотуга, «эрим-эрим», дип торган морожныйны ялап, бер шешә лимонад белән юып куйгач, җыенның бөтен кызыгы бетә, мәйданның ислемайлы җиле куып тоталмаслык итеп, өйгә таба йөгерәм... Быел әллә нишләдем... Кунак кызлар күп кайта икән бит безгә! Аларның матурлыгын күрсәң!.. Кигән киемнәрен ни дип тә аңлата алмыйм, һәрхәлдә, ак алъяпкычлы, озын җиңле, коңгырт мәктәп формасы түгел инде. Мәйдан тирәли очынып йөри торган аллы-гөлле сабын куыклары, юк, чыршы уенчыклары кебек, дисәм, үпкәләрләр... Һәрхәлдә салават күперенең җиде төсе дә бар аларда. Үзләре ялгыз йөрмиләр, икәүләп тә, дүртәүләп. Ну, без дә Рафаэль белән, ике кәҗә бер чират, кайсыларын гына куып китсәк тә, гел бергә... Бер уңайдан өч кыз белән таныштым, өчесе дә... Илсөяр исемле

булып чыкты... Салкын чишмә авылыннан килгәне дә, күрше Күн авылыннан Үлмәсгөл апаларга кунакка кайтканы да. Дүртенчесе... Үзебезнең авыл кызы Гөлназ иде... Минем аны озын тәнәфесләрдә күргәнем бар инде, хәтта «Отличниклар тактасы»нда фотосы да эленеп тора... Ә бүген танымадым, бәйрәм бизәгенә әверелгән... Сабан туе да кыска булды, иртәнге 10да башланды, көтү кайткач бетте... Кичке җыенга чыгудан файда юк, Гөлназның капкалары эчтән бикләнә... Ул бит әле җиденчене генә тәмамлады...

Сабантуй «Мәдрәсә бакчасы» дигән аланда уза. Авыл уртасында булгач, халык төрле якка төркем-төркем тарала. Мин дә үзебезнең Гөлназлы төркемгә иярдем. Кызга бигүк якын килмәсәм дә, адымым нык, баш горур! Яңа өебезне дә үтеп киттем. Инде алданрак атлаучылар миңа борылып-борылып карый, ә арттагылар пышан-пышан фараз кыла... Сер бирмим, төркем таралып, соңгысы булып Гөлназ калганчы барам да барам әле! Мин хәзер шифер түбәле малай!

Ниһаять, икәүдән икәү генә калабыз бугай! Гөлназның: «Әнә, мәктәпне күрәсеңме?» – дигән гөрелдәвек тавышына ышанып, ул әйткән якка җан ыргытып алдым. Тик берни аңышмыйча борылсам – үзебезнең Гөлназ, әнисен күргән болан баласыдай ике-өч адым сикерүгә күздән югалып бара иде инде, бизәкле капканың ачылып ябылганы гына ишетелеп калды. Яшел йөзле, ак керфекле зур-зур өч тәрәзәсенә ут алып, бурасы киң такталар белән тышланган, калай түбәле өй Гөлназны үзенә бикләп куйды бугай...

Бүген кояш бигрәкләр дә иртә баеды...

Мин кайтып кергәндә, әни өйдә юк иде. Кәҗә-сарыкларны япкан, каз бәбкәләре тынычланган. Сыер савасы юк... Яңа өйгә күчкәннән бирле аңлый алмыйм мин әнине. Салам түбә астында бер оя булып яшәдек, инде зур түбә астында ялгызлыктан колагым чыңлый, ди. Беләм инде, Нәфисә апаларда «кич утыра», алар безгә каршы як күрше, капкаларыбыз ачык чакта бер-беребезне бик якын ишетәбез. Нәфисә апаның «Герой ана» дигән медале бар. Ире – теге «Сыер күле» янына салынган тавык фермасында мөдир. Җиде балалы гаиләдә әни нинди кызык табадыр? Утны яндырсам, чыгып җитә инде дә...

Бүген кызлар озатып йөрдем. Сабантуй көнне! Беренче тапкыр! Беренчесе үк – Гөлназ. Беренче... Мактанасың килгәндә, янында кеше булмаса, кыен икән ул. Ә Гөлназның мактанасы килмиме икән? Беләсе иде шуны. Корыч малаен кызык иттем, көне буе Сабантуйда әлсерәгән килеш ял да иттермичә, кереп качтым, дип аның да мактанасы киләдер әле.

Тирләп-пешеп уйланып утырган арада авырлык белән генә мөлдерәмә тулган ай калыкты. Ул гүя минем тәрәзәмне эзләп тапты да: «Дәфтәреңнән куш бит ертып ал да, хат яз!» дип пышылдады... Ялындырып торырга вакыт юк. Ай яктысы башкалар тәрәзәсенә күчкәнче хат язарга утырдым. Беренче юллары ук шигырь кебек килеп чыкты...

*Сагынганда, кайда син, дип, нигә кайгыга калыйм, янымда син – табигатьнең һәр фигылендә таныйм...*

Отличник кыз хаталарын чүпләмәсен, дип, чистага күчереп яздым. Иртәгә мин бу хатны Питрәчкә илтеп салам.

Икенче көнне үк без Рафаэль белән, сөт машинасына утырып, Питрәч Сабан туена киттек. Бәйрәмгә Шәле халкын ташыр өчен колхоз дүрт машина куя. Ләкин алар әле иртәнге сигезләрсез килеп басмый, ул чакта инде халык та илаһи-уптым кузгала, анда «дүрт сарык бер чират» башлана. Машиналар дүртәр рейс ясар, дигәннәрие, ләкин һәркем беренчеләренә утырырга тырыша, бастырып төялгән утын кебек әле бер, әле икенче якка авышып барса да бара,

иң мөһиме – алдан өлгерү. Ә кайткан чакта машиналар исереп бетә, күпчелек җәяү кайтырга тырыша, берәүнең дә районда кунып калганы юк. Яулык өстеннән ирләренең кепкасын киеп куйган апалар, нарат төбендә амбразура каплап яткан агайларны уятып, сигез сәгать буе әрләшеп кайта булыр. «Бүтән сиңа ышанып, район Сабан туена чыксаммы, Аллам сакласын! Урыс булганчы лыкынмасаң суң. Әнә, синең ишеләр ат җигеп килә. Гармун уйнап кайта! Әйдә инде, атла, кешедән яхшы түгел!» Шөкер, бу каһәрләр – «тукран тәүбәсе» генә, икенче җыенга чаклы онытыла, юкса, Шәле белән Күн авылы килүдән туктар иде дә, район үзәге бәйрәмсез калыр иде. И татар теле, зарланыр, әрләр өчен бигрәкләр дә ягымлы тел инде син!..

Безнең Питрәчтә татар, урыс, керәшен өч өлешкә тигез санда. Иртән урын өстендә артык иркәләнеп ятсаң, әнинең: «Тор, Иван, юын, укын, чукын!» – дип үрти торган гадәте бар... Рафаэль белән без Военком бинасының ишек яңагына эленгән почта әрҗәсе янына килеп басканда, Иваннар чукынырга да өлгермәгәндер әле.

Ул көнне район Сабан туе булгандырмы, юкмы, хәтерләмим инде. Әмма дә өйгә кайткан сәгатьтән үк хат ташучы Маһикамал апаның урамыбыздан үтеп киткәнен сагалый башладым...

Гөлназдан хат юк та юк... Халык җиләккә ябырылды... Печәнгә төште. Җавап һаман юк. Әллә военком каршындагы әрҗәдән алып, синең хатны берәр призывникка җибәрделәр микән, ди Рафаэль. Хаталарын төзәтеп язганнан соң, тегесен ташламаган идем әле, яңадан күчереп, шул ук хатны тагын җибәрдем. Барыбер җавап килмәде... Көн дә кич клуб тирәсеннән эзлим үзен... Гөлназны чыгармыйлар, күрәсең, чөнки егет сөярдәй Сәрия апасы бар...

Аптырагач, ул хатның күчермәсен Күн авылы Илсөяренә дә, Салкын чишмәнекенә дә җибәрдем. Җаваплары бик тиз килде... Эшли бит почта! Күрше авыл кызлары минем шигырьне мактаганнар да хәтта... Без бәләкәй чакта бүгенге кебек бөтен кеше дә шигырь язмый иде шул...

Язарыңа сәбәп булыр, дипме, Ходай җәйге каникулда кунак кызларны безнең авылга кайтара торды, танышкан берсе белән хат алышам. Әлфия, Сәрия, Рәмзия, Алмазияләргә җибәрә торгач, теге шигырь дүрт куплетка җитте. Ә күңелем белән һаман да Гөлназдан җавап көттем.

***

Сигезьеллык белемгә сөенеп, ярты халык колхоз эшенә киткән иде. Ләкин күрше авыллардан җыелган интернат укучылары килеп кушылгач, классыбызда тагын буш урыннар калмады.

Борысны борыска ялгап салынган ике катлы агач мәктәп исемә төшкән саен сискәнеп куям. Ничекләр итеп күтәрде икән ул безне – 600 баланы?!. Бөтен мәктәп халкы белән линейкага тезелеп баскан коридор идәненең өрлеге – аскы катның матчасы – баш-башларыннан черемичә, кырык ел буе ничек сакланган соң ул? Аскы катта 200 кешелек Пионер бүлмәсе, озын урындыкларын сәхнәгә күчереп торсаң – спортзал! Өстә китапханә һәм буфет, һәр класс саен утын ягып җылыта торган «көймә» мич... Физика һәм химия кабинетлары. Укулар ике сменалы булса да, җыелышлар, тантаналы кичәләр бергә үткәрелә торган иде. Түбәсеннән су үтмәде, туфраксадан балчык коелмады, кайсы тарафтан иссә дә, җил-буран кермәде. Кырык ел буе басыла торгач, мүкләре чәерләнеп, борысларның эргәсе эргәгә ябышкандыр да ике катлы дивары монолитка әйләнгәндер.

Шәле агаларын «шабашниклар» дип күпме генә үртәсәләр дә, чынлап

та, кулына балта тота белмәгән ир заты юк бездә. Әлеге мәктәпне үзебезнең балта осталары күтәргән. Ул ЮНЕСКОда теркәлеп, архитектура истәлеге булып сакланырга лаек иде. Ундүрт яшеннән Габдулла Тукайга гашыйк булган Зәйтүнә шушы мәктәптә мөгаллимлек иткән. Ул сөекле шагыйрьнең шигырьләрен укыган чакта бәләкәй Атилла (Расих), Шәле балалары арасында утырып, әнисен тыңларга яраткан. Ике катлы агач мәктәпнең пионер бүлмәсендә композитор Заһид Хәбибуллин, скрипкада уйнап, Сара Садыйкованы җырлаткан. Шушы бәләкәй генә сәхнәдә олуг язучыларыбыз Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов, Нәби Дәүли, Шәйхи Маннур, Зәки Нури, Илдар Юзеев, Мәхмүт Хөсәен, Гариф Ахуновлар чыгыш ясаган. Һәм бу исемлекне әле бик озаклап дәвам итеп булыр иде...

Мәктәпләрдә – өй язмышы...

Мин укып бетергән елның көзендә үк балалар яңа таш мәктәпкә күчте. Сигез ел буе түбә күрмичә өелеп тора иде, бер җәй эчендә өлгерттеләр үзен.

Иске мәктәпне, күз алдында сүтеп, утынга өләштеләр. Мичләрен бульдозер белән җимереп, нигезләрен җир белән тигезләделәр. Халык күп җыелды. Тамаша күрер өчен түгел, саубуллашыр өчен. Ни дисәң дә, үз дәверендә авылның өч мең кешесен укырга-язарга өйрәткән, чын Совет кешесе итеп тәрбияләгән, үстергән өй бит ул!..

Җимерү турындагы Актка кул куяр өчен чакыртылган РОНО комиссиясе һәм янгын сүндерүчеләр, Муса Җәлил әйтмешли, «читтән көлеп карап тордылар...» Алар өчен бу күренеш – искелек калдыгыннан котылу үрнәге генә иде.

Без ике катлы агач мәктәпнең соңгы укучылары...

Һәр елның февраль башында студентларның зачёт-имтиханнардан соң, кышкы каникуллары башлангач, «Мәктәп карлыгачлары» белән очрашу кичәләре була торган иде. Үзең утырган парта арасына кереп, сөекле укытучы апаларың белән ачык дәрес үткәрү – бәйрәмнең күздән яшь китерердәй дулкынландыргыч һәм үтә дә моңсу минутлары була торган иде... Безнең парталарны эзләп табарлык түгел инде. Яңа мәктәпнең җиһазлары да яңартылган. Һәр биш ел саен күрешербез, дигән вәгъдәләребез «карлыгач» оялары белән утынга китте. Биш ел да үтте, ун... егерме... утыз... Күпме санасаң да, классташларыбызның күрешә алганы юк. Яңа мәктәпнекеләр күрешеп торалар үзе...

1984 елның маенда, Язучылар оешмасы машинасы белән Арчага кайттык. С.Хәкин, Г.Ахунов, М.Мәһдиев һәм мин. Гариф абыйның председатель чагы. Берәр атнадан Язучылар съезды булырга тиеш, җитәкчелектә үзгәрешләр көтелә... Сагышлы сәяхәт иде бу. Башта Өчилегә, аннан Күлле Кимегә, кайтыр якта Гөберчәккә кереп, җирсүне басарбыз дип баралар... Ләкин Өчиле дигән тукталышта бернинди дә авыл юк иде. Гариф Ахунов машинадан төшү белән: «Менә, менә безнең өй урыны шушы инде. Монда капка баганасының төбе, әнә тегендә баз чокыры, менә, менә бу төштә нигез эзе...» дип, алабуталы кычыткан арасында шагыйранә такмаклый башлады... Ул көнне алар никтер Күлле Кимегә дә, Гөберчәккә дә кереп тормадылар. Гариф абыйның сагышы барыбызга да җитте... Һәм мин дә бу сагышны уртаклашу йөзеннән юл буе үзебезнең агач мәктәп нигезен күзаллап бардым.

1965 елның 1 нче сентябрендә Кыңгырау бәйрәмен мәктәп коридорында гына үткәрделәр. Яшене яшьнәмәсә дә, авыл өстенә килеп эленгән болытларның яңгыры күренеп тора иде инде.

Ике катлы агач мәктәпнең өске коридорында... 600 бала линейкага

тезелгән(!). Шуңа өстәп, әле мин белгәннәре генә дә – егермеләп укытучы! Алгы сафка орынмаска тырышып кына, мәктәп директоры Наил Зиннәт улы Нуруллин (язучы һәм әдәбият галиме, профессор Ибраһим Нуруллинның бертуган абыйсы) арлы-бирле йөренә. Нindидер бик җитди сүз әйтергә тели, ә үзе, линейканың өч-дүрт җирендә тукталып, «Исәнмесез?!» дип баш селки дә, безне завучка калдырып, кабинетына кереп китә. Сигез ел укып, директорның ул «җитди сүзен» тәки ишетмәдем. Наил «Зиннәтеч»: тәбәнәк һәм базык гәүдәле; сакал-мыек үстермәде; чәчен ике куллап, артка сыпырырга гадәтләнгән иде; адымнары вак-вак, ләкин акрын йөри; сигез ел эчендә ялгышып кына да елмайганын күрмәдем. Бу «иске» директорның Казанга күчеп китәр алдыннан соңгы линейкасы булган.

Линейка дигәне без аягүрә үткәрелгән зур җыелышка охшап калды. Мәктәп безне сагынып көткән, җәй буе яңалыклар күпләп җыелган. Укытучылар сөйләргә атлыгып тора... Исемлектәгеләр чыгыш ясап бетерде дигәндә генә, колхоз председателе Фәйзи абый сүз алды. »...Исәнмесез, пнимаете так, тырышып укыгыз, вузларга кереп Шәле данын күтәрегез, пнимаете так. Укырга керә алмаганнар – колхозга пожалысты, эш җитәрлек, пнимаете так! Ну, сез хәзер булышчылар, көл җыюны, кош тизәге китерүне һәм дә гараждан чәлдермичә генә, пнимаете так, тимер-томыр җыюны киметмәгез! Сентябрьнең унбишләреннән колхоз кырына бәрәңге алырга чыгарсыз, өзелгән дәресләрне куып җитәрсез. Пнимаете так, сау булыгыз!»

Ниһаять, «Белем бәйрәме» тәмам! «Ур-ра!» кычкырып, озын тәнәфескә таралыштык. Теге болытлар безнең хәлне тәрәзәдән күреп алганнардыр, яңгырларын бушатмыйча гына Бимә урманына авышканнар. Без югында мәктәп ишегалдында туфли күмелерлек чирәм үскән. Урамга чыгуга өч төркем хасил булды: вожатый октябрятлар белән «Гөлбану» уенын башлап җибәрде, пионерлар – спорт мәйданында таган атына, комсомол значогы таккан төркем, председательгә охшатырга тырышып, Фәйзи абый чыгышы буенча фикер алышабыз. Яшь комсомол буларак, Гөлназ төркем читендә калган. Рафаэль белән киңәшләшеп тормадым, әҗәтен сорап килгән әрсездәй, туп-туры эндәштем:

– Ник минем хатыма җавап язмадың? Җәй буе көттем! – дидем. Ә ул, сынын горур тотып, иңбашы аша гына җавап бирде.

– Мәктәп бакчасына су сибәргә килгәч, синең хатны Мөхәммәт абыйга күрсәттем. Ул миңа, шигырь яза торган кешедән ераграк йөр, сеңлем, диде...

Һәм Гөлназ, минем сиңа бурычым юк дигәндәй, кисәк борылды да, кырыслыгына масаеп, пионерлар төркеменә кушылды...

Менә шундый гап-гади арифметика – үзебезнең Гөлназны язып куям, ике Илсөяр хәтердә генә кала.

Абый дигәнебез – Мөхәммәт Садыйков. Күн авылыннан килеп, Шәледә укыган, пединститутны бетергәч, тагын тарих укытучысы булып эшкә кайткан. Шигырьләре район газетасында еш басыла. Киләсе елга Казанда «Беренче карлыгачлар» исеме белән китабы чыгарга тиеш, диделәр. «Карга карганың күзен чукымый» дигән әйтем шагыйрьләргә кагылмый, күрәсең. Әгәр хатны шигырь белән башламасам, бәлкем, Гөлназ аны, шагыйрь абыйга күрсәтеп тормыйча, ертып кына аткан булыр иде. Юк шул инде, кызларга хат язганда, мин үземне бөек шагыйрь кебек хис итәм: соклансыннар миңа, тел шартлатсыннар! Күпме китап укыдым, Һинд киноларының берсен дә калдырмыйм, беләм – гашыйк кешеләр гел шагыйрьләрчә сөйләшә, димәк, шигърият мәхәббәттән

яралган. Ләкин, исемнәр күбәйгән саен, хатлар калыная бара һәм шигырь туып өлгерми, бөлгенлеккә төшә. Мин инде хикәяләүгә күчәм... Тау Илендәге Наилә, Иске Йорт кызы Миңзифа, Чыныкныкы Гөлнәфидә, Йорткүл кызы Мәдинәләрнең берсе дә минем хатларны ертып атмагандыр...

Әле уч төбенә сыярлык итеп кенә, муенымдагы «шрам»ны күләгәдәрәк калдырыбрак төшерелгән фотомны да җибәреп өлгерәм. Көнчыгыш Казакъстанның Шемонайха бистәсендә 9 нчы класс укучысы Камалова Нәзифә яши. Ул Яңа 1966 ел белән котлап җибәргән открыткасына: «Зур язучы булгач, син мине онытырсың әле...» дигән... Ялгызлык ул колагыңны чыңлатырлык тынлык белән газаплый. Хат – ул юаныч, хат – ул дус! Хат алышу – озак көттергән җаваплар белән кара-каршы сөйләшү. Һәм мин бары тик минем өчен генә үскән бердәнбер кыз баланы матур әдәбият белән эзлим.

Нәзифә... Казакъстан...

Үзе уйлап чыгарган әкияткә үзе ышанган кеше бер Хуҗа Насретдин гынамы?..

2017 елның май аенда Казакъстанның Төркестан шәһәреннән көтелмәгәнчәрәк, шул ук вакытта минем өчен бераз серлерәк, димме, хәбәр килде.

11-13 нче числода, төрки-дөнья язучыларының һәм шагыйрьләренең китап күргәзмәсе оештырылачак икән. Шунда катнашу өчен ризалыгымны сорыйлар, билетларны алдан ук алып куясылар, бөтен чыгымнарны Чимкент (Шымкент) өлкәсенең хакимияте күтәрә, диләр. Шундук сөйләшү өзелде, ерак ара шул, роуминг хәлсездер, дияргә мөмкинлек бар...

Әйе, көтелмәгәнрәк һәм серлерәк хәбәр бу... Рашат Низамиев әйтмешли: беренчедән, иҗат даирәсендә чит ил чакыруларын минутында ук кулга төшерә торган даими делегация бар – чыгымнарны Антарктида күтәрә калса, алар пингвиннар каршында да чыгыш ясарга риза; икенчедән, күрше республикалардан сәфәр кылып кайтканда, ялыктыргыч юлны мавыктыргыч итәр өчен телефон аша тавышларын үзгәртеп, кызык ясарга һәвәс дусларыбыз бар (мин бит артистлар арасында язучы, ә язучылар арасында артист булырга яратам, шуңа күрә дә рәхәтләнәләр үртәп); өченчедән, «Гадиләгә өч авылдан өч яучы килгән, өчесенә дә риза дигән!»... Чакырган җиргә бармый калсаң, гадәттә, бүтән чакырмыйлар. Мин йөремсәк кеше, чакырулары чынлап булса, әлбәттә, барам... Алай гына да түгел, күңел әле һаман сергә мохтаҗ... Бу чакыруны Нәзифә оештырмаганмы? Аның адресын миңа тыкрык аша күршебез Муса абый биргән иде, бертуган сеңлесе, ягъни Нәзифәнең булачак әнисе, комсомол путёвкасы белән Чирәм җир күтәрергә дип чыгып киткән дә шунда бер казакъ егетенә кияүгә чыгып калган...

Чимкент аэропортына килеп төшкән минуттан өч көн буе як-ягыма карандым... Менә хәзер, кинәт кенә минем яшьләрдәге кара тутлы, табак битле, үткен күзле бер ханым каршыма килеп баса да, бу сезнеке түгелме, дип, крокодил тиреле букча кесәсеннән минем кәртечкәмне чыгара... Әйе шул, мин бу. И-и, бигрәкләр дә бала-чага булганмын инде, дип, әйтермен инде. Шуннан соң ул балаларын саный башлар, ә инде оныкларын саный башлагач, Нәзифә ханым, зинһар гафу итегез, безне «Ханәкә» китапханәсендә делегация көтә, Ходай кушса, күрешербез әле, диярмен дә, «әле дә ярый моңа өйләнмәгәнмен», дигән сөенеч белән, кунаклар арасында югалырмын... Әйе!

Йөземгә буе җитмәгәч, төлке дә әйткән, пешмәгән әле бу, дип. Сөяксез тел тик торганда, уй дигәнең кылтайган була. Өч көн буе, хәтта кайтыр якта самолётка кереп утыргач та, як-ягыма карандым, каләмем түгел, калебем маҗара эзли. Ә маҗара эзләгән кеше – ул күпне күргән көмеш көзге кебек,

тузан кунмасын өчен аңа гел яңа шәүлә кирәк... Нәзифә белән икебез ике якта яшәсәк тә, мәктәпне бер үк елда тәмамладык инде. Институтка керә алмагач, эш эзләп йөргән арада мин аның соңгы хатына тиз генә җавап яза алмадым. Шуның белән ара өзелде. Әлбәттә, үсмер чакта язган хатларның вәгъдәсе юк. Ләкин Нәзифә, йотылып калган җавап, әманәткә әверелсә, ярты гасыр үткәч, агач курчакларга яшеренеп, исемсез хат рәвешендә килеп җитәргә мөмкиндер бит? Бик мөмкин...

Бүгенге көнгә чаклы, мин, алты тапкыр эш урынымны алыштырдым (әле хезмәт кенәгәсенә язылмаганнарын да кушып санасаң, дистәдән артып китә); даими яшәү урыны эзләп, адресымны җиде кат үзгәрткәнмен: су бораулап; филармония лекторийлары буенча авыл эшчәннәре белән очрашулар үткәреп; күренекле җырчылар һәм дә язучылар төркеменә ияреп, Идел буе республикаларында, Мәскәүдә, Ленинградта, Төмәндә, Көнбатыш Себер шәһәрләрендә чыгыш ясауларны барлап чыксаң... мине кайсы гына хат ташучы эзләп таба алсын соң?! Радиоэлектроника казанышлары, интернет челтәрләре, сайтлар, ватсаплар белән эзләп табарлар иде, кирәгең юктыр, дип, авызымны ябарга ашыкмагыз. Мин – физика, химия, биология һәм геометрия дәресләренең «ударнигы», кибетләрдән детальләр эзләп, радиоалгычлар җыйган, 1983 елда Аккош күленә барып, Гомәр ага Бәшировның «Сиваш» китабы чаклы гына экранлы ватык телевизорын төзәтеп кайткан һәвәскәр – металл чыбык буйлап секундка 300 мең километр тизлек белән йөри торган бәйсез электроннарның, көне-төне кешенең җанын-тәнен-аңын үтәли чыга торган экран нурланышларының ни икәнен яхшы беләм... Шуңа күрә дә гап-гади кесә телефоны гына йөртәм. Миңа бүген «Нихәл? Эшлисеңме әле? Авылга кайтасыңмы? Телевизордан күрдек... Мин әле бу...» дигән СМСлар да җитеп тора. Исемеңне яшереп, кача-поса язып, почталарга барып, ят адреслар белән тутырып мәшәкатьләнгәнче, кесә телефоныннан бер авыр сулавың да җитә ләбаса...

Казакъстанга китап күргәзмәсенә чакыруларының сере соңыннан ачыкланды. Төркестаннан туп-туры «Татар-информ» агентлыгына чыкканнар. Шартлары бик гади үзе – һәр илдән, һәр җөмһүрияттән бер генә язучы катнаша ала, исеме, иҗаты һәм яңа чыккан китабы игътибарга лаек булырга тиеш... Ә «Татар-информ»да кечкенәдән үк татар әдәбиятын – поэзиясен һәм прозасын җентекләп укып, вакытында туры фикерен әйтә белә торган талантлы шәхес бар, ул – Рузилә Мөхәммәтова, ике уйлап тормый, минем исемне атый. Мактанырга рөхсәт итегез, мин ул күргәзмәдә «Игезәкләр йолдызлыгы» һәм «Карурманда кара песи» китаплары белән катнаштым. Илле кешелек делегация минем витринаны үтеп киткәч, Башкортстан язучысы, Салават Юлаев премиясе лауреаты Ринат Камалов белән Азәрбайҗанның күренекле балалар шагыйре, профессор Заһид Хәлил кире килеп, минем китапларны актардылар...

– Да, Татарстан китап чыгара белә, – диде Заһид әфәнде һәм күргәзмәгә куелган 300 данә тиражлы юка тышлы «Ак ләкләкләр» китабын култамга белән миңа бүләк итте (Баку. 2016).

Ринат Камаловның фамилиясе, нәүмиз күңелемә, самолётта килгәндә үк бик ягымлы булып ишетелгән иде дә, иркенләп аралаша торгач, аңладым – казакъ кызы Нәзифә Камалова белән аның берникди дә туганлыгы юк икән...

Кеше исемнәре дә тиктомалдан гына кушылмый. Ә шәһәр-авылларның исеме җисеменнән чыга. Ташкент белән Шымкент (Чимкент) арасы Казан – Арча арасы чаклы гына икән. Ташкент – таш кала, ә Шымкент яшел кала

дигән мәгънәдә икән. Китап күргәзмәсенә җыйналган кунакларның соңгы көне аэропортлы Шымкент шәһәренә сәяхәт ясап үтте. Казакъстан илнең үзәген дә, чит-читен дә төзекләндергән. Төркестаннан Шымкентка кайтканда, спидометр 140 ка җиткәч, кунакларның аягы тормоз эзли башлаган иде инде. Ләкин олы юл аэродром мәйданы кебек тигез һәм нык булгач, тизлеккә тиз ияләшәсең. Аларда да 110нан арттырмаска дигән катгый кагыйдә бар. Тик шофёрлар үзләренчә яши – 120 чакрымлы юлда һичнинди ГАИ посты юк. Өч көн эчендә, үзебезнең Тольятти заводында эшләнгән бер генә машина да очрамады. Бөтенесе «Шкода», «Фольксваген», «Уз Дэу» кебек машиналар... Әллә соң безнең юллардагы агрессия, дорфалык һәм тәртип бозулар Россия автопромы белән таралды микән?!. Шәһәр эчендә, гомумән, тәртип, дүрт-биш чатлы тыкрыкларда светофорга буйсыну, күрше машиналарны хөрмәт итү, әдәплелек нык сизелә. Казаннан килгән кеше өчен Шымкент урамнары инструкторлар күзәткәндә, имтихан тапшырып йөрүче өйрәнчек шофёрларны хәтерләтә: комачауламаска, ашыкмаска, узмаска, кычкыртмаска, сүгенмәскә, иң мөһиме – тәртип сакларга тырышу сизелә.

Яшел кала дисәләр дә, урман юк инде монда, һәр өй җимеш бакчасында. Шәһәр эчендә аккан суы якын килгәч кенә күренә торган бердәнбер тирән эчле ерганак бар. Тирә-якта борынгылар утыртып калдырган пальмалар. Ерганак яры буйлап сузылган таш тротуарда кеше өзелми. Дымлы, җиләс һәм тансык һава Шымкентның җилкуарларын үзенә тартып тора. Никахтан соң фотога төшү, туган көннәрне шушында үткәрү йолага әверелгән, кафеларында ике-өч төрле кымыздан гайре, каты эчемлекләр күренми, хәер, теләгән кешегә әлеге «Дендрарий»дан чыккач, кибетләрдә хөррият үзе. Күпчелек халык читтән килгән, ике телдә аралашу нык сизелә. Ирләре шаһзадә түгел, ярый инде шунда. Ә кызлары! Затлы нәселдән урлап кайтып үрчеткәннәр, диярсең! Ялганлар хәлем юк, җиләк-җимеш диетасында утыралармы – симезләрен күрмәдем. Буйга – миннән бераз калкураклар, сыннары биюченекедәй төз. Чик сызыгына якын булгангамы, казакъ этносы бу тирәдә үзенең шоколадтай чыраен югалткан, түгәрәк йөзләрендә сөт яктысы, шешмә кабаклы булмасалар да, күзләре кысык, шуңадырмы, Шымкент кызлары гел елмаеп, йокымсырап йөриләрдер кебек. Ышанмасагыз, профессор Хатыйп Миңнегуловтан сорагыз, ул үзенә тормыш иптәшен шул яктан сайлап алып кайткан.

Көн эчендә без шәһәрнең биш китапханәсен йөреп чыктык. Ә хакимият бинасы белән янәшәдә яңа гына салынган Китап сараена (Үзәк китапханә дип кенә әйтергә телем әйләнми) безнең күргәзмә әсбапларны, шул исәптән, минекеләрне дә, фондка күчереп өлгергәннәр иде инде.

Күгәрченнәрнең җиләк-җимешкә исләре китми, шәһәр эчендә аларны бөтенләй күрмәдем. Ә карлыгачларга җылы якта ризык җитәрлек. Карлыгачлар, кешеләрдән курку хисен югалтып, тәмам әрсезләнгәннәр. Алар супермаркетларның ишек өстенә үк оялаганнар; тукталышлардагы баганаларның тишеген табып, бетон куышлыкта гаилә корырга өйрәнгәннәр.

Шәһәр читендә бодай үстерерлек, куна тактасыдай тип-тигез җирләр күкрәп ята. Климат аермасына карамастан, уҗымнар Шәле кырларындагыча гына. Иген өстенә чит ил болытлары очып кергәли – сурәтләре дә нәкъ бездәгечә ләкин тургайлары гына юк...

Ерак сәфәрдән кайткач, күчтәнәч өметләнерләр дип, портфельгә «Kazakctan» дигән биш-алты шоколад салдык, калганы үзебезнең кибетләрдә дә шыгрым тулы.

Сагынуыбызны сизенгән шикелле, билгеләнгән вакыттан бер минутка да соңармыйча, аэробус безне тургайлы болытлар тарафына алып менеп китте. Нәзифәле Казакъстан ак болытлар эчендә калды...

## Абау, мәхәббәтсез!

«Синең аркада гына харап булды апаң! Гөнаһ шомлыгы, каян өйрәндең шул хат язышу уенын?! Армиядәге абыеңа бер-ике җөмлә генә булса да язып сал инде, улым, дип ялынган чакларда вакытың юк синең, әллә кайдагы үзбәк малаена апаң исеменнән мәхәббәт хатлары алышып торырга бер дә иренмәдең...»

Әнидән мин бу зарны хәзер еш ишетә башладым. Кайсыбер көннәрдә ул аны икешәр-өчәр тапкыр кабатлый: сүзен сүзгә туры китереп, ятлагандай итеп, күңел рәнҗешенә охшатып. Бөтен гаепне апаның үзенә сылтап, акланырга тырышам, ә ул мине ишетми дә!.. «Синең аркада гына харап булды...»

Авылда без рус телен татарча укыдык. Апаның Союздаш республика егетләренә язарлык грамотасы юк. Ә минем писарьлык тәҗрибәм зур, ни дисәң дә, Питрәчнең марҗа кызлары белән хат алышып торам. Күршедәге Фатыйма әбинең төрмәдә утырган кызына да посылка адресларын мин тутырам.

Фатыйма «Ком сәгате» романындагы Юаш Нотфулланың кари энисе. Герой-ана Нәфисәсе үлгәч, Нотфулла, яшь сазамыкка өйләнеп, җиде баласын җитәкләп, Оренбург далаларына Чирәм җир күтәрергә чыгып китте. Фатыйма әби, дини китапларны иске телдә җиңел укыса да, кириллицаны өйрәнә алмады. Өй эчендә совет телендә язарлык кешесе дә юк. Хәзер мин булам аның елъязмачысы. Чирәм җирнең миңа да бер кишәрлеге калган иде. 1968 елның көзендә барып, сөреп кайттым. Ә Нотфулла шунда төпләнеп калды. Җиде баласы җиде якка чәчелде...

«А/Я – УЭ. 148/3 а» дигән сәяси сернең ни икәнен мин генә беләм – Пановка авылындагы хатын-кызлар төрмәсе ул! «Идел» альманахына тапшырылган «Кыңгыр эш» дигән повестемны укып чыккач, ул вакыттагы җаваплы мөхәррир Хәкимҗан ага Халиков, исемдә калырлык итеп әйткән иде:

«Энем, бүтән кабатларлык итмә, Советлар Союзында хатын-кыз төрмәләре юк!»

«Ничек булмасын?! Ленино-Кокушкино музееннан сигез генә чакрымда бар. Мин анда ике ай саен посылка җибәрәм... Күрше әбинең олы кызына, ун көн саен бер хат, адресы да повестьта төгәл язылган.»

«Мин әйткәч, юк инде, димәк!»

Хәкимҗан ага минем икеләнеп калуымны сизде булса кирәк, төшенерлек итеп аңлатырга кереште:

«Юк, дияргә кушылгач, юк!»

«Күрәләтә ялганлап язу килеп чыга түгелме?»

«Коммунизм төзи торган илдә җинаятьче хатыннар була алмый, син аларны саф кызлар, үрнәк аналар итеп сурәтлә...»

«Кыңгыр эш» Хәкимҗан Халиков кушканча басылып чыкты. Ләкин юраган юш килер, дигән фал бар бит әле... Миңа шул «үрнәк аналарны» үз күзләрем белән күрергә туры килде.

Ирегә чикләнгән җилкенчәкләр өчен хат алышудан да ләззәтлерәк ни булсын тагын! Моны мин СССР вакытында казарма тормышына мәҗбүриләнгән солдатларны да күздә тотып әйтәм.

Апамның адресын авылдашыбыз Хатип биргән һәм үзбәк егете исеменнән хатны да русчалатып Хатип үзе язып торган. Ныклап уйлап карасаң, өч ел буена Хатип белән без икәү хат алышкан кебек килеп чыга. Нәрсәләр язганымны хәтерләмим, ләкин апам, клубка чыгуын сирәгәйтеп, авыл егетләрен үзеннән биздереп бетерде. Ә инде дембельдән соң, үзбәк егете Хатипка ияреп, Шәлегә кунакка кайтып төшкәч, аның беренче хәбәрен хәтерлим: «Алай ук кысык күзле түгел ул, гел татарга охшаган!»

Кунак егете Хатипларда атналап ятмагандыр, печән өсте иде. Авыл советында язылышып та кайттылар. Шул көнне үк апам колхозның гектар ярымлы бәрәңге сутыеннан, кукуруз арасыннан чүп үләне йолкып кышлык печән әзерләүдән һәм карлы-буранлы ятимлектән котылып, җылы бакчалары җиләк-җимешкә күмелгән, мамыклы Үзбәкстанга китеп барды.

Ташкент юлы Шәленең Сабантуй аланы читендә генә икән ул!..

Әни йөрәген тотып, урын өстенә ауды...

«Никах укыттык, туй үткәрдек. Монда туйлар кызык икән: ирләр бер якта, хатыннар икенче якта аерым утыра. Урамда исереп йөрүчеләр күренми. Монда бала-чагадан да күбрәк нәрсә юк. Җимеш бакчабыз зур, Шават каналыннан су сибәбез...» – дигәнрәк бер хаты килгән иде. Шуннан хәбәре өзелде. Әни авылның Чишмә башы дигән «Матбугат үзәгеннән» чиләк-көянтәләп шомлы хәбәр ташый. Имеш, ул якта кыз ягына калым түләрлек булмаганнар гына читтән өйләнә икән... Имеш, анда хатыннарны бикләп тоталар икән... Өйләре – балчык, өстәлләре – идән икән...

Өч ай буе бүтән хат-хәбәре килмәгәч, әнинең «Апаң синең аркада гына харап булды» – дигән сүзенә тагын бер җөмлә өстәлде: «Бар да алып кайт апаңны, чиләнеп ятмасын анда, мин аны коллыкта яшәсен өчен үстермәдем!»

Караком чүленә барып җитәр өчен акча әмәлләргә кирәк әле башта. Колхозның әнигә түләрлек акчасы юк, тиз генә кала базарына илтеп килер идең, яңа бәрәңге дә өлгермәгән, ә искесе – бөрешкән...

Ул өч айда гына да мин инде өч эш алыштырдым.

Безнең миллионер колхозда терлек асты җыештыручылар, көтүчеләр, бозау караучылар, сыер савучылар һәрвакытта да кадер-хөрмәттә булды, елның теләсә кайсы фасылында кил – буш урын бар. Көрәк, сәнәк, чиләген дә колхоз бушлай бирә, чыбыркыны гына үзеңә ишәсе... Вә ләкин урта мәктәпне уңышлы гына тәмамлаган егет фермада сәнәк күтәреп йөрсә... ояты кемгә – әлбәттә, сине ун ел буе укыткан укытучыларыңа! Болай да инде Корыч малаеның башта университетка, аннары консерваториягә керә алмыйча кайтуына укытучыларның һәркайсы үзен гаепле саный. Кызыл бәйрәмнәрдә трибунага чыгып нотык сөйләгәндә, мәктәп директорының беренче сүзе нәкъ менә институтка укырга керә алган «карлыгачларны» санаудан башлана...

Минем ише «чәүкәләр» елдан-ел арта торып, «ЛАЗ» автобусы шыплап тулырлык җыелганбыз. Төяделәр дә алып киттеләр «16 нчы» завод дигәннәренә.

Эш көнебез бик кызык үтте, беренче көн булгангадыр инде... Колхозыбызның бөтен техникасы сыярлык биек түшәмле, тимер идәнле цехта тормыш гөрли. Тагын ике автобус төялеп килсәк тә, сыя идек әле. Шәһәр эшчеләре бик өнәми, ахрысы, бу цехны. Юкса эше дә әллә ни катлаулы түгел: мактанчык агайларның баш бармагы хәтлек чарны уч төбеңә кысып тотасың, аңа каеш эчәге сыман шланг тоташкан, тыгыз һаваны ачып җибәрүгә ул (аны никтер фортунка дип атыйлар иде) шундый зур тизлектә әйләнә ки, хәтта сызгыра башлый. Икенче кулыңда күгәрми торган корычтан коелган ит турагыч формасы. Вәт

эчен-тышын шомартасың шуның! Кытыршы урыннары калса, ОТК кире бора... Очкын очырабыз – бөтен цех көйгән тимер исе белән тулды. 1967 елга багышлап, сигез сәгать эчендә 67 ит турагыч шомарттым. Икенче көнне генә әйттеләр, план үтәр өчен бер сменага 300 кирәк икән.

Бер ай эшләгәч, тәки норманы тутыра башладык.

Шунысы җайлы: көн саен өйгә кайтып йөрибез. Клубта кичке уеннар башлануга өлгерәбез. Бер-берең белән күрешкәндә генә кыен: бармаклар язылмый, уч төбендә гел фортунка зыңлап торадыр кебек. Уң кул буйсынмый шикелле, бармак арасыннан кәгазь шуа да чыга, хезмәт хакы алган көнне акчаны да сул кул белән санадым.

Юлда барганда, берсендә арифметик мисал чишеп алдык: без, Шәле малайлары, смена саен 14 мең ит турагыч шомартабыз икән, шуны 24 эш көненә тапкырласаң... 336 мең килеп чыга... Бу бит, йөк рәвешенә китерсәң дә, 500 тонна тутыкмый торган корыч дигән сүз! Вәт турап та күрсәтә халык итне!

Һавадагы кыр казларын да санарга кушмыйлар.

Ике ай дигәндә, безнең «ЛАЗ»ны «Паз»ик алыштырды... Соңгысында, «ашыгыч ярдәм» машинасына охшаган «УАЗ»икка күчеп утырдык, сигез генә кеше калган идек, анысы да туктады. Эштән качмаган идек, юкса, безнең гаеп юк. Әллә тутыкмый торган корычларын җәлләделәр, әллә Казанның ите бетте шунда... Аңламадык.

Мәгәр минем кушаматны әйтүдән гайрәтләре чигеп, «корыч» сүзеннән гарык булган иде авылдашларым...

Киләсе елга тагын имтихан биреп карарга исәп. Студент булганчы ук Казанга китеп урнашуның фәтвасын күрмим. Әни әйтмешли, таш калада тамыр җәюләре җиңел түгелдер, минем ише прапискасызларга шәһәр кешесеннән калган урыннар гына эләгер. Андый гына эшләр авылыбызда да муеннан! Ялыныч белән килсәң, белешмә сорап, җаныңа тиючеләр юк, кем малае икәнеңне, ничек укыганыңны, нәрсәгә маһирлыгыңны бөтен «чишмә башы» белә.

Әнә, авылның өч кибетен тауар белән өзлексез тәэмин итеп торучы, кулланучылар җәмгыяте кеше эзли, ди... Килдем. Күрештем. Әйттем... Сельпо рәисе Булат абый шул көнне үк мине товароведка ияртеп, Казанга җибәрде. Иң мөһиме – ике машина да буш кайтырга тиеш түгел, кузовны чүмәкәйләп төясәң, тагын да әйбәт.

Казанны аркылы-торкылы гизеп, базадан – складка, подвалдан – причалга йөреп кайткач, өч кибет тә сүз китермәслек итеп өйдек, ни бар – шуның белән өстеннән каплап бәйләдек тә ташы кызган каладан чыгып сыздык. Безнең машина алдан китте, чөнки йөгебез авыр: өч мичкә көнбагыш мае, унике әрҗә маргарин, икешәр чиләкләп ябылган тугыз тартма повидло, өч йөз кило кер сабыны, ә өскә йөз илле кило туңдырылган балык... Саннарын, авырлыгын төгәл әйтәм, чөнки кулымдагы боерык кәгазен укып барам. Кайткач, Булат абыйга исән-имин тапшырасым бар. Балык әзрәк, кәнишне, ну авыл кибетләрендә зур суыткычлар юк, тиз бозыла торган әйберләр көннеке көнгә сатылып бетәргә тиеш икән...

Арттагы машинаның эше рәхәт – аларга гел тәм-том төялгән, йөкләре җиңел. Безне узып китмәс өчен йә куас эчәргә туктыйлардыр, йә юл читенә чыгып, «эскимо» дигән шоколадлы туңдырма ялыйлар булыр...

Питрәч белән Шәле арасын сигез чакрымлы наратлык каплап тора. Шушы урман юлыннан ярты гасыр буе дәүләткә икмәк ташыганнар, халык туктаусыз базарга йөргән, район Сабантуйларына килгән. Урыны-урыны белән ярты

гасырлык чокырлары да бар, таптала торгач комы тыгызлангандырмы, Ходайның рәхмәте, елның теләсә кайсы фасылында да юл өзеге булганы юк.

Монда җәяүлеләр дә туктап тормый. Иске урманда өлкәннәр холкы: наратлар пышылдап кына сөйләшә; биек ботакларда тыйнак тукраннар күк гөмбәзен шакый; тәҗрибәле былбыллары, үзенә генә хас лейтмотивны саклап, моңын суза; йокыдан исергән урман җилләре шул моңның кайтавазын җыя.

Мин, инде почти товаровед, тәрәзәсе төшерелгән ишектән терсәгемне чыгарып барам. Урманның чәерле һавасы кабина эчендәге бензин исен җиңгән. Беренче дигән төшенчәне өстәгәч, бик күп сүзләрнең мәгънәсе арта. Беренче эш көнемнән горурлану хисе күңел төпкелендә кыбырсып бара. Шушындый олы юлда нүжәли берәрсе очрамас, кулын каш өстенә куеп, мине җентекләмәс икән инде?!.

Безгә тизрәк кайтырга кушалармы, арттагы машина, куып җитеп, кычкыртырга кереште. Тизлекне арттыра башлагач, тагын да ныграк кычкырта болар! Ә урманны чыккач, юл киңәйгән җирдә, безне узып китеп, юлыбызга аркылы бастылар... Машиналары туктап өлгермәде, товаровед очып төште дә туп-туры минем өскә килә, әйтерсең лә рульдә – мин?!. Якамнан эләктереп алды да тезепме тезә:

»... дипме кабинада ыржаеп кайтасың? Синең урының кузовта иде... Бар җый... хәзер балыкларыңны... юл буе... Ярты ел эшләсәң дә... түләп бетерә алмассың...»

Һәм товаровед: авыз, ана, иман, ден, җан дигән сүзләрне, киләчәк заман фигыльләре белән төрләндереп, миңа каядыр олагырга кушты. Аның сүгенү тезмәсе секундына 340 метр тизлек белән кайтаваз булып яңгырады. Әле дә ярый, авыл ерак, кеше ишетмәде...

Сәгатьләр буе кояш астында кайта торгач, балыкларның бозы эрегән, кәгазь каплары җебегән, машинабыз чокырларны санап авыш-түеш барганда шуып коелганнар, бөтенесе дә түгел, әлбәттә...

Әтисез өйдә үскәч, гауга-талашка иммунитет бик юк минем, сүгенү сүзләреннән кисәк миңгерәдем бугай, буш кулларымны селкеп кире киттем. Монысына товаровedның гупчим ачуы чыкты, сүгенә-сүгенә карлыгып бетте...

Алар коелган кадәресен җыя-җыя кайтканнар икән, кычыткан капчык яртылаш тулган иде. Боерык кәгазе минем исемгә язылмагач, түлисе дә юк инде дә мәгәр, кайту белән сатуга куйганчы дип, комлы балыкларны коендырып алдык...

Иртәгә эшкә килмә, дип әйтүче булмады, ә мин килеп тә тормадым. Әни мине орышырга тиеш иде инде, мондый очракларда әтиле малайларга нык эләгә torгандыр. Ятим баланы картайганчы иркәлиләр шул. Әнинең сүзе бик кыска булды:

«Урыннан кузгалганда, җигүле ат та бераз көчәнеп ала инде, улым...», – диде дә алъяпкыч итәгенең күз яше сөртә торган төшен бөтәрли башлады...

«Апаң янына кайчан барырга уйлыйсың соң? Исән микән инде ул анда?»

«Якын ара түгел бит, әни, поезд белән дә өч көнлек юл... Бераз акча эшлим инде. Әнә, Белкино авылында ферма штукатурлыйсы бар, дип ишеттем, бригада җыялар.»

«Чиләк белән измә ташып, гарипләнерсең тагы. Авыл советына барып, Разыя апаң белән киңәшеп кайтыйм әле», – диде дә эш сәгатьләре беткәнче, дигәндәй, ашыгып чыгып та китте.

Әни ничек тиз чыгып киткән булса, шулай тиз әйләнеп тә кайтты. Разыя апа әтием ягыннан туган тиешле, ул анда зур кеше – авыл советы секретаре булып эшли, киңәш бирүне кыска тоткандыр.

«Улым, комсомол вожагы эшеннән качкан, ди, урыны бер атнадан бирле буш, ди, зарплатасы 60 сум, ди. Разыя апаң әйтә, улың ушлы, үсә-үсә партком секретаре булыр, ди. Колхоз председателе дә башта комсомол секретаре булып тотынган, ди. Әллә тәвәккәллисеңме, улым?»

«Юк! Алай түгел ул, әни!»

«Син кечкенәдән шулай кире булдың. Җавабыңны беләм: юк, алай түгел ул, дип башлыйсың!»

«Әйбәт эштән кеше кача, димени! Бик яхшы беләм мин колхоз комсомолларын! Ай саен өй борынча йөреп, взнос җыярга кирәк. 28 яшькә җиткәнче икешәр-өчәр бала табалар да өйләреннән чыкмыйлар, җыелышларга кул селтиләр, взнос сорап килсәң, капкаларын бикләп куялар. Ә райком планны үтәргә куша, бәйрәм алдыннан җыелышлар үткәрмәсәң, ярышлар оештырмасаң, бюрога чакыртып сүгәләр... Юк! Бармыйм.

Минем җаный көтүче...
Мин дә айга менәр идем,
Юк этеп җибәрүче!..»

«Ачу китереп такмак чыгарып утырма әле. Алайса, Апакайда бик зур тавык фермасы салалар, рабочийлар җитми, ди. Шунда бар!»

Бу юлысы: «Юк! Алай түгел ул!» – дип каршы төшмәдем.

***

Апакай – авылның борынгы бабайлар кушкан исеме. Мин VII класста укыганда, ул Ленино-Кокушкино составына кергән һәм алга таба, чын исеме халык телендә генә калды. Ленин музее аркасында Казан белән ике арага асфальт юл салынды. Һәм даими рәвештә автобус йөреп торды. Кала белән элемтә яхшыргач, балалары тәпи йөрергә өйрәнү белән авылдан чыгып качу ягын карыйлар иде. Шуңа күрә дә тавык фермасы төзелешенә эшчеләрне бөтен районнан җыйганнар, минем гөнаһларым шомлыгына, Пановка төрмәсеннән хатын-кызлар отрядын да китергәннәр иде.

Шәледән дүрт малай килдек. Дүртебезне дә бер әби өенә урнаштырдылар, ашату белән фатир хакын төзелеш түли. Нәкъ шәһәрдәгечә тәртип – атнага биш көн эшлибез, шимбә-якшәмбе ял итәбез. Эш дигәнебез көн саен багана төбе казу – кеше башына ике чокыр!

Киләчәктә монда бер миллион тавык асрарлык шәһәрчек булачак, диләр. Минем үз гомеремдә миллионга чаклы санап караганым булмады, кирәге чыкмады, ирендерә дә. Ишегалдыбыздагы ундүрт-унбиш тавыктан да гарык булган авыл малае өчен күз алдына китергесез сан инде ул! Апакай басуы мул тормыш өчен игълан ителгән очсыз-кырыйсыз сугыш кырына әверелгән, түбәләрне күтәреп торырга тиешле таш баганалары да миллионга җитәргә тиеш, күрәсең! Бу тирәдә экскаваторлар бик күренми. Кулдан казылган чокырларга бетон измәсе дә азрак китә, фундаментлары да геометрия дәреслегендәге фигуралар кебек төзек чыга икән.

Ике чокыр бер чират, дигәндәй, көнлек норма үтәлгәч, кичкә таба Апакай клубына чыгабыз, дигән уйдан икенче сулыш ачыла! Тизрәк фатирга кайткач, ашыгып ашыйсы, кабыл-тибел юынасы, чәчкә хушбуй сибәсе дә урамга ыргыласы.

Безнең авылныкылар җырга һәвәс, ә Апакай кызлары биергә оста.

Район мәктәпләре арасында үзешчәннәр смотры үткәрелә иде. Бию буенча беренчелекне апакайлылар яулый торды. Барыбыз да алдан ук белеп, көтәбез шуларны – украин халык биюе ул. Такыяларына атлас тасмалар элеп, дүрт кыз чыга: өчесе чәчәкле «дугага» җигелгән, ә берсенең кулында ак дилбегә. Сәхнә түрендә тик йөгереп йөриләр... Ел саен бер нәрсә инде, биючеләрен дә таныйбыз, көен дә беләбез, кушылып «лә-лә-лә» дип утырабыз. Кайсы гына авылдан, нинди генә сәләтлеләр мактанмасын, барыбер Апакай мәктәбе – җиңүче! Авылыңда Ленин музее булгач, шулай инде ул, аны гына аңламыйбыз түгел, комсомоллар ич без...

Җәйге каникулда Шәлегә Апакайның берәр кызы кунакка килсә, клуб ишеге төбендә мотоцикллар күбәя. Клуб ябылганчы, домино суга торган җилкенчәкләр, баян тавышын ишетүгә вальс биер өчен Апакай кызына чиратка басалар иде.

Мотоциклы егетләрнең берсе, укытучы Семён абый малае, Ленино-Кокушкинода тавык фермасы салырга дигән исемлеккә иң алдан барып язылган. Дөрес, әтисе мотоциклын бирмәгән, егет безнең белән килә, безгә ияреп кайта, фатирга да бергә урнаштык. Ул инде биюче кызларның исемнәрен белешкән, урамга чыккач та, безне кисәтеп куйды.

«Халидәгә борын сызгыртсагыз – минә!» – диде, йодрыгын Апакай егетләренә күрсәткәндәй канатланып.

«Беләбез инде кем икәнеңне, дуңгыз ите ашап үскәч, йодрык шәп синең. Халидәң үзеңә булсын. Көчеңне сакла, чибәр күренә, егете күптер, җиңел генә алалмассың» – дип, урамдагы бәхәсне туктаттым.

...Килеп керсәк, бер клуб кунак кыз гүя!.. Берсеннән-берсе чибәр... Күзне тыеп булмый, кемгә генә карасаң да, яңа йөз, яңа буй-сын, яңа исем... Әйтерсең лә, мәктәп тактасына акбур белән язылган иске формулаларны, үрнәк җөмләләрне, өйгә бирелгән эшләрне, кагыйдәләрне сөртеп аттылар да аның урынына моңарчы белмәгән, өйрәнмәгән, әмма иң кирәкле яңаларын язып куйдылар... Мин яңадан туып, кинәт кенә үсеп киттем һәм яшьлегем башланды кебек: монда салам түбәң дә калайлы, институтка керә алмагансың икән, дип үртәүчеләр дә юк; муенымдагы җөйне онытып, башны югары тоттым. Пионер яшеннән башлап, шушы көнгә чаклы хат алышкан кызларымның адресларын югалттым, исемнәрен оныттым, куш бит тутырып язган шигъри мәхәббәтнамәләремнән ваз кичтем... Аның хакына! Өч иҗекле исем бигрәк матур яңгырый! Зә-ри-я! Иң мөһиме, бу исемнең малай исеме белән төрләнеше юк. Юкса хәзер Сәлим – Сәлимә, Фәрит – Фәридә, Рәшит – Рәшидәләр күбәйде.

Беренче көннәрдә миннән качып йөрде. Озата кайтам дип чыксам, күздән югала; клуб ишеге төбендә сагалап торсам, Апакай малайларына тагылып, кинобудкага кереп кача... Зәриягә кызыгып йөргәнемне бөтен кеше белә хәзер, башка кызлары сәлам дә бирмиләр. Миңа бер генә юл кала: йә чибәркәйне үземә каратырга, йә тавык фермасын төзелмәгән килеш калдырып чыгып качарга! Семён абый малаеның киңәше ярап куйды: «Син аны капка төпләрендә сагалап тор», – диде.

Торам инде... капка баганасына сыенып... Үч иткәндәй, гармунчылары да алҗый белмәде бүген. Ниһаять, туктады дигәч кенә, патефон тәлинкәсен әйләндерергә тотындылар... Әллә минем зарыгып көткәнемне белеп, Семён малае юри оештырамы моны? Нинди бетмәс-төкәнмәс, озын-озак төн соң бу?!

Ниһаять, клуб сүнде... Үшнә елгасының тузгыган ярын яулаган бакалар бакылдавы гына төнге тынлыкка хуҗа булып калды. Нишләргә хәзер? Капкаларына аркылы басып сөйләшеп торырга үгетләргәме? Әллә өй түренә

килеп җиткәнче үк кулыннан эләктереп, читкә сөйрәргәме? Берәр бәйләнчеге озата кайтып маташса, төртеп егаргамы? Шушы яшенә тиклем Корыч малае килер әле дип, үзенекен көтеп утырганмы? Фаразларым челпәрәмә килде... Мин үз сорауларыма җавап эзләгән арада, әллә кайдан гына Зәрия пәйда булды. Ашыкмады, күрмәмешкә сабышып кыланмады, качмады, ә туп-туры яныма килеп басты! «Гафу ит, биш кенә минутка, озак тотмам», – дигәнрәк алдан ук әзерләп куйган төче сүзләрнең кирәге калмады.

«Куркытмадыммы, Зәрия?»

«Өй түренә кайтып җиткәч, кем курка, ди инде...»

«Минем урында башкалар булса?»

«Безнекеләр алай сюрприз ясап тормыйлар. Аннан соң, мин бит синең көтеп торганыңны сизендем.»

«Каян? Семён малае әйттеме?»

«Беркем дә әйтмәде. Үзем белдем. Атна буе мине сагалап йөрдең дә и вдруг – югалдың. Ә иптәшләрең клубта... Аңладым инде.»

«Ә мин сине хәтерлим. Украин биюендә дилбегә тотучы идең.»

«Үзең соң баштарак «Казакъ кызы сөйгәнем»не җырлый идең. Аннары «Әниемә хат»ка күчтең.»

«Зәрия, без бит күптәнге танышлар икәнбез. Әйдә урам әйләнәбез!»

«Иртәгә эшкә түгелме соң сезгә? Миңа карама – йокым туйгач кына уянам.»

«Алайса, каникулда!»

»... дисәң дә була. Сәүдә техникумына кердем. Укулар башланганчы йокы симертәм.»

Күңелем сизә, хәзер ул минем укырга керү-кермәвем хакында сорашачак. Авыз ачарга ирек бирмәдем, култыклап алып, капка төбеннән китәргә әйдәдем. Шөкер, каршы килмәде, ләкин, сул ягыма күчеп, үзе култыклап алды.

«Зәрия, сезнең өйгә район гәҗите киләме? Бәлки минем шигырьләрне дә укыганың бардыр?»

«Килүен килә. Тик мин шигырьләр яратмыйм шул.»

«Яратмыйм?! Яшьлек үзе – поэзия бит инде ул!»

«Аңламыйм мин аны. Миңа калса, шагыйрьләр ул шигырьләрне үзләре өчен генә язалардыр кебек. Шагыйрьне аңлар өчен шагыйрь булу кирәктер.»

«Синеңчә, Зәрия, җырчылар да үзләре өчен генә җырлыймы?»

«Әйбәт көйгә шигырьнең кирәге юк. Моң сүзсез дә яши ала. Һәр җыр – кешенең берәр авырткан җиренә тия, ә моң – онытылган сагыш-хәсрәтне яңартып тора...»

«Зәрия, синең әти-әниең укытучылармы әллә?»

«Юк, әнием – сатучы. Әтиемне кечкенәдән белмим, кайдадыр, кем булып эшлидер, әйтә алмыйм. Ә син үзең кем булырга хыялланасың соң?»

«Аптырашта калдым әле. Шагыйрь булырга иде дә исәп, инде... хикәя язуга күчәрмен, ахрысы... Әллә ни куандырган эшем юк әле. Ике чокыр казыйм да синең янга йөгерәм, ике чокыр казыйм да тагын... Шулай үземә биография ясап йөрим.»

«Шигырьләр язгач, сөйгән кызларың күптер...»

«Мин әле гел сөелмәгән килеш.»

«Әни әйтә, төн уртасында егетләрнең теле ачылыр, кызларның колагы томаланыр, ди.»

«Мине дә әни, уен беткәч, уенчыкларыңны урынына куй, дип өйрәтте. Әйдә, Зәрия, өеңә озатып куям.»

«Тыныч йокы!» – диде дә минем саубуллашканымны да көтмичә, кисәк китеп барды. Асфальт юлда туфли үкчәсе йөрәк тибешемне үртәде: «Тып-тып, тып-тып» һәм «тыптыптыптып!» итеп капкадан кереп китте.

Тыныч йокы, имеш. Зәрияне күргәннән бирле тыныч йокының төшемә дә кергәне юк! Август азагы җитүгә, төзелешне төзелгәненчә калдырам да Зәрия белән култыклашып, Казанга китәм. Җәяүләп! Бөтенләйгә! Сәүдә техникумы тирәсендә эшкә урнашам. Көне-төне эшлим! Фатир алам... Ә июль җитте исә институтка имтихан тапшырам... Ел саен! Кирәксә, биш – җиде – ун ел рәттән! Укырга кергәнче туктамыйм... Вакыт җитәрлек, XX гасырның әле ир уртасы чагы гына.

Ә иртәгә...

Иртәгә тагын ике чокыр – бер күрешү...

Кояш сәгате кичкә авышкач, әллә кайдан гына куәт өстәлә, энергиям ташып чыга, көрәк тирәнгәрәк керә, әрлән балчык чокыр төбеннән кантарлап оча. Тизрәк норманы үтәп, фатирга башкалардан алданрак кайтып, сай лэгәндә «Бодрость» шампуне белән чәчне юып, күлмәкне алыштырып, күн чабатаны вәзилинләп, Үшнә ярына ашыгасы килә...

Калынрак каердым бугай, көрәк сабы шартлап сынды. Вакыт әрәм итмим, балта осталары янына йөгерәм. Шушындый да зур төзелештә сыну-сындыру гадәти хәл, күрәсең, сүзсез генә алдылар да сап эзләргә дип, калайдан корылган сарайга кереп югалдылар. Баскан урынымда ашкынып көтәм. Шулвакыт колак артымда ниндидер хатын-кызның пышылдавын ишетәм:

«Син түгелме бу, Корыч?!»

Борылып карасам, күрше Фатыйма әбинең кызы Хаҗәр апа басып тора, йөзендә сагыш белән елмаю бергә кушылган. Беләм, Пановкада утыра иде, төрмәдән качканмы әллә? Йөрәгем «жу-у!» итеп куйды, ә ул мине сөенергә тиеш, дип уйлагандыр инде.

«Курыкма. Без монда эшлибез. – Хаҗәр апаның гәҗит бөгәрләвенә охшаган тавышына сыек кына моң кушылды. – Тәртипле тоткыннарга вольное поселениедә эшләргә рөхсәт бар. Әни нихәл анда? Только миңа карап сөйләшмә, читкәрәк борыл. Әнә, вагон почмагына таянып күнитек ялтыратып торган адәм актыгын күрәсеңме? Безнең конвоир инде ул. Ишетә күрмәсен. Гражданскийлар белән аралашу тыела безгә. Ну, әни нихәл, дим?»

«Аллага шөкер. Бәбиләргә исем куша, мәет ашларына йөри...»

«Йөрсен. Сәдаканы күбрәк җыйсын. Авылга кайчан кайтасың?»

«Иртәгә инде, хозяйканың борчак чумарыннан туйдым. Әни пешергән өчпочмакларны сагындым!»

«Корыч тәре! Ачу китереп торма әле! Әнигә әйт, синең аркылы посылка җибәрсен.»

«Кирәк әйберләрнең исемлеген язып бир.»

«Нинди исемлек?!. Чәй кирәк, күбрәк итеп, конфет салсын, исле сабыным да бетте... Бераз сәдакасын да җибәрсен теш порошогына батырып кына...»

«Ярар, әйтермен. Кайткач та, туп-туры Фатыйма әбигә керермен.»

«Почтага җибәргән кебек итеп, адресларын язып тутырмагыз тагын посылканы. Түгәрәкләп тә төрмәгез – шешә, дип уйларлар. Чүпрәк сетка төбенә генә салсын. Хәзер син кузгалма, башта мин югалам... Ә син, Корыч, чистый мужик булып үсеп җиткәнсең, тавышың да калынайган. Сәгать төзәтерлегең бар хәзер...»

Читкә борылып басып калсам да, Хаҗәр апаның «сәгать...» сүзен әйткәндә кинаяле елмаюын күз алдыма китерәм.

Төзәтү дигәннән...

Галанка мич белән тәрәзәсез стена аралыгындагы агач карават турысына эленгән ул сәгать, ялгышмасам, Фатыйма әбинең яшьлегеннән бирле йөри бугай инде. Такта йөзе өй кыегына охшаган, саннары Рим тамгасы белән. Якягы ачык булгач, сырлы тәгәрмәчләре күренеп тора. Әгәр син аның чылбырын кичтән күтәреп куярга иренсәң, чуен гере караватка башына терәлә дә, тузан йоккан бакыр телен салындырып, үчекләгән кыяфәттә туктап кала.

Ул сәгать никтер гел иртәнге якта туктый иде: Фатыйма әби саваплы ашка киткәч, әни чишмәдә чакта, Армиягә китәргә повестка алган Габдрахман абый уянгачрак...

Һәм Габдрахман абый Фатыйма әби белән әни әйләнеп кайтканчы, сәгатьне төзәтеп чыга иде.

Ә беркөнне иртән Габдрахман абыйның яшьтәшләре безнең капка төбенә җыелдылар, гармунчы Исламгали машинадан егылып төшкәнче җырлап, урам әйләнделәр. Һәм Питрәч военкоматыннан кире әйләнеп кайтмадылар. Вьетнам сугышының кызган чагы иде әле ул...

Хаҗәр апа йоклап калган, сулышының иннек исе югалган, ул әле Габдрахман абыйның Армиягә киткәнен ишетмәгән дә.

«Абыеңа әйт, сәгать тагын ватылган, тизрәк керсен!» – диде дә, әнинең сулы көянтәсенә бәрелүдән оялыпмы, ашыгып чыгып китте.

Авыл җире дигәч тә, бездә дә бөтен нәрсә сәгатьләп бүленгән. Хаҗәр апа, Габдрахман абыйның киткәнен белмичә, тукталган вакытка карап ята микән? Минем иске радиолар, ватык будильниклар сүткәнем бар анысы...

Керсәм, Фатыйма әби өйдә юк. Хаҗәр апа эчке күлмәктән генә, агач караватка сузылып яткан, өстенә дә ябынмаган үзе, галанканың җылысы тиз бетә, өйләре дә салкынча. Ул мине күрү белән сикереп торды да каршыма килеп басты.

«Бар, чыгып кит тизрәк! Абыең кирәк хәзер!» – диде ул, мине тирән сулышы белән өреп чыгарырга теләгәндәй. Аннан өч көн буе түгелмәгән такта чәй исе килә иде.

«Абый Армиягә китте бит!»

Ул кинәт сүтелгән чәч толымы белән күзен уа башлады.

«Ник саубуллашмыйча китте соң ул?»

«Бөтенебез белән дә саубуллашты!»

«Ә минем белән?»

«Борчылма, Хаҗәр апай, сәгатеңне үзем төзәтеп карыйм...»

«Сиңа тагы, сәгать төзәтү, салагы!»

Мин караватка сикереп мендем дә сәгатькә үрелдем. Герен күтәргәндә кыегайган гына бит ул, йөреп тә китте. Хаҗәр апа сөенмәде. Шулай да аркамнан сөеп, рәхмәт әйтә башлаган иде, чыгып качтым. Мин инде 8нче классның беренче чирeген бетереп киләм, аркамнан сөйдереп, башымнан сыйпаттыра торган яшьтән узган идем...

Менә шушы апа ирегеннән мәхрүм ителгән дә, хәзер инде авылдагы әнисе янына да кайта алмый, атналык интернатка тапшырылган ике улын да күрергә мәхрүм диген, ә?!. Минем аңа ничек тә ярдәм итәсем килде, төзелештән соң көн саен кайтып, Фатыйма әбинең посылкасын ташырга әзер идем.

Өч тапкыр алып килдем, бернинди дә авырлыгын күрмим, Хаҗәр апа

күчтәнәчкә күбрәк чәй соратты, прәннек-конфетлардан бик тиз туйды. Конвоир да үшән булды, ахрысы, ул-бу сиздергәне юк, дигән идем, көтмәгәндә генә, төзелеш мастеры Шәйхулла Галимуллович көрәк сабыма килеп ябышты, үзе як-ягына карана. Минем тирәдә бөтен кеше дә пышылдап сөйләшә бугай.

«Энекәш, – диде ул, колагыма әйтәсе сүзне күземә бәреп, – хат ташучы булып киттең, син бит закон бозасың, ә закон бозучыларны ни көткәнен, әнә, күрәсең...»

«Юк, алай түгел ул!..» дип каршы дәштерә торган кирелегем әллә кая гына юкка чыкты, башны аска идем. Хезмәт дәресендә игәү сындырган малай шикелле басып торам. Шулчак, «укытучым» Шәйхулла Галимуллович иңбашыма орынып алды да мәнсезләргә юнәлеш бирә торган имән бармагын күккә төбәде. Мин аны: «Ходай барысын да күрә!» – дип әйтергә тели дип уйлаган идем, бактың исә, баш очыбызда ике болыт эленеп тора. Җентекләбрәк карасаң, тик тормыйлар икән үзләре. Чалт аяз күк йөзендә җиңел болыт, су белән мөлдерәмә тулган зуррагын куа килә. Куып та тотты, игәүгә-игәү суккандай очкын ялтырап алды, мичкәләр дөбердәште, суы гына түгелмәде. Ике болыт бер булып китеп тә бардылар...

Кушылуның әллә нинди ысуллары бар, анысы яңалык түгел, ә күк капусы дигән чиксезлектә ике болытның сыеша алмыйча бәрелешүе генә сәер...

Әлеге болытлар яңгыр хәбәрчесе икән. Пановка төрмәсе ягыннан җиһанның иң кара болыты килеп чыкты. Аңа Җир шарының бөтен болытлары ияргән һәм ул, бозлык чоры афәтен сурәтләп, офыкны яулаган да безнең өскә шуыша... Әлегә мичкәләре дөбердәми, корыч игәүләре генә көн яктысын җиңеп, туктаусыз яшьни. Озата барган давылы да күзгә күренерлек тузанлы.

Шәйхулла Галимулловичның йөзенә болыт шәүләсе төште.

– Тәк! Хәтәр яңгыр килә! Эш коралларын тизрәк тапшырып, бу тирәдән ашыгырга кирәк!

Кисәтеп өлгерәсе кешеләре бихисап иде әле аның.

Без – Җир малайлары, бөтен ризыгыбыз җирдә үсә: кырда, болында, түтәлдә, дигәндәй, аяк астына карап кына йөрибез. Авыл өстеннән самолёт очып үтсә дә, исебез китми. Вәт гарасат бүген һавада! Ярты сәгать эчендә җир өстен оныттык, күккә карап өйрәнмәгәч, муен алҗый, мәгәр үрә катып, фатирга йөгерәбез. Капкадан кергәнче үк боз ява башлады, аннан салкын душ китте, төнгә таба гына суы җылынды. Бөтен тәрәзәдән яшен яктысы керә, күк күкрәүләренә дә күнегеп барабыз, тик шарлавыктай койган яңгырдан гына курку басылмый.

Көтмәгәндә, Семён малае: «Клубка чыгу юк бүген!» – димәсенме!.. Яшенле яңгырда кычкырып көләргә кушмыйлар, ә монда ничек түзәрсең?!. Җыйнаулашып көлгәч, курку өрки икән ул. «Үз авылыбызның клубы да агач, җитмәсә инеш буенда ук...» – дигәнием, көлүдән шып туктадык.

Төзелеш – үзле эш, яңгыр яуганда, өйдә яттык. Кояш чykканда, өйлә вакыты иде инде. Чокырларыбыз яңгыр белән мөлдерәмә тулган, җир авызына капкан килеш йоталмыйча интегә. Соң булса да, ярый ла эшкә чыкканбыз, кассирша килде. Фамилияләребезне кычкырып, акча өләшә. Ярыш алдыннан «старт»ка баскан чабышчы кебек исемеңне көтәсең. Ә анда акча саный-саный сөял чыккан симез бармаклар өр-яңа «пачканың» буй-буй сызыклы билбавын ертып, пышылдап кына арифметик мисал чишә: бишне уналтыга тапкырлагач, буладыр... Аһ, ул акчаларның хуш исе! Мин инде кәгазь күрмәгән кеше түгел, чиле-пешле шигырьләремә үч итеп күпме ерттым, гөлбакчалы авыллардан

килгән йөзләрчә кызлар хаты ачтым, ләкин яңа акча исен кабатларлык бүтән сөенечле исне тойганым юк! Бу акчаларны әллә кайчан ук эшләп була иде бит инде, ну, шушы мәктәптә үткән әрәм еллар, дигән шайтан коткысы зиһенемне үртәп алды.

Авылда иң беренче булып, механизаторлар акча ала иде. Колхоз кассасына тезелгән ирләр чираты янә кибеттә кабатлана иде. Мондый көнне сатучы өчен «ике кәҗә – бер чират»... Сәгадәт апа әүвәл кара тышлы «гамәл дәфтәре»ннән әҗәтләрен тикшереп чыга. Өйдәгеләре өчен бер кило конфет белән кара җимеш компоты чутлый. Аннары гына ярты литрлыны буш шешәгә бүлеп тигезли. Һәм ике «механизатор» чираттан чыга, ләвкә читендә генә бушата да кул сырты белән авызын сөртеп ала, шуннан соң кәнфит кәгазен сүтәргә керешә, ашыкмый, тамак төбендә калган «арыш мае»ның ашказанына төшеп беткәнен көтә... Менә шушы була инде колхоз механизаторының иң бәхетле көне!

Төзелеш мәйданы кипкәнче, дип, безне дә кайтарып җибәрделәр. Калган көннең сәгатен дә әрәм итмичә авылга ашыктык. Юл уңае, Питрәч гастрономына кереп, күчтәнәч җыйдык. Көчле яңгырдан соң машиналар гараждан чыкмый, көтеп торасы да юк. Балакларны сызганып, ялан тәпиләп, лимонад йота-йота, урманны чыкканчы җырлап кайттык... Ул көнне без барыбыз да тигез идек...

Башка көннәрдә әни мине сөенеченнән елап каршы ала иде. Бу юлысы никтер сөенмәде. Елавын елаган үзе, анысы сизелеп тора. Сәбәбен дә шундук әйтеп салды.

«Почтага барып, Үзбәкстан белән сөйләшергә язылганыем. Ике сутки көтәргә туры килде әле.»

«Сөйләшә алдыңмы? Апа ни хәл анда?»

«Ниткән сөйләшү, ди ул! Өч минут буе «Әни, әни, әни!», «Кызым, кызым, алю, өф-өф, алю!» дип утырдык. Ни ул, ни мин бүтәнне ишетмәдем. Әйтәм бит, бикләп тоталар аны! Юкса сөйләшерие...»

«Алайса, яңадан переговорга бирик. Ун минут итик, әйдә?!»

«Җук, җук! Акча да әрәм итмә, көне дә кадерле. Бар да алып кайт апаңны! Кол булып ятмасын анда. Хатлар яза-яза үзең биреп җибәрдең, инде үзең апкайт. Сау гына булсын, туган җирдә чыпчык үлмәс...»

«Ярар, алайса иртәгә Ташкент поездына билет алам.»

«Нинди поезд, ди ул?! Поезд барып җиткәнче, апаңа берәр хәл булса... Аллам сакласын! Самолёт белән кит!»

Безнең СССРда шәһәргә урнашкан, йә булмаса колхозны ташлап качкан кешеләр генә паспорт артыннан йөри. Күпчелек халык, паспортсыз-нисез, метрикә дигән яшь язуы белән яшәп һәм эшләп ята. Ерак юлга чыгар алдыннан мин дә бер кесәмә комсомол билеты, икенчесенә акча белән «приписное свидетельство»[1]ны кулъяулыкка төреп салдым. Болак елгасы буендагы «Аэропорт» кассасында боларын да тикшереп тормадылар, фамилиямне сорап, ничек ишетсәләр, шулай язып, заём кәгазе кебек бизәкле билет тоттырдылар.

Ә китәсе көнне күрше-тирә, дус-иш белән саубуллашып йөргәнемне хәтерләмим. Әни генә инде апам хәсрәтен оныткандай, минем өчен борчыла башлады. Егерме беренче елгы ачлыкка озата диярсең, өч тәлинкә умач ашарга куша. Ул көне-төне колхоз эшендә йөргәч, намазга утыруны ниятли алмый, шулай да яшен яшьнәгәндә, абыемнан солдат хаты алганда, йә ризык тирәсендә йөргәндә, күңелендәге догаларын бик аңлаешлы итеп бөртекле һәм

[1]Приписное свидетельство – яше 16га җиткән егетләр өчен хәрби таныклык.

укынган саен: «И Ходаем, икенче баламнан да мәхрүм итмә инде берүк!..» – дип, ялварып куя.

Шәле авылына очрашуга килгәч, шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең бер шигырь укыганын хәтерлим:

«Килеп керсәм Аннага,
Башын тыккан ваннага!
Яшәп була ваннасыз,
Яшәп булмый Аннасыз!..»

Анна исемле берәр Герой-Ана булды микән соң, дүрт моторлы «АН-10» самолётын никтер «Аннушка» дип үртиләр иде. Аэродром Питрәч ягына терәлеп торгач, без инде күп кенә очкычларны күреп беләбез. «Аннушка»ны шуннан таныйбыз – ул йөкле кит балыгын күтәреп киткән сәмруг кошы турындагы әкиятне хәтерләтә.

Ташкент юлы безнең авыл өстенә салынган икән. Калай әтәчле түбәдән ары биеклеккә менмәгән гавам миңа кул болгап калгандыр инде! Урыным, шөкер, тәрәзә янына туры килде. Шуңа Җир белән Күк аермасын чагыштырып барам, ябырылып. Түгәрәк тәрәзәдә түгәрәк күк йөзе. Кичәге яңгырлардан җиңеләйгән болытларга өстән карасаң, кар өемнәренә охшаган икән, монда инде кояшны бернәрсә дә каплый алмый. Шунысы гына бар, без очкан арада ике сәгатькә иртәрәк караңгы төште, вакыт аермасы дип аңлаттылар. «Аннушка» алпамша гәүдәле булса да, бик җитез икән, стюардесса кызый: »...сәгатенә 600 чакрым юл үтә», дигәч, мин бу тизлекне Семён малаеның мотоциклы белән дә, «Җитмеш» Мөхәммәт абыйның машинасы белән дә чагыштырып, күз алдыма китереп карыйм – коточкыч! Шунысы гына сәер: күктә дә самолётлар сыярлык чокырлар бар икән, мәтәләбез, дигәндә генә, гүя безне ниндидер илаһи көчләр тотып ала да йомшак кына күтәреп, җәһәннәм чокырыннан чыгара... Тавык фермасына казылган чокырларыбыз кипшенгәндер. Кич тә җитте, Апакай кызлары клуб тирәсендә чыркылдашадыр. Зәрияне кем генә озата кайтыр икән инде бүген?!.

География дәресендә без йөзләгән шәһәр исемен ятлаганбыздыр, әнә шуларның берсе – җем-җем утка төренеп ята. Үзбәк лётчиклары, Ташкентның бөтен матурлыгы белән мактанырга теләгәндәй, шәһәр өстеннән ике кат урадылар...

Пассажир дигәнең сәер халык, юлның теге ягына төшсә дә, бу ягына кайтса да, ике кулына йә чемодан, йә бүксәле сумка эленгән булыр! Менә ичмасам мин, ике кулымны кесәмә тыгып, калай баскычтан төштем, аякта – күн чабата, өстә ачык изүле йон свитер – анысын да әни мәҗбүр итеп кидерде, җылы сөяк сындырмас, тирләсәң, майкадан йөрерсең, диде. Чынлап та, Ташкент җылысына ышанып, кыска җиңле ефәк күлмәктән калган апалар минем свитерга кызыгып карап тордылар.

Җиргә төшү белән очып кына «белешмәләр тәрәзәсен» эзләп таптым. Җемелдәп торган кара күзле кызга соравым кыска: «Шават районына ничек барып була?» Баштарак татарча сорашкан идем, төшенмим, дип җавап бирделәр. Ну, мин инде русча хатлар язмаган кеше түгел, кабатлап сорадым һәм ике төрле җавап алдым. Поезд белән китсәң, Ташкенттан тәүлеккә якын барасы, ди, ә һавадан ике сәгатьлек юл икән. Тик бүген инде соң, иртәгәгә чаклы бер чара да юк, аэропортта төн уздырырга туры киләчәк.

Белешмәләр тәрәзәсендәге кызның белмәгәне юктыр да, шикләнмим, ә түрдә кино пәрдәсе чаклы карта күргәч, алдагы сәяхәтнең очын-кырыен күрергә теләдем. Апам барып адашкан Шават бистәсе Караком чүленең иң түрендә, Хива каласы янында ук икән. Күңелемә килгән беренче шик – чүлдә шакаллар күптер инде... Икенче шигем шул булды: юлчылар залында капчыксыман биштәрләрен аяк очына куеп йокымсыраган агайларның барысы да кызгылт-яшел-коңгырт сызыклы, буй-буй чапан кигән, башларында ак җеп белән чигелгән кара кәләпүш. Ә бит җизни буласы кеше Шәле укытучылары кебек кәчтүм-чалбар кигән, ә үзе яланбаш иде...

Ике кәҗә – бер чират...

Уналты сәгатенә дә, ике сәгатькә дә бер көн уза дигән сүз. Поезд белән барам – билеты арзанрак. Минем «ипиле Ташкенттан» кул сәгате алам дигән хыялым да бар, кайткач, Семён малаена үзбәк җизнинең кияү бүләге, дип мактанырмын. Бинаның икенче катында урын юк – балалы хатыннар кунакханә иткәннәр... Почмакта авыл кибетендәгечә ләвкә тора, таш стенага буяулы зур хәрефләр белән «Чай» дип язып куйганнар, ләвкә артында ак кәчтүм сыман кыска халат кигән табак битле үзбәк, арып кайткан ат сыман, аягүрә йокымсырый, миңа карый кебек, күрми генә үзе. Ә мин күрәм: ләвкәдәге коштабакларда ит белән төрелгән юка камырлы сумсалар, кетердәвек ләвәш кисәкләре ымсындырып тора.

Ятыр корсак ятыр, ике сумсаны тартыр.

«Ике стакан чәй!» – дидем мин, кунакларча горурлык белән.

Кыска халат фарфор чәйнекне миңа таба этте дә өстәлдәге тәгамнәргә ишарәләде.

«Юк-юк, бүтән бернәрсә кирәкми! Чәй генә! Минем бик тә эчәсем килә...»

Кыска халат чәйнекне кире тартып алды.

«Су урамда!» диде дә тагын аягүрә күзен йомды.

Самолётларның да черем иткән чагымы – аэропорт тирәсендәге бакчада бар табигать саташмыйча гына йокымсырый, самавыр борыныннан касәгә аккан су тавышыдай чәпердәү дә ишетелә хәтта... Әлеге уенчык фонтан мосафирханәнең бердәнбер бушлай чишмәсе иде. Туйганчы эчтем!

Ятыр корсак ятыр, озакламый таң атыр...

Ике кулымны кесәмә тыктым да буш эскәмияләрнең берсенә барып аудым. Бу көннең соңгы мазасы мин идем бугай, дөнья тынды. Ташкент күге белән күзгә-күз карашып ятабыз... Чиста, куе, әкәмәт шәмәхә гөмбәзгә көмеш йолдызларны ябыштырып куйганнар...

Безнең якта һава болай ук игътибарны җәлеп итәрлек түгел, гөмбәзнең шәмәхәсе су кушып сыегайтылган кебегрәк, йолдызларын да йон бияләй белән шомартасы бар... Хәер, һәр авылда үзенчәрәктер, бәлкем... Шәледә, ике кулын баш астына салып, күккә карап ятучыларны бик өнәп бетермиләр үзе... Августның җимешле һавасы уйларны куерта...

Иртәгә үзбәк җизни мин килгән хөрмәткә казан асып, бөтен кышлакка җитәрлек пылау пешерер. Агач кашыкны чүмәкәйләп өеп, авызны пешермәсенгә өф-өф итеп...

Мин бик кыбырсык кеше: йөреп-йөреп уйланам; кабыл-тибел ашыйм; ашыгып сөйләшәм; дәресләрдә җавап биргәндә, бер аяктан икенче аякка авышып, алпан-тилпән киләм; йоклаганда, мендәрне бәреп төшереп, җәймәгә уралып бетәм, бер караватка ятам, икенчесендә уянам, йокы аралаш торып, урамга чыгарга маташкан төннәрем дә булгалаган, ярый әле, әни сизгер!..

Уянып китсәм, ике кулым баш астында... «Әни өйдәме?» – дигән уй шундук юкка чыкты, чөнки авылым да юк, әни дә юк, акчам да юк... Дөрес, бер кесәмдә комсомол билетым исән – «взнослар түләнде» дигән штамп сугылган бит арасында Хрущёв бабай яңарткан 1 сумлык кысылып калган... Бу акчага бер кило шикәр, йә биш «морожный» тия; теләсәң, биш тапкыр рәттән зурлар киносы карап чыгарга җитә...

Кемнең йокысы кайчан туядыр, мин үзем ашыйсым килгәннән уянам... Их, ма! Юлга чыгар алдыннан әни кыстаганда, шулпаның өченче тәлинкәсен дә бушатасы калган!.. Умач хыялыннан тамак туйгандай булды, уенчык фонтанга килеп, әүвәл су эчтем, аннан бармак очын чылатып кына күзне юдым. Сул кулны кесәдән чыгарды юк – ул минем бер тәңкәлек комсомол билетын саклый.

Фонтан тирәли үземчә план корып йөрим. Уйлар бик кыска, ни турында гына хыяллансам да, азагы цирк билеты чаклы гына бер сумга килеп төртелә.

Иртәнге сәгатькә сүз куешкандай, әле анда, әле тегендә бер-беренә кушылып, үзбәк көе уянды. Миңа әллә каян гына көч өстәлде. Аэропорт бинасына тәртип саклар өчен куелган милиционерны эзләп таптым да югалган акчаларымны даулыйм.

Мин татарча, ул үзенчә гәпләшәбез. Тик ул төшенми, мин аныкын аңлап бетермим. Шуннан соң үзбәк җизнигә хат язган ише кыска җөмләләр белән генә русчага күчтем. Ул минем белән сөйләшкән арада әле мыегын, әле күзенә кереп торган калын кашларын сыйпап ала. Чырае өч мыеклы кебек...

«Төнлә акчамны урладылар.»

«Син кем? Каян килдең?»

«Казаннан».

«Армиядән качып йөрисеңме?»

«Юк. Армиягә иртә, миңа унҗиде тулды гына әле. Апам, мескен, үзбәккә кияүгә чыкты. Караком чүленә. Шуны эзләп барам.

«Бар! Ургенчка чаклы самолёт оча или поезд белән.»

«Акчамны урладылар, дим ич! Сез монда үзегезнең һәр кесә карагын таныйсыз. Тотыгыз үзен.»

«Караклар безгә самолёт белән килә. Җирле халык урлашуга бармый.»

«Мин кая барыйм соң хәзер? Берәр поездга утыртып җибәрегез алайса...»

«Телеңә күп салынып торсаң, урын табам мин сиңа... Ну-ка, документыңны күрсәт әле? Кем син?»

Мин зур горурлык белән комсомол билетымны суздым. Ул аның фәлшесен табарга теләгәндәй, җентекләп актарды. Бармак башы хәтлек кенә фотомны чыраема якын китереп карады.

Шушы минутта кесә карагыма рәхмәтле дә идем мин, билетыма тимәгән бит! Үзе дә, бәлкем, заманында комсомол активисты булгандыр әле...

«Өч мыеклы» милиционер абый елмайды да хәтта.

Фуражкасы эченә бөкләп салынган ашъяулык чаклы көрән кульяулыгын алып чәчен корытты, муенын сөртте, зәңгәр күлмәгенең кыска җиңеннән тыгылып култык астын сөрткәләде. Шуннан соң гына кодрәтеннән килгән иң зур киңәшен бирде:

«Горком комсомолга бар син!»

Автобуска утырып, соңгы тукталышка чаклы бар, дигән иде, җәяүләп, бушлай гына киттем, вакытым иркен лә...

Ләкин горком комсомолда мин бик озак юанмадым. Оештыру эшләре бүлеге мөдирәсе Ирина Хаҗиева дигән бер түтәй, өметемне кырт кисте, самолётка

түгел, хет Шават станциясенә чаклы гына әҗәткә поезд билеты алып бирегез, барып җитүгә акчасын перевод белән җибәрәм, дигәч... җавабына аркан ава яздым.

«Паспортың юк бит... Ә бу документ түгел!..»

Һәм ул ике мең чакрым юл үтеп тә бөгәрләнмәгән, взнослары ике айга алдан түләнгән, каләм очы кадәр дә тап тимәгән, биш орден сурәте төшерелгән һәм СССР байрагы түсендәге комач тышлы комсомол билетымны кире бирде... Юк, бирмәде, озын торыклы, ялтыравык өстәл аркылы алдыма ыргытты! Йа Хода, мондый сүз авызыңнан ычкынса, безнең Казандамы?!. Комитетларда тетмәңне тетеп, выговорлар чәпәп, дивар гәҗитләренә язып, комсомолыңнан куарлар иде... Ачуымнан ачыгуыма хәтлек онытылды. Аңладым хәлемне, миңа вакыт әрәм итәргә ярамый, янә ышыкланыр җиремә – аэропортка кайттым. Шунда ук почта тәрәзәсенә чират алып, ашыгыч телеграмма кәгазен тутыра башладым. Һәр сүзе ун тиен, ди!

Тыныш билгеләре бик кыйбат икән ул... Беренче «иншам» бюджетка сыешмады. Яңадан каезладым, кыскарттым, иң кирәкле сүзләрен генә калдырдым: «Акчасыз документсыз калдым. Ташкент аэропортында көтәм! Мин.»

Ашыгыч телеграмма ике сәгатьтә барып җитә, диделәр. Өстән-өстән генә санап чыгардым, үзбәк җизни биш-алты сәгатьтән соң килеп җитәргә тиеш.

Гел ашау турында гына уйлап утырмас өчен шәһәр буйлап сәяхәткә чыгып киттем.

Ташкент «Ташшәһәр» дигән мәгънәне аңлатса да, ул үзе гел яшеллеккә чумган. Йортлар биек түгел, яннарына килеп басмыйча күренмиләр дә хәтта.

Узган 1966 елның 26 нчы апрелендәге көчле җир тетрәүдән соң, күпкатлы төзелешне яңача кора башлаганнар: йортлар, машина әрҗәсе кебек рессорлар өстендә утыра, тетрәү дулкынында биеп торырга тиешләр, дип фаразлана икән. Урамда урысча сөйләшеп йөрүчеләр хәйран гына. Бөек Ватан сугышы вакытында эвакуацияләнеп, ачлыктан исән-имин котылган халыкның күбесе икмәкле-җимешле Ташкентта бөтенләйгә төпләнеп калган. Җир тетрәүдән җимерелгән шәһәрне торгызыр өчен союздаш республикалардан меңнәрчә төзүче килгән, алар моннан китәргә ашыкмый бугай. 26 нчы апрель көне төшереп калдырылган яңа календарьларны үз күзләрем белән күрдем...

Ышык урыннарда «чәйханә»дән дә күп нәрсә юк, һәммәсе дә музыка акырта, кайда гына, кайсын гына тыңласаң да көйләре – бөтенесе бертөрле кебек, дойра белән гиджак әле кушылып, әле алмаш-тилмәш моң тутырып тора. Урамнары да нәкъ Казандагы кебек – күбесенчә марксизм-ленинизм фәлсәфәчеләре, рус һәм дөнья әдәбияты классикларының исемен саклый.

Шәле халкының иң сөекле базары Казанның Чехов урамында бит инде. Ташкентта да Чехов базары бар икән, белеп түгел, ялгыш килеп чыктым. И сөендем, и сөендем инде... Менә хәзер бәрәңге сата торган ләвкәдә әниемнең: «Полявой картошка! Лорх! Лорх! Рощипышный!»[2] – дип такмаклаган тавышын ишетәм дә, йөгереп килеп, тастымал төенчектән юл хәстәрлеге өчен кичтән үк пешерелгән ике кәбестә бөккәнен алып... икесен дә берьюлы ашый башлыйм. Әнием үзе аркамнан сөя, үзе өзгәләнеп әрли: «Кая югалдың инде, чукынчык малай, хулиганнарга ияреп киттең мәллә дип, котым очты... Полявой картошкы. Лорх! Лорх! Один гына мешок остался...»

Ташкент базарында гел ирләр генә сату итә. Урысчаны шәп сукалыйлар,

[2]Кыр бәрәңгесе, ярмалы мәгънәсендә.

барысы да. Кайдан килдең, ни эзлисең, дип сораштырган булалар. Ни хәлең бар энекәш, дип, хәлемә керүче генә юк. Аларга охшарга тырышып, инде күземне кысыбрак та йөреп карыйм. Сатып алучы түгеллегемне әллә кайдан күреп торалар. Пешкәнме соң, диебрәк, бер грушага үрелгән идем, чебен куарга дип бөгәрләп тоткан «Правда» гәҗите белән кулыма сукты, саран тәре! Гәҗитен тартып алганыем – кысык күзе ачылды, ну авызы ябылды тегенең.

Күптән шулай кирәк булган! Кулга гәҗит тотып йөрим хәзер. Агайлар үзләре үк: «Менә монысын ал. Менә мондые да бар», – дип кодалыйлар. Кыскасы, Ташкентның икмәген күрмәсәм дә, биш-алты чия, ике алма телеме авыз иттем мин монда.

Шулчак кояшка күзем төште, баш түбәсеннән узып, Казан ягына авыша башлаган бит! Үзбәк җизни, мине әрли-әрли, «Справочное бюро» янында йөренә торгандыр...

Кем-кемне көткәнен бинаның эчендә-тышында радио хәбәр итеп тора. Бу кадәр дә озак итеп радио тыңлаганым юк иде әле минем... Караңгы төште... Яңа көн башланды... Су эчәргә барып килсәм дә, залдагы агайларга әйтеп калдырам, фамилиям нәкъ үзбәкчә диярлек, буташтырырлык түгел... Алтышар сәгатьле уку көннәрендә, апа, тамак кипте, чыгып керим әле, дип сорасаң, укытучыларның бик еш кабатлый торган җаваплары бар иде. Имеш, адәм баласы сусыз җиде тәүлек, ә ашамыйча айдан артык түзә ала, ди. Киресенчә түгел микән? Хәер, укытучылар алдашмас, без аларга ун ел буе ышандык. Су ягы иркен, ә ачлык мәсьәләсендә ике генә тәүлек үтте әле. Җәй айларында халык юлга тарала, көне-сәгате белән генә билет алырлык түгелдер.

Өч тәүлек тә үтте...

Телеграмманы алгач та... Ну, җизнинең саранлыгын җиңәрләр. Кияү бүләге итеп, сөяк саплы пәке дә бүләк итә белмәде, акчага кысмыр кешедер, юкса үзбәкчә йоласын үтәп, калымын түләп, үз милләт кызын алган булыр иде әле. Карун... Апам борчыладыр, бер ана карыныннан туган, ятимлекне миннән өч елга алданрак күргән Корыч кызы бит ул да... Юкка гына сабырсыз, дип үрти идең син мине, апа, сабыр мин! Кирәксә, көтә алам... Хәер сорашмыйча, саранnarга сер бирмичә, хат язышкан кызларымнан сөелмәгән килеш, комсомол билетымны күкрәгемә кысып, туган ягыма карап көтә алам!..

Үз рейсларына алданрак килгән юлчыларны урамнан ук каршы алырга өйрәндем. Таксидан төшкәннәренең бозау чаклы сумкаларын хәлемнән килгәнчә күтәрешәм, тәгәрмәчле бишекләрен бусага аркылы кертешәм, җемелдәп торган йөзем тәлгәшләрен күчерешәм, куш йодрык чаклы алмалары балкып торган биштәрләрен илтәм... Рәхмәт әйтәләр... Сөйләшеп китәбез шулай. Минем хәлнең асылына бик тиз төшенәләр үзләре. Тотыналар киңәш бирергә... «Сиңа тимер юл вокзалына күчәргә кирәк, анда халык миһербанлырак... Вокзалдан ерак түгел генә «Бәхет күле» белән «Рәхәт күле». Ул туристларның яраткан урыны, бәлкем, якташларың очрап куяр... Юк, юк, сиңа «Яшел базар»ны эзләп табарга кирәк. Хәзер бакчаларда эш күп: торф ташыйсы, җир казыйсы бар. Йорт салучыларга да кеше җитми. Авыр эш өчен көннекен көнгә түләп баралар. Бер атнадан юллык акча җыярсың. Сиңа фатир кирәкми, вокзалда җәй буе кунып ятучылар бар...»

Авырлыктан курыккан юк анысы. Җиденче каникулда ук тракторда сабанчы булып эшләгән кеше лә мин. Ләкин... пускачны кабызыр өчен дә әүвәл ягулык салырга кирәк. Ашарыма булса, шпалларны санап, җәяү кайтып китәр идем әле... Казанга!

Самолёттан төшкәнемә җиде көн...

Никтер су эчәсе дә килми. Инде аэропорт радиоларын тыңламыйм. Каршы алырга килделәр ни дә, килмәделәр ни. Төн уртасы ни дә, көн уртасы ни – ияләнгән эскәмиядә чалкан ятам. Тагын Казаннан килгән пассажирларны каршыладым, Шәле кешесе очрамасмы, дигән идем... Ике миллион кешесе булган шәһәрдә мин япа-ялгыз... Самолёт тавышына да иялӘндем, гөрелтеләре аэродром шөпшәләреише генә... Күктән кызган таш исе ява... Әни олы мичкә яккан. Мин, ут каршына тезеп, кара ипи телеме кыздырам... Чуеннан тавык бәрәңгесе сайлыйм. Кабыгын әрчеп көнбагыш маена манам... Майдан никтер «Тройной» хушбуе исе килә... Фу!

«Тор! Монда көндез йокларга ярамый!» – дигән тавышка иренеп кенә күземне ачам. Теге «өч мыеклы» милиционер туганым! Елмаерга теләгәнемне сиздердем. Ул мине шундук танып алды.

«Вай, комсомол, син шул көннән бирле һаман да мондамы әле?! Мин инде син эзләгән якларда командировкада йөреп кайттым.»

«Туганнарым килмәделәр ич. Телеграммам бигүк ашыгыч булмады бугай.»

«Сиңа хәзер бер генә юл кала. Атларлык хәлең бармы? Әнә теге «УАЗ»икка кадәр. Җитәкләп алып барсам, дөрес аңламаслар.»

Кая алып китәсең, дип, төпченеп, көчемне әрәм итмәдем, милиция машинасына төягәч, кая булсын инде тагын... Миңа хәзер барыбер... Әни генә менә... Олыгайган көнендә ике баласыннан да мәхрүм калды...

«УАЗ»ик туктагач, кая таба барасыны «өч мыеклы» дустым миңа тәрәзә аша гына аңлатты.

«Әнә, капканы күрәсеңме? Шакылдат. Ачарлар. Үз аягы белән килгән кешегә мөнәсәбәт бүтән анда. Әгәр мин китереп тапшырсам, сине сукбай итеп «попрошайниклар» исемлегенә теркиләр. Миңа да синең аркада бик күп волокита тутырасы була. Анда иртә-кич ашаталар. Көндезгесе эш урынында. Машинага төяп, колхозга йөртерләр. Билетка акча җыйгач, кемлегеңне раслап справка бирерләр. Аннан җаның теләгән якка олагырсың. Бүтән минем күземә чалынасы булма.»

Безнең авылның имән баганалы капкалары, такта коймалары уенчык кына икән ул... Чәнечкеле тимер чыбык белән кат-кат уратып алынган калай диварның торба баганалы, өч метр биеклектәге ике канатлы тимер капка янына килеп баскач, унҗиде ел буе яшәгән дөньям әллә кая югалды. Ике мең чакрым үтелгән юлым кинәт өзелеп, аяк астында бер таш кисәге генә калды. Әгәр хәзер шушы капка да ачылмаса, кире чигенерлек өмет юк. Йодрыклап дөбердәтәм, борылып, сандали үкчәсе белән төям, эчтәгеләрнең исе дә китми. Алай да туктаусыз бимазалый торгач, теге яктан суык тимерче тавышы ишетелде. Олы капка канатында кечкенә капка ярыгы пәйда булды.

«Нәрсәңне югалттың?»

«Сезгә килдем.»

«Монда килмиләр... Конвой белән генә алып киләләр.»

«Әнә бит минем конвой!»

Кечкенә капка төбенә чаклы ачылды, ләкин эчке сакчы әле һаман да мине кертергә җыенмый, ике куллап ишектә аркылы тора. Өч мыеклы дустымның «УАЗ»игы бер кычкыртып, ике тапкыр фарасын яндырып-сүндереп алгач кына рөхсәт булды. Мин кире уйламасыннар тагын, дигәндәй, очынып, зур ишегалдындагы тынлыкка килеп кердем. Як-ягыма каранып өлгермәдем әле, чөнки сакчы баш изәп, үз артыннан ашыгырга кушты. Күрәсең, ул эчтә постта утыручыдыр.

Бу оешманың ни өчендер урам ягында исеме язылмаган, бары тик контора кашагасында гына ике телдә шәрехләнгән күрсәткеч тора: «Эчке эшләр министрлыгының Ташкент шәһәре идарәсенә караган «Приёмник распределитель»гә тапшырганнар икән мине... Сакчы дигәнем кызыл почмак сыманрак бүлмәдә утыра. Ул үз өстәленең икенче ягына урын күрсәтте дә каядыр чыгып китте. Кыланышларына караганда, министрлыгына күрә бигүк эчке эшләр белән шөгыльләнми бугай болар: кемлегемне дә сорашмаган килеш ялгызымны гына калдырдылар; кабинетларында сейф та юк; рацияләре дә күренми; китапханәгә охшаган шүрлектә кәгазь төпләмәләре генә; почмакта – озын аяклы этажерка өстендә Ленин бюсты. Ачык тәрәзә артында шылт иткән өн дә юк, әйтерсең лә, бу тирәдә тавышлану катгый тыелган, шуңа күрә дә кануни тынлык хөкем сөрә...

Ниһаять, озын коридор буйлап килгән аяк тавышлары ишетелде. Кыска-кыска җөмләләр белән генә сүз алышалар: берсе – сакчымыздыр, икенчесе хатын-кыз заты булса кирәк.

Ияреп кергән ханым врач булып чыкты. Күрәсең, әлеге казаматка китерелгән кешеләрне әүвәл врач тикшерә торгандыр. Идәнгә җәелгән линолеумның уңган бизәкләрен санап утырсам да, бу апаның мине җентекләп күзәтүен тоям. Кизү торучы сакчы:

«Фамилия? Кайдан килдең?» – дип әйтүгә, мин аңа комсомол билетымны суздым, ә ул, сорау алудан туктап, хирысланып укыды да врач апага тапшырды: «Адресына игътибар итегез...» – диде ул, нindидер мөһим хәбәр җиткерергә теләгәндәй.

Бүлмәдә бер минутлык тынлык урнашты.

«Балакаем! Нишләп йөрисең син монда?!»

Сискәнүдән сикереп тордым! Ул бит саф татарча, мин укыган әлифба телендә эндәште! Күршебез, указсыз абыстай Фатыйма әби төрмәдәге кызы Хаҗәр апага хатлар язган өчен миңа атап, догалар кылганда, Ходаем сине ярдәменнән ташламасын, йөргән юлларыңда, кылган эшләреңдә фәрештәләрне юлдаш итсен, дип багышлаулар өсти иде... Менә бит инде, ул фәрештә каршымда басып тора: дөньяның иң ак халатын кигән; иң керсез ак калфак, чигүле чуәктән; көмеш беләзеге күренсен өчен генә җиң очын сызганган, колагында энҗе бөртеге! «Балакаем!» дип эндәшүендә мин күрергә теләгән чүл килене – бертуган апам тавышы! Шәфкать туташларының иң шәфкатьлесе. Чын фәрештә!

Врач апаның кочагына ташланасым, Ташкентта күргәннәремне сөйләп бирәсем килде. Ләкин атна буе вокзалда яшәгән һәм сукбай хәленә төшкән малайдан җирәнер, дип тыелып калдым. Ике йодрык белән шытырдатып кысып, күз яшьләремне томаламакчы булам. Ләкин бу елау түгел, бу – сөенү! Мин бүген ялгыз түгел!

«Елама. Зур егет бит инде син. Сөйгән кызың да бардыр әле, ә?!»

Фәрештәмнең юатуына буйсыныпмы, кинәт кенә тамагым тук, өстем – бөтен кешегә әверелеп, чак кына Апакай кызы Зәрия турында сөйләп ташламадым... «Еламыйм мин, апай, просто бу көннәрдә су күп эчтем, күз яшем сыегайгандыр.»

Врач апа минем хәл-әхвәлне төпченеп тормады. Бу йортка килеп керерлек булгач,ниләр күргәнне чамалыйдыр инде. Ә үзе, исеме Миләүшә бугай. Бөгелмәдән, диде, ире прораб икән, Җир тетрәүдән соң партия кушуы буенча җибәрелгәннәр, Татариядә минем яшьләрдәге энекәше калган, ди.

Шушы ук өстәлдә миңа башта сөтле чәй әзерләделәр, аннары сай гына тәлинкә белән шулпа җылытып китерделәр, калҗасы да булган булуын, ну

миңа бүген үк ит ашарга ярамый әле, диделәр. Калын күзикмәккә охшаган камыр әйберен Ташкент ипие – нан, диделәр. Мин аны шулпага турап салдым. Хуҗалар мин ашаганны карап тормас өчен киштәдәге кәгазьләрне актаргалаштыргаладылар. Ә мин тыгылмас өчен сөйләштерештергәлим.

«Апай, кулыгыз тәмле икән, ашыгыз телне йотарлык.»

«Минеке түгел. Отрядка без ризыкны чәйханәдән ташыйбыз.»

«Отрядка? Ник, мин монда үзем генә түгелмени?»

«Попрашайниклар күбәйде генә.»

«Шушындый зур хәвефтән соң дамы?!»

«Нәкь сугыштагы кебек инде. Җимерелгән шәһәрдә муродёрлар үрчи. Бераз хәл алгач, Сергей (сакчымыз) сиңа отрядларны күрсәтер. Моңарчы безгә үз аягы белән кергән кунак юк иде әле. Сиңа кайдадыр йоклардай урын әзерлисе бар.»

Ишегалды шуңа тыныч: отрядның буш вакыты подвалдагы камераларда үтә икән. Җир астындагы баскыч таштан коелган, төшкән саен урам челләсе ерагая, тән сөенә, һава тыгызлана... Һава дигәннән, беренче камераның күзлек пыяласы чаклы гына тәрәзәсенә күз салгач, сулыш алудан туктый яздым. Ике катлы сәндерәдә аунап ятучы ирләрне шәмәхә төтен эчендә көч-хәл белән абайларлык. Сергей әллә үртәп, әллә миннән тизрәк котылыр өчен сорап куйды:

«Бер сәке буш. Кунасыңмы шунда?!»

«Тәмәке төтененнән минуты белән тончыгам бит мин анда. Әйдә, икенче бүлмәне карыйк.»

«Икенче камера да шундый ук. Буш урыны да юк хәтта. Сиңа 16 яшь тулды инде. Әйдә, өченчене дә күрик. Хатын-кызлар белән мунча кергәнең бармы әле?»

«6 яшемә чаклы барые...»

«Алайса, кил, күр әнә!»

Ник телемә салындым да, ник төннеккә күз салдым! Йа, Ходა! Диңгезе ташлап качкан яр буенда кызыналармыни! Әллә берсе бәбили шунда – чалкан, тезләрен бөкләп... туасы бәбиен ишектәге сыңар күзлеккә төбәп яткан... Кансыз! Пановка төрмәсенә эләккән Хаҗәр апа күз алдыма килде. Ни хәлләр итеп түзә икән?! Ул бит Фатыйма абыстай кызы! Ник ул анда?! Хәер, бу турыда уйланырлык вакытым бар әле минем...

«Сергей абый, бу кешеләр берәрсен кыйнаганмы, талаганмы? Ник монда соң алар?»

«Юк. Болар шәһәребез өчен потенциаль җинаятьчеләр. Төрле хулиганлык өчен тотылганнар. Документлары да юк, акчалары, торыр урыннары да. Этлек белән кәсеп итүчеләр инде. Араларында гаиләләреннән качып килүчеләр дә бар.»

«Малай-шалайлармы?»

«Юк. Үсмерләр белән бүтән оешмалар шөгыльләнә.» Ә боларны ике атна эшләтәбез дә кулларына справка тоттырып, берәр поездга утыртып җибәрәбез.»

«Кая?»

«Белмим кая! Икенче шәһәргә. Безнеке кебек ише «Приёмник»лар бөтен өлкәләрдә бар...»

*(Ахыры киләсе санда)*



Шәүкәт
Гаделша

# ЯШЕН АТАРГА ТИЕШ...

## Болан

Яр буенда болан ята,
Сузып хәлсез аякларын.
Күтәрә алмый өскә башын,
Карга баткан тоякларын.

Яр өстеннән кеше үтә,
Ә боланның соңгы төне.
Үлем көтә, күзләр йомык,
Күрмәде ул соңгы көнне.

Яши авыл – бара-кайта,
Көн дә аңа җае чыга.
Ә мин яр астында... телим
Болан булып кычкырырга.

Кар ява да ява һаман,
Гәүдә әзер күмелергә.
Юкса болан килгән иде
Кешеләргә күренергә.

***

Кая киткән икән каен,
Төбе генә калган.
Күңелемне шомландырып,
Ят күренә алан.
Ботакларын селкеп, каен
Бары төшкә керә.
Кайткан-киткән чакларымда
Юк ул сөйләшергә.

---

Шәүкәт ГАДЕЛША (1949) – *шагыйрь. «Ярык мөгез», «Ядрә тигән», «Чоңгыл» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Җил сызгыра, елый кебек
Буш, каенсыз урын.
Яктылыкны суындырып,
Кояш карый кырын.

## Өйрәтче...

Әйт әле,
Карлыган куагы,
Сине җил
Аланнан куамы?

Эчтәрәк
Җимешләр өлгерә.
Монда бит
Җил генә йөгерә.

Миңа да
Эчкәрәк керергә,
Урманның байлыгын
Күрергә.

Бәлки, мин
Табармын кирәкне,
Тормышым
Эзләргә өйрәтте.

Аңламыйм:
Шыңшыймы, көләме?
Бик сәер
Урманның гүләве.

Күрәме
Янына килгәнне,
Эзләнеп,
Җанына тигәнне?

Нишлисең?
Урманга сузылам.
Аның бит
Куенында мин туган.

Өйрәтче,
Карлыган куагы,
Урманның
Булырга кунагы.

***

Төн күк йөзенә
Канатын сузган.
Йоклый алмыйча
Урамга чыгам.

Кемнең еракта
Лампасы яна?
Нигә кыймылдый
Абзарда тана?

Чак ишеттереп
Күк ыңгыраша,
Ни үткәрмәкче
Йөрәгем аша?

Мин йокымсырап
Урамны тыңлыйм.

Кычкырып әйтмим:
«Тормыштан туйдым!».

Әйтә миңа төн,
Ишекне терәп:
«Йокла! Уйланма,
Яшәргә кирәк».

Нидер әйтергә
Уянды җилләр.
Күпме авылда
Миндәен җүләр.

Их, төн, яхшылап
Йокларга иде.
Тик йоклый алмыйм,
Мин үзгә инде.

***

Кинәт балкып куйды
Урман алды.
Чабып барган куян
Туктап калды.

Колакларын кысып
Миңа карый.
Нигә тынды икән
Тирә-ягы?

И табигать, тыйма,
Барыйм инде.
Офык читләренә
Карыйм инде.
Офык читләренә
Нурлар элеп,
Бәхетемнең йөзе
Балкыр кебек.

Куян ник туктады,
Әллә арды?
Ник яшерми аны
Кышның кары?
Кирәкми бит аңа
Миннән качу.
Минем теләк: офык
Читен ачу.

***

Туган авылым торган
Бәхет ишеген ачып.
Тик аны күрмәгәнмен,
Киткәнмен ерак качып.

Яшьлегемнең еллары
Артымда тынып калды.
Тормышым барлыгымны
Тишек савытка салды.

Хәзер кайтсам авылга,
Урамда көеп торам.
Бәхет ишеге череп,
Күзгә күренмәс булган.

***

Болыт уйлана кебек,
Тора нәрсәдер көтеп.
Ага тавышсыз инеш,
Яшен атарга тиеш.

Ярда күңелсез нарат,
Тора күңелсез карап.
Ятам тормаган килеш,
Яшен атарга тиеш.

Тавышланмый көн, тынган.
Кешеләр бар да уйчан.
Уйный йөрәктә тибеш,
Яшен – атарга тиеш.

Беркая да бармыймын,
Ятам уйланган килеш.
Бүгенме, иртәгәме
Яшен – атарга тиеш.

Чынлык гадәти түгел,
Туйдырды имеш-мимеш.
Барсын да сискәндереп,
Яшен атарга тиеш.

***

Әллә безгә җил сызгыра
Барган чакта Бүрәнгә*?
Тотыйк әле күпләп балык,
Аулар корып тирәнгә.

Урламыйбыз кешенекен,
Без тотабыз үзебез,
Егып күлнең камышларын,
Көймә генә эзлибез.

Ә мин күлгә карап торам,
Агайларым сүгенә.
Кояш тыгыз нурлар коя
Тыныч күлнең өстенә.

Никтер бүген балык уйный,
Чума анда, монда да.

* Бүрән – күл исеме

Көймә юкка агайларның
Күңелләре болгана.

Ә мин көймә булмаганга
Эчтән генә куанам.
Аулар тузгып ята ярда, –
Күл суында юмаган.

Йөзә балык, чумып ала.
Яши безнең күлебез.
Димәк, әле мөмкинлек бар,
Мескеннәрдән түгел без.

Күңелемдә шатлык туа
Аулар тузгып ятканда,
Бүрәнемнең балыкларын
Тоталмыйча кайтканда.

***

Тегермән хәлсез,
Канатлар бәйле.
Тырышның монда
Кызганыч хәле.

Уянды ният,
Аңымны төйде:
Тегермән ташы
Әйләнсен иде.

Тегермәнче карт
Йөресен иде,
Тулы капчыклар
Күренсен иде.

Түбә тишелгән,
Дивары черек.
Җилләр елыйлар,
Ярыкка кереп.


Ташланган урын,
Беркем дә керми.
Бар буена да
Кычыткан үрли.

Мин ташлый алмыйм,
Һаман да киләм.
Күңелсез калып,
Башымны иям.

Җилләрне куам,
Ачудан тибеп.
Тамагым ачый
Яшь йоткан кебек.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Әхәт
Сафиуллин

# КЫТАЙ ГАЙФУЛЛА

ПОВЕСТЬ

Аңлап булмаслык дәрәҗәдә гаҗәп бу дөнья! Бигрәк тә аның соңгы еллардагы ачышлары гаҗәпләндерә. Әйтик, хәзерге минутта ул, Гайфулла, кемдер әйтмешли, күкнең җиденче катында самолётта очып барган килеш, өендә аш-су пешереп йөргән хатыны белән кесә телефоныннан сөйләшә! «Роза! Мин самолётта инде. Ни эшләр бетерәсең?» «Аш пешерәм. Карале, Гайфулла, кызларыбызны минем өчен дә коч, яме!»

Моны могҗиза димичә, ни дисең инде?! Хәйран калырлык күренеш бит бу! Самолётның ерак араларны якынайтуын әйт тагын! Заманында әлеге юлны айлар буе үткәннәр! Мәрхүм әтисе Габдулла сөйләвенчә, бабалары Гафиятулла хәзер алар яшәп яткан Кытайга Татарстан дигән илдән айлар буе барып-кайтып йөргән.

Бабасы туган ягын бик сагына иде, мәрхүм. Инде тәмам картайгач, үзе әйтмешли, рәте китә башлагач, үзенең туган авылын, туган ягын сагынып, еш кына күз яшьләре аша исенә төшерә иде. Хәтта көчсез тавышы белән бер җыр җырларга яратты әле ул:

Әрәмәгә керсәм, үлән сирәк,
Сахраларга чыксам, җир җиләк.
Эчемдә генә минем утлар яна,
Ник җилкенә икән бу йөрәк...

Хәер, аның бу җырны авызы эченнән генә мыгырдавын җырлау дип тә әйтеп булмагандыр: тавышының зәгыйфь, көчсез булуы өстенә, ул үз күңеле өчен андагы һәр сүзнең тәмен, аһәңен, моңын тоярга, хәтта аларның яңгырашын берәм-берәм үлчәп карарга теләгән сыман, һич тә ашыкмыйча, үзенә бертөрле хисләр дулкынына бирелеп пышылдый иде кебек. Андый чакларда кайчандыр коңгырт булып, инде төссезләнеп, уңып калган күзләреннән ирексездән яшь бәреп чыга...

Менә хәзер күз алдына китерүенчә, бабасы бу җырны яшьрәк чакта, мөгаен, үзенең көчле, көр тавышы белән матур итеп җырлаган булгандыр. Әй сагына иде ул туган ягын, бик сагына иде! Кем белә, бәлки, төгәл үзенең туган авылын искә

---

Әхәт САФИУЛЛИН (1936) – *прозаик, журналист; «Язларыңда ялгыз йөрсәң», «Онытылган вәгъдә», «И гомер, гомер» повестьлары һәм күп кенә хикәяләр, юморескалар авторы. Казанда яши.*

алып, улына, ягъни Гайфулланың әтисенә бу турыда сөйләгәне дә булгандыр. Бәлки, барысы да – үзенең кендек каны тамган йортлары, гомере буе күңелендә йөрткән туган авылының урамнары, гүзәл тирә-ягы – кырлары, урманнары, инешләре, болын-тугайлары, сиртмәле коелары һәм шунда калган әби-бабалары, әти-әниләре – барысы да әнә шул «туган як» дигән ике сүзгә сыйгандыр... Ә ул туган ягын гомере ахырына якынлаша барган саен ешрак телгә алды. Кайчак исемнәре белән: безнең очның Фәйзрахман абый, яисә безнең Смиле күперендә, йә безнең инешнең Минвәли абыйлар артындагы тугаенда, дип сөйләп китә иде ул, туган авылын искә төшереп. Дөрес, ул исемнәр Гайфуллага да, аның әтисенә дә берни дә аңлатмадылар, чөнки Кытайга килгәндә, әтисенә ике яшь чамасы гына булган, ә Гайфулла исә монда туды. Димәк, аларны кытайлылар дип әйтергә була. Шуңа күрә бабасы ул инеш-суларны, болын-тугайларны туган ягын үзәге өзелеп сагынганга искә алган икән, мәрхүм.

Заманында ул сөйләгәннәр белән кызыксынасы калган. Ахырында аның кайсы районның кайсы авылында тууы турында гына булса да сораштырып, хәтта, дөнья хәлен белеп булмый, дип, берәр җиргә язып куярга да кирәк булгандыр. Тик ул чакта болар кирәге чыкмас дип уйланылган шул... Моннан ничәмә дистә еллар элек, кайчан да булса дәүләт чикләре ачылыр да, бабаларының туган-үскән якларына – хәзерге Татарстан җиренә барып чыгарга мөмкинлек туар дип кем белгән!

Стюардессаның: «Хәзер очкыч Россия чиген үтеп керә», дигән сүзләре Гайфулланың уйларын бүлде. Ул ирексездән иллюминаторга таба борылып, түбәнгә күз салды. Аста очы-кырые күренмәгән җир җәйрәп ята. Әнә бик тар озын тасма булып Байкал-Амур тимер юлы сузылган. Башка бер мизгелдә, Россиянең кайсыдыр шәһәре өстеннән үткәндә, аста башларын күккә терәгән торбалардан болыт сыман булып, күккә төтен күтәрелә. Аз гына читтәрәк ниндидер елга өсте ялтырап тора, моннан анда йөзеп баручы теплоход шырпы тартмасы хәтлек кенә күренә.

...Кытайга алар буыныннан беренче булып, татарларның караңгы бер авылында яшәп яткан бабасы Гафиятулла барып кайткан. Әлбәттә, ул чагында көче ташып торган яшь ир-ат, бөтен гомерләре буе игенче хезмәте белән көн күргән әти-әнисеннән аермалы буларак, ничектер сәүдә эше белән шөгыльләнеп киткән. 1892 елда Кытай тикле дөнья читендә дә әнә шул сәүдә эшләре белән барып чыккан. Моннан нәрсәләр алып барып саткан ул анда, аннан монда нәрсәләр алып кайткан – бу кадәресе билгеле дә түгел инде. Тик шунысы ачык: йөри торгач, аның сәүдә эше шактый уңган, хәтта анда үз кибетен дә ачып җибәргән. Ә аннары авылларына кайтып, гаиләсен дә шушында алып килгән. Их, исән чагында Кытайдагы сәүдәсе турында тәфсилләп сораштырасы калган да, юк шул, сорашылмаган, белешелмәгән... Аннары бабасы үлеп китте. Ул чакта Гайфуллага нибары сигез яшьләр тирәсе генә иде. Аның сәүдәсе турында сораштыру булганмыни бала уенда! Тора-бара әти-әниләре дә бакыйлыкка күчте. Аның әнисе дә татар иде – димәк, ул вакытларда Кытайга бабалары гына күчеп килмәгән...

***

Гайфуллалар яшәгән шәһәрдә башка татар гаиләләре бер дистәгә дә җитми, нигездә, аларның кан-кардәшләре генә диярлек. Шуңа күрә алардан алты йөз чакрымдагы икенче шәһәрдә яшәүче бер татар гаиләсенең җиткән кызлары барын ишеткәч, кыз ошаса, берочтан озын-озакка сузмыйча гына өйләнү мәсьәләсен дә чишеп кайтып булыр, бәлки, дип, Габдулла һәм өченче

дистәсенә якынаеп килгән Гайфулла, ерак җир дип тормыйча, шунда юл тоттылар. Белешмәләр бюросыннан алган адреслары буенча барып танышты алар. Яшьләр бер-берсен беренче күрүдә үк ошаттылар һәм... ике көннән соң өйләнешеп тә куйдылар! Чөнки Гайфулла әти-әнисенең теләге улларын татар кызына өйләндерү, ә кыз әти-әнисенең теләге исә кызларын татар егетенә кияүгә бирү иде! Әгәр бу гаилә турында ишетмәгән булсалар, Гайфулла, мөгаен, йә казакъ, йә уйгур кызына өйләнер иде. Бу Кытайдагы татарлар арасында шактый киң таралган йола. Анысы да татар кызлары юклыктан, ни чарадан бичара булу аркасында гына.

***

Гайфулланың уйларын тагын стюардессаның тавышы бүлде:

– Казан аэропортына якынлашабыз, каешларны бәйләгез.

Самолёт, моның кайсы җиренәрәк төшеп утырыйм икән дигән сыман, аэродром өстеннән бер әйләнеш ясап, һаман җиргә якынлаша барып, бераздан аягына сөрлегеп киткән ат шикелле бетон юлга бераз сизелерлек итеп бәрелеп алды да, җайлы төшүенә куангандай, инде ашыкмыйча гына шуннан йөгереп китте һәм, тизлеген әкренәйтә төшеп, бөтенләй туктап калды.

«Шөкер, Ходаем, синең ризалыгың белән, исән-сау һәм хәвеф-хәтәрсез генә килеп төштек! – диде Гайфулла, куркынычсызлык каешын ычкындырып. – Мең рәхмәтләр сиңа!»

Аны залда дусты Рөстәм көтеп тора иде. Бик җылы күрештеләр.

Сөйләшә-сөйләшә Рөстәм машинасы янына килеп, Гайфулланың сумкасын багажникка куйдылар.

– Поплыли? – диде Рөстәм, машинасын кабызып.

– Монысы безнеңчә ничек була?!

– Ни... ачуланма, дус, мин синең татар икәнеңне гел онытып җибәрәм, – дип көлде Рөстәм. – Монда, Россиядә урыслар арасында яшәгәнгә еш кына урыс сүзләре дә ычкына. Без моңа күнеккән инде. Ә мин әйткән «поплыли» сүзе безнеңчәгә күчергәндә, шаярып әйтелгән, йөзеп киттекме, ягъни кузгалдыкмы дигәнне аңлата...

– Ә аны: «Аллага тапшырып, кузгалдыкмы?» дисәң, нәкъ татарча була түгелме соң?

– Дөрес әйтәсең, алай дияргә дә була.

– Ярар, Аллага тапшырып кузгалдык, алайса, – диде Гайфулла. – Ходай безне хәвеф-хәтәрдән саклый күрсен!

– Шулай булсын!

– Карале, Рөстәм, әллә мин кунакханәгә генә урнашыйммы? Килгән саен сезне борчуы уңайсыз була башлады.

– Скажешь тоже! – дип, Рөстәм аңа чем-кара күзләре белән ачулы караш ташлап алды. Тик тагын урыс сүзләрен ычкындыруын сизеп, шундук бу ялгышын төзәтергә теләп, татарчага күчте: – Ниткән борчу?! Бу турыда сүз дә булырга мөмкин түгел! Син – безнең кунагыбыз!

– Без кытайлар белән кытайча, үзара өйдә дә, урамда да гел татарча гына сөйләшәбез. Бернинди кытай сүзе кыстырмыйча, рәхәтләнеп, тәмен-ямен белеп! Бергә-бергә, рәхәтләнеп, татар җырларын тыңлыйбыз, татар китапларын укыйбыз. Мин Казанга килгәли башлагач, безнең өйдә татар җырлы күп кассеталар җыйналды, китапханәм татар китаплары белән баеды.

– Моңа бары тик сокланырга гына кала.

– Карале, Гайфулла, нишләп син бер дә йорт турында сорамыйсың? Үзең белешкәләп йөр әле, диден дә, хәзер бу турыда сүз дә катмыйсың.

– Бу хакта үзең сүз башларсың, дип уйлаган идем.

– Кире уйламагансыңдыр ич?

– Әйткән сүземнән кире кайта торган кеше түгел мин. Белештеңме әллә?

– Бар бер йорт. Җитмәсә, беләсеңме, кайда?.. Безнең авылда! Бүген-иртәгә кызыгыз янында бул да, берсекөнгә шуны карарга кайтып китәрбез.

***

Гайфулла белән Рөстәм моннан өч ел элек очраклы рәвештә генә танышканнар иде. Дөресен әйткәндә, аларны кызлары таныштырды дияргә була. Чит илләрдә яшәүче татарларның да Татарстанда белем алу мөмкинлекләре ачылып, бу хәбәр Кытайга да килеп иреште. Шунда Гайфулланың башына: «Әгәр олы кызыбызны шунда укырга җибәрсәк...» дигән уй килде. Бу турыда бераз вакыт үзе генә уйланып йөрде дә, аннары хатыны Рауза белән киңәшергә булды.

– Әгәр без Таңсылуны шунда укырга җибәрсәк, ничек булыр икән? – диде. – Ни әйтсәң дә, Татарстан безнең әби-бабаларыбыз җире бит! Бәлки, Ходай кушып, аннары ул шунда төпләнеп тә калыр.

– Ни диярге дә белмим, Гайфулла. Дөресен генә әйткәндә, соңгы вакытларда нигәдер Татарстан турында үзем дә еш уйлана башладым. Әллә, дим, борынгыларның: «Җан тартмаса, кан тарта» дигәннәре дөресме икән? Тик хәзерге вакытта Россиядә тормыш бездән авыр, диләр. Икенчедән, Таңсылу монда да университетта укый. Алла боерса, тагын өч елдан аны көн саен телевизордан күреп торырбыз. Һөнәре дә начар түгел: телевидение алып баручысы! Дәрәҗәсе ни тора! Анда барырга риза булырмы, юкмы?..

– Тормыш кайда да җиңел түгел. Ләкин аны тырышлык белән җиңәргә буладыр. Тир түккән кеше кайда да югалмый. Тора-бара тормыш яклары анда да яхшырыр, дип уйларга кирәк. Хәзер Россиядә дә шәхси эш белән шөгыльләнергә юл ачык. Әгәр Таңсылуны укырга шунда кертсәк, бәлки, үзебез дә шунда күчү турында уйлашырбыз аннары, ә, Рауза?

– Мин һич каршы түгел, ләкин әйтәм бит: ул риза булырмы, юкмы? Анда укуның мондагыдан нинди өстенлеге бар икән?

– Өстенлеге шунда: ул татарлар иле! Анда – татар мохите! Безнең өчен болар һич тә вак нәрсә түгел.

Бу мәсьәләгә кызлары университетның икенче курсын тәмамлагач әйләнеп кайттылар. Ул әти-әнисенең тәкъдименә шатланып риза булды. Һәм Гайфулла белән Таңсылу вузларга имтиханнар башланырга шактый вакыт кала, тиешле документларын җыйнап, Казанга очтылар. Анда кунакханәгә урнашып, башта Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгына кереп, чит илдә яшәүче татарлар өчен каралган квотага керүләрен расладылар. Аннары берничә мәртәбә кайчандыр В.И.Ленин исемен йөртеп, аннары Казан федераль (Идел буе) университетына әйләнгән вузга барып, андагы кабул итү шартлары турында бәйнә-бәйнә белештеләр, һәм Таңсылу инде үзләре сайлаган социология факультетына укырга керергә гариза биреп, документларын тапшырды да имтиханнарга әзерләнә башлады. Имтихан дигәннән, инде Кытай университетының ике курсын тәмамлаган студент буларак, аңа аны өстәмә рәвештә бары тик бер генә фәннән бирергә туры килде, ә болай аның белән әңгәмә генә кордылар. Шулай итеп, ул әти-әнисен шатландырып, заманында данлыклы саналган университет студенты булды! Анда керү чорында ят

шәһәрдә ялгызын гына калдырмас өчен Гайфулла үзе дә Казанда яшәде, аны рухландыру максатыннан, университетта да еш булды.

Шушы ук уку йортына керү имтиханы тапшыручы кызы янына килеп йөргән Рөстәм белән алар шул чакта университет коридорында таныштылар. Аннары акыл-фигыльләре дә бик килеште бугай, дуслашып киттеләр. Бу дуслыкка бигрәк Гайфулла сөенде, чөнки монда аның туган-тумачасы түгел, бер танышы да юк иде. Үзе әйтмешли, аны Рөстәм белән Ходай таныштырды. Казанга килгән чакларында – кызы укырга кергәннән соң ул монда еш була башлады – Рөстәм аны гел үзләренә алып китә, һәм ул кирәк кадәр аларда яшәде. Бәхеткә, аларның кызлары да бер-берсе белән бик дуслашты. Мондый дуслык чит илдән килеп, ят шәһәрдә яшәүче Таңсылу өчен бик кадерле иде: Рөстәмнең кызы Айгөл аны шәһәр белән таныштырды, ял көннәрендә дә гел бергә булдылар.

Кызлары Казанда укый башлагач, Гайфулла белән Рауза Татарстанның берәр авылына күчеп кайту турында торган саен ешрак уйлый башлады. Казанга түгел, авылга күчәргә иде исәпләре. Димәк, моның өчен беренче эш итеп, анда өй сатып алырга кирәк. Әлбәттә, авылларда өй сатучылар күптер, тик төгәл генә белмичә, сездә өй сатылмыймы, дип, тиктомалдан гына кайсы авылга барып чыгасың? Шуңа күрә Казанга соңгы килүендә Гайфулла бу турыда белешүне дусты Рөстәмгә тапшырган иде.

***

Нәкъ Рөстәм әйткәнчә эшләделәр: Гайфулла ике көн кызлары янында булды да сатылачак өйне карарга дип, авылга кайтып киттеләр.

Гайфулланың Бәйрәкә авылын күргәне бар иде инде. Шулай Казанга чираттагы килүендә: «Минем авылны да күреп кит әле, әйдә!» – дип, аны Рөстәм алып кайткан иде. Шуңа күрә, сатылачак өйне инде үзе күргән, җитмәсә, дустының туган авылында икәнен дә ишеткәч, моңа бик шатланды.

Бәйрәкә бик матур җирдә урнашкан: кыл уртасыннан диярлек мул сулы инеш ага. Рөстәмнең әйтүенчә, ул балыкка бай. Су буйларында – бормалы тугайлар, авылның ике ягында – урман. Анда кура җиләге, шомырт, миләшләр котырып үсә. Чикләвек уңган елларда аны җыеп та бетерә алмыйлар, имеш.

Авылда татарлар яшәве әллә кайдан күренеп тора: өйләр, лапас-кура, койма-рәшәткәләр төзек, җыйнак, матур. Күп йортларның капкалары, тәрәзә яңаклары такталардан тишеп-уеп һәм кисеп ясалган төрле бизәкләр белән бизәлгән, төрле төсләргә буялган, шуңа күрә күз карашын ерактан ук җәлеп итәләр. Әлбәттә, соңгы елларда анда да тәрәзәләре кадаклап куелган өйләр барлыкка килә башлаган. Шәһәргә күчеп киткәннәр, дип аңлатты Рөстәм.

– Кешеләр туган-үскән авылларын ташлап, ник шәһәргә китә икән соң? – дип кызыксынды Гайфулла.

– Колхозлар бетте, кешеләргә эш юк. Инвестор дигәннәре килеп, берничә ел җирнең җелеген суыра да китеп бара. Аның урынына башкасы килә, тик берсе дә җиргә хөрмәт белән карап, аны ашлау, хайваннарны үрчетү турында уйламый, чөнки максатлары – бернинди чыгым түкмичә генә, җирдән күбрәк керем алу, мал-туарын акчага әйләнерү. Алар яшәвен дә шәһәрдә яши бит. Заманында безнең колхоз миллионер булып, зур-зур ике ферма савым сыерлары гына бар иде! Шуның өстенә дүрт мең баш сарык асралган фермасы! Хәзер шуларның берсе дә калмады, фермалар таланып, ташландыкка әйләнде. Шуннан соң, билгеле, халык эшсез калды, яшьләр шәһәргә китү ягын карый...

– Ләкин теләгән кеше үз эшен ачып җибәрә ала бит хәзер! Эшсез калган

кешеләр ник шуның белән шөгыльләнми? Тирә-якта никадәр җир җәйрәп ята! Зур байлык бит бу!

– Кешеләр түрәләргә ышанмый, шуңа күрә эшләренең барып чыгарына өметләре дә ныклы түгел, бөлгенлеккә төшәрбез, дип куркалар. Ә җирне эшкәртергә дә кирәк бит. Аны кем ничек, ни белән эшкәртсен?!

– Бәлки, кешеләрнең психологиясендәдер гаеп? Гел колхозга, уңган җитәкчегә генә ышанып, эленке-салынкы эшләргә өйрәнмәдеме икән алар?

– Монысы да бардыр. Кешеләр аңлавынча, колхоз нәрсә ул? Коллектив хуҗалык. Шуңа күрә аны берәү дә: «Минеке!» – дип әйтә алмады. Чөнки ул аерым кешенеке түгел, ә уртак. Күмәк икән, аңа караш та шулай: эш өчен беркем янмады-көймәде, милкенә дә чит итеп карады. Ә бит кешенең үз хуҗалыгына карашы бөтенләй башка: ул үзендәге сыңар кадакка да «Бу минеке!» дип карый, җиргә төшсә, иелеп ала, кәкрәйгән булса, турайта! Икенче яктан, түрәләр психологиясе дә бозылды. Аларның күбесе, тормышның үзгәрә баруын аңламыйчамы, әллә аңлапмы, һаман шул совет чорындагы гадәт белән яши, һәр яңалыкка кул-аягы белән каршы чыга. Мәсәлән, бер дустым, туган-тумачасының пай җирләрен берләштереп, фермерлык эшен ачып җибәрү өчен район юлын бер ел таптады! Ишетәсеңме, бер ел буе! Килгән саен йә бер, йә икенче документың җитми, дип кире борып, тинтерәтеп бетерделәр.

– Бәлки, ул эшмәкәрлек турындагы законнарны, үз хокукларын начар белгәндер?

– Нишләп белмәсен! Ул төшеп калган акылсыз бәндә түгел лә...

– Бездә башкача, – диде ишеткәннәренә ышанырга да, ышанмаска да белмәгән Гайфулла. – Бөтенләй башкача бездә! Күп очракларда кирәкле кәгазьләрне хәтта өйгә килеп эшләп бирәләр!

– Алайса, сездә ришвәт алу гадәте дә юк?! Беләсеңме, безнең түрәләр кечкенә генә белешмә язып бирүне яисә үз эшеңне ачуны ни өчен сузалар?

– Юк, белмим. Ни өчен?

– Күбесе үзенә йомышы төшкән һәр кешедән ришвәт өмет итә. Кулына акча төртсәң, ел буе йөреп тә очына чыга алмаган эшеңне ярты сәгатьтә эшләп бирергә мөмкиннәр! Рөстәм артыгын әйтеп ташладым, дип уйлап алды да Гайфулланы тынычландырырга ашыкты:

– Курыкма, монда төпләнеп калсаң, фермер булырга исәбең юктыр. Киңәш тә итмим. Бер сыер, берничә сарык асрап, рәхәтләнеп яши бир! Артыгына кизәнмә дә, анысы кирәк тә түгел. Җирне бик яратасың икән, рәхәтләнеп үз бакчаңда казын, теләгән яшелчәңне үстер, төрле җимеш агачлары утыртып җибәр, өстеңә артык йөк алырга тырышма!

– Карар идек әле анда, – диде Гайфулла. – Башта урнашасы бар.

– Авыл кешесе буласың килгәч, урнашырсың, Алла боерса. Монда барып чыкмаса, башка авылда, башка җирдә...

– Миңа сезнең авыл бик ошады, йорт мәсьәләсе дә хәл ителсә, бик яхшы булыр иде.

***

Гайфулла Рөстәм белән башта өйнең һәр почмагын диярлек эченнән дә, тышыннан да карап-капшап чыкты. Ул нарат бүрәнәләреннән сигез ел элек кенә салынган, әле бик яхшы хәлдә. Гайфуллага каралты-курасы да ошады: лапаслары иркен, нык-таза, әле стеналарының такталары каралып та өлгермәгән. Өй шикелле итеп бурадан салынган җылы сарае да бар! Монда хуҗалыгын тәртиптә тотарга күнеккән, хайваннарны яратып, күңелен биреп

асраган кеше яшәгәнлеге һәр нәрсәдән сизелеп тора. Гайфулла үзен шушы йортның хуҗасы итеп сизгәндәй сөенеп карап йөрде. Хәтта кайсы абзарда сыер, кайсында сарыклар тотарга икәнлеген дә аныклап куйды...

Гайфулла кесә телефоны аша гына хатыны Раузага йорт сатып алуы турында хәбәр итте һәм, Казанга кайтып, кызлары белән күреште дә Кытайга очты.

Анда атна-ун көн эчендә, шәһәрдәге ике катлы йортларын сатканнан соң, барлык туган-тумачалары, таныш-белешләре белән саубуллашып, үзләре белән юл сумкаларын гына алдылар да Казанга очтылар. Рөстәм, ике көннән мин сезне авылга үзем илтеп куям дип, ялга кадәр көтеп торуларын сораган иде дә, тик аларның тизрәк үз йортларына кайтасы килде. Әйе, үз йортларына! Ничек матур яңгырый иде бу алар өчен!

– Булды, җитте, Рөстәм! – диде аңа Гайфулла. – Моңарчы күрсәткән яхшылыкларыгыз өчен дә оялып йөрим, безгә күпме изгелек эшләдегез инде! Моннан соң барысын да үзебез ерып чыгарга тиеш! Мондагы тормышка бары тик шулай гына җайлаша алырбыз, Алла боерса. Бик зур рәхмәт сезгә, дус!

Алар район үзәгенә кайтып төшкәндә, төш вакыты узган иде инде.

– Хәзер кибетләргә кереп чыгарга кирәк булыр, Рауза, – диде Гайфулла. – Безнең өчен яңа тормыш башлана. Кашыктан алып!

– Ничек кашыктан алып?! – Хатыны коңгырт күзләрен түгәрәкләндерде.

– Ничек булсын, туры мәгънәдә, җаным, чөнки хәзергә безнең өйдә бер кашык белән бер тәлинкә әсәре дә юк бит!

– Алып кайтасы калган...

– Кеше көлдереп, Кытайдан тикле күтәреп йөрергәме? Хәзер супермаркетка керәбез дә алабыз аларны, Алла боерса!

***

Бераздан зур хәрефләр белән «Супермаркет» дип язылган шактый иркен кибеткә кереп, карап йөри башладылар.

– Карале, Рауза, менә нинди матур кашыклар! – диде Гайфулла, бер бүлек янында туктап. – Агачтан эшләнгәннәр!

– Ярар, тик башка төрлесен дә, берничә чәнечке белән калак, тәлинкә дә алырга кирәк. Унарны гына булса да...

– Бәлки, хәзергә биш тәлинкә җитеп торыр? Аларны күтәреп кайтасы да бар бит! Әлегә без авылда түгел. Калганнарын башка чакта алырбыз.

– Калган эшкә кар ява, ди халык. Алган-алган, җитәрлек булсын. Күбрәк алгач, бәяләренә ташлама да ясарлар.

– Алыйк соң, алайса. Ул кадәр авыр нәрсәләр түгел.

– Безгә унар данә менә бу тәлинкәне, менә монысын, ун агач кашык, унны менә мондый кашык һәм ун чәнечке белән ун чәй кашыгы бирегез! – диде Рауза сатучыга, сайлаган әйберләренә күрсәтә-күрсәтә. – Күпләп алганда, сездә ташлама ясала торгандыр бит?

– Нинди ташлама?! – дип гаҗәпләнде чибәр генә татар кызы һәм сүзнең ни турында баруын аңламавын күрсәтеп, иңбашларын җыерып куйды.

Ә Рауза белән Гайфулла исә аның соравын аңламый тордылар.

– Әйберне күпләп алганда, бәяләре бераз төшерелергә тиештер бит?

– Син нәрсә, апай, күктән төштеңме әллә?! – дип тагын да гаҗәпләнде чибәр кыз.

– Мин күктән төшмәдем, сеңлем, – диде Рауза. – Бездә, мәсәлән, кибетләрдә

әйберләрне сатулашып алып була. Ә күпләп алганда, сатучылар бәяне үзләре төшерә.

– Кайда ул сездә? – дип көлде сатучы. Аның моңарчы шактый ук чибәр күренгән йөзе ямьсезләнеп, кыйшаеп калгандай тоелды. – Кайда бар андый магазиннар?!

– Кытайда бар, сеңлем, андый кибетләр.

– Кыт-тай-да-а?! Син нәрсә, апай, очсыз товарлар эзләп, безгә шуннан тикле килдеңме? Ялгышкан син, апай, Кытай түгел, Россия бу! Бездә куелган бәя төшерелми. Базарда гына сатулашып була. Йә, аласыңмы, юкмы?

***

Ходайның рәхмәте, Гайфулла куллары белән күренгән һәр машинага изи торгач, шуларның берсе килеп туктады.

– Сезгә кайсы авылга? – дип сорады шофёр, тәрәзәдән башын тыгып.

– Бәйрәкәгә.

– Димәк, мине көтәсез булып чыга алайса! Шунда кайтышым. Тик башта түләү мәсьәләсен килешергә кирәк.

– Анысын гына килешербез. Күпме аласыз? – дип сорады Гайфулла.

– Белеп торыгыз: моннан Бәйрәкәгә нәкъ унике чакрым! Шунысы да хак: монда асфальт юллар юк, безнең машиналарны чокыр-чакыр бетерә, – диде егет, кулы белән чәчләрен сыпырып. – Йә ничек, илле сумга килешсәгез – утырасыз, килешмәсәгез – юнь бәяле бүтән машинаны көтәсез...

– Әлбәттә, килешәбез, энем! – дип сүзгә Рауза кушылды. – Болай да шактый басып торабыз инде.

– Алайса, рәхим итеп утырыгыз! – диде егет һәм, үрелеп, арткы ишекләрнең бикләрен күтәреп куйды.

Кузгалып киттеләр. Егет сүзчән булып чыкты. Алар утырып өлгермәде, Гайфуллага кулын сузып:

– Таныш булыйк: Фердинанд булам, – диде. – Безнең авылда яшисе булгач, әле күп тапкырлар очрашырбыз. Авыл кешесенә район юлын еш таптарга туры килә...

– Гайфулла абыең булам, – диде Гайфулла. – Ә бу – минем тормыш иптәшем Рауза апаң булыр...

– Сез Казаннанмы?

– Юк, энем, Кытайдан без.

– Кай-да-ан?! – дип гаҗәпләнде шофёр. Хәтта түгәрәк, тулы йөзе ничектер өскә таба сузылган сыман тоелды, ә шомырттай кара күзләре зур булып ачылды һәм шактый вакыт шул килеш калды. – Нинди бәла кузгатты сезне аннан?!

– Шөкер, бернинди бәла дә күрмәдек. Туган як сагындырды, энем! – диде Гайфулла. – Дөресен әйткәндә, кайчандыр әби-бабаларыбыз яшәгән туган як. Болай без икебез дә Кытайда туып-үстек...

– Ничего себя! – дип куйды Фердинанд.

– Нәрсә дидең, энем?

– Сез нәрсә, бер дә урысча белмисезме әллә?

– Беләбез, дип әйтә алмыйбыз шул. Аннан соң татарга урысча сөйләшү килешми дә бит. Менә хәзер сез әйткән сүзләр ни дигәнне аңлата?

– Ни... ычкына инде алар шулай... Гадәтләнгән, чөнки урыс илендә яшибез ич. «Ничего себя»ның төгәл тәрҗемәсен үзем дә әйтә алмыйм... Гаҗәпләнүне белдерә шикелле... Сез бездә кайда яшәмәкче?

– Әйтәм бит, анда йорт сатып алдык.

– Кемнәр йорты икән ул? – диде егет, уйга калгандай маңгаен җыерып һәм, борылып, Гайфуллага сораулы караш ташлады.

– Без аны Тәфкил дигән кешедән сатып алдык. Хуҗасы малае янына Казанга киткән, диделәр.

– Ә-ә-ә, алайса, Хәмәтнур абый йорты ул! Әйе, аны малае Казанга алып китте. Өе яхшы, нык, тагын йөз ел торырлык әле! Тик аңа газ кермәгән. Ул өйне Хәмәтнур абый авылга газ керткәч салды. Тик нигәдер газ кертмәде, янәсе, әби-бабалары ансыз да яшәгән. Гел учакка, мичкә утын ягып яшәделәр, җүләрләр! Алайса, газ мәсьәләсен хәл итү мәшәкатьләре белән район юлын шушы машинада күп тапкыр үтәсең бар икән әле, Гайфи абый!

– Минем исемем Гайфулла, энем! Мин аны бозып әйтүләрен һич яратмыйм... – диде Гайфулла, нык итеп.

– Авылда исемне кыскартып әйтергә күнеккән без. Шулай уңайрак...

– Белмим, бәлки, кемгәдер уңайдыр да, тик ул миңа мулла кушкан исем. Шуңа күрә мин аны һич тә боздыра алмыйм!

– Күнегергә кирәк булыр, Гайфулла абый. Авылда сине күбесе барыбер шулай дип йөртәчәк, әгәр монда яшәп калырга уйласагыз...

***

Бу йортның сатылуы турында, әлбәттә, авылда ишеткән булганнардыр. Ә яңа хуҗаларының кайтып керүен кайдан белгәннәр диген, утырып чәй эчәргә дә өлгермәделәр, ике ир-ат килеп керде.

– Хәерле кич! Без шушы урамда яшәүчеләр булабыз, – диде алар икесе бер авыздан. Әйтерсең, монда керер алдыннан репетиция үткәргәннәр. – Беренчедән, сезне безнең авылга килеп төпләнүегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Икенчедән, танышырга дип кердек... – Алар берәм-берәм үзләренең исемнәрен атады. Озын буйлы, какча гәүдәле, өчпочмакка охшаган сузынкы ябык йөзлесе – Харис, икенчесе уртача буйлы, шактый нык бәдәнле, табак битлесе Хөрмәт исемле икән.

– Рәхмәт, рәхмәт. Мин Гайфулла исемле булам, ә бу – минем тормыш иптәшем – Рауза. Танышуыбызга бик шатбыз.

– Без дә шат, – диде Харис, өйне күздән кичереп. – Туктале, дидек, яңа авылдашлар белән танышып чыгыйк...

– Нәкъ шулай, – дип җөпләде аның сүзен кечке кунакларның Хөрмәт исемлесе. – Ни әйтсәң дә, яңа кешеләр бит, дидек.

– Якын итеп керүегезгә рәхмәт, – диде Гайфулла. – Менә утыртырга гына урын юк әлегә. Гафу итәрсез, әлегә урындыкларыбыз да юк... Яңа җирдәге тормышыбызны кашыктан башларга уйладык, – диде.

– Ничек кашыктан?! – дип гаҗәпләнде Хөрмәт.

– Яңа өйләнешүчеләр шикелле, кашык сатып алудан...

– Андый гадәт бетте инде ул. Хәзер кызлар кияүгә чыкканда егеттән, кашыгың бармы, дип түгел, машинаң бармы, дип сорыйлар! – Харис бу сүзләрен бик тапкыр дип санады бугай, сары тешләрен күрсәтеп, ямьсез итеп, хихылдап көлеп алды.

– Монысын әйтә алмыйм, тик без нәкъ кашыктан башларга булдык. Менә бүген кашыклар белән берничә тәлинкә сатып алдык.

– Тик монда яши башлауның беренче көнен билгеләп үтәргә оныткансыз, ахрысы... – Харис, хәйләкәр елмаеп, иреннәрен ялап алды. – Безнең халыкта аның йоласы шулай бит хәзер: башта юарга кирәк!

– Ничек юарга?! – дип сорады сүзнең ни турында баруын аңламаган хуҗа, – Әле без кайтып кына кердек бит. Өйне шушы көннәрдә юып алырбыз дип торабыз. Дөрес, кеше-кара тормагач, тузан да утыргандыр.

– Аңламадың син мине, Гайфулла абый. Мин башка төрле юу, ягъни тамак чылату турында әйтәм... Йолабыз шундый: берәр яңа эш алдыннан, яисә менә сезнең шикелле, яңа җирдә яши башлаган очракта, шул хөрмәткә, бер-ике рюмка аракы эчеп куярга кирәк, диюем. Бу юлы аңлаешлы итеп әйттемме?

– Ә-ә, менә ни турында икән син! Тик, гафу итәсез, безнең андый йола турында ишеткәнебез дә юк! Без һәр эш, һәр гамәл бисмилла белән башланырга тиеш дип беләбез. Аракы эчүдән башланган гамәл юньле булып чыгар дип уйламыйм. Татарда гомергә дә булмаган андый начар йола!

– Бәлки, элек булмагандыр да, хәзер бар инде ул...

– Гафу итәсең, Харис энем, әмма мин моны татар кешесенә килешә торган нәрсә дип әйтә алмыйм.

– Ярар соң, теләмисез икән, бернишләр хәл юк. Тик без ул йола хакында искә төшерергә генә теләгән идек.

Кичке кунаклар, авызларын салындырып, чыгып киттеләр.

– Бу авылның йолалары кызык икән, – диде Рауза, алар артыннан ишек ябылгач.

***

Бәйрәкәдә тәүге төнне үткәргәннән соң, Гайфулла йокысыннан уянып, ишегалларына чykканда, бик иртә иде әле. Ул ярым караңгыда нindидер канәгатьлек хисе белән абзар-кураларына күз йөгертеп чыкты. Лапас стенасына сөялеп торган көрәк, сәнәк, тырма ише нәрсәләрне күреп алды да, алар арасыннан себеркене табып, авырлыгын үлчәп карарга теләгәндәй, берничә мәртәбә кулында сикертеп куйды. Аны кулына алгач, эчендә, кайдадыр тирәндә, нindидер якты, матур, күркәм хис уянып киткәндәй булды. Гаҗәп тә түгел: ул үз йорт-җиренең ишегалдында басып тора лабаса! Мондагы бар нәрсә дә аларныкы!

Ул бисмилласын әйтеп, уч төбенә төкереп, ишегалдын себерергә кереште. Бер дә ашыкмыйча, тәмен белеп себерде. Аннан соң капка төбенә чыкты да бераз вакыт йокысыннан уянып килгән авылга карап торды. Берничә әтәч, таң атканны белдереп, ярыша-ярыша аваз салды, аргы урамда эт өреп куйды. Гайфулланың күңелен, әле хәзергә үзе дә ахырынача аңлап бетерә алмаган, нindидер җылы, җанына якын дулкынландыргыч хис ташкыны сызып үтте.

***

Ул кичен, Фердинандны күрергә дип, аның өенә китте.

– О-о, Гайфулла абый! Нәрсә, берәр йомышың төштеме әллә? – дип бөтен йөзе белән балкып каршы алды аны егет.

– Иртәгә районга бармыйсыңмы, дип сорамакчы идем, Фердинанд энем. Эш килеп чыкты.

– Әле шушы арада гына булдың түгелме син анда, Гайфулла абый?!

– Монысы башка эш...

– Хәер, синең эшләрең күп булыр әле! Алайса, иртән сәгать сигезенче яртыда килерсең.

– Соң түгелме?

– Район оешмалары сигездән генә эшли башлый. Так шту таман гына була, – диде Фердинанд. – Бәясен үзең беләсең инде, Гайфулла абый. Соңга калма! Мин көтәргә яратмыйм.

Гайфулла сораша-сораша, машиналар сата торган фирмага китте. Ул Фердинандка бу юлы нигә килүен әйтмәде – әллә ала, әллә юк әле.

Нинди генә машиналар юк монда! Кытайда аның үзенеке «Мицубиси» иде. Хәзер дә шундыйны ук аласы итте: беренчедән, ышанычлы машина булса, икенчедән, инде ул аңа иялэнгән иде.

Бу – күп еллар буе машиналар сату белән эш итүче Казан фирмасының филиалы икән. Монда ул, шундук ЮХИДИ теркәве узып, номер да алды. Гайфулла өчен шундук номер алу үзе зур бәхет иде. Шөкер, бүген уңган юлга чыккан икән ул! Бөтен рәсми якларны килештереп, акчасын түләп, тиешле документларын алгач, ул машинасына тиз генә бензин да салдырды. Кибетләргә кереп, шактый кирәк-ярак та алгач, газ кертү белән шөгыльләнүче оешмага китте.

Дөрес, аның башлыгын бераз көтеп торырга туры килде. Исәнләшеп, үзенең кем икәнен әйткәннән соң, бу авылга яңа гына кайтып керүләрен, тик ул йортка газ кертелмәгән булуын аңлатып бирде.

– Да-а, – дип сузды кабинет хуҗасы, калын гына бер журналны кулына алып. – Эшләр авыр безнең бу мәсьәләдә. Чират бик зур...

– Аңлавымча, сезнең район газлаштырылып беткән бугай инде, – диде Гайфулла, гәрчә мондый мәгълүматы булмаса да.

– Газлаштыру плитәгә газ тоташтыру гына түгел бит ул. Хәзер күп кеше өйләрен җылытуны да газга күчерә. Шуңа күрә чират барлыкка килде. Сезне яхшы аңлаган хәлдә дә, хәзергә моны эшләргә мөмкинлегебез юк, дияргә мәҗбүрмен.

– Проектын эшли торсыннар иде. Анысына да вакыт кирәктер. Ә сезнең «хәзергә мөмкинлегебез юк» дигәнне ничек аңларга? Кайчан туар соң ул мөмкинлек? Аны күпме көтәргә?

– Газны барысының да бик тиз генә керттерәсе килә. Бу аңлашыла да. Тик безнең мөмкинлекләр чиксез түгел. Менә шуны аңлатырга тырышам мин сиңа. Син Казанда нинди эштә идең, Гайфулла абый?

– Мин Казаннан түгел.

– Чаллыдан что ли?

– Юк, Чаллыдан да түгел. Кытайдан мин, Исмәгыйль әфәнде!

– Кайдан, кайдан?! – дип гаҗәпләнеп сорады кабинет хуҗасы, хәтта корт чаккандай, сискәнеп киткәндәй булды һәм шундук «сез»гә күчте: – Шаяртасызмы?

– Сез нәрсә, Исмәгыйль әфәнде, мин бала-чагага охшаганмы?

– Ышануы кыен: үзегез Кытайда яшәгән, ә үзегез чеп-чи татар! Шуңа гаҗәпләнүем.

– Әйе, хатыным белән без Кытайда туганбыз, тик әби-бабайларыбыз безгә туган телебезне онытырга ирек бирмәде.

– Фантастика! Валлаһи, фантастика! Кем булып эшләдегез сез анда?

– Мин инженер-электроник. Кытайда университет тәмамладым.

– Кытай телендәме?!

– Әлбәттә! Мин тумыштан кытай телен үзләштереп яшәгән кеше бит!

– Фантастика! Ничек татарчаны да шулай яхшы беләсез соң сез?!

– Мөмкин булса, мин йомышым мәсьәләсенә күчәр идем, Исмәгыйль әфәнде...

– Аңлыйм мин сезне: хәзер газсыз тормыш тормыш түгел инде! Алайса, татар кешесе дә булгач, сезнең хакка чиратны күрмәскә тырышсак кына... – Кабинет хуҗасы үзенең сүзләре ничек тәэсир иткәнен белергә теләгәндәй,

тиз генә Гайфуллага карап алды. – Тик бу эш бераз кыйммәткәрәк төшәр... Чөнки аңлыйсыздыр, чиратлары җитүен дүрт күз белән көткән кешеләрне санга сукмау була...

– Сез проект белән бергә аның сметасын да төзисездер бит?

– Әлбәттә, барысы да законлы булачак: проект, смета, килешү. Тик минем сезнең үтенечне канәгатьләндерү өчен, Кытай тикле Кытайдан килеп чыгуыгызны искә алып, тагын да ачыграк әйтсәк, сезне хөрмәт итеп, бу эшнең чиратсыз башкарылуын гына искә төшерүем. Ягъни бу башкалар чиратын артка чигерү хисабына эшләнәчәк, Гайфулла абый. Сез мине аңлыйсызмы?

– Бик яхшы аңлыйм. Күпмегә тартыр икән соң ул «кыйммәткәрәк»?

– Әллә ни артыкка төшми инде ул, әйткәч тә... Тем более Кытайдан кайткан кеше өчен. Акча янчыгыгыз сай булса, шул тикле ерак җирдән монда кайтмас идегез. Дөрес уйлыйммы, Гайфулла абый?

– Үземне ярлы кеше дип әйтә алмыйм, әлбәттә. Тик мин һәр юаньне тир түгеп алдым. Шуңа күрә аны һич тә ришвәткә тотасым килми.

– Ни сөйлисез, Гайфулла абый?! Нинди ришвәт? Бары тик хәлегезгә керү генә бу! Өстәвенә, шушы көннәрдә үк газлы булачаксыз!

– Алай да миңа карата булган бу хөрмәтегез күпме торыр соң?

– Әйтик, ул... әйтик ул... ун мең доллар чамасы гына булыр. Сметадан тыш, әлбәттә. Тере акча белән...

– Беләсез булыр, Исмәгыйль Исламович, ришвәт өчен Кытайда бик каты җәза каралган. Аның өчен монда да рәхмәт әйтмиләрдер. Сез моннан курыкмыйсызмы?

– Ни сөйлисез, Гайфулла абый? Нинди ришвәт? Кайдан алдыгыз аны?

– Әле генә миннән ун мең доллар ришвәт сорадыгыз бит!

– Саташасыз, булмады андый нәрсә! Юкны бар итеп, мине куркытырга маташмагыз! Сезнең бу гамәлегез шантаж дип атала, Гайфулла абый. Монда юләрләр юк, сезнең коры сүзегезгә кем ышансын?

– Эшлиме? – дип сорады Гайфулла, өстәлдәге ноутбукка күрсәтеп.

– Эшли, әлбәттә. Тик аның белән нишләмәкче буласыз?

– Хәзер күрерсез...

Гайфулла костюм кесәсенә кыстырып куелган авторучкасын алды да, аннан кеп-кечкенә генә нindidер ялтыравыклы нәрсә чыгарып ноутбукка тыкты.

– Менә карагыз, Исмәгыйль әфәнде, – диде ул, клавишаларга басып.

Шунда ноутбук экранында аның белән сөйләшеп утырган кабинет хуҗасының ап-ачык йөзе пәйда булды. Кыскасы, кечкенә генә бу приборда алар сөйләшүе төшерелеп алынган иде.

Язманы күреп, районның газ хуҗалыгы башлыгы бер ноутбукка, бер аңа карап, гаҗәпләнү генә түгел, ни әйтергә белмичә, тәмам югалып калды.

– Сез – татар, ә мин милләтемнең һәр кешесен хөрмәт итәм, – диде Гайфулла. – Кешегә беркайчан начарлык эшләү теләгем булмады. Мин исә бу язманы бүтән җирдә дә күрсәтә алыр идем. Ләкин сезгә хөрмәт йөзеннән кисәтәсем генә килде: бу рәвешле акча эшләргә телисез икән, кайчан да булса барыбер кабачаксыз бит, Исмәгыйль Исламович! Ә сезнең гаиләгез, балаларыгыз бардыр. Шулар хакына мондый юлга баса күрмәгез! Булганына шөкер итеп яшәргә кирәк. Ул чагында намусыгыз да чиста булып калыр, кешеләр күзенә туры карый алырсыз. Мине дөрес аңлагыз!

– Карале, Гайфулла абый, ничек яздыгыз соң сез моны?! – диде гаҗәпләнүеннән аңыша башлаган кабинет хуҗасы. – Минем белән

кымшанып та карамыйча сөйләшеп утырдыгыз, ә шунда ничектер язып та алгансыз!..

– Сез минем инженер-электрончы икәнемне искәрмәдегез бугай.

– Да-а-а, Гайфулла абый, кызык иттегез сез мине! Зур сабак бирдегез...

– Әгәр файдасы тиярлек булса, мин шат кына. Ләкин бу шантаж түгел.

– Да-а-а, Гайфулла абый, – дип кабатлады түрә, башын чайкап һәм өстәлдәге селектор төймәсенә басты. – Проектант Фәйзуллин керсен! – диде. – Хәзер аны алып китәсез, анда тиешле эшен тәмамлагач, кире китереп куясыз!

– Әлбәттә, Исмәгыйль Исламович. Рәхмәт сезгә!

– Ярар сана... Проектларны да, сметасын да озакка сузмаска тырышырбыз...

***

Бәйрәкәгә кайтып төпләнүләренә ел чамасы дигәндә, Гайфулла белән Рауза бер сыер, ике сарык сатып алдылар. Тик үзләренең пай җирләре булмавы гына начар. Әгәр дә ул тиеш булса, алар аны ызанлатып, үзләренеке итеп законлаштырырлар иде. Әлегә пай җирләрен алып: «Бу үземнеке!» – дип йөргән кеше юк диярлек монда. Алар инвестор кулында – беркем дә үз җиренең кайда, кайсы кырда икәнен белми. Ә инвестор исә, аның өчен, авыл халкына бераз печән яисә салам биргән булып бәхилләтә. Ашлык бик сирәк елларда гына эләгә.

– Сез үз пай җирегезне нигә алмадыгыз, Хәким абый? – дип кызыксынды Гайфулла.

– Аның белән нишлик без?! – дип гаҗәпләнде күршесе. – Нәрсә белән сукалатыйк, нәрсә белән чәчик, урыйк, сугыйк? Кемнең трактор, йә чәчкеч алырлык рәте бар? Комбайн турында әйтмим дә инде... Хәзер техниканың бәясе – коточкыч!

– Теләгәндә, берничә кеше җирләрне берләштерә алыр иде. Алай җиңелрәк була бит.

– Шулаен шулай да, тик хәзер кеше бер-беренә дә, хөкүмәткә дә ышанмый дип әйтимме... Әллә мондый яңалыкка барырга куркабызмы?.. Әле бит ул пай җирләрен бүлеп бирергә ашкынып торучы да юк. Ике-өч кеше алырга дип артыннан йөреп караган иде дә, эшләре барып чыкмады: башта төрле сәбәпләр белән бирмәделәр, аннан соң, халык бик шаулаша торгач, эшкә ярамаган, җәһәннәм астындагы җирне тәкъдим иткән булдылар. Билгеле, бу эшкә төкереп, теләкләреннән кире кайттылар.

– Начар, Хәким абый, бик начар, – диде Гайфулла. – Дәүләт кешеләргә фермерлык хуҗалыклары төзергә, аларның эшен җайга салырга ярдәм итәргә тиеш бит.

– Тиеш нәрсәләр күп инде ул. Тик тормышта ни өчендер бөтенләй киресе килеп чыга.

Гайфулла хатыны белән киңәшеп, арендага бераз җир алмакчы булды һәм фермерлык хуҗалыгына кагылышлы законнар белән таныша башлады. Рөстәм аңа аларның татарчасын алып кайткан иде. Хәер, инде ул урысча да шактый сукалый.

Әгәр арендага җир алып булса, бер өлешенә люцерна яисә рапс чәчмәкчеләр иде. Ә техника мәсьәләсендә беренче елларда инвестор механизаторлары белән килешеп булыр иде: авылда бакчасын беркем дә көрәк белән казымый, җаен табып, сукалаталар бит! Бушка түгел, әлбәттә... Тора-бара искерәк трактор булса да сатып алырлар иде.

Уйлары тәмам ныгып җиткәч, Гайфулла җир мәсьәләсендә район юлын

көн аралаш диярлек таптады. Тик үч иткән шикелле шактый вакыт аны бер кабинеттан икенчесенә, икенчесеннән өченчесенә аткарып йөрттеләр. Шулай тинтерәп йөри торгач, ниһаять, җир мәсьәләсен кулында тотучы район түрәсе Шакировның үзе янына керә алды һәм, нинди эш белән йөрүен аңлатып, гаризасын сузды.

– Авыр мәсьәлә бу, бик авыр мәсьәлә! – диде түрә, күзен түшәмгә төбәп. Әйтерсең, Гайфуллага кирәкле җир әнә шунда эленеп тора иде. – Буш җирләр юк шул бездә, менә нәрсәсе белән авыр бу мәсьәлә...

– Ә Бәйрәкә авылы кешеләренең пай җирләре кайда булып чыга соң ул вакытта? – дип сорады Гайфулла.

– Кайда булсын, инвесторда! Алар үзләренә тиешле җирләрен алырга теләмәделәр.

– Дәүләт карамагындагы җирләр дә бардыр бит әле, Рафаэль Зарипович. Шул фондтан бирергә мөмкиндер ич?

– Ул җир дә инвестор карамагында... Аны буш яткырып булмый бит!

– Сез мине, Бәйрәкә тирәли җәйрәп яткан кырлардан бер гектар җир бүлеп булмый, дип ышандырмакчы буласызмы?

– Мин беркемне бернигә дә ышандырырга тырышмыйм!

– Фермерлыкны җир алып кына үстерергә димәгән. Башка юллары да бар аның. Мәсәлән, сыерлар асрап – сөтен, бозаулар симертеп, итен сатарга була?!.

– Хайван асрагач, аны ашатырга, кышлык печән әзерләргә кирәк...

– Соң, кешеләр җир алмыйча да әзерли бит әнә!

– Безнең авыл кешеләре берәр сыер гына асрый. Ә фермер хуҗалыгы оештырыла икән, димәк, анда берничә савым сыер булырга тиеш дип аңлыйм мин. Аннары бозаулары китә, таналары, сарыклар үрчетмичә дә булмый... Аларны елга буйларыннан җыйган каты-коты белән генә асрыйсыңмы? Әгәр теләсәгез, бу мәсьәләне уңай хәл итү сезнең өчен берни дә тормый дип уйлыйм, Рафаэль Зарипович.

Кабинет хуҗасы, чыраена уйланган төсмер чыгарып, бер сүз дә әйтмичә тынып калды. Шактый озак утырды ул шулай. Аннары авызыннан ашыкмыйча гына:

– Булышасы да килә сиңа... – дип уфтану сыгып чыгарды. – Тик буш җирнең юклыгы комачаулый...

– Ярар, иртәгә, – ул алдындагы календарьга карап алды, – юк, иртәгә Казанга киңәшмәгә барасы икән, берсекөнгә кер әле син минем янга. Бәлки, аңарчы башыбызга берәр яхшы уй килер...

Әйткән көнне яңадан килеп, кабинет хуҗасы Рафаэль Зарипович аны бик җылы каршы алды, хәтта, ни гаҗәп, күптәнге танышы кебек өстәле артыннан чыгып, кул биреп күреште.

– Синең гозерең буенча бер вариант бар, тик бераз чыгымга барырга туры килер, – диде ул үз урынына барып утыруга ук, эшне озакка сузасы килмичә. – Чөнки җирне инвестордан кисеп аласы, ә моның өчен аны бәхилләтмичә булмый...

– Бәйрәкә янында ук утыз-кырык гектар ташландык, чүп үләннәре баскан җир җәйрәп ята, Рафаэль Зарипович.

– Ул җир файдаланудан вакытлыча, ял иттерер өчен генә чыгарылган. Элеккеге көчен җыйсын өчен, җиргә дә ял кирәк бит...

– Аңлавымча, җирнең көчен, алабута белән әрем үстереп түгел, ашлама кертеп торгызалар иде. Статистикага караганда, бүгенге көндә Россиядә 80 миллион гектар җир ташландык хәлдә...

– Күрәм, син газеталар да укыйсың икән, Гайфулла абый! – дип көлде кабинет хуҗасы. – Әгәр сиңа җир кирәкми икән, минем вакытымны юкка әрәм иттермә! Безнең сөйләшү шуның белән тәмам...

– Район юлын эшем юктан гына таптамыйм! Миңа җир бик кирәк. Аның расланган бәясен күрсәтегез дә, кая түлисе икәнен әйтегез!

– Нинди расланган бәя?! Ни сөйлисең, Гайфулла абый? Мин синең хәлеңә керергә тырышып, хәтта закон тикле законны бозуга бармакчы, ә син...

– Димәк, бу законсыз эш?

– Законсыз эш дип... Кирәге чыккач, нишлисең, гозереңне тыңлап, хәлеңә кереп, законлаштырырга туры килер инде... Тик ни... – Түрә тавышын әкренәйтә төшеп, тирә-ягына күз салып алды. – Моның өчен акчаны – үзең аңлый торгансыңдыр дип беләм – кассага түгел... – Кабинет хуҗасы, аңа иелә төшеп, җирнең хакын атады.

– Сез мине ришвәт бирергә этәрәсезме, Рафаэль Зарипович?! – диде Гайфулла, ачуын яшерергә тырышып. – Моның өчен рәхмәт әйтмиләр бугай...

– Нинди ришвәт? Без икәү генә һәм синең гозереңне үтәү турында сөйләшәбез түгелме? Безне ишетүче юк! Әгәр сиңа чыннан да җир кирәк икән, акчаңны чыгарып саласың да, мин шундук аны үзең теләгән урыннан ызанлатырга боерам! Бу – ир-ат сүзе, Гайфулла абый! Йә, килештекме?

– Белүемчә, аренда җире сатып бирелергә тиеш түгел. Җитмәсә, шундый кыйбат бәягә!

– Мин аны сиңа арендага түгел, ә пай җире итеп гомерлеккә бирәм! Рәхәтен күр! Теләмисең икән, алмыйсың гына. Менә шул.

– Аңлашылды, Рафаэль Зарипович. Ярар, мин хатын белән киңәшим дә, хәбәр итәрмен.

– Ярар, киңәш, әлбәттә, киңәш! Киңәшле эш таркалмас, дигән безнең әби-бабайлар, – дип елмайды районның җир дилбегәсен кулында тоткан кабинет хуҗасы.

Шушы сөйләшүдән соң ачуыннан нишләргә дә белмәде Гайфулла. Газеталар, телевидение, радио көне-төне бу илдә коррупциягә каршы аяусыз көрәш бара, дип шаулый бирәләр!

Их, менә берәрсен, әйтик, шул ук Рафаэль әфәндене ришвәт алганда кулыннан эләктерергә! Бәлки, ниһаять түрәләр район халкыннан акча суыруны туктатырлар иде. Әгәр чынлап фаш итәргә телисең икән, моны районның үзендә ерып чыгуы мөмкин дә түгелдер, чөнки алар үзара кода-кодагыйлык, туган-тумача, дуслык җепләре белән бәйләнешеп беткәндер. Димәк, бер-берсен батыруга теш-тырнак белән каршы торачаклар! Юк, бу эшне бары тик Казан аша гына башкарып чыгарга буладыр. Ә нәрсә, бәлки, Аллага тапшырып, тәвәккәлләргәдер? Җәмгыятьне җимергеч бу ришвәтчелеккә каршы кайчан да булса чын көрәш башланырга тиештер бит!

Башына кергән бу уй Гайфуллага тынгылык бирмичә, әледән-әле күңеленә килеп, ачуын әледән-әле кабарта торды. Кабинет хуҗалары кешеләрне ни өчен ачыктан-ачык ришвәт бирергә мәҗбүр итә? Үзләренең җәзасыз калуларына ышанганга, оятларын һәм намусларын җуйганга, халык дәшми торганга күрә! Ә халык ришвәт бирмәгән очракта эше барып чыкмаслыгын яхшы аңлый. Шуңа күрә теге йомышы өчен дә акча төртә, бу йомышы өчен дә...

– Бүген Казанга барам, Рауза, – диде ул беркөнне, иртән торгач.

– Кичен бу турыда берни дә әйтмәдең...

– Рөстәмне күрәсем бар иде, – дип ялганлады Гайфулла. – Һаман вакыт табып булмый...

Ул Казанга килгәч, чыннан да, иң беренче Рөстәм белән очрашып, бу уен аңа да җиткерде.

– Кара аны, аннары сиңа монда яшәү авыр булмасмы икән соң? – диде дусты. – Түрәләр бер-берсен яклый да, саклый да белә! Үч алулары бар.

– Түзеп торырлык түгел ич: һәр түрә ачыктан-ачык, күзгә карап ришвәт таләп итә!

– Бу яңалык түгел, мин сиңа әйткән идем...

– Ир-ат дөньяда куркып яшәргә тиеш түгел. Аллага тапшырып, Эчке эшләр министрлыгына барам!

– Әгәр бу эшең барып чыкса, районда нинди бомба шартлавын күз алдыма китерәм. Бәлки, шуннан соң район түрәләре бераз айнып китәр, урыннарында нигә утыруларын исләренә төшерер. Тик шуны белеп тор: ул бомба кыйпылчыгының үзеңне яралавы бар! Мин кисәттем, үзеңә карыйсың...

Гайфулланы икътисади җинаятьләргә каршы көрәш бүлегендә дикъкать белән тыңлап, төшергән язмасын караганнан соң, түрәнең кулына тавыш-тынсыз гына богау салу чарасы күрелде. Тиешле суммада тамгалы акчалар әзерләнеп, Гайфулла аны түрәгә бирүгә, хуҗа кабинетына «аның кабул итүен көтеп торган ике авыл агае» – Казаннан килгән ике хезмәткәр килеп керергә тиеш иде.

Барысы да уйланылганча килеп чыкты. Гайфулла соралган акчаны бирергә ризалыгын белдергәннән соң, районның җир хуҗасы аны ике көннән кабинетында көтәсен әйтте. Билгеләнгән сәгатьтә акчаны аның кулына бирүе булды, кинәт кабинетка ике «авыл агае» килеп керде дә әле генә алган ул акчаларның тамгалы икәнен раслап, кулына богау салды.Ә Казанда тикшерү барышында аңа язманы да күрсәткәч, түрә тәмам коелып төште, аның кем һәм ничек төшергәнен аңлый алмыйча аптырап калды. Ахырда, димәк, кабинетка яшерен камера куелган булган, дип уйлады.

Бу вакыйганы телевизордан да күрсәттеләр, аның турында радиодан да сөйләделәр, газеталарда да яздылар. Ул район халкында ниндидер канәгатьлек хисе тудырса, район түрәләре өчен аяз көндә яшен суккан шикелле булды. Сагаеп калдылар. Халык «глава» дип йөрткән район башлыгы бу турыда белүгә үк сәгате-минутында милиция башлыгы белән прокурорны үзенә чакыртып: «Ничек шулай килеп чыкты, нигә бу турыда ни милиция, ни прокуратура берни дә белми калды?! Казан каян белгән, ул ничек МВДга тикле барып кергән?!» – дип, өстәл төеп ярсыды.

Ул чакта кабинет хуҗасы белән бергә, «вазифаи затка ришвәт бирүе өчен» дип, Гайфулланы да «кулга алганнар» иде. Берничә сорау бирделәр дә шул ук көнне җибәрделәр.

Аннары аның бу «Эш»тә төп фигура булуы барыбер ачыкланачак: судта ул төшергән видеоязма да күрсәтеләчәк, үзе дә шаһит итеп чакыртылачак. Ләкин тикшерү эше бик сузылып, аңарчы елдан артык вакыт узачак...

Гайфулланы беркем дә эзәрлекләмәде, эшенә аяк чалучы да булмады. Киресенчә, бу вакыйгадан соң, түрәләр, аннан үзләре курка сыман тоелды. Инде һәрберсе йомышын тиз һәм җиренә җиткереп үтәргә тырыша: әнә, сораган җирен дә алды, фермер булып теркәлгәндә дә, бернинди кыенлык кичермәде. Әгәр район өчен гадәттән тыш булып саналган бу хәл килеп чыкмаса, аңа фермер булып теркәлү өчен район юлын күпме таптарга туры килер дә, ишекләрен шакырга мәҗбүр булган кабинет хуҗалары аннан нинди ришвәтләр таләп итәр иде!..

Тик монда «янәсе» дип фараз кылырлык, гаҗәпләнерлек нәрсә юк иде.

Дөресен әйткәндә, түрәләр (вакытлыча дип уйларга кирәк) сагаеп кына калдылар.

Гайфулланы авылда тырышлыгы, һәр эшен булсын дип, җиренә җиткереп башкарып чыгуы өчен хөрмәт иттеләр. Тәвәккәллеген, намуслылыгын күргән авылдашлары алдында аның абруе тагын да үсә төште. Хәер, алар арасында аны күралмаучылар да булгандыр, әлбәттә: эш сөймәс ялкаулар, эленке-салынкы гына йөрүчеләр һәр җирдә бар һәм алар Гайфулла кебек тырыш кешеләрне сөйми, киресенчә, андыйларга карата күңелләрендә кара көнчелек йөртә торган була. Ләкин шушы вакыйгадан соң аларга районда йомышларын үтәве күпкә җиңеләйде: түрәләр халыкка игътибарлырак була башлады.

***

Тора-бара Гайфулла белән Рауза сыерлар санын унике башка җиткереп, ташландык хәлдәге элеккеге колхоз фермасының бер өлешен төзекләндереп, малларны шунда асрый башладылар. Әлбәттә, алар бозаулый торды, шулай итеп, эре мөгезлеләр саны ишәя барды.

Гайфулла сыер асрый башлаган беренче көннәреннән үк сөтләрен җыючыга түгел, ә район үзәгенә алып барып сатты. Моның өчен тагылмалы арба сатып алып, аңа үз кулы белән суыткыч җайланма көйләп куйды. Сөтенең сап-салкын һәм кибетнекеннән тәмлерәк тә, шактый очсыз да икәнен белеп алган хуҗабикәләр, ул киләсе көнне көтеп торалар иде.

Тора-бара ул базар павильонында үз «нокта»сын булдырды һәм киләчәктә мини сөт эшкәртү заводы кору турында хыяллана башлады. Тик бу бер кеше көче генә җитәрлек мәсьәлә түгел иде, әлбәттә, шуны аңлатып, эш сөючән кайбер авылдашларын пай җирләрен алырга күндерергә тырышты. Әгәр риза булсалар, җирләрне берләштереп, сөтчелек белән генә түгел, игенчелек, яшелчәчелек белән дә шөгыльләнергә мөмкин булыр иде.

Бу эшне күршесеннән башлады, берничә атна уйланып йөргәннән соң, ул тәки Гайфулланың сүзенә колак салды һәм, авырлык белән булса да, район юлын таптый торгач, гаиләсенә тиешле пай җирен алуга иреште. Берничә гектар иде ул!

Гайфулланың фермерлык хуҗалыгы кинәт кенә зураеп китте. Алар ул җирдә арпа чәчә башладылар, чөнки Гайфулла, сыра заводында булып, киләчәктә уңышны шунда сату турында килешү төзеп кайткан иде.

Бераздан хәтта Хөрмәт белән Харис та үз җирләрен ызанлатып, Гайфулла хуҗалыгына кушуны сорадылар.

Чәчүлек мәйданы зурая торды. Трактор белән сука, аннары печән чапкыч сатып алды.

Бәйрәкәлеләрнең кисәк кенә «йокыдан уянуы» район башлыгын да, инвесторны да шатландырды дип әйтеп булмый. Алай да хуҗалыкның җир мәйданы арта торды, инде анда бодай белән арыш та игелә башлады. Алган уңыш, кергән табыш пайлар исәбеннән һәм хуҗалыктагы хезмәтләреннән чыгып бүленде. Иң мөһиме – кешеләрдә иртәгәге көнгә ышаныч туды, алар эшле булды. Хәтта моңарчы тамак чылатырга эзләнеп йөргән Хөрмәт кышын фермада эшләде, җәен көтү көтте. Ә элек колхоз механизаторы булып эшләгән, эчүе аркасында эшеннән алынган Харис та, авылдашлары әйтмешли, «кеше булды» – эчүен ташлап тракторда эшли башлады. Хәким абыйның килене хуҗалыкның бухгалтеры хәзер...

***

Бүген Казаннан, Гайфулла белән Раузадан олы кызлары Таңсылуның кулын сорар өчен, булачак кода-кодагыйлары белән булачак кияүләре кайтачак. Әлбәттә, бу алар өчен зур һәм икеләтә шатлык. Булачак кияүләренең татар баласы булуы аерата сөендерде. Татар егетләренең рус кызына өйләнүе, яисә, киресенчә, татар кызының рус егетенә кияүгә чыгуы монда гадәти күренеш дип кабул ителсә дә, Гайфулла белән Рауза кызлары янында татар кияве булуын телиләр иде.

Бу хәбәр Бәйрәкә урамнары буйлап бик тиз таралды.

– Тиздән Кытай Гайфуллаларда туй булачак, туй! Кызларын кияүгә бирәләр! – дип, бу күркәм вакыйгага алар белән бергә авыл халкы да шатланды, чөнки инде аларны үз итеп, яратып өлгерделәр. Ә «Кытай» кушаматын монда яши башлагач ук ябыштырып куйганнар иде.

***

Тегермән мәсьәләсен киләчәккә калдырып, кредитка бортлы машина алырга булдылар, чөнки элек күрше колхоздан сатып алган иске машина гына канәгатьләндерми башлады: беренчедән, хуҗалыклары зурая барса, икенчедән, бигрәк тә игеннәрне урып-җыю чорында инвестор машиналарына гына таяну ышанычсыз.

Гайфулла банкка китте. Бу эш белән шөгыльләнүче бүлек мөдире аңа филиал башлыгына кереп, рөхсәт алырга кушты. Нишлисең, шуның ишеген шакырга туры килде.

«Әйе, керегез!» дигән тавышка кабинет ишеген ачса, беравык үз күзләренә ышанмый торды: аның түрендә, «Т» хәрефен хәтерләткән зур өстәл артында... Рафаэль Зарипович утыра! Әлбәттә, Гайфулла аның хөкем ителгән алты ел урынына ике ел гына утырып чыгуы турында ишеткәне бар иде. Ул чакта кайберәүләр, әллә амнистиягә эләккән, әллә Казандагы дуслары тырышкан, дип тә сөйләнде. Чынын үзе генә беләдер...

– Тау белән тау гына очрашмый! Нәрсә, Гайфулла абый, безгә йомыш төштеме әллә?

«Карале, хәтта исемне дә онытмаган!» дип уйлап куйды бераз каушап калган Гайфулла.

– Төште шул, Рафаэль Зарипович... Исәнмесез!

– Исән, исән. Инде мин сине Кытаеңа кайтып киткәндер, дип уйлаган идем... Йә, ни йомыш?

– Машина алмакчы идем... Бераз кредит кирәк... – Ул суммасын атады.

– Кредит барысына да кирәк. Ә синең җаваплылыкны үз өстенә алучы кешең бармы соң?

– Мин үзем җаваплы кеше! Нигә миңа башка берәү?

– Күрәм, банктан кредит алу тәртибен белмисең икән син, Гайфулла абый! Әйтик, әгәр дә мәгәр фермерлык хуҗалыгың бөлгенлеккә төшеп, алган кредитыңны кайтара алмасаң, аны кем түләргә тиеш?

– Минем өчен кем түләсен?!

– Синең өчен җаваплылыкны үз өстенә алган әнә шул – поручитель түләргә тиеш була аны, Гайфулла абый.

– Минем хуҗалык, Аллага шөкер, аягында нык басып тора. Бөлгенлек турында уйлаган юк.

– Алай димә – дөнья бу! Ә ул кырыкка төрләнүчән: бүген болай, иртәгә тегеләй... Димәк, юк синең андый кешең?

– Күршем Хәким абый бар...

– Юк, бармый: андый-мондый хәл килеп чыкса, бете белән түләсенме ул?! Монда түләрлек рәте күренеп торган абруйлы кешенең җаваплылыгы сорала! Ә синең, күрәм, юк андый кешең. Табарсың дип тә уйламыйм, чөнки әллә кайдан килеп чыккан сукбайга кем ышансын?!

– Чамалап сөйләшегез: мин сукбай түгел! Икенчедән, әллә кайдан түгел, ә дөньякүләм абруйлы Кытайдан килдем.

– Ә нигә килдең син монда? Бездә баюы җиңел дип уйладыңмы?

– Ник килгәнемне бер мәртәбә аңлаттым инде мин сезгә...

– Ярар, күп сүз – юк сүз. Кыскасы, безнең банк сиңа кредит бирә алмый. Хуш, минем вакытым тар... – Кабинет хуҗасы, моңа каршы ни әйтер икән дип, бераз вакыт аңа сынап карап торды да, тавышын әкренәйтә төшеп дәвам итте: – Әгәр дә чынлап та бик кирәк икән, ул вакытта хәлеңә керергә була... Шәт, син мине аңлыйсыңдыр, Гайфулла абый?.. – Ул ашыкмыйча гына өстәленең өске тартмасына ачып, шуңа төртеп күрсәтте. – Миннән булсын изгелек: алган акчаңның ун процентын шушы тартмага салырга килешсәк, бер сәгать эчендә моннан баеп чыгып китәсең!..

Бөкрене кабер генә турайтыр, дигән шул безнең әби-бабайлар. Төрмә дә төзәтә алмаган моны, дип уйлады Гайфулла.

– Кабат элеккеге тырмага басмакчы буласыз бугай? Тагын элэгүдән курыкмыйсызмыни соң, Рафаэль Зарипович?!

– Курыкмыйм, чөнки ул тырманы читкә томырдым мин! Бу кабинетта бернинди видео да булмаячак! Аны куркынычсызлык хезмәте егетләре көненә икешәр тапкыр тикшереп чыга! Так что, тормыш дәресләрен мыекка чолгап барабыз, Гайфулла абый. Шәт, монда кергәндә алар белән син дә очрашкансыңдыр? – Банкир, ниндидер канәгатьлек белән елмаеп, җилкәсе белән йомшак кәнәфиенең артына ныграк терәлеп куйды.

– Тентеделәр...

– Әйтәм бит!

– Тик алар кесәдәге наган белән пычакны гына күрергә сәләтле.

– Ул-бу булмасын өчен шул бик җиткән!

– Ә видео мәсьәләсендә ничек?

– Аны да күрәләр!

– Ә мин – шушы минутта ук! Моның киресен раслый алам! Тик башта шулай килешик: миңа кредитны бернинди ришвәтсез бирәсез! Ризамы?

Гайфулланың тәкъдиме аны пошаманга салды. Җиңелгән очракта шактый акчадан коры кала, шул ук вакытта серне белү теләге дә бик көчле: «Бу нәрсәнең башка төре дә бар микәнни?!»

Банкир, чынлап әйтәме, әллә бу ниндидер шантаж гынамы, дип шикләнеп, уңайсыз утырган сыман, урынында угаланып алды һәм, уйланып, шактый вакытка сүзсез калды. Бары тик шуннан соң гына:

– Мин риза. Йә, раслап кара! – диде.

Гайфулла, күкрәк кесәсеннән күренеп торган «авторучка»сын алды да аннан кечкенә генә нәрсә чыгарып, өстәл өстендәге ноутбукка тыкты. Берничә клавишаны баскач:

– Рәхим итегез! – диде.

Ноутбугына төбәлгән Шакировның күзе шар булды: анда бик ачык итеп

сөйләшүләре язылган иде! Ул бер Гайфуллага, бер ноутбук экранына карап, телсез калды. Озак вакыт ни дип әйтергә дә белмәде: ярга чыгарып аткан балык сыман, авызын бер ачты, бер япты – нидер әйтмәкче булды, тик сүзе чыкмады. Шактый вакыт шулай утырганнан соң, корт чаккан шикелле кинәт кенә урыныннан сикереп торды һәм шашынган сыман күзләрен акайтып, төкереген чәчеп:

– Теге чактагы язманы да син эшләгән, син! – дип акырды һәм, ике кулы белән башын тотып, кабат урынына сеңде. Тавышы йомшара төште. – Ә мин, җүләр, Казанның махсус хезмәткәрләре эшедер бу, дип уйлап йөрдем. Шпиондыр син, ил өчен куркыныч кеше! Бар ычкын моннан! Кредит түгел, кәҗә тоягы сиңа!

– Сүздән кире кайту ир-атка килешә торган эш түгел. Ярар, Рафаэль Зарипович, эш алайга китсә, мин аны башка җирдә күрсәтергә мәҗбүр булам... – Гайфулла тыныч булырга тырышып, урыныннан торды.

– Куркытма мине, куркытма! Шуны исеңдә тот: мин бит аны син күрсәтергә уйлаган җирдә, шулай яздыра торган гадәте барын белә торып, аның шантажчы икәнен ачу өчен юри шулай сөйләштем, дип әйтә алам. Аннары синең белән нинди орган шөгыльләнәсен, үзеңне ни көткәнен күз алдыңа да китерә алмыйсың! Сине, шпион дип табачаклар – алар моны бик оста эшли! Йә төрмәдә черетәләр, йә егерме дүрт сәгать эчендә Кытаеңа сөрәләр... Бу сиңа Кытай түгел, ә Россия! Менә шулай, Гайфулла абый. Так шту, сызып ташла бу язмаңны! Үзеңә бәла эзләмә!

***

Җәйге көннең берсендә, таң алдыннан, йокының иң тәмле чагында, кемдер сыер фермасына ут төртте. Бәхетләренә, иртә уянырга күнеккән каравылчы аны янгын җәелеп киткәнче үк күреп алып, шундук сүндерде. Ул шунда бер җиңел машинаның урманга таба китеп баруын күреп калган. Димәк, ут төртүче Бәйрәкәнеке түгел. Аннан соң бу гамәл күбрәк куркыту, кисәтү өчен генә эшләнгәнне хәтерләтә иде. Ферманы юк итәргә теләгән бәндә өрлек башына утлы чүпрәк кенә куеп калдырмас, янучан нәрсә сибәр иде. Хәер, ул хәерсезнең уен кем белгән?

Шушы хәлдән соң Гайфулла, ут төртүчене эзләүләрен сорап, милициягә гариза язып бирде. Милиция дә булып китте, район янгынчылары да килде. Сораштылар, беркетмәләр яздылар һәм... шуның белән вәссәлам: бернинди уңай нәтиҗә дә күренмәде. Шуннан соң Гайфулла, дөнья эшен белеп булмый дип, фермасына берничә видео куярга мәҗбүр булды.

Аннары күп тә үтмәде, Гайфулланың хуҗалыгына район янгынчылары ешлады: өендә дә, фермасында да куркынычсызлык кагыйдәләренең ничек үтәлешен тикшерделәр, шунысы гаҗәп – башка беркемнең йорт-җиренә дә кермичә, атна саен диярлек! Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, ди халык. Эзләнә торгач, янгынга каршы чараның «тиешле дәрәҗәдә түгел»леген ачыклап, ике мәртәбә штраф салдылар.

Беркөнне Гайфулла белән Рауза кичке ашларын ашап утырганда, аларга инвестор идарәчесе, элек Бәйрәкәнең «Таң» колхозы дип йөртелгән чактагы рәисе Кылый Мифтах килеп керде.

– Мин әле бу, Гайфулла абый, – диде ул, нигәдер уңайсызланган сыман, күзен идәнгә төбәп. – Ашыгыз тәмле булсын!

– Рәхмәт, Мифтах. Мактап йөрисең икән. Әйдә уз, ашыбыздан авыз ит!

– Юк, юк, узып тормыйм – ашыгам. Күңелсез хәбәр белән мин... Безнең амбардагы ашлыгыңны алырга тиеш буласың, Гайфулла абый... – Мифтах, үзен бүлдерүдән курыккан сыман, ашыгып дәвам итте. – Тик монда мин не причём, тырнак очы хәтле дә гөнаһым юк, ипи тотып ант итә алам, Гайфулла абый. Кушалар... өстән кушалар... Моңарчы бер дә каршы килмәдем. Ә хәзер берни дә эшли алмыйм... Районда белгәннәр...

– Инвестор амбарында районның ни катнашы бар?!

– Ничек кенә бардыр әле, Гайфулла абый! Белмибез генә. Хак булса, безнең инвестор – Дәүләт Советы депутаты булу өстенә, глава хатынының якын туганы, диләр. Дөрестер, глава тикмәгә генә бөтен җире, техникасы, фермалары белән бергә колхоз тикле колхозны кулына тоттырмас иде!

– Син инвесторның үзен күреп беләсеңме? Бәйрәкәгә килгәне бармы?

– Бер тапкыр да күргәнем юк, Гайфулла абый. Монда нигә килеп йөрсен ул?! Хәтта фамилиясен дә белмим мин аның! Район нәчәльствосы эшли аның өчен. Бөтен күрсәтмәләрне авыл хуҗалыгы бүлегеннән алам. Аны исә глава апасының малае җитәкли. Монысын точно беләм!

– Авыр хәбәр алып килдең син, Мифтах. Ярар, нишлисең, башка урын эзләргә туры килер...

– Тик миңа үпкәли күрмә, Гайфулла абый. Үзең беләсең, мин – подчинённый кеше...

– Сиңа рәхмәттән башка сүзем юк. Техника белән дә булышып килдең, амбарыгыздан да күп файдаландык...

– Техника дигәннән, онытып торам, моннан соң сиңа техника белән ярдәм итү дә тыела. Бу турыда мин барлык механизаторларны да кисәтергә тиеш. Кем дә кем бу күрсәтмәне боза, эшеннән куылачак, диделәр. Моны контрольдә тоту участок милиционеры, Әтәч Гыйльметдин малае Илһамга йөкләнгән. Менә шундый эшләр, Гайфулла абый. Болгана дөнья, нигә болгануын аңлап та булмый... Ярый, сау булыгыз, киттем мин, – дип, Мифтах чыгып китте.

Шөкер, ашлыкларын урнаштыру мәсьәләсен Хәким ерып чыкты: кайчандыр аларга күрше авылдан «перси» итеп куелган, хәзер үзләрендә, Мифтах шикелле үк, инвестор идарәчесе булып эшләгән, аңа туган тиешле Муллахмәт хәлләренә керде. Моңарчы аның урып-җыю чорында аларга комбайн белән дә булышканы бар.

Йомышлары төшеп, Гайфулла белән Рауза Казанга барганнар иде. Кичен кайтып керүләренә үк күршесе дәште.

– Миңа кереп чык әле, Гайфулла, – диде ул, нәрсәдәндер шикләнгән сыман, тирә-ягына карана-карана. – Ашыгыч эш...

– Әле кайтып кына кердек, Хәким абый, сулу алырга да өлгермәдек, – дип көлде Гайфулла.

– Әйтәм бит: ашыгыч эш бу.

– Шушында гына сөйләшик, – диде күршесе капка төбенә чыгуга, тавышын әкренәйтә төшеп. – Менә нәрсә... Бүген сез киткәч, безгә ике кеше килеп керде. Икесе дә эшләпәдән, галстуктан, кара костюм-чалбардан, ап-ак күлмәктән. Бик ягымлылар. Миннән гел синең турыда сораштылар: нинди кеше, кемнәр белән очраша, янына чит кешеләр килеп йөрмиме, үзе Казанга еш барамы? Гомумән, шуның ише сораулар... Киткәндә бу сөйләшү турында беркемгә дә әйтмәскә куштылар. Шуннан соң никтер: «Болар тегеннән түгелме икән?» – дип шикләнеп куйдым. – Ул бармагы белән өскә, һавага таба төртеп алды. – Үзең

чамалыйсыңдыр... Әллә, мин әйтәм, болар безнең Гайфулланы Кытай шпионы дип уйлыйлармы? Чөнки сораулары гаҗәп бит...

– Кайгырма юкка, Хәким абый, – дип көлгән булды Гайфулла. Тик чынында күңеленә кинәт шом бәреп керде.

«ФСБ хезмәткәрләре гади фермер белән ник кызыксынсын? – дип тынычландырырга тырышты ул үзен. – Ниндидер башка берәүләр булгандыр алар. Алай дисәң... Туктале, банкта чакта Шакиров авызыннан чыккан иде түгелме «шпион», «ил өчен куркыныч кеше син», дигән сүзләр?! Бәлки, үч итеп, тынычлыгын бозыйм әле моның, дип, таныш-белешләре аша ул башлап җибәргән эштер бу? Хәер, юктыр, моңа бара алмас, чөнки хәзер ул аннан үзе шикләнә. Шулай булмаса, икенче көнне иртүк: «Кредитыңны килеп ал, Гайфулла абый!» дип шалтыратмас иде. Димәк, ул видеоязманың кайда булса да пәйда булуыннан курка! Шакиров дөрес әйткән: чыннан да, менә ничек үзгәрүчән шул дөнья! Ни уйларга да белмәссең!.. Монысы да соңгы вакытта һәм кинәт кенә бер-бер артлы аңа каршы башланган кара эшләр чылбырының бер буыны түгелме? Артык күбәеп китте алар! Әйтерсең, кемдер махсус оештырып тора!..»

Шушы көннән соң ул җан тынычлыгын югалтты. Гәрчә бернинди гаебе булмаса да, кара машина белән йорты янына килеп туктарлар да, Хәким абый әйтмешли, аннан эшләпәле, галстуклы, өсләренә кара костюм-чалбар, ап-ак күлмәк кигән икәү килеп керер, ягымлы тавыш белән: «Сез Ватанга хыянәт итүдә гаепләнәсез, Гайфулла абый!» – дип әйтерләр кебек тоелды. Шөкер, андый машина капка төпләренә килеп туктамады, аннан эшләпәлеләр төшмәде, өйләренә кермәде, кулына богау салмады...

Бары тик беркөнне борчылуы йөзенә чыккан күршесе Хәким килеп керде дә, исәнләшергә дә онытып, ничектер коелып төшкән кыяфәт белән:

– Ишеттеңме, Гайфулла, Дәүләт Думасы эшмәкәрләргә салымны биш мәртәбә күтәрү турында закон кабул иткән, – диде.– Тиздән гамәлгә керәчәк...

Моны ишеткәч, гомерендә бер генә урысча сүз дә кушып сөйләмәгән Гайфулла аны гаҗәпләндереп:

– Ничего себе! – дип куйды. – Ялгыш ишеткәнсеңдер, Хәким абый: кönе-төне кече һәм урта бизнесны үстерү турында сөйләгән хөкүмәт мондый адымга бармас! Бу – аларның тамырына балта белән чабу! Кизәнеп, бөтен көч белән, бетсен дип!

– Һич тә гаҗәпләнмә моңа, Гайфулла! Бездә сөйләү эшләүне аңлатмый. Сүзе бер төрле, эш – сөйләгәннең нәкъ киресе. Ә дөрес ишетүем хак: әле генә телевизордан әйттеләр.

– Син хаклы, Хәким абый... Моны үзем дә күрәм: бу илдә сүз белән эш арасы җир белән күк арасына тиң. Бу илдә сөйли генә беләләр...

Әйе, Гайфулла безнең илдә димәде, ә ачык итеп, ниндидер әчке ачыну, шул ук вакытта үкенү белән: «Бу илдә», – диде. Шуның белән үзен Бәйрәкәдән аерып куйды. Чөнки инде ул Кытайга кире кайтып китәргә кирәклекне бөтен чынбарлыгы белән аңлаган иде...

Ләис
Зөлкарнәй

# НУГАЙ ЙОРТЫ

## САДАКТАГЫ УН КЫЙССА

### Кантүрә[1]

*Кузалак арба йөрмәстәй*
*Каргаулымы иде илегез?*
*Терәкле арба йөрмәстәй*
*Тиргәүлеме иде илегез?*
*Гарип бер юлчы килмәстәй*
*Хәерсезме иде илегез?*
*Каласын күрдем анда,*
*Йортын күрдем юлда,*
*Тияге монда, үзе кайда?*
*Җир кемнеке, тел кемнеке?*
«Идегәй» дастаны

Империя кирмән сала,
Имчеләре кирмәт[2] сала
Ил-йортның ак нигезенә.
Яклаучыңны күтәр, иләт,
Утырсын хан! –
Ак киездә...

Җиңелү әлфирак[3] түгел:
Татар бит ул яфрак түгел, –
Яши алмый калтырап!
Алгы-салгы вакытларда
Алгысынган халыкларга
Ил санлатырлык
Хан кирәк!

Ак киездә күтәрделәр,
Кулдан-кулга этәрделәр:
«Яшә, Солтангәрәй[4]!»
«Яшә, Дәште Кыпчак[5]!»
Көн арбасы...
Тараласы түгел иде:
Алдан бара!

Чәкүшкәсе
төшкән көпчәк...

Ил арбасы
Тараласы түгел иде,
Тараласы түгел иде
Дәште Кыпчак!

Пычакка пычак килде!
Нугай, Урдаң:
Бушап калды
Алтын Урда турагачы[6] –
Төкле Аяк[7]
Муены да
каерылган!

Яу чабулар ятракмы,
Инде татар яфракмы?! –
Яшәрбезме, калтырап?..
Яулар шашып килә торды –
Татар башын татар орды:
Илне алдамаган хан кирәк!
Яуда алда барган!
Хан кирәк.

*Ахыры. Башы узган санда.*

**2**

Бидаяклар[8]
Чөя нугай, сөенешеп:
Ак киездә –
Карасакал,
Кара лачын...
Сизәдер хан:
Сигез төмән гаскәренең,
Каторжаннар булып,
Илгә таралсын!

Илбасарлар кирмән сала
Асабалар кулы белән...
Җир читенә җитмәкчеләр
Бөек Ефәк Юлы белән.
Һун бабалар салган юлда –
Себер Юлы...
Нугай Юлы...
Икесен дә бер иттереп,
Ду китереп,
Сәүдә итте татар,
Сәүдә итә! –
Сагаймастан сагаймалы...

Ил-күч китмәс ялгыш юлдан:
Балбал белән каюланган... –
Адаштырмас Нугай Юлы.
Илбасарлар кала куймый,
Көнчыгышка «капка уя», –
Ал-даш-тыр-мас! Нугай Юлы:
Илбасарлар
Капкын куя!
Асабалар кулы белән...
Сагаймастан сагаймалы!

Кашкыр бүре куып атта,
Ил бидаяклар чөйгән чакта,
Шоңкар кычкыра!
Шаңгырап:
Шаңлап бүре тибәр өчен
Кирәк чөеп җибәрүчең! –
Тургачын сузган
Хан кирәк!

**3**

Ор[9] калада оя корган
Кыркылдаган каракошны
Тибәргә җыелганнармы?.. –
Бармаклардай тырпаешкан
Таш багана...
Казыкларда... –
Карасакал лачыннары[10]!

Казыкларга утыртканнар...
Инде бар, кара танып,
Какланганнар куырылып:
Кантүрә бу...
Монсы Юныс,
Җыянгол,
Карабаш,
Якуп...

Ау тургачы – тырнактан
Чөеп җибәргәнне көтеп,
Шулай тынып калганнардыр
Таш багана... казыкларда...
Юа да юа яңгыр...
Юа да юа яңгыр...

Шәфәкъ юган вак яңгырдан
Кытыклана котны алып,
Салкын Ташның чокыр учы.
Полковник[11] сытты битендә
Кан табыдай
Камкагачны[12]...

Тәфтиләү үткән авылларның[13]
Сөяк исле тәтеннәре
Бүген дә күз әчеттерә... –
Ничек инде янып бетсен?!
Авыл халкы кереп тулган,
Морҗадай утырып калган,
Кыйгаешкан
Мәчетләре...

Шәфәкъ юган вак яңгырдан
Кытыклана котны алып,
Салкын Ташның канлы учы:
Таш бармаклар
Йомылганчы!
Юлыңда бул,
Полковник,
Син дә Ходай камкагачы.

**4**

Туктады тылмач Тәфтиләү:
Салкын Ташта[14], күлдәвектә
Ялгыз сарала ат тора!
Хуҗасын эзләп килгәндер...
«Аркан атыйм сараланңа,
Бугалак салыйм,
Кантүрә!»

«Татарга тылмач кирәкми», –
Татар белән орышканда,
Генералга кирәк тылмач.
Татарга тылмач кирәгә,
Дөньясы
Болгатылгач... –
Рәсәйдә гел кирәк тылмач!
Татарга гел кирәк тылмач!

Ата-бабам –
Чыңгыздан[15].
Әтрәк-әләм казанган
Илсез ханга казганмам...
Татарга –
Ак патша терәк.

Ата-бабам – Чыңгыздан,
Илсез татар –
Чоң тузан...

Татарга ак патша кирәк!
Патшага
Алпамша кирәк!

**5**

Кантүрәгә чирү биреп,
Азат казакъ даласына
Качкан, әнә, Карасакал...
Казыктагы Кантүрәне,
Инде хәзер, казак булып,
Бер көтү карга саклар...

Мең угры җәза көтә[16],
Бергә чабар идек башын!
Йә колак-борынсыз килеш...
Түшәр иде кирмән ташын.
Юләр булды,
Ялвармады...
Тугры, имеш, ханына:

«Чабучы булсаң[17],
Баш – менә!
Түгүче булсаң, кан – менә!»

Идегәй токымы, имеш...
Китсәң дә йөз чакрым,
Эзәрлекләп үткәзәчәк! –
Тишеп карый...
Күз чокыры.

Патшабикә ярлыкый ул,
Ялваруларсыз-нисез дә...
Кантүрә яклаган иләт –
Көрәп салган измә генә...
Империя нигезенә!

Болганып кал,
Болгатканда,
Ил җаена изел генә!.. –
Җавап булды бер генә:
«Чабучы булсаң, баш – менә!
Түгүче булсаң,
Кан – менә!»

Императрица ярлыкаса,
Генераллар кызык таба:
«Ак киезгә хан утыртсаң,
Үзең утыр
Казыкка!»

**6**

Гүләде Күк...
Гүелдәде
Тәңре чары, Тәңре чары...
Таңга чаклы
        очты гына
Сөт тамчысы – очкыннары...
Кан тамчысы – очкыннары...

Ай батканчы ак томанга,
Айбалтаның, томса йөзе
Яктырганчы, яктырганчы,
Гүләде Күк! Гүелдәде... –
Үткерләде
Тәңре чары! –
Көн иңеннән чабылганын
Сизми калсын таң кояшы...

Салкын шәфәкъ кискәсендә
Кояш башы белән бергә
Тәкәбберләр янтаешыр... –
Ашар күккә асабалар:
Орынбурда,
Кырылышып,
Ташымадык Җаек ташын!

Юеш зиндан түшәменә
Эленгән дә үрмәкүчкәй,
Юллар юрап, төшә әнә...
Тәңредән хәбәр ташый –
Тоҗым җебен ягып үтә
Мең токынның һәрберенә!

Үзе генә белгән түшәменнән
Төшә-менә, төшә-менә,
Тәңредән хәбәр ташый –
Тоҗым җебен ялгап үтә
Мең токынның һәрберенә!

Бурлатка буяр бу таңны
Шәфкатьсез Сакмар ыстаны, –
Шәфәкъларның Салкын Ташы...
Баскыч санап күтәрелә,
Күтәрелә акрын гына
Такыр башлы
Таң кояшы...

**7**

Канлы чиләк тоткан денщик
Каршыга килә чабып,
Кысык күзе сөенешкән:
«Алексей Иванови-и-ич[18]!

Мулдан бүген сезнең өлеш! –
Колак-борын
Өелешкән!..»

Тамагын кыра полковник:
«Үләксә күрсәтмә, күсәк!
Казна янга
Калдырасы... –
Утарыма алдырасы...
Каторжаннарымны күрсәт!»

Шәмсез шәфәкъ элмәгендә
Төн түмәрен тибү белән
Гаярь башлар чайкалышыр... –

Ашар күккә асабалар[19]:
Чиләбеләрдә
Чиләнеп,
Тасламадык Урал ташын!

**8**

Кантүрәнең
Сараласы
Яфрак кашка
Алып килә шигыремне
Салкын Ташка.

Ат догасы,
Бәддогасы
Чатный ирен җәлпәгендә:
«Тезген чишеп, җәһәт кенә
Кайчан, кайчан,
Әй, яубашым!
Сикерерсең ияремә...
Исәннәрне ияртергә...

Ходай эчеп,
Каплап куйган тустаганда, –
Курдай сеңеп,
Курганнарда ятса гына,
Асманнарга ашкан була
Асабалар...

Җәннәт көтмәс җәлладтан соң,
Җәннәт көтмәс җәлладтан соң, –
Бисмилласыз кассап алар!

Бөек Ефәк Юлы уза
Астан гына...
Бөек Ефәк Юлы уза
Асманнарга...»

Садактагы кыйссаларны
Алып килә Салкын Ташка
Субаш аты Яфрак кашка,
Әрем исе тыннан бөркеп,
Ат догасы укышырга...
Ат догасы укышырга...

Иярләнгән көе йөри...
Иярендә – канҗагасы[20].
Садагында – кыйссалар...
Әзер йөри сугыш аты,
Яуга әзер
Субаш аты! –
Карнай[21] өреп куйсалар.
Тик тезгене сөрлектерә,
Бәйләнмәгән чөелдереп.
«Кайчан, кайчан, әй, яубашым,
Кинәнәбез,
Яуга йөреп!»

**9**

Салкын Ташның каргалары
Көн күзен дә чукып алган... –
Офыктан, канап,
Таң бәрә!
Купты торна кәрваннары...
Кәрван белән бертавыштан
Оранлыйсың, Кантүрә...

«Асабалар!
Асманнарга ашыкмагыз! –
Ашмый торыйк
Асманнарга, асабалар!
Безнең токым
Шыр килмешәк булсын өчен
Туган җирдән
Йолкып алып аса алар...
Актамырлы,
Аксыргаклы,
Ак әремле
Ак йортымны
Кара кизү – караяктай[22]!
Баса алар!

Ни җан белән ашмак кирәк
Асманнарга?!
Ашыкмаек
Асманнарга,
Асабалар!
Сулышларны элмәк кылы
Кыскан сыман, акрынлап,
Телеңне дә, денеңне дә
Кыса алар!
Ашмый торыйк
Асманнарга, асабалар!
Туган җирдә
Шыр килмешәк итү өчен,
Тамыр белән

Йолкып алып аса алар!
Ку сөяге
Курганнарда ятса гына,
Асманнарга
Аша ала
Асабалар!..»

**10**

Ялгыш юлдан китмәс ил-күч:
Курганнар белән каюлы... –
Адаштырмас Себер Юлы.
Илбасарлар кала куймый, –
Күчмә кошка капка куя...
Ал-даш-тыр-мас Себер Юлы:
Илбасарлар
Капкын куя!
Асабалар кулы белән...
Сагаймастан сагаймалы.

Асабалар китереп басар,
Үзе куйган капкынына:
Ни иле булмас!
Ни чиге булмас!
Ни шиге булмас,
Дөнья тоткан урдалардан
Мәскәүләрдә
Урам гына[23]...
Тасраеп калганына...

Ил булып тукылган Рәсәй! –
Җайнамаган постау сыман
Уң ягы көяз киездәй...
Аркау җебе –
Асабадан,
Ил булып, тукылган Рәсәй
Алтын Урда станында!

**11**

Тезгенне тартты полковник:
Салкын Ташта, күлдәвектә
Ялгыз сарала ат тора,
Хуҗасына үрелгән ул...
«Аркан атыйм саралаңа,
Бугалак салыйм, Кантүрә!»

Куып җитеп,
Үткәзәчәк!
Китсәң дә йөз чакрым,
Үтсә дә йөз гасырың...
Тишеп карый субашының –
Урдаларның күз чокыры:
*«Колдан вәзир куйсак та,*
*Колның телен алсак та,*
*Гәүдә түбәндә калды,*
*Баш әле дә синнән югары...[24]»*
Югары
Ике башлы тугра-лачыны[25]... –
Җучи Олысының
Тугры лачыны!

Ничек инде
Ил-йортыбыз булмасын, ди?! –
Түбәсендә һаман да
Урда туграсы...
Әй, Рәсәй,
Күкләр пышылдагандыр сиңа:
Алтын Урда станында,
Уртак илкәй булып,
Тукыласыңны.

**12**

Ил арбасы
Тараласы түгел иде... –
Орыласы Орлары
Орды гына!
Ягалардан килгән
Илдә ага булса,
Ил арбасы кала
Утын урынына!

Тугландык Урданың
Яу гөбеләрендә:
Тулар туглый-туглый,
Тугыз буын тугландык:
Булатлы Болгардан,
Пычаклы
Кыпчактан,
Урманлы Угырдан,
Тугайлы
Нугайдан, –
«Җиһаннан Җыйганнан»,
Йомарламга калып,
Атланмайдай төште
Ханлыкларда халык!

Ил арбасын тартып,
Тауга менгән идек...
Төшүләре хәтәр икән... –
Тугарылдык!

Ничек инде
Иле-көне калмасын, ди?!
Биш империя
Корган гаярь токымның[26]...
Әй, Рәсәй!
Син ул Алтын Урда станында,
Кырыс татар
Ырысы булып тукылдың!

**13**

Тау салмасаң, таптап үтә,
Җигелгәнне
Тапап үтә! –
Тау төшкәндә, тоталмадык,
Тоталмадык ил арбасын!

Чырсызланган чорданмы ул,
Кан костырган Орданмы ул?!
Аягүрә торганмы ул,
Арканчыны органмы ул?! –

Ияр-аркан сөйрәп кайта...
Кантүрәнең Сараласы!
Ил арбасы
Тараласы түгел иде, –
Эх, тоталмадык,
То-тал-ма-дык!!!
Ил арбасын.

**14**

...Елизавета Петровна[27] шәм куйдырды. –
Шом йөгерде!
Шом йөгерде!
Йөрәгенә:
Томсалаган... Консыз калган...
Казан Ана
Иконасы!

---

[1]Кантүрә – Карасакал гаскәрендә төмән башы, милли азатлык хәрәкәте каһарманы, Солтангәрәй хан казакъ даласына ярдәм эзләп киткәч,сигез төмән гаскәрне әйдәгән субашы (1700 – 1740, 25 август).

[2] Кирмәт – кирәмәт, бозым.

[3] Әлфирак – озакка аерылганда әйтелүче сүз, аерылышу җыры.

[4] Солтангәрәй – Карасакал – Күчем хан нәселеннән булган каһарман морза.

[5] Дәште Кыпчак, Алтын Урда, Нугай Йорты – V-XVIII гасырларда бер-бер артлы дәвран сөргән татар дәүләтләре.

[6] Турагач – ау лачыны куначасы.

[7] Төкле Аяк – Туктамыш ханның ау лачыны.

[8] Бидаяк – ау эшенә ярамаган тилгән.

[9] Ор кала – Орск шәһәре.

[10] Карасакал лачыннары – тарихта «Карасакал явы» дип йөртелгән баш күтәрүчеләрне, патша гаскәрләре килеп тар-мар итә.1740 елның 25 августында Ор каласы тирәсендә Карасакалның төп ярдәмчеләре булган типтәр Кантүрә; башкорт, мишәр, нугайлардан Юныс Исмәгыйль улы; Җыянгол Үсәкә улы; Карабаш; Якуп Касыйм улы тимер казыкларга утыртыла.Унбер кеше, җанбашларыннан тимер ыргак кертелеп, асылганнар; сиксән биш кешене бауга асканнар, егерме бер кешенең башларын кисеп, колгага такканнар.

[11] Полковник – башкорт халык җырында каргалган Тәфтиләү – Котлымөхәммәт Мәмеш улы Тәфкилов (Алексей Иванович Тевкелев) чукынган морза, алпавыт, дипломат, тылмач (1674 – 1766). Тәфкилов 1735-40 елларда Себер һәм Нугай юлларындагы бәйсезлек күтәрелешләрен бастыруда катнаша.

[12] Камкагач – камка (көнчыгыш шивәсендә): «Камкагач, киявең килә, капкаң ач!»

[13] Тәфтиләү үткән авыллар – җәза гаскәрен җитәкләүче урыс генералы А.И.Румянцевның раславына караганда, тылмач полковник тыныч халыкны җәзалауда зур тырышлыклар күрсәтә: меңгә якын авылны яндыра; 1736 елның март-апрель айларында гына да 503 авылны җир белән тигезли, 10 меңләп кешенең җанын кыя. Саннарда генерал ялгышмас... Әмма чын җәллад генерал үзе түгел микән: мемуарында Тәфкиловны шулай искә алып, канлы кулларын штаб тылмачының дары исе сеңмәгән кителенә сөртеп калдыргандыр сыман.

[14] Салкын Таш – җәза урыны.

[15] «Ата-бабам Чыңгыздан» – Тәфкиловның нәселе Чыңгыз ханнан килә.

[16] «Мең угыры җәза көтә,» – генерал В.А.Урусов (Нугай Йортыннан килгән Арыслан би токымыннан) җитәкчелегендә Орынбур янындагы Сакмар станында да меңләп каһарманны җәзалыйлар: 1740 елның 17 сентябрендә генә дә 120 каһарманның башы чабыла, 50 яугирне асалар, 301 тоткынның борын-колакларын кисәләр.

[17] «Чабучы булсаң...» – «Идегәй» дастаныннан.

[18] Алексей Иванович – Тәфкиловның чукынгач алган исеме.

[19] Асаба – җирле халык, төп халык.

[20] Канҗага – ияр артына тагылган күн капчык.

[21] Карнай – яу быргысы.

[22] Караяк – үсемлекләрнең сабаклары каралудан гыйбарәт авыру.

[23] «Урам гына...» – Ордынка урамы.

[24] «Колдан вәзир куйсак та, Колның телен алсак та...» – «Идегәй» дастаныннан, татарның киләчәген күрәзәлек кылган юллар.

[25] «Югары ике башлы тугра-лачыны…» – «Карасакал явы»н бастыручы җәза гаскәре – драгун гвардиясенең байрагына да Чыңгыздан калган ике башлы бөркет – «дәүләт кош» туграсы чигелгән.

[26] «Биш империя корган токым…» – төрки бабаларыбыз төзегән Кушан, Дәште Кыпчак, Күк Түрк каганаты, Алтын Урда һәм Нугай Йортының Мәскәү олысыннан азган Россия империяләре.

[27] Елизавета Петровна – императрица.

## Кайтып илен тапмаса

*Айдан якты нәрсә юк –*
*Кара болыт басмаса,*
*Адәм гарибә[1] шул булыр –*
*Кайтып илен тапмаса!*
«Идегәй» дастаны

Тим Чуарга
Өч юл туры, таңга чаклы:
Казлар Юлы,
тугай юлы,
тулы ай юлы... –
Ураулы догалары шаукымыннан
Әби чәчләре[2] белми дә тураюны! –
Өч юлның да яктысында шау коенган
Ач әрвахларга[3] ясин чыга,
Ач әрвахларга ясин чыга
Томан җәйгән Нугай Юлы.

Чыгын җыймас, өмет җуймас,–
Көтеп туймас Нугай Юлы!
Иләтеңнең һаман таңы
Сызылмаган...
Мәскәүләрдә
Ханзадәсен чумыргач та,
Иконасын «лач» үбеп!
Чаң сукты Казан...

Чаң суктылар Кирмән тауда! –
Тау астында,
Саз астында...
Каугасын сукты Ташаяк[4]!
Күтәреп куям, дип аен,
Күтәрелеп чыккан саен,
Батса да канга... –
Башаяк!

Казаннарны,
Чукындырып бастырганда,
Нугай Йорты инде чыкмас, кубарылып.
Ничек кенә каелмассың ак өметкә?! –
Ил атлары торса синдә!
Тугарылып...

**2**

Ак өметкә каюланган Нугай Юлы,
Ил арбасы
Кайсы чатта соң орылган? –
Җаеклардан
Җайлап кына чыгалмаса,
Кырылыплар чыкса чыга... –
Каерыла иде Урда[5]!
Кырымнан...

Кичке таңга каюланган Казлар Юлы,
Синнән дә
Ак дүнәндә[6]
Тәңре үткәндер! –
Кара гавам сәҗдә кыла ак кылганда...
Тун кигән би
Күтәрелми
Атыннан да, –
Мәскәүләрдә, көмеш алып,
Тәре үпкәндер!

Өметләрнең аҗаганы сүрелсенгә,
Асаба җан асманнарга үрелсенгә,
Тәңре Азак-йортын, әйе,
Күпсенәчәк! –
Ак өмет кузлаган кара күзләргә дә,
Диңгезләрнең
Тере суын,
Тозсызлатып,
Нур-тәресе чекрәйгән!
Күк сеңәчәк!

**3**

Ак томаннар чатыр корган Тугай юлы,
Таң йокысын саклап тора артышларың.
Дошман явы[7] камышларга кереп посты!
Җәйләү халкын
уятырга
соңармасмы? –
Сорнайларын суга сонган саз кошлары...

Кирмәнчектә[8]
Сазлык кына саклап тора:
Колыннарын
урап баскан
атлар сыман.
Килгән җайга кысып алды дошман явы! –
Коелышты җәйләү халкы
Яр астына...

Кашлакта тора фельдмаршал[9]! –
Аптырамас,
Мең учаклы җәйләү халкы азлыгына.
Ярлар буйлап
өркеп чаба
атлар гына:
Сабый кочкан карт-корылар тула әнә! –

Шом сулаган
Алыпсуы сазлыгына.

Кирмәнчектә
Сазлык кына саклап тора:
Колыннарын
урап баскан
атлар сыман.
Яр өстендә драгуннар тынып калган:
Күтәрелгән томан гына... –
Яр астында!

Томаннардан ак биләүсә суза куллар:
«Ал, Ходаем!
Күккә генә – кол булганны...»
Җанны ярып,
Кешни яр буйлаган атлар! –
Каян белсен алар:
Батып...
Котылганны...

**4**

Дала баласында әле,
Тәңре исән! –
Өмет баглый офыктагы кара көнгә:
Өзелсә дә,
Сулышыңны ялгый Тәңре,
Сирпелеп, таң сидерәгән
Караңгыга!

Томаннардан ак биләүсә суза куллар!
«Ал, Ходаем!
Күккә генә –
Кол булганны!»
Атлар әле яр буйлатыр.
Тим Чуар да ял уйнатыр.
Ат бит ул!
Белеп туадыр:
батып кына... –
котылганны!

Кичә баткан бурлат кояш бүген калка! –
Ялларында –
Төннең сазы.
Сүсән исе.
Тим Чуарның ак җайдагы җыеп узар
Томаннарның
саз сеңмәгән
биләүсәсен:
Ханбикәләр газабы ул! –
Ак итәргә. Ак китәргә,
сазга бату газабы.
Ханбикәләр газабы ул! –
Җанга газап салган илдә
җәзалану газабы.

Томырылды ат кешнәве, җанны ярып:
– Тамырланды убырлы ил сазлыклары! –
Асау – горур
Ыруларны
Аска орыр!
Убырлы ил
сазлыклары:
Асау ыру – коланнарың, –
Аһ! Ханбикәм,
Озак торыр.

Колы итеп,
Колыныңны[10] озак тотыр! –
Кылкындырып,
Газаплатыр
убырлы ил
сазлыклары.

**5**

Газапланыр!
Ак җайдак та:
Урап кайта Кирмәнчеккә, –
Көзге томан төшкән чакта,
Кичкырынлап...
Төнге утлауга ак толпар җибәрә ул,
Шулай тонык шәм кабыза җилләрдә ул! –
Таланган курганның...
таллы
кучкарында...

Сорнайларын суга сонган саз кошлары
Саташыплар уяна да
Сантый булып кычкыра.
Саз кошлары шашкандыр ул:
Саз төпләре гөбесеннән
Сабый булып кычкыра,
Сабый булып кычкыра,
Убып-убып кычкыра!

Бүз йолдызлар!
Суворовның
Тоз саркыган күзләредәй,
Азак дала көзләренә,
Һаман өстән карыйсызмы?
Сабый сөякләре белән
Һич кенә юк агарасы,
Сабый сөякләре белән!
Һич кенә юк!
Агарасы!
Империя тарихының
Нугай Йортын эзсез йоткан –
Татар баткан кара сазы.

Кирмәнчекнең киртләч-киртләч саз өсләре,
Шомаланып агып яткан Алыпсулар

Ак биләвен чылатмаган томан төшсә,
Авыр сулар...
Ханбикәдәй...
Авыр сулар...

**6**

Ак өметкә каюланган Нугай Юлы,
Ил арбасы калды синдә, –
Тугарылды.
Урдалары орылсын дип, –
Имән көпчәк тырнагыдай
Иләтләре шартлап сынсын,
Тернәкләнми кырылсын дип,
Баганалар утыртылган, Нугай Юлы,
Ил арбасы синдә тора! –
Тугарулы...

Нугай Юлы кайдан уза, дип сорама, –
Казлар уза!
Төбәкләрдән төбәкләргә... –
Ил-йорт Өлкәрен
Гел өстә дөрләткәнгә...
Баш каерып,
Ят юлларда йөри-йөри,
Йөдәүләрдән
йөгән өзгән
йөрәкләргә...
Ай юлларын
Җәеп куйган тугай юлы! –

Кара баганалар багар, Нугай Юлы,
Иләтемнең алда таңы сызылмаган:
Шомландырган
Бурлат шәфәкъ төянгән дә
Иделләргә
чыга төрбә
Казансудан[11].
Ханнарына
Кирмән тауда һәйкәл дә юк.
Ил хакында,
Тел хакында әйткән дә юк! –
Сызланам да!
Уңайсызланам:
Иләтемнең һаман таңы сызылмаган...

Таңга чаклы!
Тим Чуарның өч юлы бар:
Тулган ай юлы, Каз Юлы,
Тугай юлы...
Өч юлның да яктылары сиңа ята,
Ак өмет белән каюлы,
Кара баганалы юлым –
Әй, Нугай Юлы!
Ил өметен хаклап, юлга чыккан саен
Тигез җирдә, –
тигез илдә
гел дә абындык! –
Ак өметнең юлы һаман хәтәр әле:
Кара баганалы икән ак өмет,
Кара баганалы! –
Илсез ак өмет.

**7**

«Сөен Бикәсез Казаным
Көенгәндер, көенгәндер:
Сөен Бикәсез Казаным
Коеннарда коенгандыр –
Кара канда коенгандыр.
Сөен Бикәсез Казаным,
Болытында кибә яңгыр!
Болытында кибә яңгыр!
Болытында кибә яңгыр! –
Ходайның ул
күз яшьләре
сибәлидер.
Казансудан ага сабый биләүләре... –
Күпме соңгы сулышларны беләүләтеп,
Кара бәсле туң йөгергән
саз каплады!
Ханбикәнеке! – газабың:
Сазы йотса, калкытмас,
Кипмәс татар газабы.
Ханбикәнеке! – газабың:
Болыт тотса, балкытмас,
Китмәс татар газабы.
Казан янды!
Казалардан кара янды!
Өстен күрде
Сабый кочкан килен-күнчек,
Ак көенчә,
сазга батып,
котылуны:
Әле дә бит шомлы ага Казансулар... –
Томаннардан
Ак биләүсә суза куллар:
«Ал, Ходаем!
Күккә генә – кол булганны...»

**8**

Томаннардан ак биләүсә суза куллар!
Таныйсыңмы?! Таныйсыңмы?!
Күптәнге дип, танмыйсыңмы?!
Ханзадәнең – җәүһәр җебе
Сидерәмәс биләүсәсен:
Алтын кушып,
Тамбурлатып чиккән иде... –
Үтәмешен табуларын көткән иде...

Татар илен!
Тануларын!
Көткән иде! –
Әманәтнең вакытлары чыккан инде.

Алдап,
Алданган хан да
Тончыккан инде!
Татар татарны алдый, ни хәл итәсең... –
Татар татарны камый, ни хәл итәсең... –
Таш өстендә таш калмый,
Ни хәл итәсең?!
Көпчәктәй түрәчектән
Чүт-чүт биек баш калмый,
Ни хәл итәсең?!

Ак җайдак та кайтыр юлга чыккан инде! –
Нугай Юлы көтеп
Талчыккан инде
Таң узып
җилдерүче
Сөен Бикәсен!

**9**

Ил өметен хаклап, юлга чыккан саен
Тигез җирдә, –
тигез илдә
гел дә абындык! –
Ак өметнең юлы һаман хәтәр әле:
Кара баганалы әле ак өмет,
Кара баганалы илдә! –
Ак өмет.

Төн тоягы болыт кыйган Нугай Юлы!
Иләтеңнең әле таңы сызылмаган.
Шомландырган бурлат шәфәкъ төянгән дә
Иделләргә чыга төрбә Казансудан.

Шомрап ага
Шомландырган Казансулар:
Томаннардан
Ак биләүсә суза куллар!

Сабый булып, саз кошлары кычкырадыр!
Тәкәрлекләр
Казан сазын келәүләсен:
Йоткан чакта тынчу кирмән сазлыклары...
Ханбикә дә,
Азанлы күкне сызландырып,

Кызгансын дип,
Ходаена сузгандыр ул, –

Казгансын дип,
Нугаена сузгандыр ул...
Казан ханы
Үтәмешнең
биләүсәсен.
Шомрап ага
Шомландырган Казансулар:
Томаннардан ак биләүсә суза куллар, –
Томырайган ак биләүсә суза куллар! –
Күтәрепләр алмыйсыңмы?
Ник күтәреп алмыйсың?!
Ник күтәреп алмыйсың?! –
Томаннардан ак биләүсә суза куллар!
...Ак биләвен,
Тамбурлатып чиккән иде... –
Үтәмешен
Табуларын көткән иде...
Татар илен!..
Тануларын!..
Көткән иде!..
Шомлы ага
Шома сулы Казансулар:
Томаннардан ак биләүсә суза куллар, –
Тупылдаган ак биләүсә суза куллар! –
Күтәрепләр алмыйсыңмы?
Ник күтәреп алмыйсың?!
Ник күтәреп алмыйсың?! –
Ак биләүдә...
җил биләмәс...
Казансулар...

---

[1]Гарибә – моңлы, кайгылы адәм.

[2] Әби чәчләре – дала кылганының чал ефәк чәчлесе.

[3]Ач әрвах – догаларга сусаган мәрхүмнәр рухы.

[4] Ташаяк – кирмән белән Болак арасындагы борынгы Казан урамы.

[5] Урда – Нугай Йорты.

[6] Дүнән – дүрт яшьлек ат.

[7] Дошман явы – 1783 елның 8 апрелендә Екатерина II нугай татарлары күпләп яшәгән Кырым, Кубань, Таман җирләрен Рәсәй биләмәләре дип игълан итә. 1783 елның 31 июлендә нугайлар баш күтәрәләр. Үз илен, ирекле Нугай Йортын саклап калу теләге шул кадәр көчле була ки, җәя-кылыч тотып, империянең мылтык-туп белән коралланган гаскәренә каршы ике ай дәвамында көрәшәләр.

[8] Кирмәнчек – Алыпсу тамагыннан (Кубансуның сул кушылдыгы) 12 чакрым югарыда тугыз курган белән уратып алынган борынгы шәһәрчек-кирмән урыны һәм сазлык.

[9] Фельдмаршал – 1783елның 12 октябрендә, баш күтәрүчеләр күпләп җыелган Кирмәнчеккә көтмәгәндә һөҗүм итеп, фельдмаршал Суворов җиңүгә ирешә.

[10] «Колы итеп, колыныңны...» – Сөен Бикәнең Мәскәүдә әсирлектә үлгән улы – Үтәмеш Гәрәй хан (1546 – 1566).

[11] Чыга төрбә Казансудан – Казан каласын яулаганда һәлак булганнар төрбәсе. Биредә христианнар белән бергә Шаһали яугирләре дә җирләнгән.

## Кисектел кыйссасы

*Сөт китәр дә ни калыр?*
*Ак күкрәктән сөт имгән*
*Сүзе татлы тел калыр;*
*Тел китәр дә ни калыр?*
*Буында типкән кан калыр;*
*Буыннан буын чабылса,*
*Ул чагында ни калыр?*
«Идегәй» дастаны

Бөгелү
Белмәс
Беләгеннән
Көчкә тотты өчәр кеше.
Аямаган
Аягыннан
Өркеп тотты дүртәр кеше!
Чонтык палач килде аксап,
Өйрәнчеге – сары малай
Килде,
Келәшчәсен күтәрешеп.

Карт иелде Батыршага[1],
Көлде күзе өркебрәк:
«Исемеңә
Җисмең лаек,
Әмма миңа
телең кирәк...»

Читтә салкын тиргә батып
Торды малай...
Карт үзе
Кысты,
Тартты келәшчәне...
Соры балку сарды йөзен –
Алды гүя
Заманаың
Бугаздан ук
Телен өзеп!
Киләп сарды каһкаһәсе:
«Канлы учта, кисәк-телем!
Тыпырчынып кисәтүең:
Хәтере бар татарларның –
Хәтәре бар татарларның,
Хәстәрләнеп үсәр теле:
«Эт көненә калдык!»[2] – диеп,
Үрсәләнеп искәртүең...

Ха, Мәзгетдин[3]!
Денне түгел,
Телеңне дә
Яклый алмадың син[4]...
Әйдәп кара[5],
Әйт сүзеңне,
Чыкмас хәтта сыңар аваз!»

...Авырткан
сүзен
кабатлады
Өнсез кыңгырау күк авыз...
Бозлы тиргә батып,
Читтә
Торды малай, торды күреп:
Йодрыкны кайрып ачты –
Кычкырды тел:
«ИРЕК!»

Киерелеп сукты тавыш[6]! –
Зинадан да
Иске зиндан
Бер таш аска китте иңеп:
«ИРЕ-ЕК!!»

Киерелеп сукты тавыш,
Тавыш сукты киерелеп! –
Дер селкенде Кышкы сарай:
«ИРЕ-Е-ЕК!!!»

Акшар-тузан төште кубып
Елизавета ятагына –
Кабаланып торды икәү,
Кагына-кагына...

Батырша кан йота...
Йота...
Бугаз аша, йөрәк аша
Авырта сүз, сызлана сүз –
Әйтә алмый.
Ыңгыраша.

Телен әнә әбәткә дип,
Ыргыталар бурзайларга...
Ыңгыраша...

Җирән бояр ындырында
Ярлы-ябагайлар да,
Кара мари урманында
Лашманчы агайлар да,
Төштә генә тимерчеләр[7] –
Такыр башлы малайлар да
ыңгыраша,
ыңгыраша,

Ыңгыраша –
Ничек әйтер «ИРЕК» сүзен,
Ничек илтер чорлар аша
Ул хак сүзне онытмыйча
Алар?!.
Телне әнә, әбәткә дип,
Бурзайларга ыргыталар.

Ыргыттылар!
Инде ничә гасыр очам.
Бурзай этләр кала өреп.
«Яфрак!» – диләр... – Корымасмын! –
Мин, Батыршаның теле,
Торыннарга оран салдым:

«ИРЕК!
ИРЕК!!
ИРЕК!!!»

Бурзай этләр тагын өрә,
Селәгәен бөркелдереп:
Халыкларның телен кискән
Заманалар бара кереп!

Империя бурзайлары
Ил-көнемне
каравыллый:
Коштабагын ялый-ялый,
Күзләремә карап улый...

[1] Батырша – Баһадир шаһ, Габдулла Гали улы (1710 – 1762, 24 июнь.) Милләт һәм дин иреге өчен яуга өндәгән каһарман.

[2] «Эт көненә калдык» – 1742 елның 19 ноябрендә Сенат Ислам диненә каршы указ чыгара. Шул вәхши фәрман үтәлеп, татарларның барлык мәчетләре юк ителергә һәм яңалары төзелмәскә тиеш була. Мәсәлән, Казан губернасында гына да 536 мәчетнең 418е юк ителә, Казан һәм Орынбур губерналарында 270 мең кеше көчләп чукындырыла.

[3] Мәзгетдин – «денне яклаучы» дигәнне аңлата, Батыршаның үзенә алган кушаматы.Чиновниклар аны, фамилия дип уйлап, «Мазгилдин» рәвешендә документларга теркәгәннәр.

[4] «Телеңне дә яклый алмадың син» – Батырша явы империя гаскәрләре тарафыннан бастырыла. Батырша хәзрәт һәм аның якыннары җәзага тартыла.1758 елның декабрендә камчы суктырылган, борыны кисеп алынган Батыршаны гомерлек каторгага – Шлиссельбург крепостена ябалар. Анда да ул христиан руханилары белән бәхәскә керә! Бәхәс җиңүче хәзрәтнең телен кисү белән тәмамлана...

[5] «Әйдәп кара...» – Габдулла хәзрәт яшәгән һәм эшләгән төбәк – Нугай юлы халкы, хәзрәтләренең өндәмәсен хуплап, яуга беренчеләрдән дәррәү күтәрелә һәм патша гаскәрләре белән көрәшне ахыргача – 1756 елның язына тикле дәвам итә.

[6] «Киерелеп сукты тавыш» – 1762 елның 24 июнендә Батырша, төрмә сакчысының балтасын богаулы кулларына тартып алып, соңгы яуга ташлана – дүрт сакчыны чабып үтерә һәм үзе дә һәлак була.

[7] «Төштә генә тимерчеләр...» – Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татарларга тимерчелек һөнәре белән шөгыльләнү катгый тыела.

## Җиләкле учак урыннары

*Куш канатлы алтын таҗ,*
*Күз урынында гәүһәр каш,*
*Чыңгыздан килгән дәүләт кош*
*Бу башымда түгелме?!.*
«Идегәй» дастаны

Ут телендә сөйләшкәннәр төнлә таулар!
Чатыр таудан хәбәр салса олуг учак,
Далага җитеп сибелгән Ык дисбесе –
Каравыл таулары, берсен-берсе
Кабатлый-кабатлый кабыначак.

Кабыначак!
Кара диңгезләргә җитеп...
Баешларда күләгәләр сагаюлы:
Тәңренең гүзәл исемнәрен кабатлый,
Җемелдәп кабатлый, әнә, Нугай Юлы...

Төпсез күккә
Төбәлешкән
Төндегеннән
Мең ел буе төтен бөркеп, очкын өргән
Нугай тирмәләре,
Кыпчак чатырлары...

Киек Каз Юлыннан бер генә кайтаваз:
Учак чатырдавы...
Учак чатырдавы...

Ут телендә сөйләшкәннәр төнлә таулар!
Сүз башлаган
Ак чатырлы
Чатыр тавы...
Ык йортыннан,
Туктамышка хәбәр илтеп,
Таң атканчы, таң атканчы Кырымга бар! –
Ямчылардан
«Җем-җем» таулар күпкә җитез, –
Яктылыкны иярләгән борынгылар!

Шәфәкъ ястыгына батып...
Чалкан ятып,
Күкнең кыйссасынмы укый Чатыр тавы?! –

Киек Казлар кыйссасының башы гына:
«Учак чатырдавы...
Учак чатырдавы...»

Чатыр таудан хәбәр салса олуг учак, –
Таулар гына булсын, –
гөлтләп кабыначак!
Булмаса тауларың,
Яса өмә! –
Өй курган:
Күкләргә якынрак торган
борынгылар! –
Даласында күпме мәңгелек өй корган...

«Беттек!» дигәндә дә,
Ачылып киткән дөнья, –
Утлар бөркеп,
Юл күрсәткән кәрван таулар;
Кырчанында кырык буын кәлтә үсеп,
Дәү аждаһа булып җиткән

Төпсез күккә
Төбәлешкән
Төндегеннән
«И Тәңрем!» – дип,
Төтен бөркеп, очкын өргән
Нугай тирмәләре, кыпчак чатырлары...
Киек Каз Юлыннан
Бер генә кайтаваз:
Учак чатырдавы... Учак чатырдавы...

Кашлагында Ак чатыры тормаса да,
Ут телендә телгәләнә Чатыр тавы.
Җан ишетә ут телендә эндәшкәнне –
Кайчак Казаннарга җитеп ишетелә,
Актарылып,
Ак чатырын
Чакырганы...

Булган заман,
Туктамыш хан
Тауларга да салган оран:
Кара диңгез ярларыннан
Кубарылган Чатыр Дагы[1],
Унҗиде мең арбаларда
Кубарылган!

Җай Ык буйлап кашлак таулар өя-өя,
Дала үтеп, Чулман – Ыкта тугарылган...
Сай Ык буйлап кантар таулар коя-коя,
Төмән-төмән нугаеның
Иңнәрендә килгән гүя! –
Безнең яклар өчен
Күптән «Чатыра!» ул,
Ак чатыр корырга,
Күптән чакыра ул,

Чакыра тау, Чатыра тау! Чатыр тавы!
Җан ишетә ут телендә эндәшкәнне, –
Кайчак Казаннарга җитеп ишетелә,
Ачыргалап,
Ак чатырын
Чакырганы.

Караңгы төн...
Айбалтасы юка иде.
Хәтеренә уйды микән Чатыр тавы:
Ак чатыры бурлатланды Йосыф бинең[2] –
Зәһәр иде баш учакның чатырдавы!
Таңнар сизелүгә...
Сүзен әйтте Йосыф, –
Хәбәр салды шундук!
Таулар телеграфы:
«Хатын-кызның
гайбәтендә
казынсагыз,
Дуңгызларга калмагае...
Казаныгыз[3]!»

Төннең тулай ястыгына кулай ятып,
Якты кыйссанымы ятлый Чатыр тавы? –
Төн уртасы җитеп килә, төн уртасы...
Кыйссаның да инде җитте төп-уртасы:
«Учак чатырдавы...»

Сөен Бикәч җиләк җыйган Чатыр тавы!
Безнең яклар өчен күптән Чатыра син.
Еракларда танып алып чакырасың... –
Туган ягым шәфәгында
«Табын корган» ыру-тамга:
Ил-йорт җыйган Чатырам син...

Илем-көнем сау булмаса,
Хәбәр йөртер тау булмаса,
Сүнмәс өмет –
Өлкәр[4] аша
Күк телендә чакырасың...
Тергезергә, ак тирмәне, –
Ил-дәүләтең чатырасын!

Күкнең телен онытмаган әле таулар!
Чатыр таудан хәбәр салса безнең учак,
Офыкка җитеп сибелгән Ык дисбесе –
Шәфәкъ йолдызлары берсен-берсе
Кабатлый-кабатлый кабыначак.

Кабыначак!
Җиһан түрләренә җитеп,
Күкләрдә дә
Күләгәләр сагаюлы...
Тәңренең гүзәл исемнәрен кабатлый,
Җемелдәп кабатлый
Киек Казлар Юлы...

Ай лампасын,
Күз чакмаслык
Кыса төшеп,
Күк кыйссасын һаман укый Чатыр тавы. –
Киек Казлар кыйссасының инде соңы...
Ак чатырда йоклый алмый яткан Сөен,
Тыңлыйсыңмы, тыңлыйсыңмы? –
«Учак чатырдавы...»

Чатыр тавы... –
Кара диңгез ярларыннан
Кубарылган[5] Чатыр Дагы,
Унҗиде мең арба белән кубарылган!
Дала үтеп,
        Ыкка җитеп,
                тугарылган...

Тауларын да
Үзе белән йөрткән халык... –
Алып килгән Кара диңгезен дә...
Түмән-түмән алып!

Акчарлаклар төшкән сиңа,Чатыр тавы:
Иләтенә киңлек даулау –
Бар тыкырдавы:
Ак күбекле кылганнарың калгышында,–
Тыңлыйсыңмы? –
Дулкын шыбырдавы!..

Гадәтләреме борынгы вакыттагы:
Акчарлаклар төшкән сиңа, Чатыр тавы!
Кычкыралар,
Диңгезләрдән җил чакырып, –
Бу яхшы фал, ди аяз күк чатырдавы!..

Ил-көнгә ак җилкән иде
Ак Чатырың... –
Акчарлаклар төшкән сиңа, Чатыр тавы!

Безнең яклар өчен күптән Чатыра син,
Ераклардан танып алып
Чакырасың,
Чакыра тау, Чатыра тау! Чатыр тавы.
Җан ишетә үз телендә эндәшкәнне, –
Кайчак Казаннарга җитеп ишетелә
Ил Чатырын...
Ак Чатырын...
Чакырганы[6]!

Чатыр тауда ут кузыдай җиләк җыеп,
Йөри әле, Сөен,
Синең дә балачак...
Чокыраеп тора учак урыннары... –
Чатыр таудан хәбәр салса хәзер учак,
Офыкка җитеп сибелгән Ык дисбесе –
Шәфәкъ йолдызлары, берсен-берсе
Кабатлый-кабатлый, кабыначак.

Кабыначак!
Сары диңгезләргә җитеп,
Кабыначак!
Алып тауларын да үтеп,
Баеш тарафлары һаман сагаюлы:
Кара төндә Нугай Юлын чалымларсың...
Чатырада Ак Чатырны сагымларсың...
Әй, сүнмәс өметкәй,
Киек Казлар Юлы!

Ям учагын
Яман яңгыр
Яткыргандыр...
Ям хәбәрен
Ялгыш алган кара яңгыр,
Соңгы ханбикәдән соңгы хәбәр сөйләп,
Канча еллар елый-елый яктыргандыр...

«Беттек!» дигәндә дә –
Дөнья яктырганын!
Тәккә генә түгел инде синең тәкрарлау,
Әй, Чатыр тау, Чатыра тау,Чатыр тавы:
Офыклар
    синдә кузгала!
            Чигенгәләп...
Килеп җитте, килеп җитте асыл хәбәр, –
Учак урынында кузлана!
Ачы җиләк...

---

[1]Чатыр Даг – Кара диңгез буендагы тау, Азнакайдагы Чатыр тауның адашы.

[2] Йосыф би – Нугай Йортының Агыйдел белән Чулман тугайларында җәйләүдә йөрергә яраткан хәрби түрә, Сөен Бикәнең әтисе.

[3] «дуңгызларга калмагае Казаныгыз...» – кул астында йөз мең гаскәре булып та сул канат нуретдине Йосыф бәк Казанны ни өчен якламаган? «Мәскәүгә каршы төшсәң, үзем гаскәремне сиңа борам!» – дип кисәткән бертуганы Исмәгыйльдәме сәбәп? Әллә ханбикәнең итәк астын тикшергән, гайбәт сазлыгында казынган Казанның үзендәме?!.

[4] Өлкәр – Иләк йолдызы төркеменең борынгы атамасы.

[5] «Кубарылган Кара диңгез ярларыннан...» – Кара диңгез, Кырым, Төньяк Кавказ якларыннан, мал-мөлкәтен унҗиде мең каңгы – зур арбаларга төяттереп, Туктамыш хан XIV гасыр ахырында йөз меңләп нугай татарын Идел – Урал төбәгенә күчерә.

[6] «Ишетелә ил чатырын... чакырганы...» – Алтын Урда татарлары – нугайлар, тора-бара Нугай Йортына караучы Болгар олысының көнчыгыш өлешен тулаем үз итеп, Идегәй һәм соңрак аның нәселләре кул астында дәүләт тоталар.Чулман һәм Агыйдел елгалары арасына таралып, ил-йорт тергезгән Нугай Йорты, татар халкының матур телле – «сөт салынган чәй шикелле йомшак» телле көнчыгыш шивәсен «талгын кайнатучы учак» булып, Казан ханлыгы алынгач та, озак еллар кузларын сүндермичә, «баш күтәргәләп!» янып-калгып тора.

# Ырудашым чабыр үлән

*Күрекле туган сылуны*
*Бикәч итеп алган йорт,*
*Ак бөркәнчек салган йорт,*
*Ал иннеген яккан йорт,*
*Кызыл мәрҗән таккан йорт,*
*Каплы камка[1] ерткан йорт,*
*Ун сан[2] нугай җыйган йорт,*
*Өлкән бер туй кылган йорт,*
*Әл-аман бул миннән соң!*
«Идегәй» дастаны

Тын елгадан –
Тубылгача!
Курган-курган дулкын куган
Офыкларны ача-ача,
Дәште Кыпчак диңгезенең
Купшак сулыш тигезләве:
Бастырып,
Упмас дулкыннарны,
Купмас дулкын атуымы?! –

Таш маңгайлы
Нугай тауда,
Ак күбекле кылган шавы...

Кушылып, кояш гөсләсенә,
Ил-йорт исен исәйткәндәй,
Чабыр үлән
Шыбырдавы...

Чал кояшка
Чалкан төшеп!
Хан шоңкары
шаңравы...

Ил-иләтне харап итеп,
Җилләр сөргән кораб итеп,
Тугыз упкын йотуымы?! –
Мәңгелеккә өретелә:
Соң сулыштай
Күтәрелә...
ак тузганак...
Ык тугае...

Нугай тауның сукмагында –
Оя-оя чабыр үлән –
Нугай Ана торыннарын
Табаныннан таныр үлән:
«Казаннардан кайткан углан,
Сөенемнән хәбәр юкмы?
Сөен Бикәч,Сөенемнән...»

Нугай тауның сукмагында
Калмастыр ла чабыр үлән, –
Даласыннан җил исүгә,
Оя-оя кубарылган.

Кубарылган табыр белән! –
Кубарылган тамыр белән,
Шаулы диңгез күбегедәй...
Төпкелләрдән иңгән гөлнең
Хуш искәен исәйтергә,
Җитми, илкәй,
Киңлегең лә,
җитми инде
киңлегең!

Ярсуланып,
Яр салдырды[3] аргы ярдан
Курган-курган
Дулкын орган
Дәвран заман:
«Сыгылдырган! Агышыма!
Сытып узган! Агышыма! –
Кырык үгез каршы тарта...
Кан чакырган!
Хан чатырын...»
Урау чорлар чакырымын!
Чорналдырып,
Якынаймаган...
тәгәрмәч
тавышына.

Тын елгадан –
Тубылгача
Курган-курган дулкын куган
Офыкларны ача-ача,
Дәште Кыпчак диңгезенең
Купшак сулыш тигезләве:
Ил сулышы
Кысылгач та,
Тын алулар булгалады... –
Буып алды!
Нугай Йортын
Кырыс
Кырым
бугалагы,

Бугалакны урап торткан, –
Оттырып та,
Отыры
Откан
Олуг Мөхәммәт хан[4]! –
Олысларын җай сулаткан
Соңгы татар ханы...

Ярып узган урман юлын
Урда ямы кыңгыравы:
«Казанда тотсаң Урдаңны,
Касыймда тот туграңны!»
Нугай Йортын[5] тиз җибәрмәс
Олуг Мөхәммәтнең зары:
«Ханлык кылдым урдаларны.
Халык кылдым!
Ханлыкларны –
Өзгәләшә-өзгәләшә[6],
Җиде ятка өләштеләр[7]
Дәүләт тотар туграмны...»

...Безне тагын дүрт гасырга
Илсез-көнсез калдыргандыр
Мәскәү – Казан арасында
Ханнар җәсәденең...
Кырык ел...
        кырык ел!
                каңгыравы[8]...

Ярсуланып,
Яр салдырды аргы ярдан
Курган-курган
Дулкын орган
Дәвран заман:
«Каһәрләгән агышыма –
Зәһәрләнгән агышыма!
Кырык үгез каршы тарта...
Кан чакырган...
Хан чатырын!» –
Чакырган еллар кылганын
Уралдырып,
 Ерагаймаган...
        тәгәрмәч
                тавышына.

Аҗаган булып, офыкта
Шулай өмет уйнаклады... –
Чалт аязда,
Яңгыр көйләп,
Сулышларны ачып җибәр,
Яргаланган Нугай тавы!

Чал кояшны
Чалкан ярды!
        Аҗау шоңкар
                шаңравы...

Нугай тауның тиңгеленнән
Ташып чыкты чабыр үлән! –
Җәяү калган торыннарны
Табаныннан таныр үлән:
«Мәскәүләрдән кайткан углан,
Әманәтме әллә һаман?!. –
 Бер хәбәр юк...
Сөенемнән...»

Тау сукмагы – чабыр үлән,
Таптауларга
Бигрәкләр дә сабыр үлән...

Чабыр үлән җыеп тоткан... –
Һаман да ул бала сыман!
Сөенечтән балкый-балкый,
Сөен кайтып бара сыман...

Күп тугладык сөенечне!.. –
Иртә кырпак төшкән чәчне
Сыйпале, җилкәй, иң элек:
«Үги ана булды Казан:
Баш чыкмады казалардан!»–
Җитми, илкәй,
Киңлегең лә,
        җитми күңел
                киңлегең!..

Кәрван-кәрван дулкын бәргән
Офыкларны ача-ача,
Тын елгадан –
Тубылгача!
Дәште Кыпчак диңгезенең
Купшак сулыш тигезләве:
Ил-иләтне,
Җаннар сорап,
Тугыз упкын
        йоттымы соң?! –
Чулпы-чулпы авыл иде...
Толымында
Ык суының...
Бу җанымда тынган да юк
Зәркәнче кош үксүенең:
«Ак Сарай алтыны иде[9]
Толымында Ык суының!»

Нугай тауның сукмагыннан
Чапты.
    Чаба
        Чабыр үлән!

Табаннары тимәстән үк,
Тамырдашын таныр үлән!
«Касыймнардан кайткан углан,
Тапмадым каберен, дисең... –
Хәбәр килер Сөенемнән!..

Хәбәр көтим...
Сөендергән...
Сөен Бикәч, Сөенемнән!»

Хуш исләр өермәсеме?! –
Чабыр үлән җыеп алган...
Ул һаман да бала сыман!
Нугай тауның сукмагыннан
Йөгергәләп, тукталгалап,
Гаҗизлектән өнсез елап,
Сөен кайтып бара сыман...

Нугай тауның сукмагында –
Оя-оя чабыр үлән:
Ыру белән кубарылган!
Диңгезнең дә күбекләре
Җәһәннәмнән күтәрелә... –
Гаҗәпләнмә!
Сөен Бикә
Кайтып керсә ыруына...

Хуш исләр
Өермәсеме,
Сумаклардан узды шулай,
Ил-йорт исен исәйтереп, –
Чабыр исен куерттырып:
– Тамырдашым чабыр үлән,
Ырудашым чабыр үлән,
Ис җыйгандай, ил-күч җыйдык,
Ис җыйгандай, ил-көч җыйдык, –
Ис җуйгандай,
Тәмам җуйдык! –
беркавымга... –
Нугай Йортын.

---

[1] Камка – кытай ефәге.
[2] Ун сан – йөз мең.
[3] Яр салдыру – хәбәр салдыру.
[4] Олуг Мөхәммәт хан – Иделнең шималь тарафында Ислам учагын кабат тергезеп, Сарайны күләгәдә калдырган Казан ханлыгына нигез салган Алтын Урда ханы, Мәскәү белән тигез сөйләшүче бөек Казан ханы.
[5] Нугай Йорты – Алтын Урда.
[6] «Өзгәләшә-өзгәләшә,
[7] Җиде ятка өләштеләр / Дәүләт тотар туграмны...» – Речь Посполитая (Польша корольлеге, Литва кенәзлеге...) һәм Россия империяләренең АлтынУрда туграсын хәтерләтүче «бөркет»ле гербларына ишарә.
[8] «Хан җәсәденең кырык ел каңгыравы...» – Казан кирмәнендә археологлар 1977 елда казып чыгарган ханнар җәсәде, җирләнергә өстән күрсәтмә көтеп, 2017 елга кадәр тузан җыеп ятты.
[9] «Ак Сарай алтыны иде/Толымында Ык суының...» – 1380 елларда Алтын Урда җирләреннән күчерелгән нугай татарлары, Ыкның ике ягында да көянтәле чулпылар сыман парлап тезелгән кышлау-җәйләүләр төзи. Киләчәктә дә бер-берсенә терәк булсалар, тарих сандыгына тиз генә кереп ятмас алар! – Ык толымындагы борынгы чулпылар – Нугай Йортының, сум алтыннан сугылгандай, вакыт күгәрегенә бирешмәүче затлы нәсел-нәсәпле татар авыллары...



Фоат
Садриев

# АЛМАЛЫ КҮЛГӘ КИТҮ

хикәя

Язның гадәти көне иде. Алты катлы йорт каршындагы балалар мәйданчыгы эскәмиясендә шактый зур яшьтәге бер кеше газета укып утыра. Өстендә көлсу вильвет пинжәк-чалбары, шундый ук төстәге замш туфлиләре, сыек шәмәхә күлмәге аның зәвыклы, матурлыкны аңлаучы кеше булуына ишарәле шикелле. Ап-ак бөдрә чәчле башы зур чәчәк таҗына охшаса, бераз пеләшләнгән баш түбәсе әлеге чәчәкнең җимшәнен хәтерләтә. Май кояшы, сөйгәне белән кавышкан яшь кыз шикелле, шаян елмая, ир кешенең керфекләре арасыннан күзләренә керә, озын тирән җыерчыклар белән сырланган киң маңгаеннан сыйпый. Кояш нурларына ияреп, назлы җил дә яшел үләннәрнең, агач яфракларының сагызлы исе белән аның битләренә, борынына кагыла, күпереп торган көмеш бөдрәләре белән уйный. Әмма боларның берсе дә кешенең игътибарын газетадан аера алмый. Тагын шунысы гаҗәп, газетасын шактый югары тотканлыктан, аның гәүдәсе төз, башы да иелмәгән. Ул болай утырып, газетасын укымыйча, әллә аның читеннән берәр нәрсә күзәтәме – белмәссең. Кеше бер аягын тезенә атландырып утырган килеш өстәге аягының туфли очын, кояш белән җилнең шаяруларын читкә этәргә теләгәндәй, селкетеп-селкетеп куя. Безнең баш миеннән иң ерак урнашкан һәм авыррак идарә ителүче әгъза булган аякларның импульсында күпмедер дәрәҗәдә кешенең эчке аңы, холык-фигыле чагыла, дип уйласак, бу зат баш бирмәс, үз дигәненә һичшиксез ирешә торган максатчан шәхестер. Чөнки аның йөз чалымнары тормышның ачысын-төчесен җитәрлек татыганлыгын сөйли.

Утларда янмыйча, суларда батмыйча, күркәм кыяфәттә шушы яшенә килеп җиткән бу кешенең исеме Юныс иде. Ул шактый якынайган машина тавышына «ялт» итеп башын күтәрде. Ак төстәге япон машинасы мәйданчык янәшәсенә туктауга аннан чем-кара бөдрә чәчле, килешле генә гәүдәсенә зәңгәр костюм-күлмәк кигән хатын рульдән җиргә төште. Бу – Юнысның кызы Хәния иде. Хәния подъездга таба ике адым атларга да өлгермәде, каршына юка гына гәүдәле, сары чәчле бер хатын белән бер ир килеп басты. Ир кулдан ясалган

Фоат САДРИЕВ (1941) – *прозаик, драматург, «Таң җиле», «Бәхетсезләр бәхете» романнары, «Шаһзаманов эше» һ.б. повестьлар авторы. Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Мөслимдә яши.*

алюмин таякка таянган һәм бераз гына аксый иде. Газетасын култык астына кыстырып, Юныс та алар янына юнәлде. Теге хатынның нечкә тавышы язгы һавада чатнап еракларга тарала иде:

– Хәния апа, зинһар, бер генә минут тыңлагыз! – Хатын кулындагы шакмаклы букчасын сикерткәләп куйды.

– Минем минут та вакытым юк!

Хәния, аларның икесенең уртасыннан чыгып, подъезд ишегенә таба атлады. Хатын белән ир аның артыннан бер тотам калышмады.

– Без бит инде сезне күрергә өч көн киләбез! – Хатын, сүзләрен раслатырга шаһит эзләгәндәй, ялварулы карашын як-якка йөртеп алды.

– Аңлыйсызмы, мин өйдә берни дә хәл итмим! – диде Хәния шактый усал тавыш белән. – Йомышыгыз булса, клиникага барыгыз.

Ул подъезд баскычына күтәрелде.

– Без анда дәваландык, ирем йөри башлады. Сезгә рәхмәт әйтергә генә килдек. Безнең шушы бәләкәй генә күчтәнәчебезне алсагыз иде!..

Ләкин хатынның ялварулы тавышы өзелде, сузган теге букчасы да асылынып калды: Хәния борылып та карамыйча, подъездның тимер ишеген аларның борын төбендә дөпелдәтеп ябып кереп тә китте. Юныс алар янына килеп җиткән иде инде. Хатын ишекне тартып-тартып карады да кычкырып елап җибәрде:

– Их, их, ихларым! – дип сузды ул нишләргә белмичә.

Хатынның чуалган сары чәчләре юеш битләренә ябышкан. Бу парның өс-башына караганда, тормышларының җиңелдән түгеллеге күренә иде. Нишләптер, хатынның колак яфрагыннан ерак түгел яңагындагы сөйкемле миңе Юнысның игътибарын җәлеп итте. (Хәниянең дә нәкъ шул урында миңе бар лабаса! Аныкы уң якта, бу хатынныкы сул яңагында). Шул миңеме, башка сәбәпме, Юныс аны кызганып куйды һәм тынычландырмакчы булып, акрын гына дәште:

– Сеңлем…

Хатын елавыннан туктап, битләренә ябышкан чәчләрен артка таба сыпырып куйды да тагын дөнья ярып нечкә тавышы белән кычкырып җибәрде:

– Әләй, Юныс Мөбарәкович!

Аның йөзе шул арада үзгәргән, кояштай балкый иде. Юныс бөтенләй аптырап калды:

– Сез каян беләсез мине?

– Ярты шәһәр сез төзегән фатирларда яшәсен дә, ничек инде сезне белмәскә ди?! – Хатын «ялт» кына аның каршына килеп тә басты. – Сез дә бу клиникада дәваланасызмыни?

– Әйе, – дип куйды Юныс, артык сүзгә урын калдырмыйча.

– Әйбәт дәвалыйлар бит, – диде хатын хисләнеп. – Иремне энә белән дә, корт чактырып та, тагын әллә ничекләр дәваладылар. Аякка басты, ышанасызмы?

– Ышанам, – диде Юныс, Хәниясе өчен куанып.

Хатын букчасыннан каклаган каз чыгарып, Юныска сузды:

– Бу күчтәнәчебез сезгә булсын. Сезнең ярдәмегезне мәңге онытасыбыз юк. Беләсезме, безнең малаебызга да унбиш яшь тулды бит.

Хатын сөйләде дә сөйләде, каклаган каз исе борыннарны гына кытыклап калмады, аны авыз итеп карау теләген дә уятты:

– Сатып бирсәгез, алам.

– Юк, юк, сатмыйм, болай гына алыгыз!

Хатынның сүзен җөпләп ире дә:

– Аласыз, алмасагыз, үпкәлибез, – дип һөҗүмгә күчте.

– Ярый, җиңдегез.

Юныс казны алды да хатынның кулына дүрт мең сум акча тоттырды.

– Юныс Мөбарәкович, сез нишлисез?! Болай булмый! – дип акчаны кире суза башлауга, Юныс аның кулын читкә этте.

– Бүген җомга көн – хәер булыр, – диде ул. – Әгәр алмасаң, үзең кебек кычкырып елыйм хәзер!

Бу сүзләрне ишеткәч, хатын белән ир пырхылдап көлеп җибәрде. Юныс аларга рәхмәт әйтә-әйтә ишектән эчкә атлады.

Ул кергәндә, Хәния белән кияве Фазыл әбәд әзерләп йөри иде. Пәһлевандай гәүдәле киявенең кызы белән шушылай өстәл янында әвәрә килүенә ул бер сөенә, бер көенә кебек. Кызы бераз арттырыбрак җибәрә шикелле. Юныс үзе аш-су әзерләшергә беркайчан да кул тыкмады. Аны күрүгә Хәниянең йөзе караңгыланып китте.

– Әллә шул хатынның күчтәнәчен алдыңмы?

– Син аның күңелен бик нык яраладың, – диде Юныс, казны читтәрәк торган бәләкәй өстәлгә куеп. – Алар ирен дәвалаган өчен сиңа рәхмәт әйтергә килгәннәр. Күчтәнәчләрен йөзләренә аткандай кереп киттең.

– Үзебез дәвалаган кешеләрдән ширпы гына алсаң да, ни буласын беләсең бит. Үзең кисәтеп куйдың.

– Кагыйдәдән чыгармалар да була. Күчтәнәчләрен алмасаң, сүзләрен тыңларга идең. Ә син аларның рәхмәтләрен таптадың. Хатын үксеп-үксеп елады. Син үзеңнең тупас кылануыңны танырга тиеш.

– Әти, син мине тәрбияләмә инде хәзер. Элегрәк шөгыльләнергә идең.

– Рәхмәт, кызым. Синең бу шелтәңне киләчәктә истә тотармын мин.

Фазыл аны якламакчы булды:

– Хәния, бабайның хәтерен калдырасың бит…

– Ә син салатыңны әзерләп бетерсәң, әйбәтрәк булыр. – Хәния башлаган сүзнең җебен кабат эләктереп алды. – Минем күңелемне көне буе ялыйлар. Әле авырулар, әле медицина персоналы. Әти, мондый күчтәнәч алуың соңгысы булсын.

– Минем белән болай сөйләшүеңне ташла син. Мин үпкәләсәм, нык үпкәлим.

– Күз өстендә каш саналган элекке трест директоры, шәһәрнең мактаулы гражданины күчтәнәч ала. Син ни әйтер идең?

– Беренчедән, мин аны сатып алдым. – Юныс казны пакеттан чыгарып куйды. – Икенчедән, әти, нәфесең теләгәндер, әйбәт булган, дияргә иде. Өченчедән, шуны әз генә кисеп бир әле.

– Кисмим, – диде Хәния. – Сиңа тозлы әйбер категорически ярамый.

– Син кырт кистең, тик казны түгел. Кияү, әз генә тура әле шул тәмле әйберне. Баядан бирле авыз сулары килеп тора бит.

Фазыл бер Хәниягә, бер Юныска карап, ак күлмәк җиңнәрен сызганып, кулына чәнечке белән пычак алды, муен ягыннан бераз кисеп-кисеп, тәлинкәгә тезде. Иң элек үзе кабып чәйнәде:

– Ярый әле алгансың, бабай. Моның тәме әллә кайларга йөгерә бит.

Каз итен тәмләп суыра башлауга, кызы үч иткәндәй телгә килде:

– Син көндезге даруыңны эчтеңме соң әле?

– Нигә эчмәскә – эчтем, – дигән булды Юныс, авызын тәмсезлисе килмичә.

– Кайчан эчтең? – Кызы аның күзләренә туп-туры карады. – Алдашып утырма карт башың белән.

– Шушы ит кисәген чәйнәп кенә бетерим инде…

Ләкин Хәния бер кулына су, икенчесенә дару тотып, аның каршына килгән иде инде.

– Бөтен авыз тәмсезләнә бит, – дип карышты Юныс.

– Тәмсез түгел ул.

– Минем авызга тыккач, сиңа тәмсез түгел, билгеле.

Хәния дару каптыргач, ачы булмаса да, ул чыраен юри әллә ниләр кыландыра-кыландыра ямьсез чытып, шактый озак торды.

Хәниянең бер кисәк каз итен кабып, чепе-чепе суырганын күреп, алар кияве белән карашып елмаеп куйдылар. Аннары Фазыл әллә ничә төрле ярма, тәмләткечләр салып үзе пешергән балык шулпасын китерде. Аны мактый-мактый ашап туйгач, кызы тары боткасы белән бавыр әзерләп чыгарды. Шулай да Юнысның гомере буе калҗасы белән ит ашарга күнеккән карыны, гадәттәгечә, нәрсәдер теләп, канәгатьләнмичәрәк калды.

Кай арада өстәлне җыештырганнар, кай арада киенгәннәрдер, Хәния аның бүлмәсенә кереп, чираттагы күрсәтмәләрен биреп китте:

– Беләм, син тагын ятарга чамалап йөрисең инде. Сиңа саф һава кирәк. Кан басымыңны кара да бераз йөреп кайт. Сәгать өчтә даруыңны эчәргә онытма. Аннары тренажёр. Газеталарыңны куй, телевизорны ачма. Бөтен тынычлыгыңны шулар ала синең.

Юныс аларның тупсаны атлап чыгып, ишекне япканнарын ишетүгә, диванына барып ятты. Акылга сыймаслык нәрсәләр таләп итә кызы. Соң дөньяның, тормышның ничек кайнаганын белмичә, ничек яшәмәк кирәк? Тома сукыр булу дигән сүз бит бу! Болар турында ныклап уйлый башласа, ул үзен читлек эченә килеп эләккән арыслан кебек сизә. Аларның тын гына аккан тормыш елгасы һич көтелмәгән борылышлар ясар кебек түгел иде югыйсә. Иң элек кызлары Хәния шәхси клиника ачарга теләве белән Юнысны да, карчыгы Фәйрүзәне дә шаккатырды. Югары категорияле кардиолог булсаң да, күкрәгеңдә ат йөрәге йөрткән очракта гына мондый олы эшкә алынып буладыр, дип уйлады алар. Әнисе кызын күз яшьләре белән йомшартырга, ниятеннән чигендерергә тырышканда, Юныс бүтәнчәрәк уйлады. Өч-дүрт урында көне-төне эшләп тә, кызлары юньле-башлы акчага тиенә алмады. Карчыгы белән «күпмегә түзәр икән бу бала», дип аз борчылмадылар бит. Кыскасы, Юныс кызының планын хуплады. Шушы фатирыннан бер квартал гына арырак төзелеп бетмәгән ике катлы йорт сатыла икән. Юныс үзләренең гомер буе җыйган акчаларын тулысынча бирде, үзе сигезенче дистәсен куганда, ике ел буе, кызы әйтмешли, «генераль прораб» булып, иртәдән кичкә кадәр бөтен эшкә җитәкчелек итте. Кызы белән кияве муеннан кредитка батты. Ничек итсәләр иттеләр, ике ел тулганда, клиника эшли башлады. Инде барлык борчулар артта калды, күңелләр тынычланды, дигәндә, коточкыч бәла килде: карчыгы Фәйрүзә кинәт үлеп китте. Ялан хәтле өйдә агач, яшелчә бакчаларын карап, берүзе елдан артык әйбәт кенә яшәде Юныс.

Былтыр ноябрь аенда кар көрәп кереп, чәй куеп җибәрде. Урам аркылы гына яшәүче дусты Әхмәтне чәйгә чакырды да туалетка керде. Шуннан соң берни хәтерләми. Әхмәт керә – дәшүче юк. Туалет ишеге эчтән бикле, шакуына җавап юк. Юнысның, трестта эшләгәндә, бер инфаркт алганын белгән Әхмәт туалет ишеген каерып ачса, ул егылып ята. Больницада аны бик озак, авырлык белән

генә аягына бастырдылар. Аннары – санаторий. Реабилитация вакытын үткәч, Хәния үзе килеп алды. Өенә кайтып чәйләр эчкәч, Юныс тәрәзә төбендәге гөлләрен карап йөрде, кайберләре белән сөйләште, кайберләрен иснәде.

– Карап туйдыңмы инде, эти? – диде түземе беткән Хәния.

– Нигә?

– Киттек безгә.

– Нишләп сезгә барыйм мин?

– Ялгызың калсаң, ни буласын аңладың бит инде.

– Мин хәзер сау-сәламәт, – дип акланмакчы булды Юныс.

– Күңеленә авыр алма, эти, бер инфаркт кичерсәң, ул инде икенчесен, өченчесен чакырырга гына тора. Әйдә, кирәкле әйберләреңне җыйныйк та кузгалыйк. Синең дә, безнең дә җаныбыз тыныч булыр.

Буйсынудан башка чара калмады. Менә кыш та үтте, яз да җитте. Юныс сихәтлегеннән зарланмый анысы. Аны бер генә нәрсә канәгатьләндерми: кызының таләпләре әйтеп бетергесез каты булып чыкты. Кызы баштан ук аның кулына бер кочак инструкция-рецептлар тоттырды. Юныс шуларга тулысынча кол кебек буйсындырылды. Төрле вакытларда әллә ничә төрле дару кабул итү, арпа, тары, карабодай, фасоль, борчак, чөгендер, кәбестә, кишер ишеләрне ашау, саф һавада йөрү, тренажёрда хәрәкәтләнү, гимнастика ясау, кан басымын дүрт мәртәбә үлчәү, камырлык, пәйгамбәр тырнагы, валериан тамыры, дегет салган сөт, сукыр кычыткан, күгәрчен ипие, солы суы, тагын әллә нәрсәләрне кайнатып эчү – барысын да үтәргә түгел, санап чыгарга да түземең җитми. Хәния берсен дә калдырмаска көне-төне колак итен чәйнәп тора. Ул һөҗүм иткән саен, Юныс карыша, мең сылтау табып, аның катгый күрсәтмәләрен сиздермичә дә, кайчакта сиздереп тә боза. Иң аянычы – өй тирәсеннән, аның клиникасыннан ерак китәргә ярамый. Болар бөтенесе дә аны нык түбәнсетә. Беркайчан да беркемгә баш имәгән, ял дигән нәрсәне белмичә, унике-ундүрт сәгать эшләгән кеше өчен болай яшәү үлем белән бер. Дөрес, Юнысның башында төрле-төрле фикерләр туа башласа да, ул әле аларны күңел бизмәненә салып үлчәп карарга әзер түгел иде.

Кыңгырау тавышы аның уйларын бүлде. Ишектән Юнысның үз урынына калдырган кешесе Дилүс Гарипов килеп керде. Ул һәрвакыттагыча пөхтә киенгән, тулы түгәрәк битләре алланып тора. Кочаклашып күрешкәч, Юныс үзен кызыксындырган сорауны бирде:

– Йә, ничек, Дилүс Әзһәмович, төгәлләдеңме йортны?

– Иртәгә тапшырабыз. – Гариповның йөзе кояштай балкыды. – Килүем дә шуңа, Юныс Мөбарәкович. Кәефегез булса, карап кайтыр идек.

Юнысның күңеленә җылы йөгерде. Менә бит, Юнысның барын онытмаган, аның бәясен ишетәсе, бераз мактанасы да киләдер.

Утыз-кырык минуттан тугыз катлы йорт янына килеп тә туктадылар. Чыннан да ул тирә-юньгә ямь биреп, элеккеләреннән нык аерылып тора иде. Эче дә яңа материаллардан заманча эшләнгән. Коридорлар киң, бүлмәләр уңайлы, тәрәзәләр зур, эчке җиһазлар ялык-йолык килеп тора.

– Молодец, сынатмыйсың, – дип мактады аны Юныс. – Иртәгә ничә фатир тапшырасыз инде?

Гариповның моңа җавабы куанырлык булмады, әлегә унике генә фатир тапшырабыз, тоткарлыклар килеп чыкты, диде. Сметада каралган акчаны кисеп, бирмичә интектерүләрен озак итеп сөйләде. Соңыннан аның офисына кайттылар. Юныс үзе киткәннән соң, офисның үзгәртелгәнлеген күргән иде

инде. Шул арада кабинет кабат эшләнгән булып чыкты. Өстәл-урындыклар Италиянекенә алыштырылган, люстрадан алып, башкалары да яңартылган. Яшьләр заманнан калышмый, министрны гына түгел, президентларны да алып керерлек кирәктер, күрәсең. Өстәл сый-нигъмәтләрдән сыгылган, учка сыярлык нечкә билле чибәр кызның йөзеннән елмаю китми. Әле бер, әле икенче төрле ризыкларны китереп кенә тора. Юныс кайсын бер капты, кайсына бөтенләй кагылмады. Гарипов төзелешне финанслауның торган саен кысылуы хакында сөйләде, элекке җитәкчесеннән киңәшләр дә сорады. Тик Юныска бу сүзләрнең, нишләптер, кызыгы бетте, йөрәге дә кысылып-кысылып куйды. Чибәр кыз чәй чыгаргач, Гарипов:

– Сезне иртәгә тантанага чакырам, – диде. – Үзем барып алырмын.

– Син инде, Дилүс Әзһәмович, мине кичерә күр – катнаша алмам. Йөрәк шаяра, дулкынланырга ярамый.

– Чыгыш ясамассыз.

– Мин даруымны эчим дә, кайтарып куярсың инде.

– Тантанада сезнең белән янәшә басып торырбыз дип, шулкадәр өметләнгән идем. Кызганыч. Бик тә кызганыч! – Ул өстәл астыннан ялык-йолык килеп торган тартма алып аңа сузды. – Моны сезгә иртәгә тапшырасы идем. Тибет монахларының яшәрткеч дарулары. Рәхим итеп алыгыз.

– Гафу ит, Дилүс Әзһәмович, мин моны ала алмыйм. Исән-имин сиксән яшемә барып җитсәм, шунда бирерсең.

Юныс шушы сүзләрне әйткәндә, теге җитез кыз аларны зур фотоаппарат белән черт-черт төшерде. Тик Гариповның кәефе шул кадәр кырылган иде, ул бик тырышса да, елмая алмады.

Кайтканда, алар бер сүз дә сөйләшмичә тып-тын утырдылар. Гариповның кесә телефоны шалтыраган иде, ул бер генә сүз әйтте: «Телевидение кирәкми инде».

Юныс тынычланмакчы булып, бүлмәсенә кереп ятты. Берни дә уйламаска тырышса да, Гарипов белән йөрү башыннан азагына кадәр күңеленнән китмәде. Юныс үзе эшләгән дәверне күз алдына китерде. Яңа йортта яши башлагач, ул бер подъезддан икенчесенә, аскы каттан өскеләренә күчә-күчә ялгызы йөрергә ярата иде. Аның өчен моннан да зур бәйрәм булмый. Иңбашына әтисенең тальянын элә. Сугышка киткәндә, әтисе ул гармунны әле өч яше дә тулмаган Юныска дип атап калдырган. Коридорда балалар йөгерешкәнен, фатирлар эчендә күченү мәшәкатьләренә бәйле күңелле шау-шуларны ишетүе аңа чиксез рәхәт. Син кешеләрнең өметләрен акладың! Синең йөзең якты. Дулкынландырырлык бөек мизгелләр! Бу уртак шатлык аларныкы да, синеке дә! Моның өчен әти гармунында уйнасаң да, җырласаң да ярый. Юныс фатирларга керә, андагыларның иңбашларыннан сөя, кешеләр таный, туктаусыз рәхмәт укыйлар, табынга чакыралар. Эчемлекләрен эчмәсә дә, Юныс тальянында уйный, үзе җырлый, башкалар да кушыла. Аның болай йөрүенә усал телләр анекдотлар чыгарса, икенчеләре легендалар иҗат итә. Ниндидер тантаналарда аны легендар шәхес дип тәкъдим итәләр, шәһәрнең мактау тактасында да шушы тальяны белән төшкән фотосы тора. Концертларда, юбилейларда күпме генә кыстасалар да, аның гармунда уйнаганы да, җырлаганы да булмады. Чөнки бу тамаша гамәле түгел. Ул яңа йортта һәм үз өендә генә башкарыла торган илаһи гамәл. Юныс ул чакта әтисе белән сөйләшә. Бу – әтисе рухына гомеренең бер өлешеннән хисап юллау.

Әлеге хатирәләр аның күңелен тагын да көчлерәк дулкынландырып

җибәрде. Ул дәртләнеп кулына тальянын алды, карурманнардан, шахталардан, Кандыр буйларыннан, Җидегән чишмәләрдән, Гөлҗамаллар, Галиябанулардан күңеленә илһам, тынычлык иңде.

Балалар бүген дә соңга калдылар. Иң элек кияве кайтып керде. Юнысның хәлен белешкәч, Хәния ясап куйган котлетны пешерергә утыртты. Букчасыннан помидор-кыяр, тәмләткеч үләннәр алып юды, өстәлгә савыт, тоз, борыч, каймак кебек нәрсәләр тезәргә тотынды. Юныс аны сүзсез генә күзәтеп утырды.

– Әллә берәр нәрсә бармы, бабай?

– Тиз генә шахмат сугып алыр идек тә, син бер дә бушар кебек күренмисең.

– Соң, әйдә, алайса! – Кулларын сөртеп Фазыл килеп тә җитте. – Калганын Хәния эшләр.

Алар сүзсез генә «блиц» уйнарга тотындылар. Һәм Юныс көтмәгәндә ачык авызлык күрсәтте: кияве аның турасын сукты да алды.

– Көндез казымны ашаган идең, хәзер турага да җитештең, – диде Юныс, авыз эченнән көйләгән кебегрәк итеп.

– Алайса, кире урынына куям…

– Кирәкми. Уйламасаң, тураңны гына түгел, иманыңны да югалтуың бар, дигән кисәтү бу.

Тураны югалту аны каушатып җибәрде. Күбесенчә, Юныс отып бара иде бит әле. Әллә ныклап какшау шушы микән?

Ул арада кабаланып Хәния кайтып керде. Күлмәген алыштырып, юынып, кухняга күз салгач, алар янына килде:

– Ник салатны ясамадың инде? Әтине шахмат белән интектермәсәң.

– Кызым, син кияүгә юкка гаеп ташлыйсың. Аны мин үзем чакырган идем.

– Уйнап утырыр чак түгел. Хәзер тиз генә капкалыйбыз да, аптека мөдиренә барабыз. Яңа дарулар бирәм, диде.

Шунда кесә телефоны шалтырады.

– Здравствуй, доченька!

Хәния Төркиядәге кызлары Ләлә белән сөйләшә-сөйләшә кухняга кереп китте. Фазыл яшелчәләрне өстәлгә чыгарып куйды да салат ясарга кереште, үзе шахмат уйнавын дәвам итте.

– Кияү, син ике эшне берьюлы башкарып, мине түбәнсетәсең бит, – диде Юныс әллә чынлап, әллә юри.

– Кызык җирендә генә туктамыйк инде…

Фазыл уйнавын дәвам итте, салатын ясап бетереп, өстенә борыч сипкәндә генә, Юныс аңа шартлатып: «Мат!» – диде.

– Менә бусы борычның соңгы бөртеге, – диде ул, канәгатьләнү белән көлеп.

Ниһаять, Хәния телефонын куйды.

– Ни хәлләре бар? – дип сорады Юныс.

– Анда оҗмах инде. Россия түгел бит ул.

– Россия булырга анда ана телләрендә сөйләшәләр. Ә син үз кызың белән русча тәгәрәтәсең. Җенем котыра шуңа.

– Әти, син гомер буе боерып туймадыңмыни?

– Боеру түгел бу! Минем белән сөйләшкәндә, аның русча бер сүз дә кыстырганы юк.

– Янында урыс ире басып тора бит. Ул ни уйлый аның татарчасын ишетеп?

– Урыска бирмәскә идең. Күпме әйттек әниең белән.

– Җитте инде, әти! Бүген нервыларым да бетте, ашыгам да. Әйдә, ашарга.

– Минем тамагым тук.

– Менә тагын үпкәләдең инде. Ярар, мин гаепле, гафу ит. Әйдә, әти.

Хәния килеп култыклагач, Юнысның күңеле йомшап китте. Берни көтәрлек рәте булмаса да, кухняга керде, даруын эчеп, Фазыл әзерләгән табынга утырды. Хәния ашыга-кабалана тәлинкәләргә котлет бүлә башлады. Юныска, Фазылга салды. Үзенә бүлгәндә бер котлеты ычкынып идәнгә барып төште. Аны кулы белән генә эләктергән иде, ут кебек кайнар котлетны ничек раковинага томырганны үзе дә сизмәде, кулын өф-өф өргәләп, салфетка белән сөртте. Моны карап утырган Юныс баш чайкап куйды.

– Нигә бөдрәләреңне чайкыйсың инде, әти?

Юныс торып басты да муенын җыерып, ике кулын ике якка җәйгәндәй итеп алды.

– Аңламыйм мин сезне, балалар. Иртүк ут капкандай чыгып чабасыз, кайтсагыз каптыр-коптыр капкалыйсыз да тагын койрыгы пешкән мәчедәй кыланасыз. Көннәр буе, еллар буе. Гәүдәгезнең бу кадәр чабуына җаныгыз ничек түзәдер – белмим. Туктарга кирәк бераз.

Хәния аны көч-хәл белән түзеп тыңлап утырды да кабынып китте.

– Ә син үзеңне оныттыңмыни? Син үзең шулай чапмадыңмыни?

– Мин шәһәр төзедем.

– Сиңа безнең клиника бәләкәй булып күренә инде ул. Кредитлар муендагы элмәк кебек куа. Анда барып бәреләсең, монда килеп төртеләсең...

– Киңәш-табыш та итмисез бит ичмасам, – дип куйды Юныс, кызының хәленә кереп.

– Миңа киңәш кирәкми, әти, миңа акча гына кирәк, – диде Хәния, кайнар котлет кисәге эләктерелгән чәнечкесен селкеп. – Акчам булса, мин киңәшнең алтынын да, көмешен дә бирәм. Кредитны капламасак, бөтенесе җилгә оча!

– Безнеке дә җиңел булмады. Тик без давылдай бөтерелмәдек.

– Синең артыңда терәк булып хөкүмәтең торган! Әйтер идем – әйттермисең...

– Әйттермим, сүкмәгез хөкүмәтне! Һәрбер кеше үзе нидер эшләргә тиеш.

Сүз шунда тукталды. Савыт-сабаларны җыештыргач, алар сәгать унсыз кайта алмабыз, дип чыгып киттеләр.

Башланган сөйләшүне Юныс күңеленнән дәвам итте. Кызы белән киявен хурларга теләми ул. Тик кешеләрнең күпчелеге туктаусыз чабулый, башын эшләтми. Нәтиҗәдә аягүрә матур төшләр күреп йөриләр. Үзенең кул астындагыларны «Кая ашыгасың, тын ал! – дип, акылларына китерә иде ул. – Безнең кул астында күпме кеше икәнлеген онытмыйк», – дип, кат-кат кабатлый иде. Җитәкчеләрнең һәр адымына халык үз адымын тигезли. Җитәкче ялгышса, халык ялгыша. Бер җан, бер тән булмаганда, койрык башка боерык бирә башлый. Аерган умарта кебек бөтенесе тузгый, болгана...

Кызына артыграк бәрелде бугай. Юныс аны кызганып куйды. Хатын-кызга кирәк булганмы бу шәхси клиника? Хәния биш яшьләр тирәсендә булганда, әнисе белән икесе уртасында утырып төшкән фотосы бар иде. Ул аны иске блокноты эчендә йөртте. Нык борчылган чакларында шуны караса, җаны тынычланып китә иде. Күптән караганы юк икән инде. Блокнотын кая куйганын да оныткан. Мөгаен, иске портфелендәдер. Ул чыннан да шунда булып чыкты. Юныс блокнот эченнән фотоны алып, бик озаклап карап утырды. Нинди яшьләр, чибәрләр – ышанырлык та түгел. Әле аның бөдрәләре дә агарып бетмәгән. Фәйрүзәсенең йөзеннән сабырлык, тыйнаклык бөркелә. Бәхетенә ул туры килмәсә, Юныс, бәлкем, күптән җир астында яткан булыр иде инде. Хәниянең күзләре ут яна, хәтта аның карашы ниндидер серле җиһан түреннән

киләдер кебек. Юныс фоторәсемне алдында тотып, озак утырды. Аннары блокнотын актаргаларга кереште. Һәр исем-фамилия, телефон нәрсәнедер исенә төшерә – бу үзенә күрә бик мавыктыргыч шөгыль булып чыкты. Юныс күпме утырганын да онытты. Менә тагын бер язу: «Ләйсән – больница, тикшерергә. Балалы хатын.» Бу сүзләрдән әүвәл ул берни дә аңламады. Аннары «Ах, аңгырабаш!» дип маңгаен учы белән чәпелдәтеп алды. Соң, бу бит теге каз биргән хатын!

...Ничек шуны хәтерли алмады ул?! Аның больницада аерым палатада дәваланып яткан чагы иде. Беркөн кич кинәт ишек ачылып китте һәм биләүдәге баласын күтәргән бер яшь хатын килеп керде. «Гафу итегез, депутат буларак сезгә килдем. Бүтән барыр җирем калмады, – дип башлап китте ул сүзен. Шушы больницада педиатрия бүлегендә санитарка булып эшли, яңа гына балалары туган, ире авырый икән. Әллә ничә ел көтеп, фатир алыр вакыт җиткәч кенә йорт төзелеше туктатылган. Ике ел көтәргә, дигәннәр. Кеше фатирында торабыз, айга җиде мең акча алам, безгә үләргә генә хәзер, ди. Кермәгән оешмам, язмаган җитәкче калмады, безгә чит илгә булса да чыгып китәргә булышыгыз, ди. Кесәсеннән алып, өстәлгә бер кочак кәгазь китереп салды. Юныс мин терелеп чыкканны көтегез, шуннан соң карарбыз, дип документларын аңа сузган иде, хатын кычкырып елап җибәрде. «Алайга калгач, булмый инде ул, әле больницада эшләмәсәм, мәңге очратасым юк иде», – дип тәкрарлады. Ул арада баласы да уянып, әче итеп акырырга тотынды. Хатын үзе дә елый, биләүдәге баласын туктаусыз беләгендә сикертә, бала сикерткән саен ярсыбрак акыра. Ишектән шәфкать туташлары кереп, чыгармакчы булганнар иде, хатын шарт идәнгә утырды, «үтерсәгез дә чыкмыйм!» дип, баласы белән парлап елавын дәвам итте. Аны көч-хәл белән сөйрәп алып чыгып киттеләр.

Озак шөгыльләнергә туры килде Юныска бу гаилә язмышы белән. Ничек итсә итте, үзләре тапшырган йорттан ике бүлмәле фатир бирдертә алды... Юныс гаҗәпләнеп уйга калды: бу дөнья чыннан да тар микән, әллә кешеләрне гел шаккатырып, һич көтелмәгән нәрсәләр китереп тудыра, кайчакта шактый усал шаярта торган үз хәрәкәте, тәртибе бар микән? Менә бит, гел көтмәгәндә нинди очрашу килеп чыкты. Кайчакларда әллә кемнәр белән бүген-иртәгә, теге атнада, бу айда, киләсе елга очрашырга дип, төп-төгәл планнар корасың – берсе дә барып чыкмый, юк кына нәрсәләр комачаулый, аркылы таяк тыга, көтелмәгән хәлләр туа...

Юныс, оеп, рәхәтләнеп йоклады. Хәтта балаларының кайтканын да сизмәде. Ул төштә әтисен күрде. Имеш тә Юныcның подъезд алдындагы мәйданчыкка таба атлавы. Анда бер ир кеше бу якка аркасын куеп утыра. Юныс аның янына килеп эскәмиягә чүмәште дә теге кешегә борылып карады һәм чак егылып китмәде: бу кеше әтисе иде! Нәкъ унтугыз яшендә төшкән фотосындагы төсле. Әтисе яңа гына колхоз басуыннан сабан сөреп кайткач төшкән булган ул фотога. Аягында оек-чабата, уң кулында чыбыркысы. Буйлы күлмәге дә, киндер чалбары да, башындагы фуражкасы да, каештан үрелгән чыбыркысы да бар. Әтисе кинәт башын аңа таба борды. «Әти!» дип кычкырмакчы булды Юныс, әмма өлгермәде. Әтисе бер генә адым читкә атлады да юкка чыкты. Аның йөзенең артык җитди, кырыс булуы гына хәтерендә калды. Бу төш аны пошаманга салды. Димәк, әтисенең рухы нәрсәдәндер канәгать түгел.

Иртән ашаганда, Юныс күргән төшен балаларына сөйләде, нишләп әти бик җитди булып керде икән, диде. Хәниянең җавабы әллә кайчан уйлап куйгандай әзер иде:

– Тиешенчә дәваланмыйсың бит. Туктаусыз әйтеп, мәҗбүриләп торырга кирәк. Кеше үзе аңлап үтәргә тиеш үзенең бурычларын.

– Тамчы тама-тама ташны тишә. Борау тишә алмаганны су тамчысы эшли. Ни өчен икәнен беләсеңме, кияү?

– Юк.

– Су тамчысы хатын-кыз затыннан булганга шулай. Су да йомшак, хатын-кыз да йомшак.

– Суктырырга оста инде син, – диде Хәния.

– Тәбәгә эләккән тычкан төсле чи-чи килеп ята башласаң, нибуч суктырырсың.

– Бусы тагын ни дигән сүзең?

– Беркая чыгармыйсың бит. Газеталарны да җыеп алгансың әнә.

– Яз көне организмның арыган чагы. Ял ит, әти. Гомер буе Ватан өчен, милләт өчен, бөтен дөнья өчен көяләндең бит инде.

Юныс бүлмәсенә керде дә телевизорны кабызды. Хәния барып аның ишеген ачмакчы иде, ул эчтән бикле булып чыкты.

– Әти, ач ишегеңне.

– Ачмыйм. Халыкара хәлләрне карыйсым бар.

– Әти, шаяртма, ач.

– Ачмыйм.

– Ярый, ярый, – диде Хәния йомшап. – Ачып куй да рәхәтләнеп кара, алайса.

Юныс ишеген киереп ачты. Хәния аңа бармак янады, кияве күз кысып куйды да эшкә киттеләр. Бер уйласаң, кызы мең мәртәбә хаклы. Тик Юнысның һич тә буйсынасы килми менә. Кырык сәбәп таба, карыша, элгәләшә. Ата кеше ул – югарырак зат. Аңа башкача, йомшаграк дәшәргә кирәк. Хәния хаклы булса да, Юныс аңардан хаклырак.

Бүген кәефе искиткеч яхшы булды. Нәкъ вакытында йөреп керде, тренажёрына да басты. Әбәт ашаганда балалар белән дә үткәннәрне искә төшереп көлешеп сөйләшеп утырдылар. Бераз черем дә итеп алгач, гәүдәсе бөтенләй җиңеләеп китте, каяндыр йөреп кайтасы килде. Тукта, аның бит күптән үз өендә булганы юк. Озын кыш буе кызы шунда бер мәртәбә дә алып бармады. Юныс ачкычларын кесәсенә салды да, балалары эштән кайтканчы, ихатасын, өен, бакчадагы агачларын карап әйләнеп килергә булды. Автобус белән биш тукталыш баргач, төшеп тагын ике квартал чамасы атлады. Аңа очраучылар сәлам биреп киттеләр, берничәсе белән сөйләшеп тә торырга туры килде. Ләкин йорты күренүгә аптырап китте. Зур капка киереп ачып куелган. Аның ике ягына коймага борыннарын төртеп җиңел машиналар тезелгән. Әнә берсенә капкадан чыгып, ике кеше утырып та китте. Юныс, әллә төш күрәмме дип, як-ягына каранды. Ишегалдында да дүрт-биш машина күзгә чалынды. «Ни була соң әле бу?» дип уйлый-уйлый, Юныс баскычтан күтәрелеп, кесәсеннән ачкычын чыгаруга, ишек үзе ачылып китте һәм ул кияве белән чак кына маңгайга маңгай бәрелмәде.

– Нишләп йөрисең, бабай? – диде ул елмаеп.

– Мин үземнең йортка дип кайткан идем дә... – Ул һава беткәндәй туктап калды, аннары каты гына сорап куйды: – Ә син монда нишлисең?

Фазылның йөзендәге ягтылык гаҗәпләнү белән алышынды:

– Без монда авыруларны дәвалыйбыз.

– Дәвалыйсыз?! Ә нишләп бу хакта мин белмим?

– Хәния сиңа әйтәм дигән иде бит...

– Күптәнме инде сез монда?

– Яңа елдан соң башладык. Сиңа әйтмәгән булып чыга, алайса...

Фазылның куллары калтырый, йөзе ап-ак булган иде. Киявенең болай дулкынлануын күргәч, Юныс хәлне төзәтү ягын карады:

– Элегрәк бер... ничектер... әйтүен әйткән иде, – дип алдашты, тотлыга-тотлыга. – Сезгә васыять ителгән бит инде ул...

Юныс авырайган аякларын көчкә сөйрәп баскычтан төште. Өй артындагы агачларны карау теләге инде юкка чыккан иде. Кияве акрын гына сорап куйды:

– Син нәрсәгә килгән идең соң, бабай?

– Болай гына... Әллә нишләп күрәсем килеп китте дә.

– Мин клиникага бара идем, – диде Фазыл. – Кайтасыңдыр бит?

– Кайтам.

Фазыл бик кызу кайтты. Яңакларының кысылуыннан аның эчендә ниндидер ялкын дөрләвен күрде Юныс. Подъезд каршына туктагач, Юныс төшмәкче булган иде, Фазыл аның терсәгенә кагылды:

– Бабай, тукта әле...

Юныс урынына утырды һәм киявенә шикле караш ташлады. Нәрсәдер бар иде...

– Миңа... – Киявенең калтыранган тавышы ят, салкын тоелды.– Миңа нишләргә микән, бабай?

Юныснның башына тимер таяк белән китереп суккандай булды. Күптән хафаланып көтеп йөргән нәрсә вулкан кебек атарга әзерләнә шай. Ул куркуын яшерү өчен йөзенә тыныч кыяфәт чыгарырга тырышып, аңа борылды:

– Син клиникага керәсем бар, дигән идең...

Фазыл гүя аның сүзләрен ишетмәде:

– Мин күпкә түзмәм кебек...

– Аңлатыбрак сөйлә әле, кияү, – диде Юныс, үзе башлаган кылануыннан һаман чыга алмыйча.

– Мин бит Хәния өчен юк...

Иң зур куркынычның килеп җиткәнлеген аңлады Юныс. Кызына ул кияү белән итагатьлерәк булу, шарт-шорт сөйләшмәү хакында күптән әйтә килде. Гадәтем шундый булгач нишлим, ул мине аңлый, үпкәләми, дип акланды Хәния. Әгәр кияү китсә, кызының яңадан беркемне дә таба алмаячагы көн кебек ачык. Шуңа күрә курыкты да Юныс. Кызының ажгырып торган усал, ялгыз хатынга әвереләчәге аның күз алдына күптән килеп, борчып тора иде. Кызы нәкъ Юныснның үзе, беркемгә дә баш ия торган түгел. Яшь чагында Фәйрүзәсе кебек йомшак, күндәм кызның кинәт болай үзгәрүе ничек сизелми калган? Кияүне ничек тели шулай төрткәләп, буйсындырып йөрткәнен күрә башлагач кына, Юныс сагаеп калды. Ә Фазылның түземе төкәнсә? Менә шул сорауга җавап эзләгәндә, кызының клиника ачу нияте Юныска бу хәтәр хәлдән котылуның иң отышлы юлы булып күренде. Аны төзү, анда эш оештыру белән шөгыльләнсә, Хәния кайнап торган энергиясен кияүне изәргә түгел, клиника мәшәкатьләренә түгәр, дип уйлады. Әмма ни гаҗәп, бу өмет көткәннең киресен бирде. Һәр ирешкән уңышы Хәнияне бер башка үсендереп җибәрде, аның янында хәтта Юныс үзе дә басынкыланып калды. Әйтерсең лә, аның эченнән күренмәс җеннәр өере чыкты һәм Хәнияне кем туры килә шуңа котырттылар. Элегрәк каршы әйткәләштергән кияү бөтенләй башын аска иде.

– Мин аның янәшәсендәге күләгә кебек, – диде Фазыл, сүзен дәвам итеп. – Яктылык төшкәндә күләгә бар, төшмәгәндә – юк...

Юныска якынлашучы бәхетсезлекне төзәтергә кирәк иде:

– Ялгышасың, кияү. Мин аермачык беләм, ул синнән башка яши алмый. Һөҗүм итү өчен аңа иң якын кешесе кирәк. Ул кешенең берсе – син, икенчесе мин. Моңа үзе теләп түгел, җене котырта аны. Син түз инде, кияү.

– Миңа түзәргә кушасың. Син үзең дә аңа түзә алмыйча, дөртләп кабынасың бит.

– Җеннең иң олысы, иң әшәкесе миндә утыра шул! – Юныс әлеге җеннәрне аралагандай, ике кулы белән бөдрә чәчләрен учлап-учлап тартты. – Син аны ташлама инде, кияү.

Аның бу сүзләреннән Фазыл ирен чите белән генә көлеп куйгандай итте.

– Мин Хәнияне теләсәм дә, ташлап китә алмыйм, – диде Фазыл, аны шаккатырып.

– Ай, рәхмәт тынычландыруың өчен.

– Юк, бабай. Сине борчый торган сүз әйтергә туры килә. Минем төзәлми торган чирем бар.

– Яман чирмени?

– Коточкыч чир. Беләсеңме, эш нидә? Бу тормышта миңа бөтенесе дә барыбер.

Киявенең сүзләре башка сыярлык түгел иде.

– Берничек тә алай була алмый! – дип кычкырды Юныс.

– Булган шул. Бөтенесе бер төстә. Мин юньләп шатланмыйм да, кайгырмыйм да. Алга ни, артка ни, уңга ни, сулга ни – барыбер. Агым кая алып бара – мин шунда...

– Юк, болай булмый! Аңлат, ничек, нәрсә?! – дип ярсыды Юныс.

Кияве башын иеп, маңгаен рульгә терәде. Аның күзләре йомык, яңак итләре уйный иде. Башын әз генә күтәргәч, йөзен читкә борып сөйли башлады:

– Бәләкәйдән үк дөнья әллә мине яратмады, әллә үзем чит иттемме... Дөнья белән очрашмадым да шикелле. Икенче сыйныфта малайларны көрәш түгәрәгенә яздылар. Мәктәп директоры көрәшче иде. Мин беркемнән дә җиңдермәдем. Ирекле көрәш буенча ярышларга йөртә башладылар. Көне буе күнегүләр, укырга вакыт та юк. Спартакиадалар, фестивальләр, грамоталар, дипломнар. Әйтерсең, нindидер өермә җирдән аерып очырып алып китте. Син – талант, диләр. Син шәһәр, республика, ил чемпионы буласың, диләр. Әти белән әнинең куанычтан башлары күктә. Мин тырышам. Йөрәк, мускуллар, буыннар машина двигателе шикелле соңгы чиккәчә эшли. Медицина институтына кергәч тә, тренерлар мине ычкындырмады. Алтынчы курста бер ярышта муеным сынды. Китте операция арты операция. Күрмәгәнем калмады. Бер ел чамасы хастаханәләрдә аунаганда, акыл керә башлады миңа. Укуымны өченче группа инвалид булып дәвам итәргә туры килде. Ник кирәк булган бу миңа? Үзем теләп, дәртләнеп алынсам, бер хәл иде. Мин бит «үс, үс!» дигәнгә үскән эт кебек ияргәнмен. Балачагым гомер арбасыннан баштук төшеп калган. Студент чакта танцыларга, театрларга йөрергә вакыт тимәде. Күнегүләр белән ярышлардан бүтән нәрсә белмәдем. Мине кызлар да, егетләр дә үз итмәде. Хәния очрамаса, мин нишләп кенә бетәр идем микән? Футбол тубы китереп типсәләр – тәгәри, типмәсәләр – тик тора... Бу дөньяга мине Хәния генә тартып чыгарды. Уен кырына чыгарган туп кебек. Бераз җан кертте. Аның җене юк, бабай. Гайрәт ул. Торган саен көчәя баручы ташкын кебек көч-дәрман. Ул мине үзе белән тота. Хәния мине ташламасын өчен мин ул кушканнарның һәммәсен дә үтим.

– Кияү, син аны яратасыңмы соң?

– Яратам! – Фазыл җанланып китте. – Яратам, тик үземчә яратам...

– Әле генә «Хәния мине күрми», дидең. Берни аңламыйм.

– Мин үзем дә аңламыйм. Шуңа аңлата да алмыйм. Ничек әйтим... Хәния мине алды, үзенеке итте. Тик тулаем түгел...

– Бусы тагын да гаҗәбрәк! – Юныс уң кулы белән тезенә шапылдатып сукты. – Сине ничек өлешләп булсын?..

Кияве күңелендәге аңлатырлык сүзләр эзләп, кашларын җыерып шактый торды.

– Миндә нидер туа... Хәния аны күрми. Әлеге яңа нәрсә белән исәпләшмәгәнлектән, гел кыен хәлгә төшерә. Ә мин котырам, тотып яңаклардай булам... Менә хәзер синең каршыңда нәкъ шундый хәлдә калдым. Оятымнан шартлыйм дип торам! Синең өйдә дәвалау оештырырга рөхсәт сорыйм, диде. Сорамаган бит! Сорамаганын ник миңа әйтмәгән?! Ә минем үпкәләр җаем да юк. Мине башкага алыштыруыннан куркып, шундук кичерәм...

Юнысны киявенең бу сүзләре сискәндереп җибәрде:

– Аның йөри торган кешесе бармы әллә?

– Белмим. Хәния белән аралашырга теләүчеләр, аралашучылар арасында кемнәр генә юк! Әгәр ташласа, теге төссез тормыш мине суырып алачак. – Фазыл тирән итеп сулыш алгач, күзләрен йомып, шактый вакыт дәшми торды. Аннары сүзен ярымпышылдап тәгәлләде: – Сизәм, каршы торырлык егәрем юк. Җан керә генә башлады бит әле миңа.

– Кияү, ник син боларны элегрәк сөйләмәдең?

– Хәния сөйләтәме шушыларны?

– Ул синең телеңә хуҗа түгел ләбаса.

– Телгә дә, уйларыма да хуҗа. Мин аңа бернәрсәне дә яшермәскә ант иттем. Үзең күреп яшисең бит ул рөхсәт иткәнне генә сөйләшкәнне.

– Минемчә, гел үк алай түгел инде, – дип каршы төште Юныс.

– Бәлки арттырамдыр. Сәбәп тә кирәк булгандыр моңа. Уйлап йөрдем йөрүен. Тик кыюлыгым җитмәде, тыңламассың, дип уйладым...

– Әллә кайчан вакыт табасы булган, – диде Юныс, машина ишеген ача башлап. – Күңелем тынычланып калды. Рәхмәт, кияү, барысын да сөйләгәнеңә.

– Миңа да җиңел булып китте.

Машинадан төшкәч, Юныс Фазыл утырган якка килде.

– Сиңа әйтеп куйыйм әле: мин беразга югалып торырмын.

– Югалып?

– Энекәш янына авылга кайтасым килә. Хәниягә әйтә күрмә, хәзер кайтып бикләп куячак.

– Әйтми китсәң, ул акылдан язачак бит.

– Мин аңа кич соңрак шалтыратырмын, – дип, киявен тынычландырып калды Юныс.

Кереп чәй эчте, ятып черем итте, аннары такси чакырды.

* * *

Ишегалдында нидер эшләп йөрүче Рәшит белән хатыны Гөлнур, Юнысны капкада күреп, каршына йөгереп килде.

– Исәнме, абый!

Икәүләшеп аны кочаклап алдылар, хәл-әхвәл сораштылар. Юнысның әйберләрен күтәреп кергәндә, Гөлнур:

– Абый, син ярата торган борай бәлеше әзер! – дип белдерде.

– Иренмисең дә инде үзең!

– Синең өчен бәлеш пешерергә дә иренеп торсам, мин кем булам соң? – дип кеткелдәде Гөлнур.

Өйгә кергәч, Юныс күчтәнәчләр салган сумкадан Гөлнурга күлмәк, Рәшиткә туфли алып бирде. Шунда оныклары Самат та уеннан кайтып керде. Юныс сумкадан бер зур гына тартма алып култыгына кыстырды һәм онык каршына килде.

– Исәнме, Самат улым!

– Исәнме, Юныс бабай!

Онык кечкенә кулын шапылдатып Юнысның учына салды.

– Сиңа ничә яшь инде? – диде Юныс аның алдына чүгәләп.

– Җиде. Быел мәктәпкә барам.

– Менә мин сиңа бер әйбер алып кайттым, улым. – Юныс тартмадан бик матур уенчык алып, аны Саматка бирде.

Уенчык дигәне бизәкле сандык өстендә янәшә утыручы малай белән кыз иде. Малай яшел түбәтәй, яшел камзул кигән. Кыз зәңгәр калфактан, ак күлмәктән. Сандыкның ике башында төрле төстәге өчәр төймәсе бар. Юныс ак төймәгә баскан иде, еректан сызылып җанны эретә торган музыка яңгырый башлады.

– Тагын берәр төймәсен үзең бас әле, – диде Юныс.

Самат зәңгәр төймәгә басуга, малай тавышы ишетелде:

Әйт әле, күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр күп очып,
Армыйсың син ничек?

Аңа кыз җырлап җавап бирде:

Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын
Якты көн булганда.

Башка төймәләренә баскач, малай белән кыз әнә шулай чиратлашып Габдулла Тукай шигырьләрен укыйлар икән. Рәшит белән Гөлнур уенчыкны бик нык мактадылар, әле мондый могҗиза беркемдә дә юк, диделәр. Тик Самат артык исе китмичә, тыныч кына карап тора бирде.

– Әллә уенчык сиңа ошамыймы, улым? – дип сорады Юныс.

– Ошый да...

– Йә, йә, әйтеп бетер...

– Миңа ни... кирәк иде... Танк, ракета... БТР...

Өчесе дә авызларын ачып калдылар. Ниһаять, Юныс телгә килде:

– Автомат кирәкмиме соң?

– Минем автомат икәү. Берсе четер-четер ата, икенчесе атканда гөлт-гөлт яна.

– Хәзер аның карый торган мультиклары да шундый бит, – диде Рәшит, акланырга теләгәндәй. – Интернеттан аерып булмый. Аның шул шайтан уеннарын уйнаганда кычкыруыннан күпме танк, күпме самолёт, күпме кеше шартлатканын белеп була...

Өлкәннәр бер-берсенә сүзсез карашып торганнан соң, юынып табынга утырдылар.

– Менә бит нинди замана! Оныкларны бездән узып, иблис тәрбияли, – диде Юныс, аптыраудан баш чайкап.

Моңа әйтер сүз юк иде. Гөлнурның борай бәлешен мактый-мактый ашадылар. Чәйләр эчкәч, Юныс:

– Килен, мин бераз сездә кунак булсам, авырыксынмассыңмы икән? – диде.

Аның бу сүзләренә Гөлнур дөртләп кабынды:

– Ни сөйлисең, абый?! Әни үлгәннән бирле чакырабыз бит. Үзебездә генә яшә, дип. Синең беркайчан да безгә артык булганың юк. Сагындырып кына киләсең.

– Беребезгә дә вакыт җитми, дөньясы котырды бит, – дип куйды Юныс. – Халыкта бөтенләй бетте чик-чама, чаба да чаба бичара.

Шунда ишек ачылып китте һәм ике кулына ике автомат тоткан Самат күренде. Автоматның берсе чыннан да четер-четер килә, икенчесенең көпшә башында челт-мелт кызыл ут кабынып тора иде. Аннары ул автоматларын аска төшереп, шигырь сөйләп китте:

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул.
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Юныс аны кочагына алды:

– Вот молодец, улым! Шул арада отып та алгансың бит! Калганнарын да ятларсыңмы?

– Ятлармын.

Шигырь ятлаган өчен мактаулардан соң, Юныс Гөлнурга дәште:

– Кая, мин алып килгән туңдырманы Саматка бир әле, килен.

Гөлнур суыткычтан алып, Саматка туңдырма сузды.

– Рәхмәт, Юныс бабай...

– Зур үс, улым, укырга барганчы шуларны ятлап бетерергә тырыш.

Самат «ятлармын», дип, туңдырмасын ялый-ялый чыгып йөгерде.

Иң элек зиратка барырга булдылар. Аларның туган авылы Чукҗирек инде күптән юк. Рәшитләр аннан унөч кенә чакрым ераклыктагы Табырлык авылында яшиләр. Үзебезнең Чукҗирекне, Алмалы күлебезне ташламыйбыз, диләр, шунда төпләнеп калдылар. Чукҗирек зиратында әби-бабаларының, туганнарының каберләрен карап йөргәндә, Хәния дөнья кубарып шалтыратты. «Мин вычислить иттем синең кайдалыгыңны», дип ярсып сөйли башлаган иде, Юныс без зиратта йөрибез әле, дип, аны тавышын акрынайтырга мәҗбүр итте. Комачаулама, барыбер кайтмыйм, ял итәм, диде.

Авыл һавасының шифасы тидеме, йөрүнең файдасымы – бу төнне Юныс бер мәртәбә дә уянмыйча йоклады. Мондый хәл кызларында бик сирәк була иде.

Иртән ашап-эчкәч, Рәшитнең әллә ничә төрле җимнәрен алып, Алмалы күлгә кармак салырга киттеләр. Әлбәттә, Самат та алардан калмады. Рәшит Юныска суалчаннар, ак кортлар, бүрттерелгән борчак, бодайлар бирде дә машинасын аның янында яр өстендә калдырып, Самат белән күлнең икенче башына җәяүләп китте.

Кармагына ак корт саплап салгач кына, Юныс тирә-юненә иркенләп күз

атты. Йә, бер Аллам! Нишләп безне аерасың син бу матурлыклардан! Синең оҗмахың теге дөньяда түгел, менә мондадыр! Нинди серле, могҗизалы тынлык бу?! Ул тынлык менә бу чут-чут сайраган кошлар тавышыннан, бакалар концертыннан, чумган балыкларның шопырдавыннан, акчарлакларның чый-чыйлап, судан балык эләктерүләреннән, төрле төсле күбәләкләрнең шаярып очуыннан, колак төбендә мең төрле бөҗәкләрнең безелдәвеннән тора. Бу тынлыкка үләннәрнең, чәчәкләрнең, камыш-күрәннәрнең, төнбоекларның хуш исләре дә сеңгән, җем-җем иткән чык бөртекләренең сафлыгы, инде күтәрелеп бетә язган аксыл томаннарның салкынлыгы да кушылган. Мондый илаһи тынлыкны бөтен җиһанның тоташ хәят дулкыны булып тибрәлүе генә тудыра аладыр. Тереклекнең шатлыклы очынуыннан яралган бу сихри тынлыкның куелыгын тәннең һәрбер күзәнәге тоя.

Алмалы күл Юнысны таныды, танымаса, шушы дәрәҗәдә ягымлы итеп каршы алыр идемени? Монда малайлар белән аларның бөтен балачаклары узды. Боз каткач, күлнең камыш-күрәннәрен чабып ягарга да, абзар, өй түбәләрен ябарга да ташыдылар.

Күлнең теге як ярыннан колхозның алма бакчасы башлана иде. Хәзер инде анда картаеп беткән берничә камырлык агачы гына калган. Алмагач утыртуны кайчандыр колхоз агрономы оештырган булган. Бакча юньләп уңыш бирмәгәч, Юнысларның әтисен агроном итеп куйганнар. Ул җил көче белән эшли торган электромотор ярдәмендә агачларга су кудыру җайланмасы эшләгән. Шуннан соң бакчаның даны бөтен Татарстанга таралган. Әниләре елый-елый сөйли иде: әтиләре яз көннәрендә алмагачлар арасында йөри-йөри тальянын өздереп уйный, үзе җырлый иде, аның җырларына алмагачлар чәчәкләрен коя-коя кушылалар иде, ди. Сугыштан җибәргән соңгы хатында әниләренә мондый җыр юллаган:

Бакчада гөлләр бар икән,
Кызыл икән, ал икән;
Синең нурлы йөзләреңне
Күрер көннәр бар микән?

Шушы җырдан соң әтисе Юныска атап бер җөмлә язган: «Мин кайта алмасам, без башлаганны син дәвам ит, илне үстерегез, ямьләгез», дигән... Кояш шактый нык кыздыра башлады. Ул күн курткасын салып, тельняшкадан гына калды. Гөлнур биргән галошларыннан, җылы оекбашларыннан котылып, йомшак үләнгә ялан аяк баскач, балакларын тезенә кадәр сызгангач, бала чагына кайткандай булды. Камыш, күрән сабаклары тирәсендә очкан аллы-гөлле күбәләкләр дә, әллә инде малай кешегә ошатып, аның янында күбрәк бөтерелә башладылар кебек. Калкавыч кына селкенергә уйламады. Юныс әллә җимләде микән дип, кармакларны су өстенә күтәреп карап кире салды, җим исән иде. Шулчак Рәшит яныннан йөгереп, Самат килеп җитте.

– Әллә берәр балык тоттың дамы, улым? – дип каршы алды аны Юныс.

– Юк әле, – дип баш чайкады Самат. – Бабай, озакламас, чиертә башлар, ди.

– Улым, син бу күлнең исеменең каян чыкканын беләсеңме?

– Белмәскә, – диде Самат. – Аны бөтен кеше дә белә.

– Йә, сөйләп күрсәт әле.

– Мөбарәк бабабыз күлнең әнә теге ягына алмалар утырткан. Кү-ү-үп итеп! – Саматның болай сузуыннан чыннан да агачларның күплеген чамалап

була иде. – Анда үскән алмалар бик тәмле булган. Кешеләр яратып ашаганнар. Шуннан күлне дә Алмалы дип атаганнар.

– Ә хәзер бакча кая киткән?

– Бабай сугышта үлгәч корыган.

– Дөрес сөйләдең, улым. Син алма яратасыңмы соң?

Самат авызын чәпелдәтеп:

– Яратам! – диде.

– Ә менә син зур булып үскәч, алмагачлар утыртыр идеңме? – Юныс балага сынаулы караш ташлады: ни дияр икән?

Тик Самат ике дә уйлап тормады:

– Безнең бакчада алма әллә ничә төрле. Күпме ашасаң да җитәрлек.

– Алар бит үзегез өчен. Ә менә башкалар өчен аерым бер җирдә күп итеп утыртыр идеңме?

Самат маңгаен, кашларын җыерып шактый уйланып торгач:

– Белмим, – диде.

– Әгәр без утыртырга кушсак?

– Утыртырмын.

– Рәхмәт, улым, – диде Юныс. – Алмагачлар утыртырга ниятең булгач, мин сиңа үземнең моряк чакта кигән тельняшкаларны бүләк итәрмен.

Самат аның тельняшкасын бармагы белән тотып, тарткалап карады.

– Әллә миңа шушы тельняшкаңны бирәсең, Юныс бабай?

– Әйе, ярыймы соң?

– Әйбәт бу. Матур. Олы гына.

– Ә без аны Гөлнур әбиең белән сиңа тап-таман итеп кечерәйтербез.

– Ярар алайса...

Саматның тагын нидер әйтәсе сизелеп тора, тик кыюлыгы җитми иде бугай.

– Тагын нәрсә бар, улым?

– Ни... Алма бакчасы үстерсәк, аның алмаларын ничек сатарбыз соң?

Юныс чак артына утырмады. Менә сөйләш син болар белән!

– Алмалары тәмле булса, аны сатып йөрисе булмас, чират торып килеп алырлар! – диде Юныс, оныкны аркасыннан сөеп.

Кинәт Саматның телефоны шалтырады. Ул аны колагына якын китереп алды да:

– Рәшит бабайга балык капкан! – дип торып йөгерде.

Юнысның күңелендә кызыгу тойгысы уянып китте. Энекәшенә капкан, ә аңа юк. Аның тельняшкасын күреп, буй-буй алабугалар җыелырга тиеш югыйсә. Әллә калкавыч селкенде инде? Ул карашын калкавычтан аермыйча, ярым иелгән хәлдә, аякларын үләннән шудыра-шудыра, су кырына атлады. Ялан аяклары белән суга терәлгән мүкле үләнгә килеп басты. Сазламыклы җир сыгылып, бармак араларыннан, табан асларыннан аяк йөзенә быжырдап су чыкты. Янәшәдәге күрәннәр, җикән камышлар шәүләсе уртасында суда ул үзен күргәч, калкавыч онытылды. Буй-буй тельняшкасы, тирә-якка тузган ап-ак чәчләре, тоташ елмаюдан торган шат чырае... Тирә-юне сайрап-җырлап, тетрәп тора. Әллә соң бу җиһанның үзәген тәшкил итүче тылсымлы көзгеме?! Ул гәүдәсен турайтты. Күл дә, күк тә, Юныс үзе дә менә шушы тетрәп, яңгырап торучы тынлыктан гына тора кебек. Каршы ярдагы камырлык, балан, зирек агачлары, тал-тирәкләр аермачык булып су өстендә чагылалар. Ул гәүдә авырлыгының югалуын тойды. Рәхәт, җиңел, күңелдә ниндидер татлы ашкыну иде. Йә, Аллам, калкавыч дерт-дерт килә башлады. Ул арада су эченә кереп

үк китте. Юныс колганы өскә күтәрмәкче булды, әмма кармак, тимер ыргакка эләккәндәй, дык итеп туктап калды. «Нәрсә булыр бу?» – дип уйлады ул. – Ауган агач тамырына эләктеме? Әллә корбан-мазармы?» Ни генә булмасын, кисәк тартырга ярамый, юкса кармак җебе өзеләчәк. Ул колгасын акрын гына төшерде, ашыкмыйча уңга-сулга йөртте – кармакта нидер барлыгы сизелә, кабаланмаска гына кирәк иде. Әз-әзләп җепне һаман үзенә тартты, нишләп бу каршылык күрсәтми соң әле, дип уйлап та бетерә алмады – җеп дырт итеп шундый нык тартылды, колгасы чак кына кулыннан ычкынып китмәде. Бераз йөрткәләп тынычландыргач, Юныс колгасын ярга куеп, җептән генә тартырга кереште, менә җепне дырылдатып, балык шапыр-шопыр су өстендә күренде. Юныс соңгы мәртәбә талпынып, балыкны ярга сөйрәп чыгарды. Көрәк киңлеге сап-сары корбан юеш үлән өстендә сикергәли-сикергәли, кабат су читенә төшә башлады. Юныс нишләргә белмичә аның өстенә ятты. Йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып дөп-дөп тибә, нәкъ йөрәге турында буйлы тельняшкасы астында балык бәргәләнә иде.

– Рәшит! Капчык! – дип кычкырды ул үз тавышына үзе буылып. – Капчык!

Яр өстендә аяк тавышлары ишетелгәч, Юныс тынычлангандай булды.

– Әти-и-и!

Хәния аны култыгыннан эләктереп күтәрмәкче булды. Юныс аңа таба каерылып кычкырып җибәрде:

– Җибәр мине! Суга төртеп төшерәм хәзер!

Хәния аның кыяфәтеннән коты алынып, кулларын ычкындырды:

– Нишлисең, эти?! Әллә җенләндеңме?

Юныс аның сүзләрен ишетмәде дә.

– Әнә теге капчыкны алып бир! – диде ул, бераз читкәрәк яткан әйберләр ягына уң кулын селкеп.

Хәния капчыкны алып килүгә:

– Авызын ач! – дип кычкырды.

– Балыкныкынмы? – каушавыннан Хәниянең башы буталган иде.

– Нинди балыкның, нинди балыкның?! Капчыкның авызын ачып тор, пешмәгән бәрәңге! – Корбанны капчыкка салгач, Юныс җиңел сулап: – Аягың җиңел икән үзеңнең. Исәнме, – диде.

– Мин исән, – диде Хәния. – Син генә котырган аю кебек акырасың. Балык өчен шушы кадәр кыланалармыни?!.

– Ә кем әйтте сиңа балык өчен дип?! – Юныс күкрәген киереп, чәчләрен бармаклары белән артка таба сыпыргалап куйды. – Бик беләсең килсә – җиңү бу! Давыллап алу! Төшеп калмаган икәнеңне балык белән көрәшеп ышандыру! Син тотылган әзер балыкка килеп тә, әнә туфлиләрең, сумкаң, сумкаңдагы әйберләрең, акчаңа кадәр чәчелеп ята.

– Синең тавышыңа суга баткансыңдыр, дип чапканда, әйбер кайгысы калырлык идемени?!

Хәния чәчелгән әйберләрен җыйды, сазга буялган балтырларын күл суында юа башлады.

– Син җир өстендәге кешене – мине тотар өчен шул хәлгә төштең. Син менә су эчендәге балыкны тотып кара. Калкавычка күзеңне чекрәйтеп, тын да алмыйча утырып кара! Су астыннан балыкның калкавычны дерт-дерт иттереп, «мин килдем» дигәнен сизеп кара.

Тавышка оныгы белән Рәшит тә килеп җитте. Ул шундый ук зурлыкта бер карп, бер корбан тоткан. Юныс аларның өчесен дә бер пакетка салып Хәниягә бирде:

– Бүген үк куырып ашагыз. Без үзебезгә тагын тотарбыз әле.

– Әти, хәзер үк кайтып китәбез. Үзеңнең кыяфәтеңә кара әле. Саздан сөйрәп алып барган төсле булгансың.

– Ә авылга мин ник кайтты, дип беләсең? Ак туфли, ак чалбар киеп, аяк очы белән коры җир эзләп йөрергәме әллә?

– Сиңа тынычлык кирәк. Мондый дулкынлануны йөрәгең ничек күтәрсен!

– Сөйләмә юкны! Мин хәзер гәүдә авырлыгымны да сизмим. Бу чын терапия!

– Ул-бу булса, монда медпункт та юк.

Юныс «ярдәм ит» дигән төсле энесенә карап куйды.

– Авыл һавасы бөтен даруларны да алыштыра ул, – дип сүзгә кушылды Рәшит. – Күрше авылдан шәфкать туташы үз машинасында килеп кенә тора. Торсын инде. Абый гомергә авылны сагынып яшәде.

– Мин китә алмыйм. Күңелем тыныч түгел. Теләсә ни эшләт.

– Энекәш, барыгыз әле, сез балык тота торыгыз.

Рәшитләр киткәч, чирәмгә үзләре алып килгән җәймәне җәйде.

– Кил әле, кызым, утырып сөйләшик, – дип, аңа урын күрсәтте.

Тик Хәния утырырга теләмәде. Юныс җәймә өстенә кунган бик матур бер чуар күбәләкне учы белән каплады. Аннары сак кына җептән нечкә аякларыннан эләктерде. Күбәләк бизәкле канатлары белән очарга талпынды. Юныс Хәниянең каршына ук килде.

– Ничек тырыша, – диде Юныс, күбәләкне Хәниянең йөзенә якынайтып. – Мине җиңмәкче була.

– Интектермә, рәхәтләнеп очсын, – диде Хәния, башын читкә борып.

– Кызганасыңмыни? – диде Юныс.

– Ничек кызганмыйсың инде? Гөнаһсыз җан иясе бит ул.

– Каян беләсең? Бәлкем гөнаһлыдыр?

– Әти, ярар инде... Очсын үз дөньясына.

– Син әйткәч – закон. – Юныс күбәләкне очырып җибәрде.

Яр буенда гел алар турында гына зур балык шопырдап чумды, хәтта койрыгы да су өстендә күренеп алды.

– Минем кармакны эзләп килгән бу, – дип куйды Юныс.

– Әти, мин синең ник бездән киткәнеңне беләм...

Кызының тавышы үпкәле иде.

– Ни өчен дип уйлыйсың?

– Синең өеңдә дәвалау оештырган өчен.

– Аңа түгел...

– Мин синнән рөхсәт сорамакчы идем. Кинәт кенә медицина җиһазлары кайтты да, шунда тутырдык. Аннары инде... әйтергә нидер комачаулады.

Хәния туктап калды. Юныс күбәләкне очыртып җибәрде дә кызы башлаган сүзне дәвам итте:

– Аны миңа әйтү кирәкмәгәндер дә. Синең белән мин әниең рухыннан рөхсәт сорарга тиеш идек. Үзе карап торган, сине үстергән, гөлләр үстергән йорты бит. Ризалашыр идеме ул? Сезнең өчен бу бөтенләй әһәмиятсез нәрсә, әлбәттә...

– Гафу ит, әти. Булмаган дип уйлыйк, онытыйк та, кайтып китик.

– Гафу үтенергә дә кирәкми... Минем гореф-гадәт, итәгать дигән нәрсәне исегезгә төшерим, дип кенә әйтүем. Ә авылга күптән кайтасы идем. – Юныс

кулын кызының иңбашына салды һәм ягымлы гына әйтте: – Туган туфрагымда бераз булыйм әле. Зинһар, аңла...

Хәния чигенергә уйламады:

– Аңларга да теләмим!

– Ул чакта кил әле, менә бу җәймәгә, – диде Юныс, каты итеп. – Мин сиңа соңгы сүземне әйтәм хәзер.

Хәния этисенең ничек әйткәндә чигенгәнен, ничек әйткәндә үз дигәнен үтәтмичә калмаганын белгәнгә күрә, янына килеп утырды. Юныс аның янәшәсенә чүмәшкәч, һәр сүзенә басым ясап, акрын гына сөйли башлады:

– Мине инфаркт ике мәртәбә куркытты. Курыктым, буйсындым, яшисем килде. Ә ничек яшәргә? Калтырап, бөтен нәрсәдән тыелыпмы? Бу сорауга җавапны сезгә күчкәч, бәргәләнеп эзләргә тотындым һәм таптым. Мин үзем теләгәнчә, башкаларга боерып яшәгән кеше. Кемдер боера икән – ул бик якын кешем булса да – буйсына алмаячагымны аңладым. Шуннан соң мин үземә үзем боерырга кирәк, дигән карарга килдем. – Ул сүзен бүлеп, каршында тырпаеп торган әрем сабагына үрелде дә аны тамыры белән йолкып алды. Тамыр төбеннән борын төрткән яшел үсентеләргә карап торды, «үлмәгән икән бит бу» дип сөйләнә-сөйләнә, әремне урынына утыртты, учлары белән як-ягыннан баскалап куйды. Шуннан соң гына сүзен кайнарланып дәвам итте: – Әйе, үзем белән үзем идарә итәргә! Ничек телим – шулай яшәячәкмен! Мин дигәнчә генә булачак. Сула, аша-эч, алга атла, еракка якты офыкка кара! Әнә ничек матур офыклар!

Хәниянең аяк астында җир бер якка янтайгандай булды. Йөрәге сизде: тормыш дигән зур йортның нигез бүрәнәсе урыныннан кубып бара... Хәния моңа кадәр беркайчан да селкенмәгән олы, мөһим нәрсә турында сүз башланганын сизде, күкрәгенә ниндидер салкынлык йөгерде.

– Мин хәзер ирекле! – диде этисе көр тавыш белән. – Сезнең кебек үк ирекле! Яшәү белән үлемгә килгәндә... эшеңне бетергәч, буталып йөрмәскә кирәк... Чикләвекнең кабыгын ватып, төшен ашагач, аны тагын ник әвәләргә? Төшнең эрерәгеме, ваграгымы... анысы язмыш эше. Адәм баласының иң миһербанлы органы йөрәк «келт» кенә итә дә елганың икенче ярына чыгарып куя... – Аның күзләре күлнең каршы ягындагы зәңгәрсу томан артында сизелер-сизелмәс кенә күренгән офыкларга төбәлгән иде. Шактый вакыт тынып торды да, нәрсәнедер оныткан кешедәй, кабат Хәниягә борылып, сүзен дәвам итте: – Мин синнән риза, кызым. Бала вакытыңда да, укыган чагыңда да игътибарым җитмәде... Булдыра алсаң, кичер...

– Әллә ниләр сөйлисең, эти... – Хәниянең күзләренә яшь тыгылды. – Беркемнән дә ким итмәдең. Син миңа сүз бир: даруларымны берсен дә калдырмыйча эчәрмен, диген.

– Эчәм, әлбәттә! – Юныс җанланып китте. – Ак флаг күтәрсәм, мин кем булам, ди?! Мин күлнең теге ярына юкка гына карап тормадым. Анда этинең алма бакчасы гөрләп үскән. Менә хәзер сизәм, аның рухы шушында – безнең яныбызда гына тора. Әтиләр без яшәсен өчен газиз башларын салган! Мине төн йокыларымнан уята-уята бер сорау борчый: этинең васыятен үти алдыммы?! – Ул ике кулы белән күзләрен каплап, башын селкеп торды. – Үземә бирелгән сәләтнең яртысын гына файдалана алдым, дип уйлыйм. Моның белән мактанып булмый. Тиз яшәлде. Учтан коры ком коелган гына шикелле... Минутлап санайсы булган... – Ул карашын югары күтәрде. – Кызым, күрәсеңме бер кош... әллә тургай... Гел безнең тирәдә сайрый... Күкнең очы да, кырые да юк... – Алар

озаклап күкне күзәттеләр, теге кошның тагын килүен көттеләр. Ул аларның үзен күрергә теләвен сизенгәндәй, юкка чыкты, әллә күктән, әллә үлән арасыннан моңлы тавышын ишеттереп-ишеттереп кенә алды. – Әти рухы алдында искә алырлык бер вакыйга бар. 1962 елгы Кариб кризисында катнаштым бит мин. Кубада ракеталар белән җир шарын сакладык. Америка ракеталары безгә каршы куелган иде. Төймәгә кайсы як басар? АКШ президенты Кеннеди белән СССР башлыгы Хрущев телефонда тарткалаша. Ни булыр? Без ракеталарга береккән. Дөнья ялкынга чорналырмы, юкмы? Вакытны йөрәк тибеше белән, минутлап санадык. Чем-кара чәчләрем шул чакта яртылаш агарган иде. Шунда кигән тельняшкам бу. Исән кайткач, гомер буе кагылмыйча сакладым. Кичә генә кидем менә. Әмма әти алдында акланырга тельняшка гына аз. Алар хыялланган ирек әле бик еракта... Якынайта алмадык... Мин әниең белән синең алда да бурычлы...

– Әти, зинһар, тукта!.. – Хәния үкси-үкси йөзен куллары белән каплады. – Түземлегем бетте... Китәм мин...

Юныс аны иңбашларыннан иркәләде:

– Кызым, бу сөйләшү... бик олы гамәл. Калдыра торган түгел... Ни хәл итим, үкенечләр күп... Әниеңә ратканымны гел-гел кабатлап тормаганыма үкенәм. Бәйрәмнәрдә бүләкләр алып та куандырмадым мин аны. Яратуны әйбер биреп яуламыйлар, дидем. Тәтәй биреп хатыныңның күңелен йомшату ул гөнаһларны юу өчен уйлап чыгарылган гамәл, дип санадым. Ялгышканымны әниеңне югалтканнан соң гына аңладым.

Хәния, күпме генә тырышса да, үксүен тыя алмады, китәргә дип кузгалган җиреннән туктап, артына борылды һәм әтисен кысып кочаклап алды, күз яшьләренә чыланган битен аның кырынмаган кытыршы битенә терәде. Аның өчен бу биттән дә йомшаграк, якынрак нәрсә юк иде җир йөзендә. Кайнар иреннәрен Юныснең колак йомшагына тигереп пышылдады:

– Мин сине шулкадәр яратам бит, әтием!..

Алар, бер тән, бер җан булып, бер-берсенең сулыш алуларын һәм йөрәк тибешләрен сизгән хәлдә бик озак тордылар. Бу иң бәхетле мизгелләр иде. Бу мизгелләргә бөтен дөнья, аларның бөтен тормышы сыйган иде. Шунда ул кызының яшьле күзләренә карап елмайды да сорап куйды:

– Гомергә лексиконыңда булмаган бу сүзләрне каян алдың?

– Киявеңнән, – дип пышылдады Хәния, елмаерга тырышып.

– Молодец, кияү! Мин дә сине өзелеп яратам, кызым!

Хәния әтисенә тутырып бер карады да машинасына атлады. Юныс аның артыннан иярде. Кызы кабинага кереп утырды, моторын кабызды, ал тәрәзәнең пыяласын төшереп:

– Хәзергә хуш, әти! – диде.

– Хуш, кызым, хуш!

Ак машина яшел болын уртасыннан шәһәр ягына юл алды. Ялан аякларыннан тельняшкасына кадәр ләмгә, балык тәңкәсенә баткан Юныс аңардан һаман ерагая баручы кызына иреннәре белән генә пышылдап хәер-фатиха юллады. Үзенең шушы кыяфәттә әз генә дә кымшанмыйча яр башында басып торуы белән ул гомере буе дөньяның барлык диңгез-океаннарын гизеп, шушы яшел бишегенә кайтып өлгәшкән карт матросны хәтерләтә иде...



Фәнәвис
Дәүләтбаев

# БАР УЛ ХАКЛЫК…

РОБАГЫЙЛАР

***

Кем ул әйтә: «Хаклык эзләп маташма да,
Юк ул хаклык – өндә килеш саташма ла».
Бар ул хаклык – Хак Тәгалә, аның дине
Юл күрсәтә саташканга, адашканга.

***

Ялгышулар туып тора бер-бер артлы,
Авыр сорау: кем хаксыз да, кем соң хаклы?
Соңармыйча тәүбә итсен ул гөнаһлы,
Тәүбәлегә Илаһым да хәерхаһлы.

***

Савап кылып яшәп калыйм дигәннәргә
Сабыр гына юл күрсәткән пәйгамбәр дә.
Хөкем кырыс чит өлешкә кергәннәргә,
Комсызларга – акча, байлык сөйгәннәргә.

***

Үзләренә җәза алар сорап тора:
Бәндәләрең хәрам җыя, гөнаһ кыла.
Тыелалмый азынганны-тузынганны,
Тәңрем, җыеп җәһәннәмгә олактыр ла!

***

Җан җылытыр җылы сүзләр кичекмәсен,
Кем булса да үзен ялгыз хис итмәсен.
Шат елмаеп карау язсын кешеләргә,
И күңелем, беркемне дә чит итмә син!

---

Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ (1951) – *шагыйрь; «Суз җырыңны, былбылым!», «Карурман чишмәсе», «Таныш халәт» һ.б. китаплар авторы. Актанышта яши.*

***

Сүз белән дә кылыч болгап уйнап була,
Дошманыңны мәсхәрәләп, кыйнап була.
И юләрем, кем соң сине тыймак була?!
Сүз дәшмәгән акыллылар тыйнак була.

***

Син мактанма йодрык төйнәп – көчем бар, дип.
Син горурлан җанга якын эшем бар, дип.
Шатлан, дустым, бар дөньясын матурларлык
Күңелемдә сүнмәс сөю хисем бар, дип.

***

Тормышы да чоңгыл кебек аска тарта,
Күрче, әнә, яшәвебез бата-калка.
Күпме генә тырышсак та җитми нидер,
Юк тынгылык, мәшәкатьләр генә арта.

***

Бар да әле минем якка, уңай гына,
Канәгатьмен тормыш барса шулай гына.
Яшәткәнгә, бәлаләрдән саклаганга,
Мең рәхмәтле мин һәрвакыт Ходаема!

***

Көчсезгә мин ташланмыймын – түгел киек.
Көнчеллектән яшәмимен эчтән көеп.
Сер түгелдер вак җанлыдан җирәнгәнем.
Минем өчен офыклар – киң, күкләр – биек.

***

Шигырьләрем түгел вәгазь, түгел азан,
Күңелемнән ни телимен шуны язам.
Янып яшәү, илһамланып иҗат итү –
Күңелемнең хасияте – түгел җәзам.

***

Тик сокланып карауларым очкан кошка,
Күңелемнән ышаныч зур якын дуска.
Күгем – биек, офыгым – киң, җаным – тыныч,
Ни әйтсәм дә, рәхмәтлемен мин язмышка!

***

Яшәп булмый гел зарланып, тормыш кыен, дип,
Отасың йә оттырасың – тормыш уен бит.
Үземнең дә хәлләр мөшкел, күреп торасың.
Әй фәкыйрем, әйтә алмыйм, миңа сыен, дип.

***

Сөенәсе имин генә көн үткәнгә,
Тиеше дә эләкми ул җебекләргә.

Тиргә батып, җир җимертеп эшләү фарыз,
Ил таяныр безнең кебек егетләргә!

***

Җиле рәхәт, суы тонык, күге зәңгәр:
Күрә белсәң, шушы җирдә бөтен ямьнәр.
Селтәнсәң дә, языгандай була тәннәр,
Барысы бергә: исләр, тәмнәр, хисләр, гамьнәр!

***

Талпынып очкан бер кош бары – күзәткәнем,
Моңын тыңлап хушланадыр йөрәккәем.
Әллә инде минем кебек сагышланып
Җырлый микән, өзелә дип, үзәккәем.

***

Тыймасаң, эштән кудыра тел дигәне,
Буранлап карны туздыра җил дигәне.
Бәйрәмнәре бетеп торган араларда
Матәм көннәре уздыра ил дигәне.

***

Бер уйласаң, тук яшибез – түгел ачлык.
Акча каян табыйм, диеп йөри башлык.
Бәхетле ит күк капусын көзен ачып –
Хак Тәгаләм, күп иттереп бирче ашлык!

***

Тыныч йокы, әлли-бәлли-бәү диясе –
Китеп барды дөньяның бер әүлиясе.
Туганнан соң гомер дигән тукталышта
Озак тормый җирдә һичбер җан иясе.

***

Тота белсәң, тын күлдә шул балык каба,
Соң түгелме атлауларым сиңа таба?
Җитеш кенә, ярсу аттай вакыт чаба,
Чын күңелдән – яратуым, соң булса да.

***

Син булганда, кирәк түгел мең алтын да,
Әй сөеклем, күңелемә син якын ла.
Мин бәхетле, сиңа таба кулын сузып,
Ят бер шәүлә тормаса синең артыңда.

***

Җиткән инде, син укысаң мин язганны,
Вулкан булып атылырлык хис җандагы.
Иренмичә шигырьләргә күз төшерсәң,
Шәт, белерсең минем нәрсә уйлаганны.



Гәүһәр Хәсәнова

# КАДЕР*

ХИКӘЯ

Тагын шушы коридор. Ярым караңгы, дистәләрчә еллар ремонт күрмичә, һавасына, стеналарына төрле исләр сеңдергән бер өметсез бушлык. Монда бәхетле кеше кермәс: бары тик чарасы калмаган, тормыш тарафыннан авыр сынауларга дучар ителгән үксезләр булыр. Аларның кыяфәтләре дә шундыйрак – төксе чырайлы, төссез киемле, күзләрендә рух юк... Мине дә монда шатлык китермәде, түземлегем бетеп, өметем өзелеп, бар нәрсәгә дә «бигайбә» дигән халәтемдә узган-кичергәннәремә нокта куяр өчен килдем...

Нәрсәдән башланды бу бәхетсезлек? Аның башы да булмады кебек. Ике сукмак бергә кушылмады, бары тик шул гына... Шуңа аларны аерырга да күп көч кирәк түгелдер дип, мин дә беркөнне монда аяк бастым.

Ләкин ялгышканмын, эшнең бу ягы шактый авыр булып чыкты: яхшымы, яманмы, ләкин көйләнеп, бер калыпка салынган тормышны җимерү җиңел түгеллеге көн кебек ачык иде...

Кәгазь тутыру, гариза язу эшләре белән матавыкланып, ике-өч тапкыр киләсе булды. Узган-барганга сораулар биреп, аптырап ишек шакып йөрүләр, көтеп торулар... Бу караңгы озын коридорларда тәҗрибәле кешеләр табылып торды, аңламаган әйберләр җае белән аңлашыла барды... Үз башыннан кичергән кешеләр, яисә шушында сәгатьләр буе суд утырышын көткәндә ишеткәннәрен, белгәннәрен сөйләүчеләр, тәҗрибә уртаклашучылар табылып торды.

Араларыннан берсе белән еш очраштык – ул миңа караңгы тарлыкка иректән ялгыш кына килеп кергән кош кебек күренде. Бу мохит кешесе түгел иде – ап-ак киемнән, озын кара чәчләрен күпертеп өскә җыйган, хуш ис бөркелеп торган затлы бер хатын. Кабат очрашканда, нәрсәдер сорадым, ул бик тәфсилләп җавап бирде һәм без сөйләшеп киттек.

Адвокат булып эшләгәнен әйтте, шуңа күрә шөгыле аны суд бинасында йөртә, ләкин – холкы яисә һөнәр үзенчәлегеме – бу гомум бәхетсезлек,

---

* Kader (гарәпчәдән) – тәкъдир, язмыш.

---

Гәүһәр ХӘСӘНОВА (1959) – *язучы, тәрҗемәче; Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Державин, С.Сөләйманова исемендәге премияләр лауреаты.*

төшенкелек арасында да аның йөзендә һәрвакыт елмаю, күзләреннән нур агыла иде.

Яшебез чама белән бер тирәдә булганлыктан, без тиз генә уртаклык та таптык: бер чорда бер үк югары уку йортын тәмамлаганбыз, бер үк елларда студент тормышы белән яшәгәнбез, икебез дә алтын бишектән төшкән шәһәр кызлары...

Ике җөмлә белән генә мин монда китергән максатымны әйттем дә авызымны артык ачмадым – яктылык, бәхет бөркеп торган хатын янында үземне өшеп күшеккән кош кебек тоясым килмәде. Ә әңгәмәдәшемнең сөйлисе килә иде, ул сөйләде дә сөйләде.

– ...Әле генә ялдан кайттым, диңгез буенда ике атна яшәдем, яшәүнең ләззәтен татыйм... Кояш, ком, фирүзә диңгез. Су чаңгысында йөрергә өйрәндем, шундый кызык икән ул, башта тозлы су йотып рәхәтләндем!.. Җәннәттә бөтен дөнья онытылып тора, андагы матур манзаралар, саф һава, искиткеч җылы, хуш исле төннәр...

(Беләм, беләм мин ул җәннәтне... Әти безне гаилә белән ике-өч елга бер диңгезгә алып бара иде. Ул вакытта, кечкенә булгангадыр инде, анда уздырган атналар бик озын тоелды, диңгезе дә, кояшы да туйдыра, өйгә кайтасы килә башлый иде. Әти: «Шушы көннәрнең никадәр зур бәхет булганын үскәч аңларсың әле, кызым», – дип әйтә иде. Хәзер аңладым инде: әти һәрвакыттагыча хаклы булган. Ничә ел ял күрмәдем, диңгез турында сүз дә юк: балалар кечкенә, артык акча да юк, өйне дә ташлап китеп булмый, ләкин иң мөһиме – арабыз ахыр чиккә җитеп бозылды, андый халәттә диңгездә ял итү турында уйлап буламыни?..)

– ...Ләкин андагы ирләр артыгы белән актив, ялгыз килгәнемне аңлагач, һич тә ирек бирмәделәр. Дорфалык юк, әлбәттә, танышырга телиләр, матур сөйләшәләр... Ләкин мине алар кызыксындырмый, күңелем ятмый, чит кеше чит инде... Мине Казанда якын кешем көтә, ялга бергә килә алмадык, гаиләсе бар, шуңа күрә минем дә ялым ял булмады, тизрәк кайтып җиттем менә...

Без аның белән рәсми бер чарада таныштык, ничектер очраклы рәвештә урыннарыбыз янәшә туры килде. Кайчакта чит кешегә эчеңне ачып сөйләве җиңелрәк, сөйләшеп киттек. Мин иремнән күптән аерылдым, хыянәтен гафу итә алмадым. Йөрәгемне җәрәхәтләде, ничәмә-ничә ел ирләрдән читләшеп яшәдем, һәрберсендә хыянәтче, коры кулланучы күрдем. Ә бу кеше белән аралашканнан соң эчемдәге боз эри башлаганын сиздем. Ул да тормышын сөйләде. Хатыны, ике баласы, яраткан эше, дуслары, һәммәсе бар... Ләкин гаиләсендә тынычлык юк, көн дә гауга, көн дә тавыш, ди. Өйләнгәндә дә, кызны бик үк яратып бетермәгән, ләкин юньле, акыллы хатын булып чыккан, өйне, балаларны карый, үз эшендә дә дәрәҗәсе бар, тик... Арада мәхәббәт булмаса, бернәрсәнең дә тәме булмый икән, ди.

(Аңлыйм, аңлыйм мин сине, чибәр хатын, ни әйткәнеңне һәр күзәнәгем белән тоям...)

– ...Мине мондый итеп сөюче тормышымда булганы юк. Ул шундый ягымлы, аның һәр хәрәкәте йомшак, сак, әйтерсең, мин бер нәфис бәллүр ваза, ялгыш кагылсаң, ватылырмын кебек. Йа Алла, кайлардан насыйп булды мондый яр?..

Хатынның күзләрендә яшь күренде, ул чын күңеленнән хисләнеп сөйли иде. Чит кешегә йөрәген ачуы да аңлашыла – ташыган фикер-тоемлауларын бераз тышка чыгарып, бәлки, анализлап карыйсы килгәндер.

Эчемнән янып, күзгә күренмәс яшьләр белән елап тыңладым – гомер буе аз гына булса да, наз тоеп яшисем, сөю-мәхәббәт эчендә йөзәсем килде, ләкин ирем миңа

карата гел коры булды, холкы шундый: ягымлы сүз әйтмәс, хисләнеп кочакламас... Күңеле чиста, юньле кеше, ләкин һич андый хәрәкәт-сүзләргә һәвәс түгел.

– ...Бүләкләре дә бик зәвыклы, нәкъ минем өчен сайлап алынган әйберләр. Аларга аеруча зур игътибар бирә, күптән түгел мине көчләп диярлек эчке кием кибетенә алып керде: «Бергә сайлыйбыз, матур гәүдәңне тагын да матуррак итеп күрәсем килә», – диде.

(Минем «кылт» итеп исемә төште: бер-ике ел элек матур эчке кием киясе килеп (балалар үсте, имезәсе юк, гәүдәм дә элекке кыяфәтенә кайткан иде), шундый кибетләргә кергәләп йөри башладым. Хатын-кыз челтәр-фәләнгә мөкиббән китә бит инде ул... Ләкин теләгемә ирешә алмадым. «Нәрсәгә кирәк ул сиңа, син болай да нормальный» дип, ирем туктатты. Чыннан да, ул әйткәч, булды бит инде, аның өчен тырышмакчы идем...)

Суд залыннан бер төркем кешеләр чыкты, әңгәмәдәшем кузгалды: аның мөштәрие килеп җитәргә тиеш иде. Минем дә саклап утырган бүлмәмә хуҗасы төшке аштан кайтты. Саубуллаштык.

...Урамда караңгы төшкән иде. Салкын җил, шыксыз яңгыр сибәли. Кайтышлый кибеттән ипи алырга кирәк, балаларга берәр тәмле ризык та онытмаска иде. Кичәдән пешергән шулпа бар, аш өлгертергә җиңел булыр бүген. Барыбыз да сәламәт, шөкер, өебез бар, эшебез бар... Ләкин... Сулап булмаслык дәрәҗәдә елыйсы килә иде. Беркайчан да кешедән көнләшмәдем, чөнки аңлыйм: һәр кеше үз юлын үзе сайлый, үз тормышын үзе яши. Мин дә кеше тормышын яши алмыйм, нигә көнләшергә?.. Ләкин... Ничекләр итеп Ходай бер кешегә шундый хисләр, җылылык бирә, ничек аның юлына шундый нечкә, сизгер, кайнар йөрәкле кешене чыгара да нигә миңа юк? Элек мондый түгел идем, мин дә яндым, дөньямны онытып яраттым, ләкин язмыш салкын, коры, игътибарсыз бер кешене бүләк итте...

...Бер ай чамасы вакыт үткәндер, инде кыш та килде, дөнья агарды, үзем дә бераз тынычландым, буласы эшләр булыр, дидем, минем язмышым – бала үстерүдер, дидем... Көннәрнең берсендә дус кызларым белән кафеда очрашу билгеләдек. Күптән беркая барганым булмаганлыктан, кием шкафыннан озак кына кием сайладым, ниһаять, очрагына туры килерлек киемем юклыгына инанып, һәрвакыттагыча карадан киенеп («нәрсә кияргә белмәсәң, карадан киен» дигән акыллы фикерне истә тотып), балаларны әни карамагына калдырып, кафега юл тоттым. Ирем ул көнне соңрак кайтырга тиеш иде, шунлыктан ул да каршы килмәде.

Тышкы караңгылык, салкын шыгырдавык кардан якты, җылы залга кергәч, башка шәһәргә эләккән кебек булдым, бераз саташып киттем. Дус кызларым утырган өстәлне күреп алдым да, тиз генә чишенеп, яннарына сыендым. Биш минут уздымы-юкмы, инде мин башка бер халәттә идем – студент чакларым искә төште, ике-өч айга бер «Ял» кафесына кереп, туңдырма ашап, әз генә шампанский эчеп, чикылдашып көлеп утыра идек. Ул вакытта безне өметле һәм әйтеп бетергесез матур хыяллар тулы тормыш көтеп тора сыман иде.

Әмма ул вакыттагы үземә бүген кызыкмадым. Буш хыяллар, фильмнардан күреп, китаплардан укып, киләчәк тормышымның булмаслык моделен төзеп, алданып яшәгәнче, хәзерге мин күп тапкыр кызыграк һәм тулы җанлы шәхес бит... Яшәвемнең һәр якты мизгелен, куанычын йөрәгем, тәнем белән тоеп, аңлап яшим, ичмаса! Дусларымны яратам, инде дистәдән артык ел таныш без, алар алдында үземне акыллырак та, матуррак та күрсәтәсе юк, мин ирекле, бер-беребезне ничек бар, шулай кабул итәбез, шулай яратабыз.

Мин иркенәеп, арткарак ташланып утырдым, кызыл шәраб бераз зиһенемне бутаган иде, күңелсезлекләр каядыр китте, уйлап куйдым: йә Алла, мин шундый бәхетле – сәламәт балаларым бар, җылы өем, ашарыма ризыгым бар һәм... әле дә якты өметләрем үлмәгән. Барысы да көенә килер, Алла боерса...

Залда да минем кебек бәхетле кешеләр утыра кебек иде, ярым караңгылык, хуш исләр, тонык кына сөйләшүләр, йомшак музыка... Кинәт залның иң ерактагы бер почмагында мин теге суд бинасында танышкан хатынны күрдем. Каршында миңа аркасы белән бер ир утыра. Ярым караңгы булса да, хатынның нәрсәдәндер рәхәтләнеп көлгәнен абайлап алдым. Бүген ул тагы да матуррак күренде: утыруында, үз-үзен тотышында үз бәясен белгән кешедә була торган зәвыклы иркенлек. Каршындагы ир нәрсәдер әйтте, хатынны кулыннан тотты, тегесе дә тынып калды. Сөйләшүләре җитдиләнде кебек...

Мин эчемнән уйлап куйдым: йә Алла, бу хатын да бәхетен көтеп алган, аны насыйп ярыннан мәхрүм итмә...

...Уйларымны ишеткәндәй, ир ашыкмыйча гына башын борды да минем якка карады...

Дөньяда бәхетнең күләме чикледер, барыбыз да берьюлы бәхетле була алмабыз... Бер кешегә килсә, икенчесеннән китәдер ул бәхет... Залның теге башыннан инде күптән китеп, кайлардадыр адашып йөреп һәм, ниһаять, бәлки, насыйбын табып, сызлаулы, яралы мәхәббәтем миңа төбәлеп тора иде...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

---

*Кайтаваз*

## Сокланып укыдым

Җөмлә саен, әсәрдә исеме аталган герой саен – тарих! Ничекләр өйрәнеп бетердең, ничекләр шундый кирәкле, үз урынында булырдай сүзләрен табып бетердең?! Бу әсәрне укыган һәр кеше боларның барысын да күңеленә сеңдерер, әсәрнең нәфис, матур теленә сокланыр, дип ышанам.

Ничекләр итеп кирәкле шигырьләр (әллә кемнәрнеке!) үз урынында күңеленә килеп торды?!

Кайлардан, ничекләр табып бетердең?!

Берәүнең Тукаебызга карата булган самими мәхәббәтен аңлардай рух, күңел!.. Тукай, Исхакый ише титаннарның кадерләрен белердәй рух, күңел!..

Мин бу юлларны Роза Туфитуллованың «Язмыш җиле» исемле романы басылып чыккан журналлар («Казан утлары», 4 нче, 5 нче саннар, 2019 ел) килеп җитеп укыгач, авторга беренче тәэсиремне әйтим, дип яздым.

Мин үзем – бик өлкән кеше инде. Тукайга багышлап язылган әсәрләрне укымыйча калдырмасам да, бу дәрәҗәдә камил булганын хәтерләмим.

**Саимә ИБРАҺИМОВА**



*Шаһизадә Үтәтиләү улы Әбдикәримов 1956 елның 16 сентябрендә Казакъстанның Кызылорда өлкәсе Кармакчы районы Яңа юл авылында туа. Казакъстан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый. Хезмәт юлын туган районында чыга торган «Коммунизм маягы» газетасының әдәби хезмәткәре булып башлап җибәрә. 1988 – 1995 елларда Байконур телерадиокомпаниясендә баш мөхәррир, рәис урынбасары, телекомпания рәисе булып эшли.*

*Бүгенге көндә Шаһизадә Әбдикәримов «Кызылорда» җәмәгать телерадиокомпаниясе»н гамәлгә куючы, «Когам» (җәмгыять) газетасының директоры, Казакъстан Язучылар һәм Журналистлар берлекләре әгъзасы, Казакъстан телерадиотапшырулар ассоциациясе Президенты, «Нур Ватан» партиясе әгъзасы, Кызылорда өлкә мәслихәте депутаты, «Кызылорда шәһәренең мактаулы гражданы» булып тора. Берничә китап авторы. «Күк астында каһанат» дигән шигырьләр китабы кыргыз телендә басылып чыккан. Шигырьләре татар телендә беренче тапкыр дөнья күрә.*

Шаһизадә
Әбдикәримов

# ХӘСРӘТЛӘНӘ ХАЛКЫМ ӨЧЕН КҮП СҮЗЕМ...

## Үзем турында

Кимчелеге аз сүземнең, тәме – күп,
Һәр әйткәнем күңелдә урын алган.
Байбога әкә иҗатымны бәһаләп:
«Казакъның ул – акыны», – дип зурлаган.

Хакимнәрдән исем даулап йөрмәдем,
Кайберәүләр кебек өшеп йә талып.
Тарпан-тулпарга охшаган холкым бар,
Яманлык күрсәм, калмадым югалып.

Йөз яшермим оялып ил каршында,
Юлым үргә, һаман биеккә илтә.
Кермәсәм дә төрле исемлекләргә,
Эшем мине гел дәрәҗәле йөртә.

Телгәләмим үз-үземне һич кызып,
Дөнья күргән агайлар күк мин түзем.
Әйткәннәрем кадак сыман кагылган, –
Хәсрәтләнә халкым өчен күп сүзем.

Әле галим булып кыштырдый каләм,
Әле ахмак сүздән гауга тудырып.
Язамын һәр җырымны ташка уеп,
Баш өстемдә калсын дип мәңге торып.

Никадәрле ялгыз талант таш ярган,
Таң булып аткан ярып караңгыны.
Бу дөньяда акыннар бар да туган,
Шигырьдә көндәш бары Абай гына!

Кимчелеге аз сүземнең, тәме – күп,
Хакыйкатькә туры килгән гаме күп.
Гөнаһ язылыр казакъка мин булмасам, –
Абайдан башка атаклы акыны юк...

## Кечкенә авыл

Кузгалды поезд...
Кул болгап
Калды туган җиркәем.
Шунда аңладым аның мин
Ничек газиз икәнен.

Ыргый поезд, томырыла,
Борчу-уйларга салып.
Төшеп калыргамы әллә,
«Стоп-кран»га басып?

Парча уранган бакчалар,
Офыкта уйный рәшә.
«Көтәрбез!» дип кулын изи
Җилләр тәрәзә аша.

Юл тоттым мин зур калага,
Хыял дәште җыр булып.
Күз-колак бул оланыңа,
Йөрмәсен дип бозылып.

Алданып ялган дан белән,
Әрәм гомер итмәсен.
Ышанып кеше сүзенә,
Көне бушка үтмәсен.

Яклаучысыз әүлиядәй,
Баштан мең сорау кичә.
Төнлә төшкән шәүлә сыман,
Керерсең кебек төшкә.

Кызыксынып карап барам.
Җанга ятмый ят оран.
Үлемнән качкан Куркыт[1] күк,
Юлдан куркып утырам!

Ыргый поезд, томырыла,
Кочагын ачкан далам.
«Стоп-кран»га басам да,
Барыбер төшеп калам!..

## Атырау[2]. Ялгыз ут

*Имангалигә*

Мамык яуды, күк мендәре ертылды,
Караңгы төн тәмам дөм-кара булды.
«Атырауда кем соң бар мине көткән?»
Соргылт вокзал тетрәп куйды, кылкынды...

Йоклый иде төнге кала төш күреп,
Игътибарсыз иде ул кунагына.

[1] Куркыт – казакъларда мифик герой.
[2] Атырау – Казакъстандагы өлкә.

Биштәремне селкеп кереп югалдым
Күп катлы өйләрнең урамына.

Күргән булды сәфәрләрнең төрлесен,
Сөенерсең, табылса кунар урын.
Җылы керде шул чагында күңелемә –
Ялгыз утка төште шунда күз нурым.

Ялгыз бер ут балкый дәшеп үзенә.
Янып-сүнеп...
Әллә кайдан күренә.
Уразасын бозмас өчен әмәлсез,
Уянгандыр күк агам сәхәренә.

Олы өйдә бүлеп февраль төнен,
Агам каршы алды шулай үз күреп.
Елан елы югалткан җан бавырын
Кабат табып...
        яртыны бөтен итеп.

Яшәвемне яхшыга мин юрадым,
Яхшылардан юлым аерма, Раббым!
Куе чәен җиңгинең тәмләп эчеп,
Язгы Җаек шикелле ташып актым.

Таңга кадәр серләшеп тә гәпләшеп,
Яңа көнгә чыктык, Кояш калыкты...
Ялгыз утның күзеннән тамган нурын
Бар тарафка чәчеп алсу таң атты.

Уйламаган, көтмәгәндә моннан соң
Атырауга таралыр яхшы атым.
Ялгыз уттан җаным алган яктылык,
Бар җиһанга сибәр нурын-яктысын.

Якын булам дисә әгәр иленә,
Уты булган юлаучы җитәр үргә.
Алда ялгыз ут күренсә күзеңә,
Ялгышып та...
        борылып үтә күрмә!

*Казакъчадан* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре.*



*Совет язучыларының I Бөтенсоюз съездында катнашучылар. Беренче рәттә (сулдан уңга): Кави Нәҗми, Алексей Толстой, Максим Горький; икенче рәттә: Ләбиб Гыйльми, Хәсән Туфан, Гомәр Толымбай, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти.*



*«Әдәбиятлар дуслыгы – халыклар дуслыгы» шигаренең рәсми девиз булып яңгыраган чаклары. Сулдан уңга: латыш Вилис Лацис, татар Кави Нәҗми, кыргыз Аалы Токомбаев, рус Александр Фадеев. 50 нче еллар.*



*Бер төркем язучылар Мәскәүгә съездга килгәч. Сулдан уңга: Әхсән Баян, Роберт Миңнуллин, Илдар Юзеев, Мансур Вәлиев, Гариф Ахунов, Ринат Мөхәммәдиев, Равил Фәйзуллин, Әдип Маликов, Рәшит Әхмәтҗанов, Гарәф Шәрәфетдинов, Рөстәм Кутуй, Шәукәт Галиев. 1980 ел.*



*«Тукаебызның тууына 89 ел тулганда, без – язучылар Кырлайда идек!» Апрель, 1975 ел.*



*Язучылар җыелышы президиумы. КПСС өлкә комитеты секретаре Морзаһит Вәлиев, идарә рәисе Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, ТАССР хөкүмәте Рәисе урынбасары, әдәбият галиме Мансур Хәсәнов.*



*Тукаебызның туган ягы Арчаны язучыларыбыз һәрчак зурлый.*

***Фотолар Р.Фәйзуллин, Л.Хәмидуллин һәм Язучылар берлеге архивларыннан алынды.***



*Азат Вахитов 1953 елда Чүпрәле районының Яңа Кәкерле авылында туа. 1968 елда Яңа Кәкерле сигезьеллык, 1970 елда Буа шәһәрендә урта мәктәпне тәмамлый. Казан төзелеш техникумында укый, соңрак Казан инженерлык-төзелеш институтында югары белем ала.*

*Татарстанның атказанган төзүчесе, Россия төзүчеләр берлегенең «Төзелештәге казанышлары өчен» ордены иясе; Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы. Чүпрәле районының Зәки Нури һәм Ульяновск өлкәсенең Габделҗәббар Кандалый исемендәге премияләре лауреаты.*

*«Гомерем агышлары», «Дөньялыкта үзем сунарчы» исемле китаплар авторы. Чүпрәледә яши.*

Азат
Вахитов

# УЙЛАР ДӘРЬЯСЫНДА ЙӨЗГӘН ЧАГЫМ...

## Авылыма кайтсам

Авылыма кайтсам әгәр,
Эзләп яшьлек эзләрен,
Йөримен таңга кадәрле:
Җанга сыймый хисләрем.

Монда минем туган йортым:
Канат чыгардым, үстем.
Иске йорт каеннарының
Шифалы суын эчтем.

Шундагы бәхетле чаклар
Калган үткән заманда.
Тик ул еллар хатирәсе
Истән чыкмый һаман да.

## Көзге этюд

Алтын көзнең асыл мизгелләре...
Һаваларда – торна эзләре.
Җитәкләшеп өлкән парлар атлый...
Бик килешеп тора көз мәле.

Кемдер күтеп ала бу чакларны,
Мин качарга телим күзләрдән.
Тик җәйләрем җәйләнгән шул инде:
Күңел тулы моңлы хисләрдән.

Карлыгачлар киткән җылы якка,
Уйнап очмый минем тирәмдә.
Куагыннан өзелгән бер тәлгәш –
Күзге балан ята чирәмдә...

## Безнең җыр

«Күктән иңгән моңдыр!» – диештеләр:
Искән җилләр хәтта тын калды.
Толымнарың белән уйный-уйный
Ак болытка алар юл алды.

Серле җыр дип кабул итте йөрәк:
Зәңгәр күкләр чумган ал нурга.
Ромашкалы ак күлмәгең төсе
Күчкән иде безнең «ак җырга».

Җылы нурлар иркәләгән таңда,
Без бәхетле идек, билгеле...
Таң чыклары белән бергә әллә
Саф мәхәббәт үзе килдеме?

...Уйлар дәрьясында йөзгән чагым,
Моңлы бер җыр китми колактан.
Икәү язган, икәү ятлаган җыр...
Ишетелә ерак-ерактан!

## Басып торам

Һәр туар көн нидер алып килә,
Һәр көн миңа тормыш сынавы.
Яшәү чоңгылында бөтереләм,
Колагымда тынмас чыңлавы.

Күңелемдә җил-давыллар дулый –
Бер басыла, тагын шашына...
Гаделсезлек тулы замананың
Басып торам зур юл ташына.

## Зөбәйдә

Яшьлегемнең гөлләр бакчасында
Очрадың син миңа, Зөбәйдә,
Чәчәк бүләк иткән идем, өзеп,
Көтмәгәндә, кинәт шул җәйдә.

Еллар гына түгел, гомер кичтек,
Авырлыклар күпме булмасын,

Тормыш дәрьясында туры йөздек,
Югалтмыйча яшәү кыйбласын.

...Җәйләр узып, көзләр җиткәч кенә
Зөбәйдәмнең сиздем карашын.
«Мин көзләргә китә алмыйм, – диде,
Җәйләремдә килә каласым».

Көзләр бары минем өчен генә,
Ә син һаман җылы җәйләрдә...
Әрнеп өзгәләнә нечкә бәгырь –
Йөрәгемне кысып бәйләргә
Син кирәксең ласа, Зөбәйдә!

## Яфрак

Ни дип әйтим, карт агачтан
Өзелгән бер яфракка.
Җил очыртып алып киткән
Кәүсәңнән бик еракка.

Сагыш тарала, үзеңме,
Әллә көзләр елакка?
Соңгы гомер чигеңдер бу –
Әйләнерсең туфракка.

Кешеләр дә яши җирдә
Шул яфрак кебек кенә.
Язмыш җиле күтәрә дә –
Җибәрә сибеп кенә...

## Каһарман

*Авылдашым – Советлар Союзы*
*герое Зариф Алимовка багышлана*

Язлар саен киек казлар кайта,
Каңгылдашып оча биектән,
Шунда туып үскән инде алар,
Кизләвенә төшеп су эчкән.

«Язлар белән кайтыр Зариф!» – диеп,
Якыннары көтте өзелеп,
Өч ай калгач Җиңү иртәсенә –
Гомере калды кинәт киселеп..

Юк, үлмәдең, Зариф, һаман да яшь –
Каһарманы булдың Ватанның.
Син һаман да якты йолдызы бит
Илем өчен аткан ал таңның!

Җиңү байрагының кызыллыгы
Батырларның каны төсеннән...
Сез үлемсез, сугыш батырлары! –
Һич чыгармас халкым исеннән...

*Миләүшә Гафурова 2000 елда Балтач районының Карадуган авылында туган. 2017 Бакый Зыятдинов исемендәге Карадуган гимназиясен тәмамлап, шул ук елны КФУның Журналистика югары мәктәбенә укырга керә. Шигырьләре төрле матбугат чараларында басыла. Рәсем ясау белән мавыга, тәрҗемә белән шөгыльләнә.*



Миләүшә
Гафурова

# КӨН ДӘ ДОГА...

## Утызынчы ел

Үкенмәскә,
Чын яшь чактан
Иң зур хаталарны җыеп
Яратырга
Өйрәтәчәк
Тәүге утызынчы елым.
Аптырарга:
«Кая куйдым
Мин бу соңгы ун елны?» – дип
Һәм, ниһаять,
Кисми түзеп,
Үстерергә озын толым.

Күп булырга
Өйрәтәчәк,
Тик кирәккә чәчелергә,
Ялганларга,
Сорасалар:
«Әни, син ник шундый уйчан?»
Сагынырга,
Кичерергә,
Аңларга иң якыннарны
Һәм укырга
Көн дә дога,
Көн дә дога,
Онытмыйча.

## Җуелган

Иртән кояш һәр атомга шыплап үзен салып куйгач,
Кабатлангач кабатланмас иң пакь уйлар,
Ертып керфек кочакларын ачылырлар гашыйк күзләр,
Һәм арылыр мәхәббәткә бетмәс мәдхияләр өзләп,
Һәм дәшелер: «Зинһар, үзгәрмә!»

Кояш үзен һич кызганмый көн дә дөньяга сибелер.
Кабатланмас сагынылган иң пакь уйлар.
Кабатланыр бары меңәр иртә элек әйтелгәне
Алышынып куркынычка: «Син, чынлап та, үзгәрмәдең,
Тик...
Нидер бөтенләйгә үзгәрде.

Ни өчен син миңа хәзер бар дөньяның үзе түгел?
Ни өчен син бары
Бердәнбер?»

## Мәҗүси Бердәнбер

Дан, акча, аш, китап, эш, намус...
Ышана, калтырый, җан бага –
Мәҗүси
Кешелек
Махсустан
Табына
Башкага,
Башкага.

Хәлбуки,
Азакта
Бер Аңа
Иганә
Һәм корбан
Буласы.
Кичекми
Үти Ул,
Искертми
Борынгы
Рәхимсез
Йоласын.

Ул үзе
Сибелгән–
Сеңдергән
Дөньяга мәҗүси тәрбия.
Яралган
Бу җиһан –
Илаһи,
Туган һәр
Кисәкчек –
Әүлия.

Ә кеше
Аларга
Баш кага,
Табына,
Ялгышып,
Башкага.

Бер мизгел
Уяныр,
Тетрәнер,
Таң калыр,
Төшенер
Хаклыкка,
Шашынып
Пышылдар
Эченнән:
«Ярлыка!
Ярлыка!
Ярлыка...»

Һәм башка
Эзләмәс,
Ул белер:
Ымсынгыч
Дөньялык –
Саф рәшә.
Ул тояр,
Ул җырлар,
Ул күрер,
Сокланыр,
Яратыр...
Ул яшәр.

Аңдагы
Яшерен,
Хак-кыргый
Мәҗүси
Кутырын
Актарыр
Һәм юар
Дөньяга
Инкыйраз
Ятлаткан
Алгарыш
Тапларын.

***

Ә бүген
Ай тулган.
Ай тулган
Хисләргә
Һәм әзер
Нур белән
Телемләп кисәргә
Бер гомер араны,
Йолырга,
Эчәргә,

Яктылык тизлеген
Өстәргә
Күчәргә...
Сорыга манылган дөньяны –
Тылсымга.
Гыйшыкка –
Гыйбадәт:
Булганга,
Булсынга.

Ай бүген —
Кан һәм сөт,
Тән һәм рух,
Кол һәм бәк.
Ә бүген
Ай тулган.
Ай тулы –
Мәхәббәт.

Ә иртән
Тулган ай
Яңадан түгелер,
Калдырып киткәндә
Икәүгә –
Бер гомер.

***

Корбан итмим –
Бу тормышка мин үземне бүләк итәм,
Тын калсынга
Һәм... ымсынып
Уйлансынга.
Чәчкәләрнең серкәченә,
Мең өркәчле комлыкларга
Мин үземне сибеп китәм,
Шунда эреп
югалсынга.

***

Яңгыр килә,
Машиналар өелеп килә бер үк көйгә.
Бер үк яктан.
Бар да – сиңа.
Бик теләсәң, әйдә, сына.
Мине сына,
Бар дөньяны:
Хак Аллага табынамы?
Сына.
Чәнчүле-кысылган
Күзләреңнең
Карашына
Түзалмыйча,
Бер мизгелдә
Ул да сынар.
Шушы сыңар
Болыттан да яшен аңкый.
Машиналар – шәһри буран.
Көлемсерәп,
Әйдә, сына.
Мин янында карап торам.

Әйдә, сына бу шәһәрне,
Бу юлларны,
Бу халыкны,
Бу галәмне –
Бар дөньяны:
Ул чынлап «Сиңа» лаекмы?

Сына.
Кытыршы тавышың
Бар тарафка бердәй чәчеп,
Бу җир шары синле булу
Горурлыгыннан үлгәнче.

Төшеңә үк явар идем.
Карашың – бердәнбер киртә.
Тик син бары сына мине!
Кыргыйларча чәнче, үртә!

Әле иртә.
Бер бокалдан – бар дөньяны...
Әле иртә.
Син башканы эчәсең,
Ә
Канның исе дә исертә.

# МИЛӘҮШӘ ГАФУРОВА ШИГЫРЬЛӘРЕ

Миләүшә Гафурова шигырьләрендә лирик героиняның тормышка гадәти булмаган караш ноктасында торуы, ак шигырьгә өстенлек бирү башта ук игътибарны җәлеп итә. Ак шигырь – фикер, акыл әдәбиятының формасы, дөньяга үзенчәлекле мөнәсәбәтне, бәяне җиткерү юлы. Татар әдәбиятында актив түгел, бәлки, гадәти булмаган шагыйрьләр иҗатының визит карточкасы. Бу форма шигырьдәге вәзен-көйнең бозылмавын, алай гына да түгел, эчтәлеккә тәңгәл эмоциональ көй табуны, сүзләрнең уңышлы сайлануын да таләп итә.

Беренче шигырь – «Утызынчы ел». Эчтәлек ягыннан, лирик герой кеше тормышында беренче утыз елның мөһим булуын белдерә: кеше шушы аралыкта яратырга, сагынырга, кичерергә... өйрәнә! Психологиягә караган көтелмәгән фикер шигърияткә әйләнгән – шәхси-фәлсәфи лирика үрнәге. Әмма текстта кинаяле шигырь орлыгы да бар: аның исеме 1930 еллар белән бәйле эчтәлек эзләргә этәрә. «Иң зур хаталарны», «кичерергә» һәм көн дә дога укырга дигән гыйбарәләр дә шушы тәэсирне көчәйтә. Әмма бу кинаяле эчтәлекне Миләүшә текстка урнаштырырга уйладымы, әллә минем укучы буларак эзләнүем шуңа алып чыктымы – бу сорауга тәгаен генә җавап биреп булмый. Гәрчә икенче эчтәлекне формалаштырырга мөмкинлек булса да!

Форма ягыннан – 2 строфалы. Беренче строфа 8/8 үлчәмле 8 юллы; 1, 3, 5, 7 тезмәләрнең икегә бүленүе күзәтелә (4+4/8; 4+4/8 рәвешендә). 2, 4, 8 тезмәләр рифмалаша һәм беренче строфа интонацион шигырь булырга дәгъва итә. Әмма икенче сигезлектә шушы вәзен саклanса да, рифмалашу юк. Димәк, ак шигырь дигән нәтиҗәгә киләбез. Гомумән, Миләүшә эчке рифмалар белән эшли белә, икенче строфада бу мөмкинлекнең барысы да файдаланылмаган.

Сүзләр сайланышын карыйк. «Чын яшь чактан» – «чын» сүзен куллану «Ялган яшь чактан» дигән алогизмга алып чыга! *«Күп булырга / Өйрәтәчәк»* – бу сурәт аңлашылып җитмәдә: шигърият гомумән үзең булып яшәү турында сөйли һәм беренче утыз елда кеше, иң беренче чиратта, үзе булып яшәргә өйрәнергә тиештер. *«Ялганларга, / Сорасалар: / «Әни, син ник шундый уйчан?»* – бу сорауга ни өчен ялганлап җавап бирергә кирәк икән?! Шул рәвешле, текстның өстенлеге дә, кимчелеге дә бер үремтәдә: яңалыгы бар, формага тәңгәл сүзләр сайланышына игътибар сорала.

«Җуелган» ак шигыре сурәтләрнең гадәти булмавы белән Шамил Анакның иҗатына аваздаш тоелды (бәлки, фигыльнең Анак яраткан ер-ыр формасы шундый тәэсир уятадыр). Мәхәббәт турындагы сәер шигырь. Фикер матур һәм көчле: чын мәхәббәт ул – сөйгәнеңне «бар дөньяның үзе» дип кабул итүдән «бердәнбер» дип карауга килү. Уйландыра, шигырьнең исеме белән бәйләнештә исә, «бар дөньяның үзе» дип карауның җуелуына үкенеч, якты сагыш кебек тә кабул ителә. Автор бик нечкә хисләр тирбәлешен бирә алу сәләтенә ия!

Чираттагы шигырь – «Мәҗүси Бердәнбер», фәлсәфи әсәр, укыла һәм кызыклы, әмма фикер буталчыклыгы бар. Кешелек ялгыш кыйммәтләргә: «Дан, акча, аш, китап, эш, намус»ка табына дигән, беренче строфада әйтелгән фикер җәмгыятьне мәҗүси, күпаллалык баскычында дип бәяли. Кыйммәтләр арасында эш, намусның булуы, тәнкыйтьтән бигрәк, уйландыру өчен хезмәт итә. Һәр строфада бу фәлсәфә көчәйтеп барыла: һәркем үзе табынганга корбан була; һәр кеше – әүлия булып дөньяга килгән һ.б. Мәҗүсилеккә – кешенең үзе Алла (әүлия) булуы каршы куела һәм соңгы строфада киләчәккә юнәлтелгән фикер (*«Һәм юар/ Дөньяга / Инкыйраз / Ятлаткан / Алгарыш / Тапларын»*) ничек аңланырга тиеш? Алгарыштан баш тартып, кеше үзенә табына башларга тиеш дипме? Ягъни биредә фикер аныклыгы таләп ителә.

Хисләрне көчәйтә барып фикерне үткенәйтү өчен кулай форма табылган: 9/9-ның бүленеп урнашуы. Әмма вәзенне саклау өчен генә кертелгән сүзләр бар: *«Кешелек / махсустан / табына»; «җан бага»*. Гомумән, М.Гафурова каләме мәхәббәт лирикасында түгел, фәлсәфи лирикада көчлерәк.

«...Әле кайчан гына мине йөрткән дөнья...» – өлгергән фәлсәфи шигырь, анда туфрак бул дигән дөньяга хәят булам дип каршы торучы кеше, аның ныклыгы, гыйсъянчылыгы раслана. Тууга ук һәр тере җан үлемгә юнәлә дигән хакыйкатьне кабатлаган лирик герой (*«Агачлар орлыкта ук – күмер һәм төтен»*) бу закончалыкка башкача күз ташлый: «зур йолдыз» кечесен йотканда, ул эзсез югалмый дип белдерә. (Сүзләр сайланышы ягыннан *«Кечесе юк булмый – ул булып тарала»* дигән фразаны *«Кечесе юк булмый – ул янып тарала»* кебегрәк үзгәртү сорала). Ягъни кешенең үлеме дә Илаһидан яралу һәм Илаһига кайту булырга тиеш! Бу фәлсәфә »...Корбан итмим...» шигырендә дәвам итә. Кеше – яшәешнең аерылгысыз өлеше дигән пантеистик караш матур шигъри формага төрелгән.

Аерым бер очракларда табигать сурәтләнеше фәлсәфә белән матур үрелеп китә (*«...Ә бүген ай тулган...»*). Табигатькә мәдхия – кеше фәлсәфәсенә әверелә («Тоташ кыш»).

Гомумән алганда, тупланмадагы шигырьләр М. Гафурованың модернизмга өстенлек бирүе турында сөйли. Татар поэзиясендә модернизм кысаларында яңарган озын шигырь формасы, гыйсъянчы лирик герой урынлы кулланыла. «...Яңгыр килә...» озын шигырендә Җиһанны бар итүчегә эндәшүче гыйсъянчы лирик герой XX йөз башы шигъриятен хәтергә китерә. Шундый ук характердагы «... Хөкем юк...» исә татар поэзиясендә 1930 елларда яратып кулланылган аң агышы-фикер агышы алымына корылган. Ул лирик геройның үзенә эндәшеп, үз-үзен зур максатлар белән яшәргә чакыруы төсен ала. «... Күңелдән җитәкләп...» шигыре – күңелнең бар дөньяны үзенә сыйдыра һәм алыштыра алуы турында, заманча һәм кызыклы. «... Шәһәрең Кабанның суында тибрәлә...» – аралашу-аңлашу сере: анда сөю өчен күңелләрнең сөйләшүе кирәк дигән матур фәлсәфә яшеренгән.

М.Гафурованың модернизм кысаларындагы серле текстлары тормышның *«күләгәле-билгесез»* яклары турында матур итеп сөйли. »... Кытыршы дивар да...» – кеше фәлсәфәсе, кешенең *«тузаннан», «дивардан», «вакыттан» – «нур»* эзләве гаять җылы. Гыйсъян фәлсәфәсен тергезгән «...Мин Аллаһның кылы...» шигырендә образлар рәте кешене бәяли: Аллаһның елавы, таңда сайрап үлгән кош, ташкын, дога, җылы, җыр. Болар – кеше җанының (лирик геройның, гомумән, кешенең) сурәте булып аңлашыла. Бу текстлар миңа XX гасырның беренче чирегендә өзелеп калган татар модернизм фәлсәфәсенең XXI гасырда уңышлы дәвам итүе булып тоелды.

Әлбәттә, мондый текстларда сер сүзләрнең урынлы, яңгыраш ягыннан охшатып сайлануына да бәйле булырга тиеш. Кайбер очракларда сүзләрне башкаралары белән алыштырасы килеп кала. Форма ягын да уйлап бетерәсе бар. Мәсәлән, «Шигырь» – дөньяның тәртипсезлеге, хаос халәте турында. Вакыт, тормыш агышы – туктаусыз хәрәкәт, төгәлләнә дә яңадан башлана. Бу мотив күңелемдә Н.Гамбәрнең «Кабатлана...» шигырен яңарта. Миләүшәгә Н.Гамбәрнең, Г.Сәлимнең, Ш.Анакның, яшьләрдән – Л.Гыйбадуллинаның шигъриятенә кабат-кабат әйләнеп кайту үз юлын, ак шигырь өчен мәҗбүри булган үз көен-музыкасын табарга ярдәм итәр кебек.

«Шигырь»нең формасы, вәзене шулай ук аерым бер нәтиҗәләргә этәрә. Асылда, 4 строфа, 6-шар тезмәле: 6-9(3+3+3)-9(3+3+3)-6(3+3)-6-9(3+3+3) үлчәме иректә аерылган. Ул И.Юзеевнең авангард строфасын хәтерләтте (И.Юзеевнең авангард тәҗрибәләре: экспрессионизм // Д.Ф.Заһидуллина. 1960-1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан, 2015. 64-85 бб.). Мондый строфаларда каймалап алу алымы фикерне төгәлләштерү өчен кулланыла ала. Миңа кешенең үз-үзенә кайтуы фәлсәфәсен җиткергән «Кайту (мин сине тоям)» шигырендә дә шушы алым урынлы булыр кебек күренә.

Әлбәттә, күзәтүләрнең күбесе – шәхси мөнәсәбәт, әмма М.Гафурова иҗатында индивидуальлекнең, фикернең көчле булуы мине әлеге детальләр хакында җентекләбрәк сөйләшергә мәҗбүр итте. Чөнки Миләүшәдә сәләт бар, әмма шагыйрьлек – зур хезмәт һәм тырышлык та таләп итә.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

*Миләүшә Гафурованың журналга кермәгән шигырьләрен сайтыбыздан укый аласыз.*



Сәмига Сәүбанова

# ДИАГНОЗ

ПОВЕСТЬ

Фатир юклыгы үзәгенә үткән иде Наиләнең. Иренең фирмасы да бар югыйсә. Күпме кешегә йорт салып бирде, ә һаман да үз куышына җитәрлек акча эшли алмый әле. Булыр да иде, Лилия сау-сәламәт туган булса...

Ходайдан узып беркая да китә алмыйсың шул. Югыйсә, ризык та талымламады, җиңел күтәргән иде.

Исемен дә алдан уйлап куйган иде. Лилия... Чәчәк кебек матур кыз булыр, янәсе. Сәламәт булсын, бөтен әгъзасы да төгәл булсын дип тә теләгән иде.

Башка балаларны әниләренә имәргә китергәндә, ул нәүмиз булып, аларның имезгәннәренә кызыгып, тулышкан күкрәген сыкты. Сөт төшмәсен өчен күкрәкне тыгыз итеп бәйләп куярга кушканнар иде. Балагыз ими сөтен суыра алмас, янәсе. Ничек итеп моңа риза булсын ул? Үзенең сөте була торып, ясалма ризык ашатыргамы? Балага әни сөте яхшырак бит! Сөте булган чаклы үзенекен ашатачак ул аңарга.

Үзең тапкан баланы ничек инде күрергә ярамасын! Кем уйлап чыгарган ул кагыйдәне? Балагызны зонд аша тукландырабыз, диделәр диюен. Кайчанга хәтле шулай булыр? Аларны өйдә зарыгып көтәләр бит!

Бәбинең дөньяга килүен дүрт күз белән көткән Камил дә кәефсез. Хатынының исән-имин котылуына сөенсә, бала белән туасы проблемалар алдында ул да югалып калган. Үзе Наиләне тынычландырган була тагын.

– Кайгырма, Ходай безгә бу сынауны җибәргән икән, ярдәменнән дә ташламас. Ул без күтәрә алмаслык авырлыкны җибәрми. Мин белештем, балабызның кимчелеген дәвалап була.

Дәвалап була дип әйтүе генә ансат. Олы кеше түгел бит ул, сабый гына! Аңынчы ничек ашаталар, ничек яшәтәләр? Нигә күрсәтмиләр, нәрсә яшерәләр? Бөтен саны төгәл кебек иде бит аның, туу белән елап та җибәрде. Әллә аның баласы елый инде? Колакка гел бала елаган тавышлар гына ишетелә.

Көткән кешегә минутлар сәгатьләр кебек тоела.

– Сезнең балагызны аерым блокка урнаштырдык әлегә, – дигән иде аңа табиб.

Кайчанга хәтле аерым блокта тотарлар аны?

– Аны бер урыннан икенче урынга башка балалар кебек йөртеп булмый әлегә, – дисә дә, баласын кулына алып, ими каптырасы килә. Әнисенә алып килсәләр, имезү җаен табачак ул, табачак!

***

Баласын күргәч, ул имәнеп китте. Аның баласымы бу? Болай түгел кебек иде бит!

Сабыйның өске ирене ачылып, авызы ябылмыйча бөтен урты күренеп, бүре баласыныкыдай ыржаеп тора иде. Ул баланы алам дип сузган кулын тартып алды.

– Минеке түгел! Минем бала түгел! Баламны алыштыргансыз! – дип кычкырып җибәрде.

Палатадагы әниләр дә үз балаларын имезергә онытып, аңа төбәлделәр.

– Туйга хәтле төзәлә ул, – диде акушер-табиб. – Аяксыз-кулсыз туган балалар да бар бит. Сезнең бар җире дә төгәл. Бу кимчелек төзәтеп булмаслык түгел, бераз көтәргә генә кирәк.

– Кыз бала бит... Ничек яшәр ул бу йөз белән?

– Алла ташламаса, бәндә ташламас.

– Ташлаган бит ул безне, әллә кайчан ташлаган!

– Авырлыклар сынау өчен бирелә. Аллаһы Тәгалә үткәреп җибәрмәстәен бирми.

– Әйтүе генә ансат. Сезгә әйтергә җиңел ул... Нишлим мин хәзер бу бала белән?..

Табиб тагын берничә тапкыр аның белән сөйләшергә тырышып карады әле. Ә ул һаман бер сүзне кабатлады:

– Минем бала бу түгел!

Берничә көн үгетләп карагач, аның янына баш табиб үзе килде.

– Баладан баш тартам, дип кул куярга кирәк сезгә, – диде ул. – Сезне монда озак яткыра алмыйбыз бүтән. Соңгы тапкыр балагызны күреп калырга теләмисезме?

– Минем бала түгел ул.

– Сезнең үз балагыз. Ышанмасагыз, генетик экспертиза ясарга туры килер. Аны ясарга акчагыз бармы соң?

– Сезнең гаеп белән булгач, мин акча түләргә тиешмени?

– Шуның өчен дә без аны алудан баш тартылган балалар реестрына куябыз. Дәвалагач, үзегез кебек бик матур кыз булачак ул. Бу баланы алырга теләүче бар.

– Кем?

– Баласыз гаилә. Ул гаиләнең мондый патологияне төзәтергә матди мөмкинлекләре бар. Башка яктан кимчелеге юк бит.

Таза бала белән дә мең төрле мәшәкать. Ә чирле баланың борчу-мәшәкатьләрен санап бетерерлек түгел. Баланың үзенеке булмавына шикләнгәннән генә түгел, ә чарасызлыктан, нишләргә белмәгәннән дә шулай әйтә бит. Табиблар моны бәби тапканнан соң була торган халәт дип аңлаталар. Риза ул, баласы хакына аны бер тапкыр да күрмәскә риза, тик аны кеше генә итсеннәр!

– Мин риза, – диде ул.

– Ирегез белән киңәштегезме? Ул нәрсә әйтер? Ул да кул куярга тиеш бит?

– Аның кул куюы кирәкми. Без аның белән ЗАГСта язылышмаган.

– Ул бит барыбер аның атасы.

– Әйе, атасы шул. Аның белән киңәшермен... Риза булмый нишләсен ул да? Риза без, риза! Кул куям! Бала белән ул түгел, миңа интегәсе бит!

Аннан соң да җавап табасы була бит әле. Үлде, дип котыла алмассыз... Бирегез, җирләргә кирәк, диюе бар бит әле.

Наиләнең башында мең төрле уй кайнады.

***

Килененең бәбидән баш тартырга җыенганын ишетеп, каенанасы килде.

– Беркемгә дә бирмибез баланы, үзебез үстерәбез! – диде ул.

– Без аны менә дигән гаиләгә бирәбез. Сез бит закон буенча чит кеше саналасыз.

– Беләм мин менә дигән гаиләләрне!

– Мин сезне аңлыйм. Тик сезгә дә болай гына биреп булмый. Законлаштырырга кирәк. Имине ала алмый ул. Без аны зонд аша ашатабыз... Ә болай ул баланы алам дигән кеше бар... Менә бит калдырам дип кулын да куйды инде...

– Ошамаса, кире бирергә ул товар түгел! Бала тапканда миңгерәйгән генә ул! Баладан яңа гына котылган кеше нәрсә димәс? Кая кул куйган кәгазе?

Табиб өстәлдән әлеге кәгазьне бирде. Әби кеше аңа күз салып та тормыйча ертып атты.

– Нишлисез, бу документ бит!

– Документ булмагае чурт булсын! Баланы китерегез. Нинди баладан баш тартканын күрәсем килә, – диде ул.

Табиб әби кеше белән бәхәсләшеп торуның файдасы юклыгын аңлады бугай.

Ул аңа халат бирде. Озын коридор буйлап балалар блогына таба алып китте һәм иң читтәге карават янына алып килде.

– Менә сезнең оныгыгыз.

Әби балага карап уйланып торды. Киленен гаепли алмады ул. Бу балага косметик операциягә хәтле пычак астына ничә тапкыр ятарга туры киләчәк әле. Һәр ана баласына матур тормыш тели. Әйе, әлегә аларның андый мөмкинлеге юк. Ә кайчан була соң ул мөмкинлек? Шул мөмкинлекне көтә-көтә гомер үтеп тә китәргә мөмкин.

Оркыяның нинди генә хәлләрдә дә югалып калмый торган гадәте бар иде. Аның баш мие компьютердан да тизрәк эшли башлады. Әле моңынчы аның кулын сузып, акча сорап йөргәне юк иде. Булганыннан канәгать яшәде, артыгын өмет итмәде, нәфесен зурайтмады. Тик оныгы турында сүз барганда, элекке гадәтләрен онытып торырга әзер ул!

– Бернинди кешегә бирү юк. Үз сөягебез үзебездән артмас, – диде ул, ике уйларга урын калдырмыйча.

– Әйдәгез, алайса минем кабинетта сөйләшик бу турыда, – диде табиб.

– Сөйләшик соң.

– Баланы без бүген үк әнисенә биреп чыгара алабыз. Тик бер ләкине бар бит... Безгә, баланы шушы хәлендә сезгә бирсәк, җавап тотарга туры киләчәк... Баланы башта бүтән бүлеккә салып, аны өйдә яши алырлык хәлгә китерәсе бар... Аны даими күзәтеп торырга кирәген аңлыйсыздыр инде... Күрәсез, имә алырлык хәлдә түгел. Зонд белән көненә алты тапкыр ашатасы була. Сез аны эшли аласызмы? Балада гадәти бүре авызы гына түгел, аның авыз куышлыгын формалаштыру өчен берничә операция кирәк... Без аны белгечләргә күрсәтергә тиешбез!

– Сез балалыкка алучы бар, дидегез бит! Аңа биреп җибәрергә ярый, ә үз әнисенә юк?

– Анысы бөтенләй башка мәсьәлә. Ул баланы кеше итә алырдай мөмкинлеге барлыгына декларация тутырды. Бар расходны да каплавы турындагы документ ул.

– Акчасы булган кешегә баланы алырга ярый, үз әнисенә – юк?

– Киленегез закон буенча ялгыз ана санала. Аңынчы туган ике баласы да үз исеменә генә яздырылган.

– Бу бит формально гына! Ялгыз ана булып фатир алырга чиратта тора ул, шуның өчен генә... Фатир булу белән язылышачак алар, улым балаларны да үз исеменә күчерәчәк.

– Үз балаларын уллыкка ала булып чыга инде.

– Теләсәгез ничек уйлагыз. Минем кеше өчен бала таба торган киленем дә, улым да юк! Хәзер һәркем үзенчә тормышын җайлый. Безнеке дә җайланыр. Без баланы кайчан алып китә алабыз?

Әйе, һәркем үзенчә җайлый... Ярый ла ире ышанычлы булса. «Ирләргә таянма, Иделгә таян!» дигән әйтем дә бар бит әле... Ирләр алар авырлыкка чыдамый, авыру бала белән күп вакыт ана кеше ялгызы кала.

Табиб әби кешегә шуларны аңлатырга теләде. Тик әби үз сүзеннән кире кайтырга уйламады да. Әбинең ныклыгы аңарга карата ихтирам, соклану хисе уятты. Бөтен әбиләр дә шундый булса, ятим балалар азрак булыр иде дә соң...

* * *

Ул чаклардагыны искә алсаң... ничек түздек икән дә, ничек чыдадык икән, дип гаҗәпләнергә генә кала. Ялгыз ана буларак, фатир алу турындагы хыялны да тормыш җилләре мамык кебек әллә кая очыртып кына алып китте. Ире дә «формально» буйдак булып йөрүдән бигрәк, балаларның үз фамилиясендә булмавыннан туеп, мөнәсәбәтләрне законлаштырды, балаларга үз фамилиясен бирде. Әкренләп баланың йөзен кеше кыяфәтенә кертү мәшәкатьләре башланды. Сәламәт балаларга игътибар азрак булды, бар игътибар да, акча да авыру балага тотылды.

Ярый әле каенанасы булышты. Әни кешегә авыр булуын ул аңлый иде. Акча ягы да кысан. Шуңа олырак балалар мәктәпкә йөри башлагач, Наиләгә эшкә урнашырга кирәк дигән фикергә килделәр.

– Балаларга үзем күз-колак булам, – диде каенанасы.

– Әтиең белән без дә булышырбыз, – диде әнисе дә.

Берүзенә бикләнеп, күзгә күренмәс мәшәкатьләрдән арыган, моның ахыры мәңге дә бетмәс кебек тоелган иде Наиләгә. Шуңа күрә өлкәннәргә ул бик рәхмәтле булды. Фатир чираты да алга таба түгел, гел артка гына күчә бара, акчасызга үлгәнче дә буласы юк заманнар башланды бит. Шуңа күрә алар фатирны әз-әзләп, өлешләп түләп алырдай эш урыны эзләргә булдылар.

Декретка чыкканчы, ул район поликлиникасында шәфкать туташы булып эшләгән иде. Табибларны элек-электән дә фатир белән куандырмадылар, шуңа күрә аңа наркология диспансерына урнашырга киңәш итте бер дусты.

– Хәлеңне аңлыйбыз, – диде баш табиб. – Анда акчасы да бездәге кебек кенә түгел, отпуск яллары да озынрак... Киттем дип онытып бетермә безне, кергәләп йөр... Көтелмәгән хәлләр булуы бар бит.

Әйе, көтелгәненнән көтелмәгән хәлләре ешрак килә соңгы вакытта. Ире дә бик тиз генә үзенә йорт салмакчы булып, җир участогы алган иде. Күпме кешегә йорт салды, үзенеке һаман да буш тора әнә. Белмәгән кеше аны әллә кайчан әллә ничә коттеджы бардыр, дип уйлыйдыр инде. Башта бик дәртләнеп йөргән иде, кикриге шиңде хәзер. Балалар үскән саен, сау-тазасына да чыгымы күбәя, ә авыруына киткән һәм китәчәк акчаның исәбенә чыгарлык түгел... Ярый әле, әллә кайларга чит илләргә йөрисе булмады, үзебездә генә хәл итәләр. Алга таба күпме операция көтәдер әле. Бу хәлендә урамда йөргәндә кызганып карауларына һаман да күнегеп бетә алмый ул.

* * *

Яңа урында акча эшләргә мөмкин иде. Ул икешәр смена да эшләде, төнгә дә калды. Ирен, балаларын күрми дә диярлек. Хәер, ире үзе дә кунарга гына кайта, иртүк чыгып китә. Ярый әле әбиләре бар. Каенанасына рәхмәтле ул, бөтен авырлык аңа туры килә. Аның да рәхәтләнеп үз көенчә генә яшисе, барасы җиренә барасы килмимени? Күңеле нечкәрде аның да. Элекләрне күп бала табып, соңыннан туганнар арасындагы ыгы-зыгы эчендә интеккән ата-аналарга аптырый иде, шуңа да ул килененең өченче балага узуын яратып бетермәгән иде. Тапкач, үсә инде, тик ничек үстерәсең бит? Советлар чорындагы кебек укыту, һөнәр бирү, фатир бушлай түгел, бөтенесе ата-ана исәбеннән. Дөрес, ул чагында бөтен кеше дә тигез, кешенең нәфесе дә алай зур түгел иде бит. Ә хәзер әллә нәрсә китте шунда... Вакыт-вакыт, балага ия бар чакта бирәсе калган икән, дип үкенгәне дә булгалады. Тик нигә әле бүтән балага түгел, нәкъ менә аларныкына чат ябыштылар? Бәлки, органнары өчендер? Авырып үлде, дигән документны алу кыенмыни акчалы кешегә? Ул үзенең гөнаһлы уйларын шунда ук читкә куа. Сәламәт балалар да, ия табылмыйча, балалар йортына эләккәч, шикләнмәс җиреңнән дә шикләнерсең...

* * *

Наиләне эштә кызганып, аңа ничек тә ярдәм итәргә тырыштылар.

– Нигә әле сиңа бала өчен инвалидлык алмаска, – диде бер вакытны аңа хезмәттәше. – Авыру бала караган өчен үзеңә дә бераз түләнер иде.

– Ул акчага яшәп буламыни?

– Шулай да уйла әле бу турыда. Инвалидлык алсаң, фатир чираты да алгарак күчә.

– Авыру бала барын беләләр бит!

– Мин болай уйладым әле, сеңлем... Ул чираттагы кешеләрнең берсе дә фатирга синең кебек үк мохтаҗ түгел. Яшәр урыннары бар, бераз көтеп тә тора алалар. Ә мин сиңа бик шәп вариант әйтәм. Безнең янәшәдә нинди диспансер бар әле тагын?

– Психоневрология диспансеры.

– Әйе шул. Синең кызыңның йөзенә карагач, бигүк акыллы түгел кебек күренә. Олигофрения диагнозы белән инвалидлык ал. Ул чагында фатир чиратына беренче урынга куячаклар.

– Андый диагноз белән яшисе дә бар бит әле.

– Син алып калырдаен бүген алу ягын кара. Алга таба күз күрер.

Наилә уйланып калды. Аның баласы җүләр түгел бит! Киресенчә, ул акыллырак та әле башка балаларыннан. Үзенең ямьсезлеген аңлап, көзгегә дә карамый хәтта. Ул башка балаларга охшарга бик тели, шуңа күрә олылар өчен дә авыр булган процедураларны сабыр гына үткәрә.

Абыйсы белән апасы нәрсә эшләсә, шуны кабатлый, хәрефләрне таный, ә ясаган рәсемнәре аның яшендәге баланыкына һич тә охшамаган. Киләчәктә аның бу сәләтен үстерергә кирәк. Телевизорда берәрсе җырлаган чак булса, аларга кушылып җырлый башлый. Музыкага да сәләте бар. Кеше арасына кыенсынмыйча алып чыгарлык итәсе бар иде! Бала үзен бүтәннәрдән ким итеп сизмәсен өчен барысын да эшләячәк! Авыз куышлыгын төзәтеп бетергәч, пластика хирургы кызының битендә бер җөй дә калдырмаска өметләндерде. Дөрес, болар бөтенесе дә акча тора, шуның өчен ял белмичә эшли бит инде ул.

* * *

Фатирны, аның чиратын артка күчереп, алдан алырга теләүчеләр бәндәдән курыкмасалар да, Алладан куркырлар әле. Ничек авыр яшәгәнен беләләр бит инде... Ул әңгәмәсендә шуларны аңлатырга тырышты. Ә танышы:

– Наиләнең матди хәле барыбызныкына караганда да яхшырак, иренең төзелеш фирмасы бар, ә үзе барыбыздан да күп акча ала дигән сүзләр йөри, шуны беләсеңме? – диде.

– Эшләсеннәр! Иренмәсеннәр. Мин дә тиешле сәгатемне генә тутырып, өйдә балаларым белән рәхәтләнеп ятарга каршы килмәс идем.

– Ярар, минем әйтүем хак булсын. Нишләргә икәнен үзең беләсең. Кире уйласаң, әйтерсең. Сүзем көчендә калыр.

Ул әңгәмәдәшенең бүтән таныш-белешләренә дә инвалидлык алуда булышуын, тиешле кешеләрне майлау өчен шактый зур суммада акча кирәген дә белә иде. Тик ул, үзенең болай да фатир алучылар чиратында аеруча мохтаҗлар исемлегендә торганын белә торып, шул хәтле акчаны җилгә очырырга теләмәде. Кешенең бәхетсезлегеннән акча эшләүләрен аңламый да, акламый да иде ул. Аңа киткән акчаны баласы өчен тотачак ул. Тик фатир бирер алдыннан, бәхетлеләр исемлегенә үзенең эләкмәвен белеп, имәнеп китте. Бүгенгесеннән колак кагасың икән, ничә ел көтәргә туры киләчәк, фатир арендалаган өчен тагын күпме акча җилгә очачак... Бу сумма инвалидлык алган өчен кирәк булганнан күпкә артыграк килеп чыга бит...

Күңелсез хәбәрне алып кайткач, өйдәгеләр аптырап калдылар.

Болай да язмыш тарафыннан кыерсытылган кызларына күрәләтә җүләр дигән диагнозны сатып алырга? Хәзер акчаны ике капма-каршы максатка тотаргамы? Бер өлешен – сәламәтләндерергә, ә бер өлешен җүләрсетер өчен... Баланың кешечә уңайлы шартларда яшәргә хакы юкмыни? Ахыргы сүзне каенана әйтте.

– Фатир кирәк!..

* * *

Тумыштан акылга зәгыйфь дип диагноз куелган бала катлаулы операцияләрне кичерә торгач, шыксыз үрдәк бәбкәсеннән аккош кебек булып үсеп килә әнә. Чынлап та аккошка охшаган ул – муены балериналарныкы кебек – биегәндә башын чөеп, аяк бармакларында басып торуын күреп, белмәгән кешеләр аны балет труппасына укырга бирергә дә киңәш итәләр иде. Тик балет ул караганда гына җиңел кебек. Аннан соң биюдән бигрәк рәссамлык сәләте ныграк анда – күңеленә ошаган һәр күренешне кәгазьгә төшерергә һәвәсрәк ул.

Наилә башка балалары өчен азрак кайгырды, алар бер эздән чыкмыйча гына укыйлар, үсәләр әнә. Бала-чага кызык бит ул, һәркайсы үзенә игътибарны күбрәк таләп итә. Әниләренә үпкәли дә алмыйлар, төнге сменада булып, кунарга да кайтмаган чаклары күп.

Башка балаларның да һәркайсының үзенә күрә сәләте бар. Тик хәзерге заманда иҗади талант, сәләт белән әллә кая бара алмыйсың, дөньяны алып барырдай һөнәр кирәк. Төп игътибарны укуга юнәлтергә булдылар. Бер ярдан икенче ярга ташланып, баланың башын катырудан файдасы урынына зыяны гына күбрәк иде алар уйлавынча.

Тик менә Лилия белән башкачарак. Аңа башка мөнәсәбәт кирәк иде.

* * *

Диагноз белән беренче кыенлык баланы мәктәпкә биргәндә башланды. Укырга керергә гаризаны җиңел генә алганнар иде алуын. Тик медкартаны алып килгәч, директорның чәче үрә торды.

– Мондый диагноз белән безнең мәктәп программасын үзләштерер дип уйлыйсызмы? – диде ул. – Хәзерге программа катлаулы, аны бик башлы балалар да авырлык белән генә үзләштерә.

– Үзләштерә ала ул программаны, бу мәктәпкә бер ел алдан ук әзерлек программаларына йөрттек бит. Укытучы тарафыннан бернинди дә каршылык булмады, – диде Наилә.

– Андый балалар өчен махсус мәктәп бар! Аннан соң сез безнең микрорайонда да яшәмисез! Гади мәктәп булса бер хәл, күз йомып та калыр идем... Элитный мәктәп бит бу! Балалар болай да артык күп, кайбер класслар икенче сменада укый.

– Ул диагноз бүген бар, иртәгә юк! Комиссия үткәреп, мин аның бу авырудан сәламәтләнүе турында белешмә алып киләм! Лилияне мәктәпкә барыр алдыннан коллективка ияләшсен дип, бераз булса да, балалар бакчасына да йөрттек. Бер төркемдәге балалар белән беренче сыйныфка барасын белгәч, бик сөенгән иде.

– Сез белешмә алып килегез, аннан сөйләшербез...

Алга таба бу диагноз белән күпме башы катачагын аңлый иде Наилә. Шуңа күрә ул кызын үзләре янындагы гадәти мәктәпкә генә бирде. Директор бер диагнозга, бер кызга карап алды да:

– Безнең барыбызның да нерв системасында азмы-күпме тайпылыш бар инде, төптән уйласаң, акыллы кешене ярты сәгать эчендә җүләргә чыгарып була. Ә сез тумыштан акылга зәгыйфь дигән диагнозлы баланы шушы дәрәҗәгә җиткергәнсез икән, башка балалар белән бер тигез укый алырына шигем юк, – диде.

Башлангыч сыйныфларда үзләренең ишегалдында аның йөзендәге гариплектән куркып уйнарга теләмәгән балалар да бар иде. Алар ул баланың бүгенге Лилия икәнен башларына да китермәделәр. Тик үзен белә башлаганнан бирле кыяфәтеннән кимсенеп үскән бала моны онытмаган, ул аның хәтеренә күпме юсаң да, бетмәстәй тап кебек булып калган иде. Шуңа күрә ул хәзер алардан яхшы якка аерылып торырга, алардан өстенрәк булырга бөтен көчен куйды. Ул балалар үзләре эшли алмаган мисалларны аңардан күчергәндә дә, аның белән дуслашырга теләгәндә дә, үзен бер башка үскәндәй тойды.

Тик күптән түгел генә кыерсытылган бала: «Мине күрегез әле, мине», – дигәндәй, үзен башкалардан бер башка өстен итеп куярга тырыша, шуңа омтыла да иде.

Мәктәптәге, икенче төрле әйткәндә, җәмгыятьтәге урыны җайланса да, өйдә башкачарак иде. Чөнки абыйсы белән апасы бөтен игътибарның, бөтен көчнең һәм күпчелек акчаның сеңелләренә тотылуын аңлап, үзләрен үгисеткән итеп тоя башлаганнар иде. Бу чынлыкта да шулай иде – Аллаһы Тәгалә аларга барысын да – тазалыкны да, матурлыкны да, зиһенне дә мулдан биргән, алар артык көч куймыйча да тормышта үз урыннарын таба алалар иде. Ә төпчекләре белән инде барысы да булды дигәндә көтелмәгән яктан сюрприз килеп чыгарга да мөмкин бит. Хәтта башкалар күзенә чалынган матурлык та, сәләт тә аларның күзенә күренми. Сеңелләре алар өчен элекке бичура шикелле булып калды. Үзләре кызыккан әйберне алырга мөмкин булмаган чагында гаепне аңардан күрәләр, төрлечә кыерсыталар, ясаган рәсемнәрен бозалар. Моның өчен үзләренә дә эләгә, тик бала кешене бернинди әмер белән дә җиңә алмыйсың, барыбер үзенекен эшли, билгеле бер вакыт җитмичә игә килми ул.

Кайчандыр әтисе чираттагы ничәнчедер операциядән соң бала битендәге төзәлеп килгән җөйләргә карап-карап торды да, чарасызлыктан:

– Тәки ярыйсы гына полуфабрикат булгансың бит! – дигән иде.

Шуннан соң аңа «полуфабрикат» дигән кушамат ябышып калды.

Шушы «полуфабрикат» сеңелләре аркасында иркен яңа фатирда яшәүләрен алар искә дә алмыйлар. Хәер, өйдә балалар алдында бу турыда сөйләшмәскә тырышалар. Балалы өйдә сер тормый бит ул, өйдә нәрсә барын хәзер саталар. Лилия дә белми әле моны. Ул хәзер элекке кебек үзен кыерсыткач, әбисе янына килеп әләкләми. Гомумән, каршылыкка кермәскә тырыша, үзен үртәгәннәргә дә әһәмият бирми, чөнки моның элекке гадәт буенча әйтелгәнен белә, чынлыкта ул үзенең көзгедәге бүгенге кыяфәтеннән бик канәгать, аңа башкасы кирәкми дә иде.

Туганнар шуның өчен дә туган – алар гел ачу тотып йөрми, гел үртәшеп кенә дә яшәмиләр, бер-берсенә үпкәләрен онытып, тату гына уйнаган чаклары да күп. Урамда бүтәннәрдән кыерсыттырмыйлар, мәктәптәге уңышлары белән куаналар да... Тик вакыт-вакыт барыбер эчкә яшеренгән көнчелек җене кузгалып алганда, нишләргә белгән хәл дә юк.

Көнләшерлек түгел дә соң. Көнчелек күп вакыт акылны томалый.

Ә болай тормыш дәвам итә...

Дәвалауга киткән чыгымнар кимегәч, матди як та җайлангандай булды, Наилә дә эштәге сәгатьләрен киметте, өйдә күбрәк була башлады. Ай саен Лилия өчен кереп барган пенсия акчасы да ярап торды. Балага яңадан медкомиссия үткәреп, диагнозын үзгәртергә дип талпынса да, тукталып калды.

* * *

Инвалидлар декадасында мөмкинлекләре чикләнгән балаларның хәйрия концертына чакыру алгач, нишләргә микән дип уйга калды Наилә. Мондый чаралардан элек тә калдырмыйлар иде. Лилияне монда бичура дип кимсетүче юк, аңа башкалар белән тигез мөнәсәбәт булгач, ул үзен иркен тота, сәхнәдә җыр-бию белән катнаша. Бу юлы да берәр чыгыш әзерләп килүләрен сораганнар һәм килмичә калмагыз дип тә өстәгәннәр.

Мондый чараларда балалар ясаган рәсемнәрдән күргәзмәләр оештыра торган булгач, ул анда кызының берничә рәсемен куярга рөхсәт итте.

Кызының уңышлары белән сөенеп утырган әни кеше концертны берничә телеоператорның камерага төшерүенә игътибар итсә дә, гаҗәпләнмәде. Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә аралашу мохитен булдыруга игътибар көчәйде соңгы вакытта.

Сәхнәдә чыгыш ясаганнан соң, Лилия әнисе янына төшеп утырды. Тәнәфестә алар янына бер хатын килде. Ул үзен бию студиясенең җитәкчесе итеп таныштырды.

– Сез бу чарага ялгышып әләккәнсез кебек тоела миңа, – диде ул.

– Шулай гына булса иде дә соң...

– Сезнең кызыгыз бер дә мөмкинлеге чикле балага охшамаган.

– Әйе... Хәзер охшамаган. Шуңа күңелем тулып утырам әле, – диде Наилә күз яшен сөртеп. – Сез аның элекке чагын күрмәдегез шул.

– Әйе, миңа сөйләделәр... Беләсезме , бу могҗиза бит! Ни әйтсәң дә, безнең медицина могҗизалар тудырырга сәләтле. Нинди генетиканы үзгәртергә кирәк бит! Бу бит Нобель премиясенә лаек ачышка тиң! Юкка гына чит илләрдә дәваланыр өчен миллионнар түгәләр. Килешәсезме?

– Әйе...

– Баланы кайсы клиникада дәваладылар?

– Кайда булсын? Үзебездә, Мәскәүгә дә барырга туры килде...

– Нишләп бу турыда матбугатта бер язма да юк? Бу сенсация тудыра торган факт бит. Беләсезме, сез интервьюлар биреп тә әллә нихәтле акча эшләр идегез. Әллә дәвалаган докторыгызга реклама кирәкмиме?

– Гафу итегез... Безгә реклама кирәкми...

Берничә көннән зәңгәр экраннарда бу концертны тулысы белән күрсәттеләр. Ә газетаның чираттагы номерының беренче битен Лилиянең фотосы белән бизәгәннәр иде.

* * *

Бер көнне Лилияне укырга алудан баш тарткан мәктәп директоры шалтыратты.

– Сез кайда югалдыгыз, Наилә ханым? – диде ул. – Без сөйләшкән идек бит...

– Нәрсә турында?

– Кызыгызны укырга алу турында...

– Без башка мәктәпкә йөрергә булдык... Анда бездән бернинди белешмә дә сорамадылар.

– Беләсезме, миңа да кирәкми сезнең белешмәгез... Балагызның күпкырлы сәләтен үстерү өчен бездә мөмкинлекләр күбрәк.

– Рәхмәт... Без бу мәктәпкә өйрәндек инде...

– Сез уйлагыз әле тагын бер кат. Гадәттә миңа баламны алыгыз дип ата-аналар үзләре килә. Мондый тәкъдимне башлап үзем ясаганым юк иде әле. Сезгә беренче тапкыр... – диде монысы да.

– Без монда ияләштек инде. Ә теге чагында алмаганыгыз өчен рәхмәт кенә.

Әлбәттә, табиб та, укытучылар да балада бернинди дә психик тайпылыш юклыгын беләләр иде. Кайсы табиб төгәл диагноз куюы белән мактана ала соң? Мондый аномалия белән туганда бигрәк тә. Тик үзләре әйтмешли, авыру баланы шушындый хәлгә җиткерә алган ата-анага да, табибларга да сокланырга гына кала. Әбисе аңа бервакытта да исеме белән дәшмәде, «матурым» гына дия иде. Аңа каршы Лилия:

– Нишләп минем битем җөйле, – дигән сораулар биреп интектерә иде.

– Фәрештәнең сиңа чираты килеп җитми әле, күр дә тор, үзең дә сизмәгәндә, бөтен җөйләреңне сыйпап төзәтер, – дигәч, кәгазь-буяу белән үзен матур итеп ясый иде дә:

– Фәрештә мине шулай итеп сыйпаячак, – дип куана иде...

* * *

Ул үзен фәрештә сыйпавын озак кына көтте әле.

Башта ак халатлы кешеләрдән куркып, ду куптарып еласа да, әкренләп аларның яхшылык эшләргә теләгәннәрен аңлый башлады. Үзе дә курчаклары белән доктор булып уйный, аларны дәвалады, үзенчә укол кадады, үзенчә матурларга яратты.

Аның мавыгуларын сөенеп күзәтеп торган Наилә боларның кайсына өстенлек бирергә белмичә аптырап калды. Укуда да алда бара, яңа теманы да тиз эләктереп ала, язуы да матур – рәссамнарга каллиграфия кирәк тә кирәк инде, музыка мәктәбенә дә теләп йөри. Бию түгәрәгендә йөрергә яратса да, буыннарына көч килеп, тезе авырта башлагач, анысына йөрмәскә күндерә

алды алуын. Алга таба аңа нинди һөнәр сайлау – менә анысы катлаулы иде. Лилия үзен авыруларны терелтүче фәрештә, яисә табиб итеп күз алдына китерсә дә, бу диагнозы белән аны медицинага якын китерерләрме соң? Шул турыда ул белгечләр белән дә киңәшеп карады. Тик алар барысы да бер фикердә булдылар.

– Медицинага түгел, идән юарга да якын китерергә ярамый.

– Идән юарга ник ярамый?

– Идәнне су урынына бензин белән юса? Ялгыш берәрсе шырпы кабызып ут чыгаруы бар!

– Ул мәктәптә беренче отличник!

– Андый диагнозлы кеше кирәкмәгәнне дә эшләргә ярата.

– Инвалидлыкны ничек юкка чыгарып була соң?

– Ә нигә аннан баш тартырга? Хезмәт кешесе белән төрле фаҗигаләр чыгып, гарипләнеп тора. Эшли алмый башлагач, яшәр өчен группа алырга сират күпере чыгасы бар. Ә сезнең гомерлеккә бирелгән. Кеше эшләп тә шул хәтле акча ала алмый... Юк белән баш катырмагыз, торсын шунда... Законнар гел үзгәреп тора. Рәссамлык таланты бар бит кызыгызда. Шул яктан үстерегез. Алар арасында бу яктан чикләү юк. Ван Гогны ишеткәнегез бармы?

– Үз колагын үзе кискән рәссам турында әйтәсезме?

– Әйе... Аның бер картинасын миллионнар түләп алалар. Дөрес, исән чагында мохтаҗлыкта яшәгән, диләр. Бәлки, сезгә уңыш иртәрәк елмаер? Ә бит бу идея! Әйбәт реклама биргәндә, сезгә череп баерга була! Чынлап та, кызыгызда рәссамлык таланты бар!

Наилә киңәшергә кызының рәсемнәрен дә алып килгән иде. Ул аларны карады да:

– Мин сезгә булыша да алам...

– Әлегә киңәшмәкче генә идем...

– Мондый нәрсәне алдан ук килешеп куялар инде. Көне җиткәч кенә соң була ул. Договор төзибез хәзердән үк. Табыштан кемгә күпме процент тиешен уйлашырбыз. Аннан соң рекламага тотынабыз. Бу отышлы вариант. Рекламаның эмблемасын уйларга кирәк.

– Рәхмәт киңәшегезгә. Тик барыбер кызымның диагнозын төзәтәсе иде. Кызның үз теләге дә бар бит әле...

Наилә, юк, кирәкми дип, кискен җавап бирмәскә булды. Аңа ничек тә кызының диагнозын бүген булмаса, алга таба юкка чыгарып, сәламәт дигән нәтиҗә кирәк. Шуңа күрә ул хәйләгә барды.

– Кызыма сәламәт дигән диагноз алып булса, мин сезнең бөтен шартларга да кул куярмын, – диде. – Ә рекламага теләсә ничек язгыгыз...

– Группа алыр өчен чирле кеше дә күпме акча түгә, ә сез, киресенчә, аны бетерер өчен түләргә җыенасыз... Сез үзегез дә сәламәт түгел бугай... Хәзерге заманда акча чыганагын юкка чыгару үзе ахмаклык... Ялгышмасам, бу диагноз аркасында фатирлы булгансыз бит...

– Ул чагында башка чарам юк иде.

Әйе, кызы үскән саен замана катлаулана бара. Бөтен мәгълүмат компьютерда, өтерен дә үзгәртә алмыйсың. Наилә үзе дә укырга медучилищега кергәндә, стажлыларга өстенлек бирелгәч, әнисе аңа кечке мәктәптә укып эшли дигән хезмәт кенәгәсе булдырган иде. Яшен дә ике яшькә зурайтты. Соңыннан врачлыкка да укырга хыялланган иде, тик кияүгә чыкты.

* * *

Вакытында гаиләсен фатир белән тәэмин итә алмавын Камил дә авыр кичерде. Дөрес, хәзер эшләре җайланды, тик балалар да өчәү бит, аларның киләчәген ул кайгыртмый, кем кайгыртсын? Ул һәр өчесенә дә әкренләп йорт салырга план корып, җир участоклары алды. Нигезен озакка чыдарлык итеп кечерәк кенә йорт салып, алга таба әкренләп киңәйтергә иде нияте. Үзләренә ошаса, балалар югалып калмас. Башлап кына җибәрергә кирәк, аннан китә ул. Кассадагы акча юкка чыга, ә җир буыннан буынга тапшырырга ярый торган, бәясе юкка чыкмый торган мөлкәт. Үзенең төзелеш фирмасы да аякка басты, балаларына эш урыны да бар дигән сүз. Лилия дә ким-хур булмас, аңа да шөгыль табылыр. Хатынын да ял күрмичә эшләүдән азат итә алды. Кызының диагнозын юкка чыгарырга йөрүенә ул көлемсерәп кенә карый. Әйдә, шөгыле булсын шунда, адәм баласына бер борчу кирәк, булмаса барыбер таба ул. Хәзер типсә тимер өзәрдәй сәламәт кешеләр дә дәүләткә бил бөгәргә ашкынып тормый. Яраткан төпчек кызы исән генә булсын!

Кызына шөгыль таба ул. Хәзер дизайнерлар бик кирәк. Аның кулы бизәргә-буярга, рәсем ясарга ятып тора. Дөнья көне-сәгате белән үзгәреп тора. Әнә бит, бөтенләй йөри алмаган кешеләр дә файдалы хезмәт башкара алсыннар, кеше арасына чыга алсыннар өчен урамнарга да, йортларга да пандуслар куялар, эш урыннары булдыралар.

* * *

Иң авыр җәрәхәтне якыннарың ясый. Чөнки алар иң йомшак җиреңнең кайда икәнен белә. Инде элекке гариплегенең эзе дә булмавына карамастан аның кушаматы Бака да булды, «Ярымфабрикат» дигәне дә ябышып калды.

Дөрес, алар бу кушаматны кеше алдында әйтмиләр. Хәтта аның үзләренең сеңлесе булуын да белдерәсе килмичә, урамда чагында аны күрмәмешкә салышып үтәләр. Лилия аларга үпкәли алмый – көзгегә дә карарга яратмаган башың белән ничек инде үз туганнарыңа үпкәләп торасың?

Шуңа да карамастан, Лилия шыксыз үрдәк бәбкәсеннән гүзәл аккошка әверелгән кебек, берзаман абыйсы белән апасыннан чибәррәк булып өлгерә башлады.

Лилиянең башкалардан аерылырга тырышмыйча, күзгә-башка чалынмыйчарак яшәү гадәте барыбер калды. Бу аның үз-үзен тотышында да, киемнәрендә дә чагылды.

Гаилә бюджеты тигез бүленә башлагач, Динар белән Мәдинә сеңелләренә карашларын үзгәрттеләр. Туганнар арасында вакытлыча татулык урнашты. Тик аңа нәрсәгә генә тотынса да, җиңел генә башкарып чыгу, җиңел генә үзләштерү сәләте бирелгән иде, ул артык көч түкмичә генә бөтен фәннәрдән дә бишкә укып, иң алдынгы укучылар рәтендә йөрде.

Ел саен мәктәпкә килгән медицина тикшерүе вакытында шундый диагнозлы баланың укуын белгәч, башта җитәкчеләргә шелтә биреп, мөмкинлекләре чикләнгән балалар янына укырга җибәрергә киңәш бирсәләр дә, аның белгеләрен күргәч тел шартлаталар һәм:

– Бөекләрнең күбесендә психик тайпылыш булганын белә идек, тик бу бала барысыннан да уздырып җибәрә, – диделәр. Ә инде баланың үзен күреп сөйләшкәч, хәлнең нидә икәнен аңласалар да, абруйлы медкомиссия карарын үзгәртергә барыбер хәлләреннән килми – чөнки бу диагноздан сәламәтләнгән бер генә очрак та юк. Шул килеш калдыралар да китеп баралар. Нигә әле аларга кемнеңдер хатасы өченме, әллә шулай махсус эшләнгән эш өченме баш катырырга? Үзләрендә юкмыни андый хаталар? Кул кулны юа, ике кул битне

юа дигәндәй, башлап кына җибәр, дәвам итүчесе табыла аның, үзеңнең кая барып төшкәнеңне белми дә калырсың...

Анысы шулай да, мөмкинлекләре чикләнгәннәр җәмгыяте дә бар бит әле. Алар да сәламәт яшәү рәвеше җәелдереп җибәрделәр. Нәтиҗәле генә эшлиләр дә. Аларның да әйбәт нәтиҗәләргә ирешәсе, ирешкәннәре белән мактанасы килә. Шуңа күрә алар вакыт-вакыт үзләренең барлыгын искә төшереп торалар һәм үткәргән чараларына кызны тартырга тырышалар. Бөтенләй баш тартып та булмый, кыз тегендә дә, монда да, һәм беркайда да түгел саналмасын өчен, вакыт-вакыт һәр ике якның – үзе укыган мәктәбенең һәм үзе теркәлгән җәмгыять чараларында катнашырга туры килә.

Кайчандыр үзенең бер көтүгә дә иярә алмыйча кагылып йөргән кош кебек чакларын онытмый ул. Тик уңышлары белән масаймый да, мин кем, дип күзгә бәрелеп тә торырга тырышмый, күләгәдәрәк каласы килә. Тик аны кирәк чагында барыбер күрәләр.

Ул әле үзенә куелган диагнозның асылын аңламый, гомумән, аңа барыбер. Хәзер аңа берәү дә бармагы белән төртеп күрсәтми, аның белән аралашудан курыкмый. Тик ул үзенең хисләрен башкалар кебек шау-шулы уеннарда коймый, балачагында сөйкемсез сөяк булып йөрүеннән кимсенү аның хәзерге аралашуына аяк чалып тора, чөнки ул үзенең барыбер башкаларга тамчы да охшамаган булуын күңеле белән сизенә. Кыяфәте түгел, күңеле аерыла аның.

Бу аерымлыкны башкаларга белгертмәскә тырышкан саен күзгә ныграк ташлана. Әгәр ул дәрестә вакыт-вакыт шуграк балаларга ияреп, укытучыга комачаулап утырса, үзенә игътибар таләп итеп шуклык, берәр хилафлык эшләсә, төркемнән аерылып та тормас иде.

Укытучылар үзләре дә вакыт-вакыт аптырашта калалар иде. Ата-аналар җыелышына килгән һәркемнең үз баласы турында мактау сүзләре ишетәсе килә, һич югы начарлар белән бергә телгә алмасыннар. Ә Лилияне башкаларга үрнәк итеп тә алып булмый, ничек инде шундый диагнозлы бала үрнәк була алсын? Артык мактап җибәрсәң – дус бар, дошман бар, дигәндәй, әллә кайларга жалу биреп, тикшерү өстенә тикшерү китертүләре бар. Укытучыны тикшерүчеләр болай да җитәрлек, ул тикшерүләр бугазга кадалган сөяк кебек. Кирәкми артыгы, булганы да җиткән. Шуның өстенә теләсә нинди бәйге, теләсә кайсы олимпиадага кызны катнаштырсаң, РОНОга җибәрелгән эш планындагы пунктның артыгы белән үтәлүенә шикләнмәскә була. Аларның гаиләне борчыган хәл белән баш катырырга вакытлары юк, аларның эше – дәрес программасы буенча белем бирү. Ә һәр бала язмышы өчен ата-ана үзе җаваплы. Ул җаваплылыкны үти алмый икән, дәүләт үз карамагына ала. Тик дәүләт булып дәүләт үзе дә шактый мәсьәләләрне объектив хәл итеп бетерә алмаганны, кая инде ул гади кешегә...

Кыз бүтәннәргә комачау итмичә, үзенең эчке дөньясына беркемне дә кертмичә яшәвен дәвам итте. Моңынчы бар көч аның тумыштан зәгыйфьлеген төзәтер өчен китте бит, рухи дөнья арткы планда кала килде.

Кыз үзенең уй-фикерләрен теркәр өчен башкалар кебек көндәлегенә җыр-шигырь текстлары язмый,чөнки анда язасың икән, икенче көнне үк башкалар беләчәк. Үртәү, үчекләү китәчәк. Сыйныфларында андый очраклар булды инде. Шуңа ул нәрсәгә булса да күңеле тулса, йә сөенсә, хисләрен альбом битләренә төшерә. Озак уйлап та утырмый ул, кәгазьгә карандашы белән җиңелчә генә сызыклар сызгандай итә дә, бераздан күз явы алырлык сурәтләр хасил була.

Хәзер апасы бүтәннәргә тиешле мактау сүзләренең үзенә түгел, Лилиягә атап әйтелгәне белән килешәсе килмәде. Бәйләнерлек тә, яратмаслык та сәбәп юк

иде югыйсә. Киемнәрнең дә матуррагы, яңасын ул кия бит. Тик бу киемнәрне алганда, аның түгел, Лилиянең дә киясен уйлап, аның өчен матуррак булсын дип алалар шикелле тоела башлады. Шуңа күрә үзе киеп ялыккач, яисә үзенә ярамый башлагач, киеменә нинди дә булса хилафлык эшләп ташларга да күп сорамый.

Ул хәзер сеңлесенең кешегә күрсәтмәслек чакларын сагына башлады. Шулай булса, күргән кеше иң беренче Лилиягә түгел, аңа ныграк игътибар итәр иде бит...

* * *

Мәктәпне тәмамлар алдыннан укытучылар кыен хәлгә калды. Бөтен фәннәрдән дә бишлегә укыган, олимпиадаларда җиңеп килгән кызга нинди аттестат бирергә? Җитмәсә, РОНОның кимендә бер баланы булса да, алтын медальгә тәкъдим итәргә дигән «негласный» күрсәтмәсе бар. Яхшы укучы балалар күп-күбен, тик бердәм дәүләт имтиханнары кертелгәч, элекке кебек алдан берни дә эшли алмыйсың шул. Тартуын тартырга да була анысы, соңыннан адәм көлкесенә калмам, дип ничек ышанып әйтәсең? Укырга кергәч, беренче имтиханнарда ук төшеп калсалар? Каян уйлап чыгардылар шул БДИ дигән куркыныч нәмәстәне? Бөтен җирдә видео, бер бөртек чәчеңне дә яшерә алмыйсың. Балалар бит болай да «имтихан» сүзеннән үк куркып кала, белгәнен дә, каушап, җавап бирә алмавы бар.

Бу Лилиягә кагылмас та анысы. Ул ничә олимпиадада катнашып, ничә җиңү яулаган, мәктәпнең данын күтәргән бала. Тик аңа ярармы соң? Болай да гадәти балалар арасында укырга ярамый торган диагнозы белән унбер ел укуы законга сыя торган нәрсә түгел. Бу очракта сыюын сыйдырдылар анысы, сәламәт мөһере сугылган, акылга сайрак балалар да җитәрлек мәктәптә. Тик аларның андый коточкыч диагнозы юк! Аларга укытучылар белемне җитәрлек дәрәҗәдә бирмәгән, йә ата-анасы тырышмаган, йә үзләре ялкау дип сәбәп табарга була. Сәламәт балаларга бирмичә, аңа бирсәләр медальне – нәрсә була инде? Йә белем бирү системасына, йә медицина өлкәсенә үзгәреш кертергә димәсләрме?

Дөрес, һәр ике өлкәнең дә куркыр җире юк: дәвалап булмастай генетик авыруга дучар булган бала барысыннан да сәләтлерәк, башлырак булып терелгән. Тик мондый очракның әлегә дөньяда булганы юк! Медицина алга китте дип, аңа сылтап та калдырыр идең... Тик ул чагында күпме тикшерү, күпме баш ватасы, күпме тәҗрибә үткәрәсе була. Алар сиңа кирәк нәтиҗә ясыймы әле, анысы да бар бит.

Укытучылар коллективы куркып калса да, мәктәп директоры совет чорында хезмәт юлын башлаган, комсомол сафларында чыныгу алган, партия сафында төрлесен күргән, коммунистлар партиясе беткәч тә, коммунист булуыннан туктамаган Минзәт Ришатович ике уйларга урын калдырмады.

– Безнең эш – белем бирү. Беребез дә авырмый тормыйбыз, аңа карап, эш туктамый. Медальне дә кем лаеклы – шуңа бирәбез. Монда мин Лилия Кантаровадан башка лаек беркемне дә күрмим. Димәк, бала бүгенге тормышка яраклашсын өчен әти-әнисе күп тырышкан. Мәктәп коллективы белән берлектә, әлбәттә. Институтка кергәндә дә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән сәламәтләре арасында чикләүләр бетерелде. Монда гайре табигый бернәрсә дә юк.

Директорның бик сирәк очракта гына коллективка каршы чыга торган гадәте бар иде. Шуңа аның белән бәхәсләшмәделәр. Бары тик:

– Андый-мондый аңлашылмаучылык чыкса, җавабын сезгә бирәсе, – диештеләр.

– Минем өчен борчылмагыз. Болай да пенсиягә чыккач, әллә нихәтле эшләдем инде. Яңа шөгыль табармын.

* * *

Шулай итеп, кыз теләсә кайсы югары уку йортына керергә хокук бирә торган балл җыеп, алтын медаль алып, мәктәбе белән хушлашты. Ул үзенең кем буласын берничә ел алдан ук хәл итеп куйган, шуның өчен тырышты да бит инде. Аны институтның музыка бүлегенә дә, рәссамнар әзерли торган уку йортына да берсүзсез алабыз дип, чакырып торалар иде. Тик кызның фәкать табибә буласы килде.

* * *

Ходайның рәхмәте, Лилияне медка берсүзсез алдылар. Бөтен фәннәрдән дә югары балл җыйган кызның акылында хилафлык бар дигән уй комиссиядәгеләрнең башына да кермәде.

– Хастаханәдә үскән кыз бит, башка һөнәрне сайласа, гаҗәп булыр иде, – диештеләр.

Дөрес, арада кызга үзләре куйган диагнозыннан шикләнүчеләр дә бар иде.

Үзе үк шактый сумманы кесәсенә шудырган судмедэкспертиза җитәкчесе дә – комиссия әгъзасы. Кызның киләчәгеннән битәр аны үз язмышы борчый иде.

– Хәзер бит элеккеге шикелле сәламәт дип, кул куеп кына булмый. Җиде ата-бабаңны да казып чыгарырлар. Әнә Наполеонның да нәсел чылбырын сүтеп маташалар хәзер генетиклар. Гарәбстанда бөтенесе дә Мөхәммәт пәйгамбәр белән туган... Җылы урынга утырырга теләүчеләр аз дип беләсезмени, сезне кузгатып? Балыкның койрыгыннан тотынсаң, башын ашамый калмыйлар инде... Диагнозы бит... Ничә мөһер сугып расланган...

Ректор курка торганнардан түгел иде.

– Елыйсы килгән бала әтисенең сакалы белән уйный. Монда – бөтен дөньяга сенсация тудырырлык ачышыбыз күз алдында. Болай да безнең кулдан тартып алырга гына торалар. Тарихта күренмәгән хәл бит шундый диагноз белән туган баланың барысын да уздырып югары балл җыюы. Хәзер сәламәт туган балаларның яши-яши башы тиешенчә эшли алмый башлавы белән килештек инде, ә менә кирес булган очракларга иялэшә алмыйбыз һаман. Ә ияләшергә вакыт! Тиккә генә дәүләт башындагылар сәламәтлеккә туймаган, теге яки бу сәбәпләр аркасында мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне җәмгыятебезгә файда китерердәй шәхесләр итәр өчен төрле чаралар җәелдермәгәндер бит.

Ректор бик акыллы фикер йөртте – беренче яртыеллык нәтиҗәләрен көтәргә, дигән нәтиҗә чыгарды. Чөнки безнең илдә барыбыз да тигез – чирлеләр дә, сәламәтләр дә. Нинди авыруларны медицинага якын китермәскә, дигән мөһер сугылган күрсәтмәнең иң каты режимнар вакытында да булганы юк. Киресенчә, халык дипломлы табиблардан туеп, медицинадан ерак торган, кеше организмы турында хәбәрдар булмаган, медицина күзлегеннән караганда, акылга җиңел шарлатаннар янына барып, гомерләрен озайтмакчы була.

Шулай булгач, бу кызның беренче сират күперен үтеп, тиешле белем алып чыга калса, менә дигән табиб була алуына ректорның шиге юк иде. Чөнки ул чирнең нәрсә икәнен укып кына түгел, үз практикасыннан чыгып та белә иде.

Кызның язмышы шулай хәл ителде.

* * *

Беренче яртыеллыкның имтиханнарын студентларның күбесе кабат-кабат бирде, бирә алмыйча түләүлегә күчүчеләр дә, китүчеләр дә булды. Түләүле уку елына ярты миллионга якын акча кирәк булгач, анда гади кеше баласы укый

алмый иде, имтиханнарны җиңә алучылар да – үз көченә генә таянган гади кеше балалары иде. Ә түләүле бүлеккә калганнары ата-анасының акчасына аркаланып кергәннәр, акча кадерен дә, аны эшләп алуның тәмен дә белмиләр, алар кеше сәламәтлеген түгел, үз кесәләрен генә кайгырталар – укып бетергәч, ата-аналары ачкан шәхси хастаханәләрдә җитәкчелек итеп, әнә шул тырышып укыган базык гәүдәле белгечләрне җыеп, үз кесәләренә акча көрәп алыр көннәре турында хыялланудан башка берни дә уйламаган, дөрес диагноз куя белмәстәй яшьләр иде.

* * *

Беренче курс кызлары моргта, кешенең анатомиясен өйрәнгәндә үк һуштан язалар иде. Ә Лилия үзен үлеләр арасында бик уңайлы хис итте. Моңа гаҗәпләнгән курсташларына ул:

– Мин тере кешеләрдән куркам, үлгәннәрдән түгел. Алар берәүгә дә зыян салмый, – дип җавап кайтарды.

Чынлап та, кыз һаман да үзенә күбрәк игътибар итә башласалар, куркынып китә иде. Бу курку үзен белә башлаганнан калган, балаларның аны күргәч, елап, әниләре тизрәк алып китсен өчен кулларыннан, күлмәк итәкләреннән тарткалаудан калган. Хәзер ул таныш түгел кешеләрнең дә үзенә сокланып карауларыннан шүрләп кала һәм күзгә ташланып, аерылып тормаслык итеп киенә, үзен дә шулай тота. Хәтта практика үткәндә авыруларның аны аеруча якын итеп, кызым йә сеңлем, дип эндәшүләре дә аны сагайта... Хаклы түгеллеген дә белә, тик ахырынача үзенең элекке шыксыз үрдәк бәбкәсе түгел, ә гүзәл аккош кебек булуына һаман да ияләшеп кенә бетә алмый.

Ә гүзәллекне күпме генә яшерсәң дә, ул кояш нуры кебек, аны берничек тә бикләп булмый шул.

* * *

Лилия үзенең авыру тарихы белән кызыксынып, архивны актарганда, нинди диагноз куюларын белгәч, күзләре түгәрәкләнде. Башта ул мин түгелдер, башка кешенең авыру тарихын актарамдыр, дип уйлаган иде. Шундый фамилияне кат-кат эзләгәннән соң гына, сүзнең үзе турында барганын аңлады.

Кыз уйга калды. Моңарчы бу диагноз аңа бернинди тә комачаулык тудырмаган иде. Тик ул элеккеге гарип бала түгел бит. Аның сәламәт кешеләр кебек яшәргә хакы бар. Ә бу диагноз – аның барлык өметләрен дә сызып ташлый. Дөрес, заманалар үзгәрде, элек дәвалап булмый торган авыруларны да терелтеп аякка бастыралар. Аның белән дә шундый очрак түгелме? Ияген, аңкавын, уртларын кешенеке кебек итәр өчен тәнен кискәләп, ничә тапкыр сөяген, итен тураклап ябыштырдылар. Бүгенге халәтенә килер өчен күпме газаплар кичергәнен ул үзе генә белә. Башка кеше булса, аларны мәңге дә искә төшермәс өчен ул хастаханәләрне ачып керү түгел, әллә каян урап үтәр иде. Ә ул һаман үткәненнән аерыла алмый, чирлеләргә ярдәм итәргә хыяллана. Бу кеше ышана торган хәлмени? Шулай булгач куелган диагноз да чынмы?

Кыз кем беләндер киңәшергә кирәк, дип уйланып калды. Үзен дәвалаган табибларны каян табасың? Мондагылар Мәскәүгә җибәрделәр, андагы табибларны хәтерләмидә инде ул. Ярым эт, бүре кыяфәтендәге кызны кемнәргә генә күрсәтмәделәр. Аның кебекләр бер ул гына түгел иде түгелен, кемне генә хәтерләп бетерсеннәр андагы табиблар да... Бер урын бушаса, ун кеше көтеп

тора бит. Тормыш яхшырган саен мондый күренешләр күбәя бара. Чернобыль, Чиләбе якларында андый гариплекләр конвейерга салынган...

Тукта әле, ник башын катырып тора соң ул? Диагнозың туры килми дип, укуыннан чыгара алмыйлар бит аны. Укуын да – ярата, имтиханнарын да тапшырыр, тәмамлап та чыгар. Ул монысына һич шикләнми. Баш кына исән булсын! Аның башы бернинди диагнозы булмаган түрә балаларыннан да шәбрәк эшли. Ул үзен кызыксындырган теманы шунда ук хәтерендә калдыра. Имтиханнарын яхшы биргәч, беркем дә аңа бәйләнми! Бернигә карамыйча, бөтен көчне укуга бирергә кирәк. Мондый диагнозлы кешегә укырга, акылын үстерергә ярамый дип, беркайда да язылмаган. Бәлки, чынлап та ул шундый диагноз белән тугандыр?!

Кыз үзенең туган көненнән алып, бүгенгә хәтле медкартасын актарды. Тик анда акылында кимчелек бар дигән сүзне тапмады. Тумыштан килгән диагнозына бу сүз соңрак өстәлгән. Бит өлешен, тәнен ничә тапкыр тураклаганнары бар. Күзенә дә төзәтмә керткәннәр икән! Бусын хәтерләми инде, ике яшь кенә булган әле аңарга. Тумыштан катаракта диелгән. Күз гөмбәзендә кимчелек... Бу авырулар картларда да була бит! Балаларда да булгалый микәнни?

Шулай да ул диагнозның килеп чыгуын әнисеннән сорарга булды.

– Әйе, туганда сине берәү дә камил акыллы булыр дип уйламаган иде. Миңа сине башта күрсәтмәделәр дә әле. Үлә бу, кеше булырлык түгел, диделәр. Кулыңда үлсә, авырга туры килер, монда гына калдыр, – диделәр. – Ничек үз кулларым белән сине үләргә калдырыйм? Дөрес, сине алырга теләүче бар иде. Риза булам, дигән гөнаһым да булды, Ходай үзе ярлыкасын инде. Кем белгән аның нинди максат белән йөргәнен? Соңыннан гына башыма килде бусы...

– Табиблар ялгышканмы яшәмәс дип?

– Юк. Имә алмагач, үләсе иденң. Кем сине авызыңа тамчылап салып йә зонд белән ашатып утырган булыр иде... Ул чагында синең кебек балаларны саклап калу өчен шартлары да юк иде бит әле. Хәзер генә ул... И, безнең синең белән күргәннәребез...

– Бу диагноздан котыласы иде, әни.

– Ул диагноз кәгазьдә генә бит! Кем тикшереп тора аны? Юк белән башыңны катырма. Тыныч кына укы. Унсигез яшь тулды, группаң бетте. Әтиең әнә синең исемгә медицина үзәге ачам дип план кора. Укуыңнан башка берни турында уйлама.

Тик диагноз барыбер кызның эчен пошырды. Ул җай чыккан саен бу турыда әтисенең дә исенә төшерде. Ә ул исә:

– Торсын шунда диагнозың саклык кассасындагы акча кебегрәк. Кирәк булып куюы бар. Бик кирәксә, хәзер юкка чыгарырбыз. Акча, дуслар барысын да хәл итә, – дип тынычландырды.

Тик вакыйга бөтенләй көтелмәгән якка борылыш ясады.

Беркөнне зур юл фаҗигасе булып, анда һәлакәткә очраган кешеләрне моргка китерделәр. Студент кызлар патологоанатом җитәкчелегендә генә кеше органнарын өйрәнәләр иде, бу юлы ул аларга үзләренә ярырга кушты. Кызлар куркып, бер-берсенә карашты. Ә теге аларны үртәгәндәй, пычагын сузды.

– Йә, кайсыгыз йөрәклерәк? – диде.

Кызлар ярдәм ит дигәндәй, Лилиягә төбәлделәр.

Мондый чакта аларга булышуы беренче генә түгел иде Лилиянең.

– И сез, куркаклар... Үлгән кешедән куркалармыни? – дип, япма астыннан чыгып торган аякка кагылды.

– Аягы җылы бит! Тере кешене ярырга җыенганбыз! – диде ул, коты очып.

– Молодец. Болай булгач, синнән менә дигән хирург чыгачак. Тик аның башы ярылган шул. Аңа хәзер берни дә ярдәм итә алмый. Без хәзер аның сәламәт органнарын алу процедурасын башларбыз. Органнарга күпме кеше чират торганын беләсез бит... – диде патологоанатом. Хәзер монда махсус бригада эшләячәк. Син ассистент булырсың. Ә сез... – диде ул студентларга карап, – ияләшә торыгыз...

Һәм мәетнең йөзен ачты. Кыз аңын югалтып егылды. Катафалкта Лилиянең әтисе ята иде.

* * *

Лилия бер атнадан соң гына аңына килде. Табиблар аның гомерен саклап калыр өчен барысын да эшләделәр. Тик сабый чагында ук операция кичергән күзенең күрү сәләте начараеп калды.Тагын шундый тетрәнүләр кичерсә, сукыраюы да мөмкин икән. Ә бу инде теге диагноз гына түгел...

– Әтиең күпме кешегә донор булды, аның аркасында алар исән калды, шулай булгач, үлгән дип әйтеп буламыни, – дип юаталар аны әҗәл тырнагыннан тартып алган табиблар.

Лилия хәзер инвалидлар җәмгыятенә йөри. Элекке диагноз янына яңасы өстәлде. Пенсиясе вакытында килеп тора. Яшәргә була... Әтисе әйтмешли, акчаның исе юк...Үзе инде бер дә тик торырга яратмый. Төрле бәйгеләрне оештырырга ярдәм итә, үзе дә катнаша. Ияләшкән урыны бит инде ул аның. Картиналарын, бер кеше килешү төзеп, чит илләргә сату белән шөгыльләнергә теләгән иде. Клиентларны кызыктырырдай биографияне дә уйлап чыгарасы түгел. Тик аңа опекун итеп билгеләнгән абыйсы ризалык бирмәде. Бу эш белән үзе шөгыльләнергә нияте дә юк түгел...

Ак халатлы шәфкать ияләре, шушы кыска гомерендә алар белән бәйле, хәтерендә калган төрле мизгелләр өр-яңадан җанланып, картиналарына күчә. Бу шөгыле аңа яшәргә көч бирә, тормышын мәгънәле итә.

Әтисенең бизнесы апасы белән җизнәсе кулына күчте. Абыйсы юридик яктан җавап бирә. Бер йодрыкка тупланып эш иткәч, эшләре дә алга бара. Сеңелләрен дизайн эшенә тартасылары бик килә дә, тик алга таба ни булыр...

Шулай тормыш дәвам итә. Бу арада Лилиянең йөзенә серле елмаю кунган – ул бәби көтә. Инвалидлар җәмгыятендә очратты ул әти буласы кешене. Ул да кайчандыр үзенә куелган диагнозыннан арына алмаган. Акылы камил, кулы алтын. Мөнәсәбәтләрен законлаштырыр өчен ЗАГСка гариза бирмәкчеләр иде, тик мондый диагнозлы кешеләрне язылыштыру бернинди юридик көчкә дә ия булмавын белгәч, кире уйладылар...

Булачак әниләр кебек хатын-кызлар консультациясенә барып язылырга дигән уеннан да кире кайтты. Мондый диагноз белән бәби табарга ярамый дип, шаушу кубуы бар. Башта тусын, аннан күз күрер. Сау-сәламәт кенә булсын берүк...

# БЕР ГОРУРЛЫК ХИСЕ

*Агач нәселе җир үтә карар,*
*адәм нәселе ил үтә карар.*
Татар халык мәкале.

Данлыклы Яһудиннар гаиләсен республикада яхшы беләләр. Җәмил Габделхәй улын озак еллар хокук сагында хезмәт иткән, аннары ТР Дәүләт Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы комитетын җитәкләгән шәхес буларак хәтерләсәләр, Наилнең исә илнең КамАЗ заводы, ак шәһәр күтәрергә алынган чорындагы җитди хезмәтләре тарихка теркәлгән. Шамил Яһудинның да нефть промышленносте өлкәсендәге эшчәнлеге күпләргә мәгълүм. Ул «Татнефтепром-Зюзеевнефть» ачык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры. Фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт премиясе лауреаты. ТР Дәүләт Советы депутаты. Шул ук тармакта хезмәт куйган Вил һәм РКБда баш табиб урынбасары булып кешеләр сәламәтлеге сагына баскан Рамил хакында да мактау сүзләре даими ишетелеп тора. Ике кыз туганнары: София үзен – төзелеш, Әлфия программист хезмәтенә багышлый. Биш бертуган ир-егетләрнең олысы – Җәмил Яһудин фәннәр кандидаты, Наил, Шамил, Рамил – фән докторлары. Барысы да Татарстанның, Россиянең атказанган хокук, төзелеш, нефть промышленносте, медицина хезмәткәрләре. Сүз уңаенда шуны да әйтик: шушы көннәрдә Шамил Яһудин тагын бер дәрәҗәгә – «Татарстанның атказанган нефтьчесе» исеменә лаек булды. Бу мәгълүмат, әлбәттә, бик кыскача гына... Чөнки аларның һәммәсе хакында да бер китап язарлык.



*Картлыкның бәхетле көннәре.*
*Уллары Шамил, киленнәре Гөлзидә янәшәсендә.*

Әлеге язмада сүзебез шушы зур шәхесләрнең «чишмә башы» – аларның әти-әниләре Габделхәй Абзалетдин улы һәм Сәрвәрия Шәкүр кызы хакында булыр. Шунысын да әйтик: Яһудиннарның зур югалту кичергән айлары: Сәрвәрия апа фанилыкны калдырып, бакыйлыкка күчкән… Безнең алар белән чор, заман хакында сөйләгән хатирәләребез олуг Ана рухына ул-кызларыннан дога булып барсын.

***

Сәрвәрия ападан: «Сезнең гаиләдә кем баш та, кем муен?» дип сорасалар, ул: «Бездә «баш»ы да, «муен»ы да юк, нибары ике канат һәм шул канат астында балалар бар...» – дип җавап биргән. Ире – Габделхәе белән 70 ел буена иңне иңгә куеп, тормыш йөген тартып,

җиде бала үстергән, аларны шәхес итеп тәрбияләгән Ак әбинең тапкыр җавабында АНА дигән бөек исемне раслый торган чын хакыйкать ята кебек. Ни дисәң дә, гаиләдәге иң олы бурыч – бала тәрбияләү вазифасы күбрәк хатын-кыз өстенә төшә шул.

## Сәрвәрия

Бүреләр... Юл буенда улап озатып калган бүреләргә күз ияләшсә дә, күңел күнекми. Сугыш чорында, әллә ирләр юклыкны тоеп, әллә ачлыктан аеруча азына алар. Ә бит Ульян өлкәсенең Әбдери авылыннан Куйбышев районына кергән Камышлыга кадәр ара байтак: Сәрвәриягә 25 чакрым юлны җәяүләп тәпилисе бар. Биштәрдә әнисе салып җибәргән бәрәңге, ипи, дөресрәге, атналык ризык шунда. Ач бүреләр моны сизмиме соң! Кызларның каршысына ук чыгып утыралар. Биштәрне чишеп, беркүпмесен юлга ташлыйлар да яңадан алга атлый кызлар. Куркудан хәлсезләнгән аяклары көчкә-көчкә буйсына. Тик бүреләр кызларга һөҗүм итү турында уйлап та карамый. Әллә ризык беткәнне күреп, әллә тамаклары туеп, юлдан читкә чыгалар да урманга табан сыпырталар. Кайчандыр мәчет вазифасын үтәгән бинада кызларның тулай торaклары – шунда кайтып җиткәч кенә, җиңел сулап куя алар.



*Сәрвәрия һәм Габделхәй Яһудиннар.*

1943 елның кара көзендә Камышлы педагогия училищесына барыргамы, юкмы, дип уйлый торгач: «Әти сугыш кырыннан исә-сау әйләнеп кайтмыйча, беркая да китмәячәкмен», дип катгый карар кабул итә Сәрвәрия. Шулай да аны әнисе Хәдичә апа күндерергә тырыша. Әле бит анда өч тапкыр ашаталар да икән... Сәрвәриягә: «Һич югы тамагың тук булыр, кызым. Фронтка язарбыз, укытучы булуыңа әтиең дә сөенер», – дип, хәер-фатихасын бирә. Юк, юк, ачтан үлмәслек ризык бирелгәне өчен түгел, гыйлем алу теләге көчле булганга, хәтта бүреләр белән күзгә-күз очрашудан да курыкмый, юл озынлыгы да өркетми аны.

Югыйсә Сәрвәрия моңарчы да башка авылдашлары кебек унике яшьтән үк үзен илгә хезмәткә багышлый, «Барысы да җиңү өчен! Барысы да фронт өчен!» дип бөтен йөрәге белән хәсрәтле көннәрнең тизрәк тәмамлануын көтеп яши. Хәер, ул башкаларны уздырып та җибәрә: тракторчылыкка укып чыга. «Тимер ат»ны иярләгән унбиш яшьлек кызга күпләр кызыгып та, сокланып та карый. «Фарзан» тракторларының да әле ул чакта фаралары да юк, төннәрен кырларда эшләгәндә, алдан керосин лампалары белән яктыртып баручылар һич күңеленнән китми Сәрвәриянең. Көне-төне эшләп, ике ел буена җиңүне якынайта шулай...

Ул чакта әле Сәрвәрия тәкъдир кавыштырачак яры – Габделхәенең дә ил гаме белән януын, үгез җигеп, колхоз кырларыннан көлтә ташуын күз алдына да китерә алмый...

## Габделхәй

Сугыш... Ир-егетләрнең җанына гамь салган чорлар. 13-14 яшьлек яшүсмерләр җилкәсендә – дөнья йөге. Габделхәй дә әтисен, абыйсын сугышка озаткан. Бер-бер артлы авылга кайгылы хәбәрләр килә. Габделхәйләр йортын да читләп үтми алар. Әтисе Абзалетдин дә, абыйсы Габделәхәт тә сугыш кырында мәңгелеккә ятып кала.

Нишлисең, ил белән бергә, язмыштан узмыш юктыр, дип эчтән әрнесәләр дә, тыштан килешә өйдәгеләр.

Өлкәннәр: «Үлсәң дә, туган җиреңә ябыш» дип кабатлаганда, чандыр яшүсмергә кирбеткән үгезне тәртә арасына кертүе бер дә җиңел эш түгел шул. Әмма Габделхәй бирешми: этисе өчен дә, абыйлары өчен дә эшли. Ә чебен-черки мыжлап торган көзге бер көнне үгез бөтенләй чыгырдан чыга: җигүле килеш Карамалы елгасына карап чаба. Яшүсмернең йөгәнләргә тырышуын һичнигә санамыйча, койрыгы белән чебен-черки куган арада, арбадагы бодай көлтәләре чүмәләсе белән агып та китә. Бодайның бөртегенә дә тияргә ярамаган заманда, чарасыз калган яшүсмер гаепсездән гаепләнә: ачуланып, орышып та карый соң аны авыл апалары. Аларның ачлыктан сулган йөзләре, сагыну-сагыш тулы күзләре Габделхәйнең гомере буена күз алдында тора.

Ләкин көннәрдән бер көнне аның үзенә дә чират җитә: егетне Кызыл Армия сафларына алалар. Ульяновскида танк училищесында әзерлек курслары үткәннән соң аны да сугышка озаталар. 1944 елның караңгы көзе була бу. «Мондый мәхшәрне бездән соңгы буыннарга күрергә язмасын, җир өсте ватык техника, мәетләр белән тулды», – дип сөйли Габделхәй ага.

Ул чакта сугыш кырында туган ягында бүреләр азынган урманнарны бер генә күз алдыннан үткәрмәгәндер егет. Әмма бүреләр Сәрвәрия исемле чибәр кызга тимәгән кебек үк, Габделхәйгә дә бер мәртәбә дә һөҗүм итмиләр. Ә монда – Кенигсберг тирәсендә, мәетләрдән түшәлгән җир өстенә үз күзләренә үзе ышанмыйча карап торганда, фашизмның бүреләрдән күпкә куркынычрак булуын аңлый ул. «Ир-егет өйдә туар, яуда үләр» дигәнне ишеткәне булса да, әлеге коточкыч күренештән тәмам өнсез кала. Барысы да кемнәрнеңдер газиз балалары ласа! Өйдә көтеп зарыккан әниләре бардыр, дип өзгәләнә.

Ләкин яулар аяусыз... «Соңгы каным тамганчы көрәшәчәкмен!» дип, үз-үзенә сүз биреп, сугыш ахырына якынлашып килгәндә ... аның үзен дә мәетләр арасыннан табып алалар. Сызраньга хәрби госпитальгә озаталар. Җиңү яулап каты яраланган, контузия алган егет, беркүпме госпитальдә дәваланып, 1946 елда туган авылы – Самара өлкәсе Кошки районы Иске Фәйзуллага кайтып егыла.

Хәер, «егыла» дию дөрес үк тә түгелдер, егылырга ярамый аңа. Көчле умарта гүләвеннән билгеле дигәндәй, ата-бабадан күчә килгән тормышны, яшәүне сөю көче яраларны ялмаштырып булса да, иртәгәсе көнгә ныграк атлап керергә чакыра. Җитмәсә, укытучы булып авылга Сәрвәрия Мәҗитова дигән кыз килгән, ул башлангычларга белем бирә икән. Балаларның куанычы эчләренә сыймый: дәресләрне аеруча кызыклы итеп алып бара, диләр. Дөнья нужасыннан арып, укытучылары белән әкиятләр иленә килеп кергән укучылар өчен офыклар киңәеп киткәндәй тоела. Яхшыдан яманны аерырга өйрәтә Сәрвәрия апалары шулай.

Авылда матди юклык өстенә рухи караңгылык хөкем сөрә. Укытучылар җитешми. Габделхәй дә Самарадагы педагогия училищесына юл тота.

## Мәхәббәт

Сәрвәрия белән Габделхәй бер мәктәптә эшлиләр. Кыз оялчан, егет тә тотнаклы. Күп үлемнәр күргән, афәтле елларны кичеп исән калган... Йөрәге тулы яра, җаны тулы җәрәхәт аның. Сөйләшеп китәр өчен дә шактый вакыт кирәк була әле. Югыйсә, сәбәп тә бар: икесе дә агитаторлар, халык арасына гел бергә чыгарга туры килә. Укытучылар авыл клубында халык өчен концертлар оештыра, спектакльләр куя. Монда да Габделхәй Хәлил булса, Сәрвәрия – Галиябану. Халык елый-елый карый. Күпләренең ирләре, этиләре, сөйгәннәре сугыштан кайтмаган. Алар, сәхнәдән күз алмыйча, барысы да үз мәхәббәте хакында уйлый.

Габделхәй белән Сәрвәрияне дә йөрәк үзенә буйсындыра. «Мәхәббәт дәрәҗә белән дә, тәрәзә белән дә исәпләшми», ди халык мәкале. Тәрәзә дигәне, егетләрнең кызларны күбрәк тәрәзә аша күзләвеннән чыгып та әйтелгәндер, бәлки. Тәүфыйклы заман. Кешелекле заман ни дисәң дә... Яшьлекнең гүзәл чорын хәтерләгәндә, Сәрвәрия апа да гади генә итеп: «Аннан бер-беребезгә ошаша башладык...» дип кенә куя.



*«Без әтиле йортка кайтабыз»...*

Ә чынлыкта, мәхәббәтен очратмаса, чак үлемнән калган, умыртка баганасы каты җәрәхәтләнгән, сугыш дигән афәт тәнне генә түгел, җаннарны имгәткәнен үз йөрәге аша кичергән егет исән кала алган булыр иде микән?

1948 елның бөтерелә-бөтерелә сап-сары яфраклар явып торган 9 сентябре аларның икесе өчен дә кадерле дә, шул ук вакытта истәлекле дә бер көнгә әверелә. Бу көнне алар никахларын рәсми рәвештә теркиләр. Ягъни бер-берсенә булган изге хисләрен җәмгыять, ата-ана, ил алдында белгертәләр.

Хәер, чынлап карасаң, мәхәббәт – ул аларның бергәләп үткән гомер юлы. Мәхәббәт – ул аларның бер-берсен кичерә белүе. Мәхәббәт – ул 70 ел дәвамында җаннарның килешеп яшәве. Ирен сөйгән хатынның өстенә нур явар ди. Әнә шул күкләрдән иңгән нурны бөтен кеше дә күрә бугай Сәрвәриядә. Аны авылда яраталар, хөрмәт итәләр. Укучылары бигрәк тә. Аңа охшарга тырышып, аның эзеннән китүчеләр, гомерен укытучы хезмәтенә багышлаучылар да аз булмый.

## Гаилә

1949 ел. Габделхәй белән Сәрвәрия юллама буенча Аксубайның Яңа Ибрай авылына килеп төшә. Кулда иске чүпрәк-чапракка төрелгән бала. Нәни Җәмилләренең бер-ике айлык чагы. Аларны мәктәп директоры Хәлим Хәйретдинов каршы ала. Ул яшь укытучыга карап-карап тора да: «И сеңлем, балаң башын да тота алмый бит әле, ничек кенә эшләрсең икән соң син?» – дип куя.

«Борчылмагыз, эшләрмен», – ди Сәрвәрия елмаеп.

Әлбәттә, Хәлим ага каршысында, илнең ир-атларга аерата мохтаҗ чорында, авылның «тимер атны» йөгәнләгән батыр йөрәкле кызы басып торуын күз алдына да китермәгәндер. Янәшәсендә сугыш җәрәхәтләреннән тәне-җаны теткәләнеп беткән, гаилә дигән җылы ояга өмет баглаган ире басып торуын да төшенеп җитмәгәндер. Шулай да Хәлим Шәрип улы бик мәрхәмәтле зат булып чыга: яшь парны ярдәменнән ташламый: эшен дә таба, фатирга да урнаштыра.

Бу туфрак алар өчен газизгә әверелә. Сәрвәрия ирен үзе дәвалый, бала тәрбияләгәндәй тәрбияли. Сугыш җәрәхәтләрен бөтенләй онытырлык итә. Габделхәй ага читтән торып Казан дәүләт университетын тәмамлый. Уллары Наил, Шамил Яңа Ибрайда, Вил, Рамил, кызлары София, Әлфия Аксубай районында туа. Шушында Габделхәй Абзалетдин улының һөнәри үсеш юлы башлана. Хәер, «һөнәри» дию бик үк дөреслеккә дә туры килмидер, чөнки укытучы булудан кузгалып киткән гомер юлы мәктәп директоры дигән баскычка күтәрелгәч кенә башка юнәлеш ала. Партия

аны артта калган колхозга рәис итеп билгели, аннан алты авылны берләштергән, эреләндерелгән «Дуслык» хуҗалыгын җитәкләүне йөкли. Партком секретаре да була Хәй Абзалыч (халык аны якын итеп шулай атый). Ул Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Аксубай районының мактаулы гражданины. Аллага шөкер, әле дә җор телле, балаларына, оныкларына җан җылысын бүлеп, ил карты булып, бәхетле картлык кичереп, унынчы дистәне ваклап килә...

Бөек Ватан сугышы инвалиды Габделхәй ага балаларга шәхси үрнәк күрсәтә. Тукаебызның: «Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш...» дигән юлларында әтиләре хакында сүз барганын уллары да, кызлары да аңлап үсә.

## Без әтиле йортка кайтабыз...

Бу юлларның әһәмиятен әти-әни канаты астына сыенган балалар белә булыр. Сугыштан соң «әти» дип дәшәр кешесе калмаган күпчелек арасында Габделхәй абый үзе дә бар бит... Ярый, Аллаһы дөньяга киләсе гөрнәдирдай уллары, чәчкәдәй кызлары хакына үзенә гомер бирә. Ярый, Сәрвәрия апаны очрата... Ә алардан балаларына яхшы тәрбия кала. Мөхәммәт пәйгамбәр: «Атаның балаларына калдырган иң зур мирасы – яхшы тәрбия», – ди. Чөнки Габделхәй абый да, Сәрвәрия апа да матди байлыкны гаиләдән алга чыгармыйлар, партия кая кушса, шунда баралар, партия ничек таләп итсә, шулай эшлиләр. 1975 елда, 30 ел бергә яшәгәннән соң гына беренче тапкыр үз йортларын җиткезеп керәләр. Шуңа карамастан Сәрвәрия апа: «Бөтен нәрсәбез булды безнең, Габделхәем бик тырыш кеше бит», дип ирен мактап-үсендереп кенә тора. Бүгенге яшьләр, бәлки, илгә мондый бирелгәнлекне күзаллап та бетермәскә мөмкин. «Ватан – анаң, Ватан – атаң!», «Ватан өчен җан фида» кебек бөек гыйбарәләрне сыйдырган әйтемнәрнең дә чын мәгънәсен Яһудиннар гаиләсе яхшы аңлый. Чөнки Габделхәй абый да, Сәрвәрия апа да – үз чорларының чын геройлары. Заман герое нинди була дигәндә, узган гасыр геройлары нәкъ алар кебек буладыр. Ә бүгенге көн геройлары – аларның ул-кызлары. Алма агачыннан ерак төшми икән шул...

Мөхәммәт пәйгамбәр үзенең бер хәдисендә: «Җәннәт аналарның аяк астында», ди. Бу – дөньядагы бәрәкәтле, хәерле тормыш дигәнне аңлата. Яһудиннар гаиләсе хакындагы язмамны әзерләгәндә, мин бу алтын сүзләрне һаман искә төшердем. Дин китапларында язылганча, ана хакы ата хакыннан биш мәртәбә өстен, ди. Әти дә, әни дә сине икесе берьюлы чакыралар икән, башта әниең янына бару тиешле, диелгән. Моны Яһудиннар гаиләсе үрнәгендә күрү, аларның әниләренә булган күңел җылысын тою, ничектер, хәтта бүгенге кырыс заманнарны да нурландырып җибәрә сыман.

Сәрвәрия апа үзе дә уллары-кызлары белән горурланып яшәгән ана бит. Аның: «Балаларым барысы да югары белем алдылар. Төрле өлкәләрдә Атказанган хезмәткәрләр булдылар. Ә мин бер генә нәрсә теләдем: Атказанган ана булсам иде, дидем. Һәм була алдым кебек», – дип ярымшаяртып әйткән сүзләрендә олы хаклык ята. Әйе, Атказанган Ананың җәмгыять алдында да, хезмәт һәм иҗат шатлыгын тоярга өйрәнгән балалары һәм укучылары каршында да йөзе ак, вазифалары үтәлгән. Уллары-кызлары мохитендә кадердә яшәгән ул. Бүген аны хөрмәт белән искә алалар. Сәрвәрия апа Нурлатның Пушкино авылы зиратына җирләнгән. Урыны җәннәттә булсын. Һәр яхшы сүз аңа дога булып барсын. Йәгез, бер дога...

**Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА**

# «КАЯ ӘЛЕ, ҮЗЕМ!»



*Илсур Шәйхетдинов хатыны Дания ханым белән.*

Илсур Шәйхетдинов яшәгән йортны инде күземне йомсам да, бик тиз табармын кебек. Бар иде заманалар, илгә-җиргә танылган кешеләрнең кайда яшәгәнен һәркем диярлек белә иде. Илсур Шәйхетдиновның йортын тиз таптым үзе. Чөнки хатыны Дания апа үзләренә ничек барасын телефоннан бик әйбәтләп аңлатты. Тау Башы бистәсенә үзәк урамнан менгәндә, кибетне узгач та, уңга борыласың, аннан ерак калмый, диде. Әгәр: «Кибеткә җиткәч, теләсә кемнән сора, әйтеп бирерләр...» – дигән булса? Алай димәс иде, әлбәттә, чөнки заманы башка. Шулай да кызык өчен кибет янында туктадым да үткән-сүткәннәрдән Социалистик Хезмәт Герое яшәгән йортны сораштырдым. Берәүләр дәүләтнең мондый бүләге барын да белмиләр иде: «Какой герой вы сказали?» – дип кызыксындылар.

– Герой Социалистического Труда.

Аптырап, иңнәрен сикертәләр, «интересно» дип куялар. «Илсур Шәйхетдинов» дип исем-фамилиясе белән дә әйтеп карыйм – юк, белмиләр. Бу хакта язып торырга да исәп юк иде, әмма өченче керүемдә ире тирәсендә «Илсурым, Илсурым...» дип бөтерелгән Дания апа күңел ярасына әйләнерлек сүз әйтеп куйды. Күрше-тирәдә яшәүче берәү моңа: «Ирең сезнең өчен генә герой ул, безнең өчен беркем түгел», – дип ычкындырган. Дания апа бу турыда өйдәгеләргә берни дә әйтмәгән булган, ахрысы, Илсур абый: «Кем шулай ди? Күрсәтермен мин аңа беркем түгел икәнемне», – дип куйды. Шуннан артыгын әйтмәде. Күкрәк сугып, «тамак кырып, мыек борып» дигәндәй йөрмәсә дә, үзенең кем икәнен белә ул. Заманында бөтен илгә танылган ир-егет өчен пычрак күңелдән чыккан моның ише сүзләр ят иде. Олы йөрәкле, горур, Дания апа әйтмешли, «тимер Илсуры» күрәсең моның ише «вак-төяк»кә игътибар итүне үзе өчен түбәнчелек санады. Ә мин аңа карап сокландым. Озын буйлы, таза гәүдәле, һәр сүзен гөлдерәп торган тавыш белән өздереп, җиренә җиткереп әйтүче бу 83 яшьлек ир-егеттән бүген дә ниндидер көч-куәт, гайрәт бөркелеп тора иде. Дөрес, Себер сазлыкларында бата-чума, кышын туңа-ката газүткәргеч торбалар салып йөргән Илсур абыйның аяклары беткән. Өй эчендә дә таякка таянып йөри. Әмма: «Берәр яңа техника бирсәләр, бүген чыгам да китәм әле мин», – дип куйгалый. Язмышын нечкәли башласаң, аның тормышындагы һәр вакыйга, һәр көн, һәр сәгать үзе бер гыйбрәт.

## «Кызым, ireңнән беркайчан да калма!»

Илсур абыйның әтисе Гарәфи абзый армиягә алынып, «үлем лагере» дип халык теленә кергән Суслонгерга эләгә. Мин анда әллә ничә тапкыр булдым. Мари урманнары сугыш еллары фаҗигаләрен һаман да сер итеп саклый әле. Ир-егетләрне сугыш серләренә өйрәтү өчен оештырылган бу лагерьга эләгүчеләр ачлыктан, төрле авырулардан кырыла, кышкы салкыннарда туңып үлә. Әмма аларның төгәл санын берәү дә белми, Оборона министрлыгы архивы да бүгенге көнгә хәтле йозакта. Үлгәннәрнең гаиләләренә бары

тик «хәбәрсез югалды» дигән хатлар килә. Кайбер тарихчылар әйтүенчә, сугышка барып җитмичә, Суслонгерда үлгәннәрне дистә меңнәр белән санарга кирәк.

Илсур абыйның әтисе – Гарәфи солдатны да шул «хәбәрсез югалганнар» язмышы көтә. «Озынколак хәбәрләр» аша хатыны Камәриягә: «Ирең үлем хәлендә, җай тапсаң, килеп ал!» дигән сүзләр килеп ирешә. Кышның салкын бер көнендә үрәчәле чана тартып Суслонгерга чыгып китә Камәрия. Ике йөз чакрым араны ничекләр барып җиткәндер ул – бер Ходай гына белә. Гарәфи солдатның иптәшләре Камәриягә иренең тире белән сөяккә генә калган гәүдәсен яшертен генә чыгарып бирәләр. Чөнки, шул ук иптәшләре әйтүенчә, ярымүле-ярымтере Гарәфине мәетләр белән бергә күммәкче булганнар. Тагын ике йөз чакрым араны чана тартып авылга көчкә кайтып җитә Камәрия һәм үзе урынга егыла. Дания апа әйтүенчә, салкын, күрәсең, җелекләренә хәтле үткәндер, аның аяклары, бөтен тәне шешеп чыга. Шулай да исән кала Камәрия һәм урында яткан килеш тагын өч бала таба. Тормышка ничек ябышып ятканнар элек, ә? Мин бүгенге гүзәл затларыбызга шушыларны сөйләсәм: «Син чана тартып, иреңне алып кайтырга барыр идеңме? Авырып урынга егылгач та, бала табар идеңме?» – дисәм, алар миңа, мөгаен: «Абый, син ычкынган ахрысы», – диярләр. «Кәмит сүз сөйләп торма! – диючеләр дә табылыр иде. Ә Камәрия апа инде шактый еллар узгач, үзләренә килен булып төшкән Даниягә: «Кызым, ireңнән беркайчан да калма!» – дип әйтеп калдыра. Гарәфине айлар-еллар дәвалап, көч-хәл белән тәки аякка бастыралар һәм ул башта туган авылы Орнашта үз өендә, аннан соң Арчаның төрле мәктәпләрендә балалар укыта.

## Олы юл башы

Арча педагогия училищесына укырга кергәндә, Илсурның күңеленә әтисе һөнәрен сайлау уе кермәгәндер, мөгаен. «Укытучы булырга хыялландым», – дигән сүзләрне аның үзеннән дә ишетмәдем.

Сугыштан соң берничә ел узгач, Шәйхетдиновлар Арчага күчеп килә. Гаилә башлыгы Гарәфи абыйны райкомга эшкә чакыралар. Арча педучилищесының әле ул заманнарда ук бик абруйлы уку йорты булуы, анда Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев кебек олпат язучыларыбыз укуы, әлбәттә инде, Илсур күңелендә әлеге уку йорты белән горурлану, шунда уку теләге уятмый калмагандыр. Педучилищеда бик яхшы укый ул, әмма балаларга сабак бирергә туры килми. Көннәрдән бер көнне бер авылдашы очрап: «Ярый, педучилищены тәмамладың, Илсур, инде шушы гәүдәң белән гомер буе балалар укытып йөрмәкче буласыңмы?» – дип куя. Аңа үпкәләми Илсур, әмма уйга кала. Чыннан да, теләсә нинди эшне җир җимертеп эшләрдәй өрлек кебек егет бит ул. Бүген сөйләшеп утырганда, Илсур абый: «Ул чакта укытучыларга алай кытлык та юк иде инде ул», – дип бераз аклангандай итә. Бәлки, укыган һөнәре буенча эшләмәвеннән кыенсынадыр. Ягъни, педучилищеда юкка гомер уздырган, «хөкүмәт ипиен бушка ашаган» булып чыга бит инде. Мондый «канатлы сүзләр» ул заманнарда еш әйтелә иде.

Илсур абый белән гәпләшеп утырганда, шуны уйлап куйдым: бит «хөкүмәт ипиен» бушка ашамаган ул, укытучылык гыйлеме алдагы тормышында бик кирәк була. Чөнки ул җитәкче буларак, йөзләгән-меңләгән кешенең остазына әйләнә. Шәкертләре бүген дә аның турында: «Илсур абый безгә укытучы-остаз да, әти кеше дә булды», – дип сөйлиләр.

## Болар хакында әле соңрак язарбыз

Һөнәр сайлаганда, бераз икеләнеп торуы герой-якташымның тормышында бердәнбер очрак булмады микән, дип шикләнәм. Чөнки аның моннан соңгы бар эшгамәлләре «кая, үзем!» дигән принципка нигезләнә. Сугыш яраларын төзәтә-төзәтә үсешкә юл алган ил өчен мондый гаярь егетләр бик кирәк була.

1953 елда партия Үзәк Комитетының авыл хуҗалыгын үстерү турында карары чыга. «17 яшьлек егет партия карарларын үтәү йөзеннән механизатор булу уе белән янып яши башлады...» дип язсам, бу сүзләр укучыга гына түгел, үземә дә көлке тоелыр иде. Әмма ул заманда һәр авыл малаеның техника белән җенләнүе – хак. Малай чакта без дә авылда бердәнбер булган машина яки трактор артыннан чаба-чаба авылны чыгып китә идек.

Авыл хуҗалыгын үстерү турында партия карары чыгып, илдә техник яңарыш шаукымы башлангач, Илсурның Үрнәк авылындагы механизация училищесына укырга керүе инде табигый. Училище тәмамлагач, Арча машина-трактор станциясендә эшли башлый ул. Баш инженер Рөстәм Халитовның иң булдыклы егетләрне үз тирәсенә җыйган чагы бу. Шуңа күрә һәрберсен үзенчә сынап карый. Сүз уңаеннан: Рөстәм Халитов – Бөек Ватан сугышы ветераны, Сугышчан Дан орденнарының тулы кавалеры. Андыйлар, гадәттә, Геройга тиңләнә. Казан компрессорлар заводында да эшләгән. Завод янында аның исемен йөрткән урам да бар.

Менә шул Халитов шактый ук шук кеше була. Илсурның тракторы ватылгач: «Складта «ДТ-54»нең балкасы бар. Шуны тимерчелеккә алып килсәң, запчасть бирәм», – ди. Әзмәвердәй таза егетнең көч-куәтен үзе сынап карыйсы килә моның. Илсур 160 килограммлы балканы кар ерып күтәреп алып килә. Баш инженер сүзендә тора, кара көнгә дип саклаган бердәнбер запчасть – бульдозер рамын Илсурга бирә. Һәр эшкә беренче булып атлыгып торганы, ышанычлы булганы өчен яраталар Илсурны. Алай гына да түгел, син монда кирәгрәк дип, бронь биреп, ел саен армиядән калдыра киләләр. Илсур моның өчен җитәкчелеккә рәхмәт әйтеп яшәгән, дисезме? Баштан сыйпаган саен Шарик кебек койрык болгарга яратучыларны җене сөйми аның. Хәрби комиссариатка бара да: «Яшьтәшләремнең инде армиядән кайтыр вакыты җитә. Нәрсә, мин башкалардан ким мәллә?» – дип военкомга бәйләнә.

Сөйләшүне сүзен-сүзгә Илсур абый инде тәгаен генә хәтерләми. Әмма броньнан баш тарта ул, МТСтагы җитәкчеләрне дә күндерә. Шулай итеп, армиягә чакырыла, һәм Азәрбайҗанда хезмәт итә. Армиядә дә иң кирәкле кешегә әйләнә. Кайтыр вакыты җиткәч, аны сроктан тыш хәрби хезмәттә калырга кыстыйлар. Бүген Илсур абый: «Калсам, инде әллә кем булган булыр идем», – дип куйгалый, ә Дания апа: «Син болай да әллә кем инде, Илсурым!» – дип, аңа елыша. Егетне армиядә шул хәтле калдырырга телиләр, артдивизион командиры Габделхак Закиров аны үгетли-үгетли поездга кадәр озатып бара. Инде үгетләүнең файдасыз икәнен аңлагач: «Ярый, кайт туган якларга. Армия хезмәтен тутыргач, мин сине барыбер эзләп табармын», – ди. Ул Казан кешесе була. Илсурны тәки эзләп таба һәм алар гомер буе йөрешеп, гаилә дуслары булып яшиләр.

## Син мине күтәрсеңме?

Безнең яшьлектә җыр җырлап, авыл урамнарын әйләнү бар иде. Без үткәндә, шагыйрьчәрәк әйтсәк, кичке авылның «күзен йомган зәңгәр тәрәзәләре пәрдә читен ачып» карыйлар иде, әмма йокы бүлеп йөрисез дип, ул-бу әйтүче булмады. Шул чактагы бер җыр искә төшә. Мин аның авторларын да белмим. Болайрак иде аның сүзләре:

*Мәхәббәт ул – яшьләргә дә, картларга да,*
*Мәхәббәтсез мөмкин түгел атларга да.*
*Ышанмасаң, сүзләремнең хаклыгына,*
*Гомер иткән кешеләрдән сорап кара.*

«Гомер иткән» дигән сүзләрне без сиксән яшьлек, туксан яшьлек, хәтта, йөзгә җиткән... дип, «кешеләрдән» дигәнне «бабайлардан», «әбиләрдән», дип үзгәртеп җырлый идек. Җырлый идек тә нигәдер елмаеп куя идек. Күрәсең, мәхәббәт дигән олы хиснең шул яшьтәгеләр күңелендә дә яшәячәгенә ышанып җитмәгәнбез. Менә бүген сиксәннең теге ягына чыккан Илсур абый һәм Дания апа белән очрашкач, яшь чактагы әлеге елмаеп куюлар күпмедер дәрәҗәдә ахмаклык кебек тоелды. Бар икән бит ул – мәхәббәт, аңа яшь куеп булмый икән бит. Әлбәттә, яшьлектәге һәм картлыктагы мәхәббәт бераз аерылып торадыр инде ул. Туфан ага Миңнуллин да: «Хатын, картайгач, диваннан тартып торгызыр өчен булса да кирәк», – дип шаярта иде. Әмма җае чыккан саен «Нәҗибә апагыз» дип әйтә һәм күзләре тагын да җылынып китә иде аның. Илсур абый белән Дания апа миңа мәхәббәт сабагы да бирделәр. Аларның танышу-кавышуларында бернинди романтика да юк үзе. Чиләбегә китәр алдыннан әтисе Гарәфи Илсурны күрше Югары Сәрдә авылы кызы, сыер савучы Дания белән

таныштыра. «Бик әйбәт кыз, шуңа өйлән», – ди. Армиядән кайткан егетнең төзү-монтаж идарәсендә эшли башлаган вакыты була һәм газ үткәрү трассаларының берсенә бульдозерчы кирәген ишетә. Үрнәктәге училищеда алган һөнәре аңа әнә шулай бик кирәк булып чыга, һәм ул газүткәргеч торбалар салучылар отрядына килеп кушыла. Ә бу эш исә тагын берничә һөнәр үзләштерүне сорый. Шуңа күрә Илсурны Чиләбегә укырга җибәрәләр дә. Китәр алдыннан ул Даниягә: «Мин кайтканны көтәрсеңме?» – ди. Дания: «Юк, көтмим. Иң элек никахлашыйк, аннан соң мин сезнең гаиләдә яшәп торырмын», – ди. Иртәгә Илсур китәсе дигән көнне ашык-пошык никах укытуны көлә-көлә сөйли Дания апа: «Туганнарының рөхсәтен алу өчен Казанга барып кайтырга да өлгердек», – ди. Язмама «бер күрүдә гашыйк булу» кебек сүзләрне кертмим. Дания апа да, Илсур абый да мондый купшы сүзләрне бик яратмыйлар, ахрысы. Бер-берсен бик ошатканнар һәм... бетте-китте. Дания иренең әнисе Камәрия апа сүзләрен васыять дип кабул иткән, күрәсең, ул гомер буе ире кая китсә – шунда була.

## Себер сазлыкларында

Чиләбедә газүткәргеч торбалар салу серләренә өйрәнеп кайткан Илсурны бригадир итеп куялар. Ике елдан, ягъни 1964 елда ул колонна җитәкчесе, тагын ике елдан участок башлыгы була. Бераздан нефть-газүткәргеч торбалар төзү идарәсе, аннан соң «Татнефтепроводстрой» тресты идарәсе җитәкчесе итеп билгеләнә. Язулары җиңел лә ул, ә бит Илсур карьера баскычлары буйлап Себер сазлыкларында күтәрелә. Себер газын бөтен илгә тарату, аннан Европа чигенә илтеп җиткерү өчен «себер китәргә» ашкынып торучылар булмый. Чөнки трассаларны тайга, тундра сазлыклары, елгалар, күлләр, Калмык далалары аша саласы. Шуңа күрә кызыктыру өчен дип, Себердә эшләп кайтканнарга Казанда фатир вәгъдә итәләр. Фатир бирәләр дә. Әмма Илсурның уйлары – башка. Ул Себердә вакытлыча гына эшләргә тиеш түгел. Никадәр купшы сүзләр булып тоелмасын, тормыш аны «масштаблы фикерләргә» өйрәтә. Себер газының ил өчен, кешеләр өчен никадәр кирәк икәнен аңламаса, ул Илсур Шәйхетдинов та булмас иде.

Сөйләшеп утырганда, Дания апа да: «Үзен бер дә жәлләмәде инде ул, һәрнәрсәгә кирәк бит дип тотынды, – диде дә, – мине дә жәлләмәде», – дип елмаеп җибәрде. Баксаң, Илсур абый хатынына да иң авыр эшләр куша торган булган. Янәсе, җитәкче үзе генә түгел, аның хатыны да кешеләргә үрнәк булырга тиеш. Шулай итеп, Дания апа пешекчегә, кер юучыга әйләнә. Трассада эшләүчеләрнең киемнәрен генә түгел, урын-җирләрен дә юа ул. Ул чакта кер юу машинасы, порошоклар юк. Сабынлап юа-юа куллары өзелеп төшәрдәй була. Агачтан-агачка бау бәйләп киптерә, күмер үтүге белән үтүкли. Ә хуҗа шактый кырыс, таләпчән: кул астында эшләгәннәр кешечә яшәргә тиеш. Шуңа күрә яңа участокка күчәр алдыннан Илсур абый шунда алдан ук балта эшенә кулы ябышкан егетләрне җибәреп ашханә, мунча, торак йорт, клуб, кибет салдыра торган була. Себер сазлыкларында эшләгән кеше тәмуг газаплары гына күрергә тиеш түгел бит инде.

Пермь партия өлкә комитеты органы булган «Звезда» газетасы моннан 38 ел элек менә ниләр яза: «Эшчеләр яшәгән вагон-йортларда номерларга хәтле язылa, ашханә, кибет, медпункт ишекләрендә эш сәгатьләре күрсәтелә иде»... Шәйхетдинов үзенең егетләре «зур җирдән» аерылган дип хис итмәсен өчен «Кызыл почмак»ка телевизор, радио куйдыра, 900 тәңкәлек газета-журналлар яздыра. Кыскасы, аның участогы кечкенә генә шәһәрчекне хәтерләтә. Анда хәтта балалар өчен уен мәйданчыгы да була. Дания апа беренче баласы Маратны тайга уртасындагы шундый шәһәрчектә, вагон-йортта таба. Һәм Марат бүгенгә хәтле әтисе һөнәрен дәвам итә.

Бер килүемдә ул әти-әнисе янына хәл белергә кайткан иде. Төп эше хәзергә Сочида икән. Хәл-әхвәлләр белештек тә, эше турында сорадым. «Бик җиңел түгел, әмма әтинеке бик авыр булган инде», – дип куйды һәм Себер сазлыкларын исенә төшерде. Ул еллар Шәйхетдиновлар күңеленә шул хәтле уелып кылган ки, Дания апа: «Казанга кайткач, шактый вакыт шоктан чыгалмый азапландык», – ди. Иреннән бер адым да калмаган яшь хатын беркөнне биләүдәге ике баласын күтәреп, ире эшләгән яңа участокка килә. «Килү» дип, ул вакытта бердәнбер транспорт чарасы вертолёт була инде. Вертолёт атлаган саен

тирбәлеп торган сазлыкка утырыр өчен берәр коры җир эзли. Гадәттә, утыра алмый, мөмкин кадәр түбән төшә дә, кешеләр җиргә сикерә. Биләүдәге сабыйларны бер корырак түмгәк өстенә куялар. Шулвакыт алар вертолёт җиле белән тәгәрәп китәләр. Ярый әле егетләр тиздән саз ерып барып, сабыйларны күтәреп алалар.

Кыскасы, Төмән тайгасы сазлыкларында кешене адым саен куркыныч сагалый. Беркөнне торба салу кранына утырган Илсур да чак кына үлемнән кала.

Сазлыкка батып барган кран өстеннән аны вертолёт алып өлгерә. Шуңа күрә Дания апа: «Илсур трассага чыгып киткән саен, исән-сау әйләнеп кайтсын иде дип Ходайга ялвара идем», – ди.

Беренче дәүләт бүләге – Ленин орденын алганда, Илсур Шәйхетдиновка нибары 29 яшь була. Әлеге олы бүләкне аңа тирә-ягын сазлыклар урап алган бер мәкерле елганы буйсындырган өчен бирәләр. Ягъни адәм аяк басмаслык урыннарда елга аша газ торбасы суза аның егетләре. Бригада кеше күрмәгән-ишетмәгән дигәндәй, яңа ысул куллана. Торбаларны җир өстендә үк эретеп ябыштыралар, изоляция чорныйлар, бер башын саз сулары кермәслек итеп томалыйлар да саз өстеннән шудыра башлыйлар. Шуның өстенә беренче тапкыр диаметры 1220 миллиметрга җиткән торбалар сала башлыйлар. Алай гына да түгел, эретеп ябыштырылган әлеге торбаларның гомуми озынлыгы 300 метрга җитә. Ул чактагы матбугатта язылганча, мондый алым, ягъни комплекслы агым ысулын кулланучы булмый әле. Теориядә генә яшәгән әлеге яңалык күпләрне өркетә. Ә Илсур Шәйхетдинов һәрвакыттагыча: «Кая әле, үзем!» – дип эшкә тотына. Соңрак аның тәҗрибәсен башкалар да өйрәнә һәм куллана башлыйлар. Егетнең даны бөтен илгә тарала. Дания апа: «Илсурым өчен Мәскәүдәге министрларның ишекләре ачык иде, һәркайсына теләсә ни вакытта керә ала иде», – дип сөйли. Сүз, әлбәттә, теләсә кайсы ишекне тибеп ачу турында бармый. Илсур Гарәфи улына һәр җирдә хөрмәт-ихтирам дигән сүз бу. Заманында СССРның нефть һәм газ предприятиеләре төзелеше министры Борис Щербин бер газета җитәкчесенә биргән интервьюсында Илсур Шәйхетдиновны аерым билгеләп үтә. Хәтта героебызның хезмәт юлы турында да тәфсилләп сөйли ул. Үз эшенең остасы булуы белән бергә, күпләргә остаз һәм зур оештыру сәләтенә ия булуы, иң авыр эшләргә иң беренче тотынуы турында сөйли, аны «хезмәт батыры» дип атый.

Министрны «суга караган» диярсең, 1975 елда Илсур абыйга Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә.

## Герой һәм аның шәкерте

Бу язмага тотыныр алдыннан Арчага кайтып, Илсур абый белән эшләгән бер егет белән очраштым. Бүгенге көндә героебызның туган авылы – Орнашта умартачылык белән шөгыльләнүче Ядкәр Мөхәммәдиев ул. Авыл инде юк. Заманында Орнашта, Ядкәр әйтмешли, «Нәкъ Арчадагы кебек гөрләп» Сабан туе уза торган булган. Бер елны Ядкәр «Мәйданга Илсур абый да кайткан» дигән хәбәр ишетә. Чирәмлектә зәңгәр күккә карап, уйланып яткан герой-авылдашын таба да: «Мин Зөфәр малае Ядкәр булам, синең белән эшлисе килә», – ди.

– Һөнәрең бармы соң?

– Тракторчы, комбайнчы.

– Армиядә булдыңмы?

– Әле яңа гына кайттым.

– Яхшы. Алайса иртәгә минем белән китәрсең. Ничек тиз эшли – сүзен дә шулай тиз тота Илсур абый. Эленке-салынкы эшләгәннәрне җене сөйми. Ядкәр: «Алладан курыккан кебек курка идек без аннан. Тик торган килеш күзенә чалынсаң, кесәсенә сугып куя иде дә: «Менә бу кесәдә синең хезмәт хакың, энем. Телим икән, алып сиңа бирәм, теләмим икән, икенче кесәгә салып куям», – дип кенә әйтә иде. Ну, эшләгән кешегә яхшы түләде. Аена, ким дигәндә, мең тәңкә ала идек. Ул заманда зур акча иде ул. Ә менә үзе акчага егылып китмәде Илсур абый. Үзенә тиешлесен генә дә җыеп барган булса, ул бүген миллионер булып яшәр иде», – ди. Ядкәр әйтүенчә, Илсур Шәйхетдинов бөтен акчасын социаль мәсьәләләргә, эшчеләргә тотып бетереп барган.

Бүгенге заман кешесен кайчандыр шундый-шундый җитәкчеләр эшләгәненә дә ышандырып булмастыр, шәт. Әле Илсур абый Матюшинода эшчеләр өчен ике катлы ике йорт та салдырган булган. Үзенә шунда бер бүлмә дә алмады ул», – ди Ядкәр. Илсур абый әле Арча тавын кистереп туры юл да ясаткан. Тукайның туган авылы Кушлавычка да юл керткән. Иң кызыгы: җитәкчеләр бу синең эш түгел, ник тотындың, димәс микән, дип шикләнгән. Юкса, үзенә бер тиен дә файда эшләмәгән бит ул.

Аның бу сыйфатлары шәкертләренә дә күчми калмагандыр. Ядкәр: «Илсур абый миңа җитәкче, остаз гына түгел, әти урынына да булды», – дип юкка гына сөйләмидер. Кадрлар мәсьәләсен дә кызык хәл итә торган булган Илсур абый. Беркөнне Ядкәргә: «Менә шундый-шундый техникада эшләргә егетләр кирәк. Безнең якта армиядән кайткан шундыйлар юк микән?» – дигән. «Бар», – ди икән Ядкәр. «Алайса, бар, кайт, шуларны җыеп кил әле!» Ядкәр Түбән-Аты авылыннан гына да 36 егетне алып килгән. Яхшы эшләгәннәр егетләр. Аларны яратып, «восьмой мартлар» дип йөрткәннәр. Түбән-Аты «8 Март» колхозына керә иде. Гомумән алганда, трассада эшләүче татарларга үпкәләүчеләр дә булган. Чөнки Шәйхетдинов егетләре социалистик ярышта катнашып, планны вакытыннан алда үтәп баралар. Хохол егетләре: «Әй, сез – татарлар, кая шулай ашыгасыз? Вакыт сузсагыз, без монда тагын күпме акча эшли алган булыр идек», – дип әйткәли торган булганнар.

## Алгы сызыкта

Язмыш Илсур абыйга заманны узып эшләргә кушкан, ахрысы. Арча егете салган нефть-газ торбалары Көнбатыш Себердән башлап, Көнбатыш Европага хәтле барып җитә.

1980 нче елларда Төмәндә, Пермьдә, Татарстанда, Мәскәүдә чыккан кайсы гына газетаны алып карама, анда Илсур Шәйхетдинов турындагы язмаларга юлыгасың.

Совет бишьеллыклары. Ул чакта «Социалистик ярыш» дигән сүзләр еш яңгырый. Әнә шул елларда Шәйхетдинов егетләре бишьеллыкны вакытыннан алда үтәү өчен социалистик ярышка кушылалар. Алай гына да түгел, Илсур абый әлеге ярышларны оештыруны башлап йөри. Тәүлеккә нормада каралган 70 метр урынына, аның егетләре җир куенына 100-120 метр торба сала. XI бишьеллыкта Ужгород юнәлешендә 820 чакрым арага торба сузып, рекорд куялар. Трассада Илсур абыйның бертуганнары Нияз, Азат, Илгиз һәм улы Илдус белән Зөфәр дә эшли. Дания апаны исә мин тыл батыры дип атар идем. Иренең хезмәт җиңүләрендә аның өлеше бик зур. Бер газетада Шәйхетдиновларның трассада хезмәт стажы 170 ел дип язылган иде.

Илне газлы итү өчен бу хәтле хезмәт куйган тагын бер гаилә бар микән? Юктыр, ишеткән булыр идек. Дания апа: «Илсурыма икенче мәртәбә герой исеме бирмәкчеләр иде», – ди. Илсур абый һәрвакыттагыча тыйнак кына итеп: «Ярар, ул хакта сөйләп торма инде», – дип куя.

Ә бит икенче тапкыр герой исеме бирергә документлар чыннан да әзерләнгән булган. Алтын йолдызны «Октябрь революциясе ордены»на алыштырганнар. Гөнаһына керәсе килми. Әмма Илсур абый катнашкан «газ эпопеясында» Герой исеме алганнар да бармак белән генә санарлык. Шуңа күрә татар егетен икенче мәртәбә герой итмәүдә милли сәясәт тә катышмаган микән, дим.

Минем бу язмамны Геройны «беркем санамаганнар» укымас. Укыганнар башкаларга сөйләсен. Без ТАССРның оешуына 100 ел тулуны бәйрәм итәргә әзерләнәбез. Шул 100нең 50 елын Илсур абый илгә, Татарстан халкына хезмәт иткән. Ул – үз хезмәте белән тарих язган кеше. Үзенә бернинди игътибар да, бүләк тә сорамый. Тыл батыры – Дания апа, кызы Гөлчәчәк белән банктан кредит алып үзе салган йортта матур гына гомер кичерә. Тарихны онытмыйбыз, дибез икән, димәк, без Социалистик Хезмәт Герое, ике мәртәбә Ленин һәм «Октябрь революциясе» орденнары белән бүләкләнгән Илсур абыйны, аның гаиләсен дә зурларга тиеш.

**Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ**

# ӨМЕТ-ХЫЯЛЛАРГА ЮЛ АЧЫЛГАН ЧАКЛАР БАР ИДЕ

Борын-борын заманнардан бирле аерым һөнәр ияләре бер тирәдәрәк яшәргә, бергә булырга тырышкан. Ул бердәмлек аларга үз һөнәрләренең серләрен бергә-бергә камилләштерергә дә, җитештерелгән әйберләрен үзара бәяләп, товарга әйләндерергә дә ярдәм иткән. Борынгы шәһәр тирәләрендә тикшерү эшләрен башкарган археологлар безгә әледән-әле: бу торак урынының фәлән өлешендә зәркәнчеләр, икенче бер өлешендә күнчеләр, өченче урында корал ясаучы тимерчеләр яшәгән, дип хәбәр итеп торалар.

Ә менә каләм осталары арасында элек андый артельләр оешмаган. Язучы һөнәре, башка кәсепләрдән аермалы буларак, ялгызлыкны, япа-ялгыз калып, иҗади хыялга бирелүне таләп итә. Әмма шул ук вакытта бит аңа, үз хөҗрәсенә бикләнеп, тыныч кына иҗат итеп ятсын өчен, андый шартларны тудыручылар да кирәк булган. Совет чоры әдибе бит алпавытлар заманындагы Пушкин да, Толстой да түгел. Ярый ла аларның көнкүрешен йөзләгән крепостной крәстиян тәэмин итеп торган...

Совет хакимияте хөкем сөрә башлаган егерменче елларда әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнгән Александр Серафимович, Алексей Толстой, Максим Горький кебек күренекле шәхесләр, көндәлек эш хакы алмыйча, киләчәк гонорар исәбенә өмет итеп кенә яшәгән язучыларның тормыш шартын җайга салуны күздә тотып, аерым берләшмә булдыру фикеренә киләләр. Шул фикерне Совет хакимияте җитәкчеләренә җиткерәләр. Һәм 1932 елда шул хакта партия Үзәк Комитеты махсус карар чыгара. Әлбәттә, бу очракта партия җитәкчеләренең үз мәнфәгатенә яраклы үз нияте дә була – иҗат кешеләрен бергә туплап, бер кысада тоту мөмкинлеге. Шул рәвешле СССР Язучылар берлеген оештыру карары кабул ителә. (Соңрак башка иҗат оешмалары да берләшмәләргә берләштерелә.)

Татарстанда да язучыларның бердәм оешмасын нигезләү комиссиясе төзелә. Аның җитәкчеләре итеп, ул вакытта Татарстан китап нәшриятында баш редактор вазифасын үтәгән Галимҗан Нигъмәти, «Кызыл Татарстан» газетасы редакторы Гаяз Ризванов (рәис) билгеләнәләр. Казанда урнашкан Татар-башкорт хәрби мәктәбе комиссары, 1926-1933 елларда татар телендә нәшер ителгән «Кызылармеец» газетасының җаваплы редакторы булган Кави Нәҗми дә шул комиссиянең актив бер вәкиле санала. 1934 елның 25-29 июль көннәрендә безнең төбәк язучыларының беренче корылтае уздырыла. Әлеге комиссия анда Язучылар берлегенә 26 кешене әгъза, 9 кешене кандидат буларак кабул итү тәкъдиме белән чыга. Корылтай ул исемлекне хуплый. Халык шагыйре Равил Фәйзуллинның «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» (2004) китабында хәбәр ителгәнчә, кандидатлар исемлегендә Ш.Усманов, Т.Гыйззәт, А.Шамов, Н.Баян, Ә.Ерикәй, Р.Ишморат кебек ярыйсы ук актив иҗат итүче яшьрәк буын шәхесләре теркәлгән. Кемнәндер ишетүемчә, Шәйхи Маннур да баштарак шул кандидатлар исемлегендә йөри. Шулай дип аталуга карамастан, аларның язучылык стажы да, матди ярдәм күрсәтүче Литфонд оешмасына тулы хокуклы әгъза булып кабул ителү вакыты да 1нче съезд үткән көннән саналган. Язучыларны оешмага кандидат буларак кабул итү тәртибе 1958 елда – РСФСР Язучылар берлеген оештыру съездында бетерелә. Шул карарга чаклы безнең оешмада иң соңгы булып кабул ителгән кандидатлар Мәхмүт Хөсәен белән Рәйсә Ишморатова иде. Аларны тулы канлы әгъза итеп теркәү «барыбер барлык мөмкинлекләрдән дә тигез файдаланалар» дигән сылтау белән җитмешенче еллар урталарынача сузылды.

Шул ук вакытта без 1нче корылтайда идарәгә сайланган 9 кешедән икесен – Вадим Краснов белән Кәшшаф Төхфәтуллинны белмибез диярлек. Краснов инде, башка

милләт вәкиле буларак, соңрак үз республикасына күчеп киткәндер. Ул корылтайдан соңгы идарә утырышында оешма җитәкчесе – Язучылар берлегенең җаваплы секретаре итеп Кави Нәҗми, эш башкаручы сәркатип буларак К.Төхфәтуллин сайлана. Беренче идарәчеләр исемлегенә тагын К.Тинчурин, Г.Гали, Х.Туфан, Г.Ризванов, Л.Гыйльми, Г.Толымбайскийлар кергән. Шул ук елның август аенда уздырылган СССР Язучылар союзының беренче съездында безнең оешмадан 12 делегат һәм шул чамада ук кунак катнаша. Ул зур корылтайда татар әдәбиятына багышлы ике нотык тыңлана (К.Нәҗми, К.Тинчурин). Корылтайда төп докладчы булган Максим Горький да татар әдәбияты вәкилләре уңышларын аерым билгеләп үтә.

Еш кына безнең кайбер истәлек язмаларында «фәлән язучы фәлән съездда, фәләне фәләненчесендә язучылар берлеге җитәкчесе буларак сайланган», дип, хата язалар. 1989 елда узган XI нче съездга чаклы бер генә җаваплы секретарь да, бер генә рәис тә корылтай барышында аерым бюллетень белән сайланмады. Элеккеге берлек җитәкчеләренең барысы да корылтай барышында яшерен тавыш биреп сайланган идарә әгъзалары булды. Ә идарәнең беренче утырышында исә идарәгә керүчеләрнең берсен баш итеп сайлап куярлар иде.

1968 елның март урталары, 7нче съезд ачылырга бер-ике көн калган чак. «Өлкә комитетының яңа секретаре Морзаһит Вәлиев Сибгат ага Хәкимне рәислеккә күндергән икән», – дигән хәбәр булды. Шул чорда Литфонд директоры вазифасын үтәгәнлектән, ул корылтайның оештыру эшләрендә үзем дә актив катнаштым. Шуңа күрә ул вакыйгаларны яхшы хәтерлим. Сибгат ага – 1960 елда ук Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булган шәхес. Ил күләмендә танылып килүче шагыйрь. РСФСР Язучылар берлегендә штаттан тыш секретарь булып, җитәкчелек тәҗрибәсе алган зат. Шуңа күрә аның чираттагы рәислеккә сайланасын күпләр хуп күргән иде. Өстәвенә, партия өлкә комитеты җитәкчелеге белән дә элемтәсе әйбәт икән. Рәислеккә аның сайланасын хуплаучылар күпчелек иде кебек. Корылтайдан соң уздырылган идарә утырышында Сибгат аганың җитәкче булудан баш тартканлыгы беленде. Берлек рәисе итеп, икенче кандидат, урындагы партия оешмасының шул еллардагы актив вәкиле Ибраһим ага Гази сайланды. (Әйтергә кирәк, шуннан соң килгән рәисләрдән Туфан Миңнуллин белән Ринат Мөхәммәдиев тә әүвәл партия оешмасы секретаре вазифасын үтәгән шәхесләр булдылар. Ягъни кешеләр белән эшләү тәҗрибәсе туплаган затлар.)

Татарстанда Язучылар берлегенең 2нче корылтае 1950 елның июнь аенда уздырыла. Бу ике корылтай арасында оешмада бик күп үзгәрешләр була. Шул еллар аралыгында оешманы җитәкләүчеләр саны да уннан артып китә. Ул вазифага баштарак идарәгә сайланган язучыларны гына куярга тырышсалар да, соңрак ул тәртип тә үзгәртелә. Мәсәлән, 1937 елда Кави Нәҗми кулга алынгач, ул вазифаны берничәшәр айлап кына Ләбиб Гыйльми белән Мирсәй Әмир башкарган. 1938 елда тутырылган, Литфонд оешмасы вәкиле Шәйхи Маннур кул куйган бер протоколда күрсәтелгәнчә, язучылар оешмасында торучылар саны бермә-бер кимегән чор ул. Кемнәрдер кулга алынган, икенчеләре исә булачак сугыш вакыйгаларына бәйле хезмәткә җәлеп ителгән була. Шул елның ахырында Язучылар берлегенең яңа җитәкчесе итеп Муса Җәлил билгеләнә. Бер үк вакытта ул Опера театрында да үз эшен элеккечә башкарып килә. Язучылар берлегендә аның ярдәмчесе вазифасын башкару эше Афзал Шамовка йөкләнә. Алар икесе дә 1нче съездда идарәгә сайланмаган кешеләр. А.Шамов бер үк вакытта китап нәшриятында Матур әдәбият секторы мөхәррире вазифасын да үтәгән. Муса Җәлилнең 1940 елның декабренә чаклы эшләү дәверендә берлектә рәсми теркәлгән язучы саны бермә-бер арта диярлек. Актив җәмәгать эшлеклесе буларак, ул Язучылар берлегенең абруен күтәрә. Муса эшләгән чорда берлеккә егермегә якын язучы әгъза буларак кабул ителә. Шул елларда язучы таныклыгы алучылар исемлегендә Н.Исәнбәт, Ә.Исхак, А.Алиш, М.Әблиев, Г.Кутуй, Гариф Галиев, Н.Дәүли, Г.Хуҗи, А.Әхмәт, Х.Госман, З.Солтан, С.Урайский, Г.Халит кебек шәхесләр бар. 1958 елга кадәр, РСФСР Язучылар берлеге барлыкка килгәнче, безнең оешма вәкилләрен берлеккә кабул итү турыдан-туры СССР Язучылар союзында башкарылган. Муса Җәлил элек, Мәскәү Язучылар оешмасының татарча язучылар секциясе җитәкчеләреннән берсе буларак, СССР оешмасы башлыклары белән дә якын элемтәдә торган. Чөнки Мәскәү оешмасы белән

СССР Язучылар оешмасы җитәкчеләре бер бинада эшлиләр. Ул еллардагы СССР Язучылар берлеге рәисе Александр Фадеев белән Муса таныш булган. Менә шул хәлләр инде аның Казанда бик тә уңышлы эшләвенә нык ярдәм итә. Шушы ук елларда ул шәхсән үзен һәм иҗатын югары бәяләгән, Оренбургта яшәү чорында ук беркадәр якыннан аралашкан олуг язучы Шәриф Камалны, иҗатының 30 еллыгын билгеләү тантанасы көннәренә атап, Ленин ордены белән бүләкләү эшен дә башлап җибәрә. (Минем архив кәгазьләре арасында Ш.Камалга шушы орденны бирү кирәклеген дәлилләп тутырылган бер язма караламасы саклана иде. Ул М.Җәлил тарафыннан язылган, култамгасы да бар.)

Бу чор вакыйгаларына озаклабрак тукталуымның сәбәбе шунда ки, моннан соң инде язучыларны берлеккә кабул итү тәртибе нык үзгәрә. Сугыш елларында ул сан табигый рәвештә күп була алмый. Ә инде сугыштан соң, бигрәк тә 1958-1990 еллар аралыгында, аларны җиз иләктән үткәреп кенә кабул итә башлыйлар. Чөнки элекке ике оешма, ике Союз арасында РСФСР Язучылар берлеге дә калкып чыга, хәл катлаулана. РСФСР Язучылар берләшмәсе бер ара безнең оешмадан елына 3-4тән дә артык кешене кабул итмәү тәртибен куйган иде. Һәм ул тәртип СССР таркалган дәвергәчә сакланды.

***

ВКП(б) Үзәк Комитетының 1932 елгы «О перестройке литературно-художественных организаций» дип исемләнгән карарының иң зур әһәмияте шунда ки, аның нигезендә язучыларның көндәлек тормышын кайгырту кирәклеге дә искә алынган була. Һәм СССР Язучыларының 1нче съездында ук язучыларга һәм гаиләләренә яшәү шартларын яхшырту өчен аерым вакыф-фонд оештыру кирәклеге дә карала. Корылтайга чыгарылганчы ук инде ул тәкъдим-карарлар тиешле дәүләт оешмаларында тикшерелгән була. Һәм шул нигездә СССР Язучылар берлегенең уставы белән бергә раслана. Ягъни булачак Әдәби фонд оешмасының төп керем нигезләре һәм чыгым юнәлешләре билгеләнә. Ул фондтан куллану инструкциясе эшләнә.

Бүгенге ярым капитализм, ярым феодализм чорына кереп баручы каләм әһелләренең исенә төшерү өчен генә булса да, ул уставта һәм кулланма өстәмәдә теркәлгән кайбер пунктларга күз төшереп үтәсе килә. Шуларның 1нче пунктында язылган сүзләргә тукталыйк (тулы дөреслек өчен русча вариантын китерәм): *«На основании Устава, утверждённого правительством СССР, Литфонд СССР оказывает своим членам и их семьям материально-бытовую и иную помощь».* Шуннан соң инде кемгә һәм нинди ярдәмнәр тиешлеге санап чыгыла. Анда гаиләләргә фатир шартларын яхшыртуга булышлык итү, авырып киткән язучыга яисә аның карамагында яшәгән гаилә вәкиленә медицина ярдәме күрсәтүдә булышу, хезмәт хакы алып эшләмәгән язучыга авырган көннәре өчен күпмедер күләмдә акча түләү, иҗат барышында ниндидер мәгълүматны ачыкларга кирәк булган очракта иҗади командировкалар оештыру, сәламәтлекне саклау өчен санаторийларга юлламалар алу, елына бер-ике мәртәбә махсус иҗат йортларына барып эшләү мөмкинлекләрен тудыру кебек чаралар каралган. Күләмле әсәр иҗат итәргә керешкән язучыга вакытлыча ссуда алып тору мөмкинлеге дә тудырылган. Шул исәптән вафат булган язучы гаиләсенә беркадәр ярдәм итү һәм башлап язучыларга акчалата өлеш чыгару пунктлары да бар иде.

Ягъни Язучылар берлеге карамагында оештырылган әлеге Әдәби фондның төп бурычы язучының тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту, сәламәтлеген саклау, иҗат итү мөмкинлекләрен тудыру һәм иҗтимагый-сәяси вә иҗади белемен үстерүгә булышлык итәрдәй чаралар күрү булды. Язучылар оешмалары карамагындагы клублар, шул исәптән Мәскәүдәге атаклы Үзәк язучылар йорты («ЦДЛ»), китапханәләр, М.Горький исемендәге әдәбият институты (Мәскәү), аның карамагында эшләүче Ике еллык югары әдәби курслар, даими рәвештә үткәрелеп килә торган төрле-төрле айлык әдәби конференцияләр яки бер һәм ике еллык семинарлар, курслар – Совет хакимияте елларында барысы да шул Әдәбият фонды кереме исәбенә яшәделәр. Сугыштан соңгы елларда шул ук фонд исәбенә СССР Язучылар берлеге карамагында махсус комиссия оештырыла. Аның төп максаты чит илләрдәге язучылар оешмалары белән арадашлык элемтәләрен җайлау һәм чит илләргә командировкалар оештыру була. Безнең



*Г.Тукай исемендәге клубта язучылар җыелышы. 1985 ел.*

оешма вәкилләреннән дә кайберәүләр шул комиссиянең матди ярдәме белән чит-ят дөньяларны күреп кайткаладылар. Ш.Маннур, С.Хәким, Р.Мостафин, Әминә һәм Чулпан Җәлиловалар берничә мәртәбә Берлинда булдылар. Күргән-белгәннәрен Муса Җәлилгә багышланган әсәрләрендә яисә истәлекләрендә кулландылар. Г.Минский, З.Мансуров, Р.Кутуй һәм аның әнисе Галимә апа Польшага ике-өч мәртәбә барып, Гадел Кутуй каберенә чәчәкләр салды. «Сызгыра торган уклар» романын язар алдыннан Нурихан Фәттах Монголиягә барды, анда бер ай чамасы йөреп, ерак бабаларыбыз яшәгән урыннарны күреп кайтты.

Язучылар берлеге оешуның беренче көннәреннән үк бөтен ил күләмендә төрле-төрле иҗат йортлары ачыла. Анда һәр язучыга яисә гаиләсенә аерым бүлмә бирелә, иҗади эш белән шөгыльләнү һәм ял итү мөмкинлекләре тудырыла. Медицина ярдәме оештырыла. Олырак яшьтәгеләр яисә сырхаулабрак йөрүче язучылар өчен табиблар даими күзәтеп торырдай махсус берничә иҗат йорты да бар иде. Безнең язучылар шуларның Мәскәү тирәсендәге «Малеевка» яисә Латвиядә Балтыйк диңгезе буендагы «Дубулты» дигәннәрен аеруча ошата иде. Г.Бәширов, Х.Туфан, Ә.Еники, А.Гыйләҗев һ.б. кайберәүләр кыш айларында нәкъ шундый иҗат йортларында эшләү безгә килешә, дип әйтерләр иде.

Сугышка чаклы Татарстанда да уналты язучыга исәпләнгән иҗат йорты эшләп алган. Аның элекке директоры Лихтентул фамилияле абзый белән миңа Мәскәүдә берничә мәртәбә очрашырга туры килде. 1960-1970 елларда ул СССР Язучылар оешмасында комендант вазифасын үти иде. Ул иҗат йорты безнең Тәтеш шәһәре янәшәсендәге алпавыт Молоствовлар утарында оештырылган була. Сугыш башлангач, 1941 елның көзендә, анда яралыларны савыктыру бүлеге ачыла. Сугыштан соң әлеге иҗат йорты эшләми. Безнең язучылардан ул иҗат йортында Ә.Исхак, М.Садрилар берәр ай чамасы торып, иҗат белән шөгыльләнгән. Мөхәммәт аганың андагы тәртипне һәм ашау-эчүнең муллыгын искә алып сөйләгәне дә булды. Анда төрле республика һәм өлкәләрдән дә язучылар кабул ителгән, Иделгә якын урында урнашкан ул иҗат йортына килүчеләр күп булган.

Литфонд нинди керем исәбенә яшәде соң? Әйе, бу фондка тупланасы акча язучыларның «иҗат җимеше»н, ягъни язган әсәрләрен товарга әйләндерүче оешмалар – китап нәшриятлары, газета-журнал редакцияләре, театрлар, концерт заллары исәбенә тулыландырылды. Аларның кеременең бер өлеше исәбенә яшәде ул оешма.

Нәшриятлар керемнең ун процент чамасын, концерт заллары һәм театрлар исә 2-2,5 процент чамасын түләп тордылар. Ул керемнең билгеле бер өлеше шулай ук күптәннән вафат булган классик әдипләрнең әсәрләрен кат-кат чыгарудан да керә

иде. Шуңа күрә нәшриятлар элек андый әсәрләрне даими рәвештә нәшер итәргә тырыштылар.

Хәзер капитализм заманына кире кайткач, инде без андый фонд тотудан мәхрүм ителдек. Шул ук фонд исәбенә элекке елларда язучылар каберенә истәлек ташы кую өчен дә күпмедер күләмдә акча бүлеп бирелде. Шул заман өчен ул бик аз да түгел иде. 400-500 сумнан артмаган кабер ташын кую карарын урындагы Язучылар берлеге идарәсе хәл итә, 1000 сум тирәсенә җиткәннәренә Мәскәү рөхсәт бирә иде. Мин белгән дәвердә бездә СССР Язучылар берлеге идарәсе карары белән андый ике кабер ташы куелды: Казандагы Архангель зиратында Галимҗан Ибраһимов кабере дип чамаланган урында һәм Алабуга шәһәрендә Марина Цветаева каберенә. Соңгы кабер ташын кую рөхсәтен безнең идарә сорамаган иде. Аны куярга безгә Мәскәү үзе кушты.

Фатир белән тәэмин ителү мәсьәләләренә дә бераз тукталып үтик. Литфонд оешмасы тернәкләнә төшкәч, илленче еллардан башлап, турыдан-туры сугыш афәтен кичермәгән төбәк оешмаларына да фатир булдыру өчен акча бүленеп бирелә башлый. Белүемчә, Татарстан Язучылар оешмасына күпмедер күләмдә шул максатка каралган акча 1950 еллар ахырында бүлеп бирелә. Гомәр ага Бәширов Язучылар берлеге рәисе вазифасын үтәгән һәм берүк вакытта СССР Язучылар берлеге секретаре булып торган елларда була бу хәл. Литфонд акчасы һәм 1957 елда Мәскәүдә узачак татар мәдәнияте декадасы көннәренә бәйле рәвештә, Татарстан хөкүмәте карары белән шул ук максатка бүлеп бирелгән акча исәбенә 1959 елда 8 язучы Маяковский урамында төзелгән яңа йорттан яхшы фатирлар ала. Заманасы өчен бик затлы саналган ул йортта өй туйлары үткәрүчеләр исемлегендә Г.Бәширов, М.Әмир, А.Шамов, Х.Туфан, Г.Әпсәләмов, Ф.Хөсни, Ә.Исхак, Т.Журавлёв гаиләләре теркәлгән.

Литфонд оешмасының Татарстан бүлеге 1934 елдан эшли. Бүлекчәнең Хәсән Сарьянга чаклы (1964-65) эшләгән җитәкчеләренең Мәскәү оешмасы белән элемтәсе чамалы була. 1965 елда Х.Сарьян Мәскәү таләп иткән документларны һәм Язучылар берлеге рәисе, РСФСР Югары советы рәисе урынбасары Мирсәй Әмир язган үтенеч хатын Литфондка тапшырып, фатирлар булдыру өчен тагын күпмедер акча алуга ирешә. Казан шәһәре башкарма комитеты счётына ул акча 1966 елда ук кергән булса да, элекке бүлекчә директорының эштән китүе, аны алыштырган М.Шәрифуллинның шул елда ук авырып вафат булуы сәбәпле, ул фатирларның очына чыгучы булмый. Ул эш минем өлешкә калган иде. Литфонд бүлекчәсе директоры вазифаларын мин 1967нең апреленнән алып 1983нең апреленә чаклы башкардым. Һәм шул чорда Әдәби фонд исәбенә алынган фатирлар да шәһәр башкарма комитеты карамагына элек күчерелгән акчаларның эзенә төшүдән башланды. Элек шәһәр башкарма комитетына буйсынган бер оешмада эшләгәнлектән, аның план, төзелеш бүлекләре, фатирларның исәп-хисабын алып баручы оешма кешеләре белән бераз танышлык та бар иде. Шул сәбәпле миңа һәр ике ел саен диярлек Мәскәү фонды таләп иткән ундүртәр имзалы, ундүрт мөһерле документларны тутырып, илтеп бирү бер гадәткә әйләнде. Язучылар берлеге рәисләре И.Гази, З.Нури, Г.Ахуновларның да тырышлыгы белән безнең оешма әлеге еллар аралыгында язучыларыбызга йөзләп фатир алуга иреште. Билгеле, алынган фатирларның барысы да яңа түгел иде. 1948 елда И.Сталин кул куйган указга нигезләнеп, без язучы гаиләләреннән бушаган «иске» фатирларны да кабат үзебездә калдыра алдык. Литфонд вәкилләре ул указның күчермәсен миңа СССР Язучылары идарәсе архивыннан табып биргәннәр иде.

Язучыларга фатирлар алу өчен СССР Литфонды тарафыннан безнең оешмага бүлеп бирелгән соңгы акча 1983 елга карый. Минем соңгы мәртәбә йөреп алган хезмәт җимеше. Шуннан соң бездә андый мәшәкатьле эш белән шөгыльләнүче булмады. Дөрес, Туфан Миңнуллин рәис булган дәвердә СССР Литфонды безгә Васильево шифаханәсе биләмәсендә бер иске йортны сатып алу өчен шактый зур суммада акча бүлеп биргән иде. Ләкин андый йорт сатып алынмыйча калды. Оешмабыз «үз санаториен» булдыра алмады. Бу мәсьәлә Г.Ахунов Язучылар берлеге идарәсе рәисе һәм СССР Югары Советы депутаты булган елларда ук кузгатылган иде. Без аның белән Васильевога барып, баш табиб Цыпленков белән киләчәктә сүтелергә билгеләнгән берничә йортны карап та йөргән идек. Ләкин мин эшләгәндә ул эшне башкарып чыгып

булмады. Бездән соң эшләүчеләр дә аның очына чыга алмады. Элек без карап, сайлап йөргән ул бер катлы биналарның берсендә хәзер Г.Камал театры артистлары өчен дип алынган ял йорты эшли.

Кайбер каләмдәшләр миннән: «Нишләп пенсия яшенә җитмичә, Литфонд оешмасыннан киттең?» – дип сорыйлар. Әдәбият институты карамагындагы Ике еллык әдәби курсларга безнең оешмадан ике елга бер мәртәбә бер-ике кеше кабул ителә иде. 1983 тә шул курсларны Ризван Хәмид тәмамлап кайтасы, алмашка башка кешеләр җибәреләсе иде. Минем күңелдә дә шунда барып уку хыялы яшәде. Язучылар берлеге миңа шул курсларга керү өчен юллама бирде. Үз гаризам белән бергә мин аны Мәскәүгә илтеп тапшырдым. Дөресрәге, ректоратка без аны Ризван белән бергә кертеп бирдек. Ә август ахырларында тегеннән хат килә: сезгә 50 яшь тулып, фәлән ай киткән. Без 50 яшькәчә генә кабул итәбез, диелгән. Хыялым чәлпәрәмә килсә дә, артык борчылмадым – гаиләм, ике балам янында калуны барыбыз да хупладык...

* * *

Язучылар берлеге карамагында соңлабрак оешкан тагын бер бүлекчә хакында әйтмичә үтү мөмкин түгел. «Пропаганда бюросы» исеме белән аталган ул оешма да заманында бик тә кирәкле эшләр башкарды. Аның төп бурычы әдәбиятны халык күңеленә якынайту чараларын күрүдән гыйбарәт иде. Әдәбият сөючеләр белән очрашулар-кичәләр оештыру, язучыларны мәктәпләргә алып бару, мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында әдәби бәйгеләр уздыру кебек эшләрне башкарырга тиеш иде ул бюро. Мәктәпләрдәге очрашулардан кала барлык чаралар да түләүле булганлыктан, язучылар белән бергә ул очрашуларда кайбер артистлар һәм композиторлар да бик теләп катнашалар иде. Бигрәк тә яшьрәк буын иҗат вәкилләрен ул чараларда катнашуның түләүле булуы да кызыктыра иде, билгеле. Һәр яз саен шәһәр күләмендә, шәһәрдә урнашкан күпчелек завод-фабрикаларда «Әдәби Казан язлары» бәйрәмен уздыру гадәткә кергән иде. Авыл һәм районнарда андый очрашулар ел дәвамында үткәрелеп килде. Күрше республикаларда яшәүче милләттәшләр белән аралашу чаралары да үткәрелә иде.

Хәтерем ялгышмаса, ул бюро бездә рәсми рәвештә 1967 ел башында оешты шикелле. 1967 елда мин Язучылар берлегендә эшли башлаганда, аның җитәкчесе Туфан Миңнуллин иде. Ләкин шул көздә үк ул аннан китте. Аңардан соң бу вазифаны ярты ел чамасы Гөлшат Зәйнашева башкарып торды. Ә 1968 елның урталарыннан башлап, анда биш-алтышар еллап бюро директоры вазифасын үтәргә алынган кешеләр килде: шагыйрь Мөнип Газар-Шәймөхәммәтев, шагыйрьлеген күпертеп күрсәтергә яратмаган Эльс Гаделев, шагыйрь Хәкимҗан Халиков. Бюро штаты өч кешедән тора иде: директор, әдәби хезмәткәр һәм бухгалтер. Соңгы вазифаны алыштыргысыз рәвештә 20 ел чамасы Дания Хәмидуллина башкарды. Ә менә әдәби хезмәткәрләр шактый еш алышынып тордылар. Озаграк эшләп, хәтердә калганнары Фәннүр Сафин, Мансур Шиһапов, Нурислам Хәсәнов, Марсель Галиев. Нәкъ алар һәм директорлары – төркем-төркем язучыларны ияртеп заводтан-заводка, районнан-районга, авылдан-авылга йөртүчеләр. Ә Марсель Галиев тагын «Әдәби Казан язлары»н оста оештыручы буларак та танылды. Совет хакимияте тәртипләре юкка чыгарга биш-алты ел кала чын-чынлап эш күрсәткән ул бюроның соңгы директоры язучы Рәфкать Кәрами булды.

Совет хакимияте дәверендә татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырып, зур уңышларга ирешкән иҗат әһелләребез ишле. Күңел түрендә балкып истә калучылардан мин бүген Һ.Такташ, М.Җәлил, Ш.Камал, Н.Исәнбәт, К.Нәҗми, Т.Гыйззәт, М.Әмир, Г.Бәширов, А.Шамов, И.Гази, Ә.Еники, Ф.Хөсни, С.Хәким, З.Нури, Г.Ахунов, Н.Фәттах, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Т.Миңнуллин, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Р.Гаташ, Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, Г.Рәхим һ.б. бик күп исемнәрне атап үтәр идем. Гәрәй Рәхим, Данил Салихов, Ләбиб Лероннарның Россия капитализмы чорына кергәч тә, Литфонд оешмасының Татарстан бүлеген торгызырга тырышып йөргәннәрен хәтерлим. Ләкин әлегә андый уңышка ирешелмәде. Бәлки киләчәктә элеккеге Литфондка тартымрак бер оешманы киләчәк буын вәкилләре тормышка ашыра алыр дигән өметтә калам.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

# УЙЛЫ СӘГАТЬЛӘРНЕ КАЙТАРГАН ШАГЫЙРЬ

Газинур… Бергәләп карлы-буранлы, яңгырлы-давыллы көннәрдә район үзәгеннән ерактагы юлсыз авыллардан Кукмарадагы «Салават күпере» иҗат берләшмәсенә йөрсәк тә, Газинурны чын-чынлап Ләис Зөлкарнәй Арча педучилищесында оештырган очрашудан белә башладым.

Ул вакытта Газинурның әдәбиятны яхшы белүенә гаҗәпләнгән идем. Тегене сөйли, моны. Хәзер менә аңлыйм: ул университетны тәмамлау алдында торган. Бар төр әдәбиятны укырга өлгергән иде. Бәяләгән, сайлаган, күңеленә якын шагыйрьләрне бер боҗрага туплаган. Бүген менә аның язганнарын шул боҗра эчендәге иң бөек затларның берсе Тукайныкылар янәшәсенә куеп карарга телим.

Бөтен җаны-тәне белән милләтен кайгыртып яшәгән Газинур Моратны Тукайга бик күп сыйфатлар якынайта. Бердән, иҗтимагый активлык: заманның, татар дөньясының актуаль мәсьәләләренә, әдәбият-сәнгать проблемаларына багышланган тәнкыйди һәм публицистик мәкаләләре көндәлек матбугатта даими басылып тора, ул сәяси көрәш мәйданнарына атылудан курыкмый; икенчедән, аның шигърияте тормыш фактларына нигезләнә, язганнары үз чорының иҗтимагый-сәяси энциклопедиясе рәвешен ала; отышлы сайланган сәнгать чаралары аркасында, бик күп әсәрләре иҗтимагый яңгырашка ия, публицистик аһәңле.

Публицистик аһәңлелеккә Газинур нәкъ менә Тукайдан килгән әдәби алымнар ярдәмендә ирешә дә. Әлеге алымнар җөмлә төзелешендәге үзара охшашлыкларга китерә, аның риторик яңгырашында, каләменең омтылышлы, ашкынып язуында, яшерелгән һәм ачыктан-ачык әйтелгән фикерләрне бергә үрүендә чагылыш таба.

Газинур сиксәненче елгы шигырьләрендә, Вөҗдан, Намус, Матур Яшәү кебек абстракт төшенчәләр белән беррәттән, Тукай, Бруно, Бируни, Хемингуэй кебек тарихта мөһим роль уйнаган, гомумфикергә туры килмәгән караш әйтергә курыкмаучы, гамәлләре белән Явызлыкка, Үзгәрмәс Фикергә каршы чыгучы шәхесләрнең исемнәрен атый. Тукай аның күзаллавында укучы тарафыннан әлеге рухи кыйммәтләрнең Җирдәге гәүдәләнеше кебек кабул ителә.

Г. Морат иҗатында, Тукайдагы кебек, хатын-кызга мәхәббәт темасы артык зур урын алып тормый, әмма бер үк вакытта капма-каршы җенескә мөнәсәбәтен, мәхәббәткә кагылышлы уйларын укучыга ирештерерлек әсәрләре дә шактый.

Газинур Морат кайбер әсәрләрендә остазы Тукай юлыннан китеп, үз халкының язмышын башкалар язмышы, үз иле сәясәтен башка хакимиятләр алып барган гамәлләр аша, узган чорлардан бигрәк, яңа заманнан алынган тарихи фактлардан файдаланып та аңлата. Яңарышлар чорында милли лидер проблемасы әдәбиятка килеп кергәч, Җиргә пәйгамбәрлек миссиясе белән килгән шагыйрь образын тудыру татар әдәбиятында, шул исәптән аның иҗатында да зур урын тота башлый, һәм аның каләме Тукай темасын яңа сулыш белән җанландырып җибәрә, бөек шагыйрьне үз исемнәрен көрәшче сыйфатында тарих битләрендә язып калдырган шәхесләр янәшәсенә куя. Мәсәлән, «Черек күл» шигырендә лирик мин татарның иң зур шәхесләрен, бигрәк тә әдипләрен алып киткән еллар, сәбәпләр турында уйлана һәм үкенеч катыш сөенеч аша ил тарихының иң дәһшәтле елларынача яшәмәгән Тукайга мөнәсәбәтле болай ди:

*«Шигырьгә күчәдер*
*Җанга*
*Сыймаган борчу-кайгың…*
*Ярый әле яд итәргә*
*Кабере бар Тукайның.»*

Г. Морат әсәрләренең Тукай белән бәйләнешлелегенә бихисап мисаллар бар, шулай да милли хәрәкәт көчәеп киткән елларда зур иҗтимагый резонанс алган «Ачлык» поэмасы белән Тукай иҗатында интертекстуаль бәйләнешләр аеруча ачык күренә.

Әлеге әсәрендә автор, Казанны алу вакыйгалары белән беррәттән, Тукай каләме белән тагын да ныграк танылган Кисекбаш, Дию, Камчылы ишаннарны да искә төшерә; Казан урамыннан этләр куган Кисекбашны чит кавемнәр иленнән куарга омтылган татар башына тиңли, ул дигәнегез, минем баш ул, дип белдерә.

Г.Моратның Тукайга кагылышлы әсәрләрендә аерым бер әдәби детальләр кабатланып килә. Боларга Клячкин хастаханәсен, ишан образларын, Печән базарын, аның гайбәтчеләрен һ.б.ларны кертеп карарга булыр иде. «Вакыт машинасы» поэмасының дүртенче бүлегендә Пасха көнендә Клячкин хастаханәсендә татар шагыйре үлү хакында юллар бар. Хәзер инде Ишми ишан кебек дошманнары да истәлек язар, ди автор. Бу урында шунысын да әйтеп узыйк: интернетның «Тукай» порталындагы видеоязмада Г.Морат укуында «Клячкин» шигыре бар.

Гомумән алганда, Газинур иҗатында, бигрәк тә лиро-эпик әсәрләрендә Тукайның тормыш юлы шактый киң чагылыш тапкан, аны хәтта эзлекле рәвештә күздән кичерергә була. Әйтик, аның «Шагыйрьнең кайтуы» исемле балладасында күбәләкләр белән уйнап үскән Апушның зур шагыйрьгә әверелүе, вафаты һәм җанының Клячкин хастаханәсендә ялгыз күбәләк рәвешендә бәргәләнүе тасвирлана.

Газинур Моратның Тукай темасын теге яки бу күләмдә ачкан әсәрләренә «Юк. (Тукайны уйлап)», «Кыш. Болгар чатында»; «Кара базар» һ.б.ларны кертергә була.

Газинур «Яратырга телим» исемле мәхәббәт шигырен *«Бу дөньяда, бу гөнаһлы Җирдә, / Йә, әйтегез, кем мин?»* соравын куеп башлаган. Бу сорауны милләтенә, укучыларына, менә миңа да бирә алыр иде. Мин шунда ук һич ялганламыйча: «Син – зур шагыйрь, милли шагыйрь, иманлы шагыйрь, син безнең күзаллауларда иңли алмаслык байлык, дәрәҗә китергән кәнәфиләрдә бушка кием туздырмыйча, гади халыкның, эш кешесенең кул көче белән туплаган байлыгын үзеңә күчерү уе белән хыялланмыйча, аңа һәр яңа туган көндә акылың, уй-фикерең белән хезмәт итәсең, бүгенгенең күпсанлы чүп әдәбияты да басып китмәслек шигырьләр язасың», – дип әйтәчәкмен.

Тирәннән, тәфсилле өйрәнгәндә, элекке бәяләреңне чәлпәрәмә китергән иҗатлар була, аерым әсәрләреннән чыгып, зур шагыйрьгә санап йөрткәннәрең дә кайвакыт уртакуллар рәтенә төшә дә куя. Газинур Моратның бөтен шигърияте белән ныклы танышлыгы булган бер укучысы, аңа бәяләмәле мәкаләләр дә язучысы сыйфатында әйтәм: укыган саен, язганнарына бәям арта гына!

Замандашым, якташым Газинур Морат (Моратов Газинур Васикъ улы) укучылар күңеленә, беренче чиратта, шагыйрь буларак узса да, ул – танылган публицист, гаҗәеп тоемлы мөхәррир. Кызганыч, миңа шигырь китапларын аның мөхәррирлегендә чыгарырга гына туры килмәде. Дөрес, бу өмет әле тәмам сүрелмәгән.

Газинур бер әсәрендә: *«Зур уңышлар яулап, заманалар / Матур бәя бирсә эшенә, / Шатлыкларын уртаклашыр өчен, / Туган ягы кирәк кешегә»,* – дип яза.

Яшьлек дустым Газинур, синең мине икебез өчен уртак туган якның бер өлеше, җанлы кисәге дип тануыңа ышанам. Бүген 60 яшьлек юбилееңа зур иҗади уңышлар белән килүеңә чиксез сөенәм, шул уңышларның шатлыгын ихлас күңелдән уртаклашам.

Кайчандыр матбугатта бастырган «кытыклар»ыңда «Шагыйрь – ак кәгазь битен намазлык итеп, канатлы сүз-гыйбарәләр дисбесенең асылташ төймәләрен тартып, Күкләр белән сөйләшеп утыручы дәрвиш-мосафир ул»,– дип белдергән идең. Дәрвишләр дә кешеләрдән тәмам аерылып, мәгънәле әңгәмәләр кормыйча яши алмый. Күкләр белән сөйләшүдән арынганда, мине, замандашларыңны эзләп тап һәм кайчандыр сөекләңә дәшкәндәй, үз шигырең белән шушы рәвешчә сүз башла:


*«Күзләреңдә яшьлек яме,*
*Иреннеңдә сөю тәме.*
*Тик көчеңне бары шунда*
*Диеп уйлама, яме.»*

Ул безне хәтта сөю-сөелүгә күмелеп яшәгән көннәрнең дә уйлы сәгатьләренә – милләт, әдәбият, киләчәк хакындагы гамьле әңгәмәләренә кайтарсын, күңелебезне саф саклаткан истәлекләрне яңартсын.

**Рифә РАХМАН**

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ ТУРЫНДА ЯҢА ХЕЗМӘТ*

Россиянең күпгасырлык тарихы шул ук вакытта анда гомер кичерүче халыклар тарихыннан да хасил була. Россия күпмилләтле дәүләте буш урында оешмый, аңарчы төрле дәүләти-сәяси берләшмәләр, шул исәптән Алтын Урда һәм Казан ханлыгы яшәп килә. 2019 елда Россия Федерациясе фәнни җәмәгатьчелегенең Алтын Урданың 750 еллыгын билгеләп үтүе очраклы түгел. Гомумроссия дәүләтчелеге барлыкка килүдә гомумтөрки мирасны, татар мирасын өйрәнү гаять зур әһәмияткә ия.




Россия тарихында үзенең күләме-исәбе (рус халкыннан соң икенче урында булуы) һәм урнашу территориясе, уртак бөек илебезнең дәүләтчелеге, мәдәнияте, икътисады үсешенә керткән өлеше буенча да татар халкы аерым урын били. Татар халкының килеп чыгышында, аның үсешендә, сәяси төзелешендә, милли мәдәнияте формалашуда Алтын Урда һәм аннан соңгы татар ханлыклары төп этапларның берсе булып тора. Алтын Урда һәм Урдадан соң яшәгән татар ханлыклары тарихы Россиянең күп кенә халыклары – башкортлар, кырым татарлары, марилар, мордвалар, нугайлар, руслар, удмуртлар, украиннар, чувашлар һәм башкалар тарихының мөһим өлешен хасил итә. Атаклы рус тарихчысы С.М. Соловьев XVI гасыр уртасында Казан ханлыгының Россия составына кертелүен юкка гына ил тарихының дәвамын күп яктан билгеләгән мөһим вакыйга дип санамады.

Шул ук вакытта, рус елъязмачылары заманнарыннан һәм революциягә кадәрге тарих фәне традицияләреннән килгән гадәт буенча, бүгенгәчә Казан ханлыгы Рус дәүләтенең «дошман»ы буларак карала. Икенче яктан, илебез галимнәре, шул исәптән Татарстан тикшеренүчеләре тарафыннан, Алтын Урдага яки урта гасырлардагы төрки империяләргә караганда, аңа азрак игътибар юнәлтелә, ханлык «караңгы күләгәдә» кала бирә. Шуңа күрә Булат Хәмидуллин үзенең яңа китабында мөрәҗәгать иткән тематика, һичшиксез, Россия тарихы өчен гаять актуаль булып тора.

Б.Хәмидуллинны һич арттырусыз Татарстанда гына түгел, Россиядә дә Казан ханлыгы буенча аз санлы профессиональ белгечләр исәбенә кертергә мөмкин. Ул 25 елдан артык урта гасырлар төркиләренең һәм татар Казан дәүләтенең этносоциаль һәм этносәяси тарихын өйрәнү белән шөгыльләнә. 2002 елда аның «Казан ханлыгы халыклары» монографиясе дөнья күрде, ул Михаил Худяковның 1923 елда басылган «Казан ханлыгы буенча очерклар» хезмәтеннән соң 80 ел чамасы вакыт узгач нәшер ителгән, әлеге дәүләткә махсус багышланган беренче китап булды. Шуннан соң бу тематика буенча аның тарафыннан язылып, 5 китап һәм 100ләп фәнни, фәнни-популяр мәкаләләр бастырып чыгарылды. Ул – Казан ханлыгына багышланып, Зур Россия энциклопедиясе өчен язылган мәкаләләр һәм 7 томлык фундаменталь «Татарлар тарихы»ның 4 нче томында урын алган Казан ханлыгы турындагы бүлек авторы, болар үзләре үк аның әлеге өлкәдә абруе танылуын күрсәтә. Авторның гаҗәеп публицист, тәрҗемәче, ТР Язучылар берлеге әгъзасы булуы нәтиҗәсендә китап матур фәнни-әдәби телдә язылган, рәхәтләнеп укыла. Ул төрле катлау укучылар, ягъни белгеч-галимнәр өчен дә, тарих белән гадәти кызыксынучылар өчен дә аңлаешлы.

Китап 19 мәкалә-очеркны берләштергән өч бүлектән, шулай ук аерым кушымтадан – авторның Казан ханлыгы тарихы буенча басылган хезмәтләре исемлегеннән тора.

Казан ханлыгы хакындагы бәян Алтын Урдага багышланган бүлектән дәвам ала. Әлеге бүлек ике зур очеркны колачлый, аларда Алтын Урда тарихының төп момент-

* Булат Хәмидуллинның «…окаянная дщерь Златой орды…» (Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. - 295 б.) монографиясенә бәяләмә

лары, татарларның этник туплану-берләшүе мәсьәләләре җентекләп карала. Цивилизация яссылыгында Алтын Урда дәверенең барлык ракурслары күрсәтелә. Бу очракта Б.Хәмидуллин илебез һәм чит илләр тарих фәненә мәгълүм чыганакларның гаять киң даирәсен җәлеп итә.

Авторның хаклы рәвештә Алтын Урда дәверен Россия төрки халыклары тарихының аерым бер өлеше буларак кына түгел, тулаем илнең гомуми үткәненең, шулай ук Евразиянең күп кенә дәүләтләре һәм халыклары тарихының аерылгысыз өлеше буларак исәпләвен ассызыклап узасы килә. Б.Хәмидуллин фикеренчә, Алтын Урданың гаять зур мирасы аның күп кенә этнослар, хәзерге вакытта Россиядә һәм аңа чиктәш территорияләрдә яшәүче халыкларның – татарларның, башкортлар, нугайлар, кумыклар, үзбәкләр, казакълар һәм башкаларның шактый өлеше өчен «бишек» булуыннан гыйбарәт. Нәкъ менә Алтын Урда, бергә яшәүнең, мәдәниятләрнең, тормыш рәвешенең һәм менталитетларның үзара якынаюының тәүге тәҗрибәсен биреп, Евразиянең киләчәктә Россия составына кергән төрки, монгол, фин-угор, көнчыгыш славян, Себер, Кавказ һәм башка халыкларын беренче мәртәбә озак вакытлар дәвамында бердәм сәяси һәм икътисади яссылыкта туплады.

Китапның 4 очерктан торган икенче бүлеге Казан ханлыгының бай тарихына, аерым алганда, анда хөкем сөргән этносәяси вазгыятькә багышланган. Бүгенге көндә мәгълүм булган гаять киң чыганаклар даирәсе һәм басылган фәнни хезмәтләр нигезендә автор ханлыкны зур һәм икътисади яктан үскән дәүләт, төбәктә һәм тулай Үзәк Евразиядә структура тәшкил иткән элемент буларак тасвирлый. Автор этносәяси вазгыятьнең төзек концептуаль схемасын төзүгә ирешкән. Әлеге схемада, бер яктан – Казан ханлыгы, анда яшәгән төрки һәм фин-угор халыкларының (аеруча җентекле рәвештә көньяк удмуртлар мисалында) бөтенлекле этносоциаль бергәлеге, икенче яктан, Алтын Урда таркалганнан соң «идарәче Чыңгызыйлар-Җүчиләр нәселе бердәмлеге» нигезендә барлыкка килгән төрки-татар дәүләтләре «йолдызлыгы»ның, «бердәм телле, бердәм динле һәм мәдәниятле дәүләт төзүче халыкның» «йолдызы» буларак карала.

Китапның зур өлешен Казан ханлыгын илебез (революциягә кадәрге Россия, совет, совет чорыннан соң), шул исәптән татар милли тарих фәнендә өйрәнүне яктыртуга багышланган 14 очерктан гыйбарәт өченче бүлек били. Әлеге очеркларда теманы өйрәнү тарихы XV-XVI гасырларда елъязмалар төзү традицияләреннән алып, XXI гасыр башындагы татар тарихчылары хезмәтләренә кадәр дәвам итә, Казан ханлыгын башлап өйрәнүчеләрнең һәм төп тикшеренүчеләрнең карашлары, керткән өлешләре тәфсилле бәян ителә. Очеркларда революциягә кадәрге рус тарих фәненең зур катламы яктыртыла, укучы аның классиклары Н.М.Карамзин, С.М.Соловьев, В.О.Ключевский, Н.И. Костомаров, шулай ук П.И.Рычков, К.Ф.Фукс, Н.К.Баженов, В.В.Вельяминов-Зернов, Г.И.Перетяткович, С.М.Шпилевскийның махсус хезмәтләре, революциягә кадәрге татар галимнәренең Казан ханлыгы тарихына карата карашлары белән танышу мөмкинлегенә ия. Әлеге теманы өйрәнү мәсьәләсендә казанышларга чагыштырмача ярлы совет тарих фәне, бүгенгәчә гавами яктан аз мәгълүм Х.Г.Гыймади һәм Ш.Ф.Мөхәммәдьяров хезмәтләре дә игътибардан читтә калмаган. Хәзерге күпкә баерак татар историографиясенә аерым очерк багышланган. Идел буенда яшәүче башка халыклар вәкилләренең карашлары күренекле чуваш тарихчысы В.Д.Димитриев хезмәтләре яссылыгында күрсәтелә. Башка галимнәрнең Казан ханлыгы тарихына һәм аның эчке төзелеше үзенчәлегенә карата еш кына капма-каршы юнәлешле фикерләренең гаять киң спектрын яктырту барышында авторның укучыга үз бәяләмәләрен көчләп такмавы, укылган материалдан чыгып аның үзенә нәтиҗәләр ясау мөмкинлеген калдыруы игътибарга лаек.

Һичшиксез, Булат Хәмидуллинның әлеге тикшеренүе аның Россия Федерациясе тарихын өйрәнүгә керткән мөһим өлеше булып тора. Китапта Алтын Урда һәм Казан ханлыгы идарәчеләренең, халкының тормышы һәм эшчәнлегенә дәлилле анализ һәм бәя бирү төрле халыклар яшәгән һәм төрле диннәр хөкем сөргән илебездә хәзерге этапта милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне үстерү һәм ныгыту юлында, һичшиксез, әһәмияткә ия.

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*тарих фәннәре докторы*

## *«Төрки әдәбиятлар һәм заман»*

### Кереш сүз

*Совет дәверендә рус әдәбияты кысаларына якынайтылган татар әдәбияты, ул кысалардан арынуга, үзгәрешләр чорына керә. Нәтиҗәдә татар әдәбиятының төрки әдәбиятлар белән якынлыгы елдан-ел ныграк күренә башлый. Аларның бер магистраль юлдан китүе, күрәсең, әдәби-мәдәни традицияләр уртаклыгы белән аңлатыла. Бүгенге төрки телле әдәбиятларда күзәтелә торган аерым бер күренешләр үз әдәбиятыбыздагы хәл-халәтне бәяләүдә ярдәмгә килә ала.*

*Төрки телле авторларны укыганда, аерым әсәрләр бөтенләй үзебезнеке кебек тоела, кайбер очракларда нишләп татар язучылары бу сукмакны күрмәделәр әле, дип тә уйланасың. Шуңа да татар укучысына төрки әдәбиятларны белү, андагы иң күркәм әсәрләр белән таныштырып бару мөһим дип саныйм. Каләм тибрәтә торган яшьләргә исә мондый мәгълүмат татар әдәбиятын үстерү, аның офыкларын киңәйтүдә нигез була алыр дип ышанам.*

*Төрки әдәбиятлардагы заманча күренешләр, иң кызыклы әсәрләр турында сөйләшү – татар әдәбиятының бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшү ул. Әлеге сөйләшү заман әдәбиятына кагылышлы теоретик фикерләр белән уртаклашырга да мөмкинлек бирә.*

# КАМАЛ АБДУЛЛАНЫҢ «СИХЕРЧЕЛӘР ҮЗӘНЛЕГЕ»

Азәрбайҗан әдәбиятының «беренче постмодернисты» Камал Абдулла үзенең өч романы белән дөньякүләм танылa. Беренчесе – «Неполная рукопись» («Тулы булмаган кульъязма») – Европа әдәбиятлары, аерым алганда, Умберто Эко йогынтысында язылган дигән тәэсир уята һәм язучыга без әле генә телгә алган беренчелекне алып килә. Классик (реализм һәм романтизм) әдәбиятны модернизм-постмодернизмнан аеру өчен әсәрдә тергезелгән дөнья сурәтен «гармония – хаос» үлчәвенә салып карау сорала. Тормыш хаос халәтендә тасвирлана икән, бу – модерн яки постмодерн юнәлеше, диләр галимнәр. Үз эчендә модернизм һәм постмодернизмны аеру өчен дә шундый иң мөһим билге бар: постмодернизм әдәбиятында бер текст эчендә берничә авторы булган берничә текст бергә үрелеп урнаша. «Неполная рукопись» шушы таләпләргә җавап бирә. Романда Милли кульъязмалар институтына килеп, XII гасыр кульъязмасын тапкан галим-филологның аны уку тарихы – бер әсәр булса, Баяндур ханның шпион эзләү һәм фарсы шаһы Исмаил Хатаи тарихы Деде Горгуд исеменнән бәян ителә. Аларның башка «авторлары» да бар: беренчесендә – Баяндур хан, фарсы шаһы тарихын билгесез кеше хәтере саклый. Бер-берсе белән үрелеп, бу тарихларга мөстәкыйль тарихлар хасил итәрлек мотивлар урнаша. Ягъни укучы фантазиясе шул мотивларны үз хыялында үстереп, үз «әсәрен», тарихын таба. Шул рәвешле, романда постмодернизмның төп шарты үтәлә: «автор үлеме» концепциясе гамәлгә ашырыла.

Төрки әдәбиятларда постмодернизм күренеше хасил булу «Европа постмодернизмы үрнәге» яки «шәрык постмодернизмы» дигән төшенчәләр формалашуга китерде. Әйтик, Камал Абдулланың без әле генә телгә алган әсәре – Европа әдәбиятлары тибында. Әмма төрки әдәбиятларда постмодернизм күренеше киңрәк җәелгән саен, аның Европа әдәбиятларындагы әсәрләрдән аермасы ныграк күзгә ташлана бара. Нәтиҗәдә башта төрки әдәбиятларда модернизм һәм постмодернизмның үзенчәлекле булуы, барлык сыйфатлар да сакланмау турында фикер әйтелә. Хәзер бу күренешне «йомшак постмодернизм» («мягкий постмодернизм») дип атау фәнни әйләнешкә кереп килә. Безнең бүгенге сөйләшүебез дә шушы күренешнең иң матур үрнәкләреннән булган әсәр – Камал Абдулланың язучы үзе роман-фантазия дип атаган «Долина кудесников» («Сихерчеләр үзәнлеге») турында булыр.

Ул хәзерге төрки телле әдәбиятлардагы иң яхшы, гаҗәеп тәэсирле фәлсәфи әсәрләрдән саналырга лаек. Романда өч текст бар: сихерчеләр үзәнлеге тарихы; Кәрванбашы тарихы; аның этисе – палач Мәмәдкули тарихы. Әмма өч тарихны

да бер автор – язучы берләштерә («автор үлеме» күзәтелмәү бу очракта «йомшак постмодернизм» дип бәяләүнең төп шартына әйләнә). Кәрванбашы һәм Мәмәдкули тарихлары безне борынгы заманнарга алып китә, әлеге ике текст та бер структурада – хакыйкать эзләү һәм үч алу кебек иҗат ителгән.

Кәрванбашы тарихында укучы Күзгә күренмәс тау артында Сихерчеләр үзәненең булуы хакында белә. Анда тылсым ияләре яши. Кәрванбашы үзенең кәрванына юлны шушы үзән аша саба: аңа этисенең рухы белән очраштырырлык сихерче табарга кирәк. Сәйах, Ак дәрвишнең укучысы, риза була һәм Мәмәдкули улына гаилә тарихын сөйли. Моны белгәч, Кәрванбашы шаһтан үч алырга ниятли: аңа агулы таяк бүләк итә. Сер ачыла, ул Кәрванбашының һәм аның хатынының үлеменә китерә. Аларның улын исә Сәйах үзе белән алып китә. Үч алып, хакыйкатьне торгызу омтылышы фаҗигагә китерә.

Мәмәдкули тарихы – үч алуның кешене палачка әйләндерүе ул. Әтисенә хыянәт иткән һәм мәгъшукасы белән бергәләп, аны үтергән өчен, яшүсмер әнисенең җанын кыя – аның палачына әйләнә. Шуннан соңгы тормышы – шаһка палач буларак хезмәт итү. Бу канлы тарихта палачка рөхсәт ителмәгән вакыйгалар килеп чыга. Ул әти-әнисен үзе үтергән Шахваренның гомерен саклый һәм аны уллыкка ала. Аннары Мәмәдкули һәм тол хатын Перниса бер-берсенә гашыйк булалар. Әмма шаһ бу мәхәббәтнең палачны үзгәрткәнен күрә: аңа Пернисаны (Кәрванбашының әнисен) үтерергә боера. Мәмәдкулины һәм Шахверенны исә шаһ үтерә.

Шул рәвешле, ике тарих та уртак фәлсәфәгә алып килә: үч тойгысы кешене һәлак итә. Яратып, кылган гөнаһларны кичереп яшәргә кирәк дигән фикерне калкуландыра.

Әмма әсәрнең иң кызыклы һәм тәэсирле тарихы – сихерчеләр үзәне тарихы. Ул вакыйгаларны һәм укучы үстереп китәргә мөмкин мотивларны бер үзәккә җыя. Суфичыл өйрәтүгә нигезләнгән һәм шуны тергезгән тасвир гаять үзенчәлекле, бер үк вакытта дини-суфичыл мәдәни тамырларга барып тоташкан кебек тоела. Бик вак детальләргә кадәр игътибар итеп сурәтләнгән бу дөнья – кешелек югалткан мөселман-суфи мәдәниятенең символы булып та аңлашыла. Ак дәрвишнең җанын үзендә йөртүче Сәйах аның кешелек хәтереннән җуелып бетмәвенә өмет бирә. Шул ук вакытта ул реинкарнация тәгълиматын белдерә. Бу очракта Ак дәрвишнең үтерелүе – Ислам тарихындагы друзлар, Сүрия суфиларының Исламнан аерылып чыккан тармагы белән бәйле мәгълүматларны искә төшерә. Сәйахның Ибраһим Хаҗи һәм Кәрванбашы белән сөйләшүендә телгә алынган топонимнар: Ак дәрвишнең Дамәшкъта, Алеппода, Хаҗибтә дин юлында булуы шул хакта сөйли. Шәрыкның бөек шагыйрьләре һәм фикер ияләре Руми, Газзали, Мансур Халлаҗ шигырьләрендә тергезелгән күзаллау белән дә ассоциацияләр туа.

Ак дәрвиш белән бәйле үч мотивы кабат калкып чыга. Аның дәрвиш өйрәтүен белгән 23 укучысы, остазларын үтерүгә җавап йөзеннән, кешелек дөньясы бу өйрәтүдән файдалана алмасын дип, упкынга сикерәләр. Ак дәрвишнең җаны Сәйахка күчү – үчләнүгә капма-каршы позиция булып аңлашыла.

Суфичыл өйрәтү дә – хакыйкать эзләү, моны язучы образлы аңлата: «Без йолдызлар дип атый торган урыннардан саркыла торган яктылык юлы – Аллаһка юл ул». Аллаһка юл – хакыйкать эзләү юлы, яктылыкка илтә! Үч алырга теләгән сихерчеләр җиргә караңгылык чакыра. Шул рәвешле, язучы үч юлын – кичерә һәм ярата белүгә каршы куя, беренчесен – караңгылык һәм кан түгү, икенчесен – яктылык һәм матурлык кебек төгәлләштерә.

Текст гаять матур һәм анда символлар, яңадан-яңа фикерләр җемелди тора. Символлар һәм ассоциатив алымнар куллану ягыннан көчле булуы, уйлап табылган дөньяның кыйссаны хәтерләтүе сәбәпле, романны модернизм агымына кертеп караучылар да булды. Әмма төрле вакытка караган төрле тарихларның, мөстәкыйль әсәрләр дәрәҗәсендә төгәлләнеп, бер текст эченә урнашуы аны постмодернизм юнәлешендә карарга мөмкинлек бирә. Әмма бу – төрки әдәбиятларга хас йомшак постмодернизм үрнәге, безнең милли әдәбиятыбызның да үсү юлы.

Хөрмәтле укучым, бу әсәргә матур анализ ясау – үзе бер ләззәт булыр иде. Әмма ул очракта укучы әсәр белән танышу һәм аннан үз күңеленә якын тарихларны аерып чыгару ләззәтеннән мәхрүм калачак. Шуңа да азәрбайҗан язучысының бу романын (калган романнарын да) укырга тәкъдим итәм. Әсәр рус телендә, Мәскәү нәшриятларында да басылган.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА**

# ФАТИХ ӘМИРХАН ТУРЫНДА ЯҢА ТАБЫЛГАН ЧЫГАНАК: КӘРИМ СӘГЫЙД КӨНДӘЛЕГЕ

*XX гасыр башы татар әдәбияты классикларының иҗатын яңа шартларда өйрәнү, заман ихтыяҗларына бәрабәр рәвештә анализларга омтылыш белән бергә, аларның тормыш юлына мөнәсәбәтле аерым бер фактларны ачыклау, мирасларын берәмтекләп туплау һәм саклау өлкәсендә дә хәрәкәт бүген сизелерлек артты дияргә мөмкин. Бу әдәбиятыбызның күренекле әдибе, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан мирасына бәйле рәвештә дә ачык сизелә. Үз чорында ук язучы һәм галим М.Мәһдиев «Фатих Әмирханның биографиясе – безнең әдәбият тарихында шактый гына «ак таплар» белән чуарланган. Бигрәк тә Ф.Әмирханның совет чоры аз өйрәнелгән. Ул бит әле Октябрь революциясеннән соң да тугыз ел яшәгән, эшләгән, иҗат иткән», дип билгеләп үткән иде. Соңгы вакытларда Татарстан Республикасы Милли музее фондларында «Хәят» повестеның икенче кисәге – дәвамы барлыгы ачыклану, Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Ф.Әмирхан шәхси фондына яңа материаллар кабул ителү – әнә шул «ак таплар»ны бетерү юнәлешендә башкарылган эшләрдән.*

*Яңа табылган материаллар арасында Ф.Әмирханның якын дусты, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Кәрим Сәгыйтов (Кәрим Сәгыйд, 1888-1939) язган көндәлек аеруча игътибарга лаек. Аны Санкт-Петербургтагы Европа университетының Россия Ислам халыклары тарихы буенча ТАИФ профессурасы галиме Әлфрид Бустанов табып ала. Бу кулъязма дәфтәр Кәрим Сәгыйднең шәхси архивында сакланып, бүген Санкт-Петербургта яшәүче оныгы Эльмира Тисенко тарафыннан Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә тапшырылды.*

*Әлеге истәлек гарәп графикасы белән татар телендә язылган һәм 65 биттән гыйбарәт. Кулъязмада 1926 елның 26 февраленнән алып 12 мартка, ягъни Фатих Әмирхан күмелгән көнгә кадәр, аның авыруына, дәвалануына бәйле фактлар, гомеренең соңгы ике атнасында булып узган вакыйгалар, вафаты, күмелү тарихы тәфсилле һәм тулы бәян ителгән. Шулай ук биредәге язмалардан әдипнең вафатыннан соң, аны хөрмәтләп күмү өчен төзелгән комиссияләр эше, аларның утырыш беркетмәләре, татарлар яшәгән төрле төбәкләрдән килгән кайгы уртаклашу телеграммаларының текстлары һәм башка мәгълүматлар белән танышырга мөмкин. Болар барысы бергә шул чорның тарихи атмосферасын, язучының аралашкан даирәсен, татар әдәбияты барышында һәм иҗтимагый-мәдәни тормышында тоткан урынын, 1930 елларда аның иҗатына мөнәсәбәтле фикер-бәяләрнең формалашу алшартларын тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Моны көндәлекне язган Кәрим Сәгыйд тә яхшы төшенгән, шуңа Фатих Әмирхан тирәсендә барган һәм үзе дә актив катнашкан вакыйгаларны бөтен нечкәлеге һәм тулылыгы белән киләчәк буыннар өчен теркәп калдырырга омтылган.*

*Гомумән, истәлек эчтәлекле, бай мәгълүматлы. Биредә чыганак тексты гарәп графикасыннан кирилл хәрефләренә бернинди үзгәртүләрсез һәм тулысынча күчерелеп, киң катлам укучыларга беренче тапкыр тәкъдим ителә.*

**Илһам ГОМӘРОВ,**
*ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты*

## АТАКЛЫ ТАТАР ӘДИБЕ ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ АВЫРУЫ, ҮЛҮЕ, КҮМЕЛҮ МӘРӘСИМЕ

**15 февраль – 12 март, 1926 ел**

Авырый башлаган көнләрендән алыб кабергә илтеб күмгәнчәгә чаклы даими рәвешдә диерлек янында булдым һәм күземдән үткәнләрнең күбесен ошбу дәфтәргә теркәдем. Исдәлек булып сакланырга тиеш.

*1 бит*

### Фатих Әмирханның ютәл авыруы

Фатих Әмирхан 1907 нче елның июль ахырларында паралич белән авырган. Шундан ике аягы да йөрергә яраксыз булыб калган. Русиядәге иң атаклы доктор, профессор һәм хирургларның берсе дә аның бу авыруын бетерә алмаганлар. Бары тик шул параличне бот уртасындан югары үткәрмичә туктатканлар гына.

Менә шул аяксыз калуыннан башлаб, ул үлгәнчегә чаклы (19 елга якын) бөтенләйгә утырган килеш гомер итде. Урындан урынга күчкәндә, үзенең гәүдәсен кешедән күтәртеб йөртде яки үзенең кечкенә арбасына утырыб йөрде. Шул вакытдан бирле яңадан бер кат аякка баса алмады. Шундан бирле ул, вакытлы рәвешдә йөреп кайтуларын алмаганда, бөтен гомерен Казанда үткәрде һәм бөтен эшләрен Казанда эшләде.

19 ел берөзлексез аягына баса алмыйча һаман утырыб яки ятыб кына яшәгән бер организмның таза була алмавы, билгеле, бик табигый бер хәл. Ләкин аның организмы шушы паралич авыруына чыдаб, аяксызлыкны йөкләгән көндән башлаб, акрын-акрын һәртөрле вак-төяк авыруларга каршы чыдамлык күрсәтергә, көрәшергә өйрәнеб киткән, чыныккан. Шуңар күрә, ул аяксыз хәлендә дә, үзенең гомерендә берничә мәртәбә нык-нык авырып алуларына карамасдан (мәсәлән, ул бик каты рәвешдә плеврит белән дә авырган имеш), соңгы елларга чаклы чибәр генә таза булыб килде. Бары тик 1925 нче елның язында гына начарлана төшде. Шул вакытда гына Атарда доктор Әбүбәкер Терегулов ютәл хәстәсе (туберкулез авыруы)

*2 бит*

барлыгын табды һәм аның киңәше буенча Фатих Әмирхан шул 1925 нче ел җәй ахырларында (15 нче августларда) даруланыр өчен Кырымга китде.

### Кырымда һәм андан кайткач

Фатих Әмирхан Казандан Кырымга киткән чагында мин Ялтада идем. Алдан сүз беркетеб куюыбыз буенча ул миңа үзенең 20 нче августда Симферопольдә булачагын телеграм белән хәбәр итде. Бу хәбәр килү белән мин Симферопольгә – Фатих Әмирханны белгән танышларга аның киләчәген Ялтадан телефон белән әйтдем; ни көнне һәм кайсы поезд белән Симферопольгә төшәчәген, аны каршы алырга кирәклеген сөйләдем. Шуның өстенә Симферопольдә торучы Исмәгыйль Лиманов, Шакир Мөхәммәдияров һәм Кырым мөфтисе Хаҗи Мөслехеддинләргә мәхсус телеграм да бирдем. Үзем шул ук көнләрне Ялтадан Казанга кайтыб китдем һәм мәхсус рәвешдә юлны Симферополь аркылы алдым. Шунда очрашдык. Симферополь укымышлылары аны бик матурлаб каршы алганлар. Якуб һәм Илһамия Богдановичларның фатирына куйганлар. Мин Фатих белән сөйләшергә барганда, шунда Кырым укымышлыларыннан Озынбашлы белән Чабчакчы һәм югарыда әйткән кешеләр бар иде[1]. Берничә сәгатьләр буенча сөйләшеб утырдык. Фатих аларга бик матурлаб һәм тулы өмидле карашлар белән Татарстан хәлләрен сөйләде һәм Кырым татарларының хәлләрен сорашды. Байтак көлке сүзләр сөйләб бик күңелле хуш мәҗлес ясады.

[1] Озынбашлы – Кырымның укымышлы, игътибарлы, нуфузлы яшьләреннән берсе. Ул бу вакыт Кырымнаркомфинның урынбасары иде. Чабчакчы – Кырымның Наркомздравы. Партияле, укымышлы, милләтче. (Автор искәрмәсе).

*3 бит*

Фатихнең кәефе якшы, юлда вагонда уңайлы булганга, янындагы караучы бала[2] җитез һәм якшы карап килгәнгә, артык ватылмаган, артык армаган иде. «Кырым миңа бик охшар төсле күренә. Симферопольдән үк һавасы безнең һавага караганда бөтенләй башка икән. Әле җингеләеп китдем», – диб, кәефләнеб сөйләде. «Монда килеб утыргач, тазарыб киткән шикелле булдым, дәрт күтәрелде, абыеңны күрәсеңме, ничек пан булыб утыра, без шул инде, әфәндем, авыруларны Кара диңгезгә ташлап калдырырга ният итдек. Йөзә бирсен әле шунда», – диде. Менә бу җөмләләр – аның хәреф-хәреф минем күңелдә калган сүзләре.

Шундан соң Фатихне Ялта тирәсендә якшы бер дачага урынлашдыру турында шундагы кырымлылар белән бераз сөйләшү булды. Алар Фатихне кадерләб кунак итергә теләгәнлекләрен һәм Ялта янында Кырым Наркомздравына караган якшы бер санаторияда урынлашдырырга ниятләб торганлыкларын аңлатдылар. Шулай эшләячәкләренә вәгъдә бирделәр. (Фатихне якшы санаторияга урынлашдыруны үтенеб, Татарстанның Наркомздравы Мөхәммәдияров Чабчакчкыга мәхсус хат да язган булган икән. Фатих миңа шуны сөйләб: «Әлегә монда эшләр әйбәт бара», – диде).

Мин Симферопольдә бер генә кич кундым. Фатих ышанычлы кешеләр кулында калды. Минем гаилә белән күрешергә һәм безне озатырга килгән танышлар һәм һәммәсе дә Фатихка кулларындан килгәнчә якшы хезмәт итәргә булдылар.

Фатих Әмирхан Казанга кайткандан соң да, бу кешеләргә бик күп рәхмәтләр әйтде. Чөнки аны анда үзләренең вәгъдәләре буенча башда бик әйбәтләб кунак иткәнләр һәм Ялта янындагы «Гастрия» диелгән иң матур бер татар санаториясына куеб, Кырымның татар докторларындан

*4 бит*

Габделгаффар дигән бер доктор карамагына табшырганлар. Шулай итеб, ул шушы санаторияда ике айдан артыграк торыб, даруланыб, 13 нче ноябрьләрдә Казанга әйләнеб кайтды. Бу вакыт аның үпкәләрендәге туберкулезасы (ютәле), үзенең әйтүенә караганда, якшы ук төзәлгән, төскә-биткә дә чибәр үк тазарган, кәефе дә нык кына күтәрелгән иде. Тәмәке тартуын бик сирәкләндергәнгә йөткерүе дә бик азайган иде.

Казанга кайткандан соң, ул шушы Кырымга баруының уңышлы чыкканлыгын хосусый утырышларда һәрвакыт шатланыб сөйли, үзенең шушы торган урынын һәм санаториясын «Кырымның иң шәб җире» диб, шулай ук үзен караган докторны һәрвакыт мактый, киләчәк җәйдә дә шунда барачакмын, диб әйтә торган иде. Ләкин аңарга Кырымдан кайткан чагында юлда тугры килгән бер уңайсызлык яңадан Кырымга барырга комачаулык итде. Шуның аркасында башка төрле авыруларга таб булыб шулардан терелә алмады. Мәсьәлә моннан гыйбарәт:

Аңарга Кырымдан кайткан чагында Мәскәү вокзалында бик озак (унбер сәгать чамасы) һичбер ял итмичә бер тоташдан утырыб Казан поездын көтеб торырга тугры килгән. Менә шушы аның биленә зур авырлык китергән. Һәм шуның аркасында аның элекдән булыб да тәмам төзәлүгә авышкан бил кимерчәге туберкулезасы кузгалган иде. Шул сәбәбле, ул Казанга кайткандан соң, бөтенләйгә диерлек утырыб тормады, тора алмады, һаман ятыб үткәрде (бары тик бер генә табкыр «Сания» операсына барыб, шунда гына утырыб торды). Менә шушы рәвешдә һаман ятыб тору аны тагын да ябыкдырды. Кырымда төзәлә башлаган туберкулезен яңадан кузгатды. Ләкин шулай да аның әле җәй башларына чаклы

*5 бит*

бик иркен Казанда торырлык хәле бар һәм яңадан Кырымга барып даруланганда, тагын сәламәтләнүенә дә өмид бик зур иде. Үзе дә: «Март җитеб, көнләр йылына башлагач, клиникага кереб, билемне төзетеб чыгармын да Кырымга китәрмен», – диб тора иде. Ләкин бөек бәхетсезлеккә каршы эш уйланганча булмады. Көтелмәгән икенче төрле авырулар белән кискәнәтдән[3] авырыб китде.

[2] Бу сүзнең карандаш белән астына сызылган. Кулъязманың 2б битендә әлеге баланың исемен ачыклаган язу бар: Зәкәрия Әмирхани.

[3] Кискәнәтдән – көтмәгәндә.

## Үлем авыруының башлануы

Фатихнең үлем авыруы 1926 нчы ел 15-16 нчы февральләрдә башланган. Хәлсезлек, дәрмансызлык сәбәбле, кичләрен тирли торган булганга күрә, битен һәм тәнен юеш чүпрәк белән сөртеб алгалаган[4]. Шул вакыт аңарга суык тигән, яңадан тирләгән, яңадан сөртенгән. Шуның нәтиҗәсендә иртәгәләрен үк кызыша башлаган, температурасы күтәрелгән. Ләкин үзе моңарга игътибар итмәскә тырышкан. Гадәти инфлюэнция[5] диб кенә караган. Шуңар күрә доктор да чакыртмаган. Янындагы кардәшләрендән Разия һәм Гомәр Әмирханлар доктор чакырыйк диб, кат-кат әйтеб карасалар да, ул боларга: «Андый инфлюэнцияләрне генә күб күрдек инде без, аны гына җиңәрлек хәлебез бар әле», – диб, үзенең авыруына һаман әһәмият бирмәскә тырышкан. Аның вакыт-вакыт температурасы күтәрелгәләб тору элекдән килгән бер гадәт булганга күрә, кардәшләре дә доктор чакыру турында аны артык көчләмәгәнләр. Инфлюэнция үтмәгән. 25 нче февральдә тагын да кәефсезләнә төшкән. Шуңар күрә кардәшләре, үзен һәрвакыт

*6 бит*

карый торган Пётр Васильевич Дезидериев дигән докторны чакыртканлар. Доктор Фатихда 16 нчы февральдән бирле үпкә шеше авыруы (воспаление легких[6]) башланган диб табкан һәм даруларга керешкән. 26 нчы февральгә чаклы Фатихнең янында бары тик кардәшләре генә (Гомәр, Разия Әмирханлар һәм кодагыйсы Газизә абыстай Яушева гына) булганлар. 25 нче февральдә җизнәсе Габдулла мулла Әмирхани да килгән. Ләкин 26 нчы февральгә аның бу авыруын дустлары да, мөхлислары[7] да, якын танышлары да һичберәүсе дә белмәгәнләр. Яллар буенча бөтен төнләрен Фатихнең өендә преферанс уйнаб үткәргән һәм шуның белән Фатихнең хәятендә әллә ничаклы гайре табигый хәлләргә сәбәб булган кешеләрдән берәүсе дә килеб чыкмаганлар.

Мин үзем дә аның авырганлыгын шушы 26 нчы февральдә кодагый Газизә абыстай Яушеваны урамда очратыб сорашкач белдем. Ләкин ул миңа: «Фатих абыегыз бераз кәефсезләнеб ята әле», – диб кенә әйтде. Шул көнне Ибраһим Бикколны очратыб, аңарга: «Фатих абый кәефсез ята икән, нигә бер дә бармыйсың, хәлен белергә кирәк», – дип әйтдем. Шул вакыт без аның белән бүген кич Фатих абый янына керергә вәгъдәләшдек. Ләкин мин аның болай ук авыр хәлдә икәнлеген белми идем. Шуңар күрә мин аңарга ашау-эчү бүләкләре алыб кердем. Миндән алда гына Ибраһим Биккол да килгән иде[8]. Бу вакыт Фатихнең янында җизнәсе Габдулла мулла Әмирхани белән кодагый Яушева һәм Разиялар бар иде. Соңындан Гомәр Әмирхан белән Фатима Апаковалар килделәр. Андан соң фельдшер Габдерахман Моратов чакырылды. Фельдшер тиз килде.

Кичә 25 нче февральдә Фатихнең авыруы нык кына көчәеб температурасы

*7 бит*

39 га күтәрелгән булган. Шул сәбәбле доктор Дезидериев иң зарур чараларны күреб, шул фельдшерицаны чакырырга кушыб киткән һәм аңарга Фатихка банкалар салырга, камфаралар җибәрергә кушкан булган.

Бүген (26 нчы февраль, җомга көн) инде аның хәле тагын да авырая төшкән, температурасы 39,5 кә җиткән иде.

Безгә Фатих белән сөйләшеб утырырга мөмкин булмады. Бары тик йөзенә караб, берничә сүз белән юатыб кына, икенче бүлмәгә чыкдык та, иң ашыгыч чаралар күрү киңәшенә керешдек. Габдулла мулла белән Гомәрне безгә хәбәр бирмәгәнлекләре өчен

---

[4] Кырымга киткәнче башлаган һәм кайткач да дәвам кыла килгән спирт яки одеклонлы салкынча су белән иртә-кич сөртенә торган гадәте бар иде. Бик күб вак авырулардан шушы «обтирание» бөтенләй хилас (?) кыла диб тирги башлагач да ташламады. (Автор искәрмәсе).

[5] Инфлюэнция – грипп.

[6] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[7] Мөхлислары – якын дуслары.

[8] Кулъязманың 5 б битендә карандаш белән түбәндәге текст бирелгән: «Фатих белән Биккол арасында шул рәвешдә сөйләшү булган:

Ибрай: Нихәл, Фатих?

Фатих: Менә каяндыр воспаления лёхки килеб чыкды. Үләргә булгач бер сәбәб кирәк бит, воспалениями, бүтәнме? Үләсе булгач түшәкдә ятыб да берсен табасың инде аның. (Шундан бераз тынычлангач янә): Ни хәбәрләр бар, матбугат юбилейсы нишли? Анда тагын кемне сүгәргә хәзерләнәләр. Анда тагын минедер инде.

Матбугат юбилейсы тиз түгел әле, ул турыда хәбәрләр юк диб тынычландырдым».

бераз орышыб алдык. Катгый рәвешдә иң ашыгыч чаралар күрергә, яңыз Дезидериев белән генә канәгатьләнмичә, Казанның иң якшы профессорларын чакырыб, ничек кенә булса да шушы авыруындан алып калу дәртен күрергә кисеб тәклиф[9] итдек. Бүген мәшһүр Казан математигы Лобачевскийның йөз еллык юбилее бәйрәме булганга күрә, профессорларны өйләрендән табу бик читен, чөнки һәммәсе дә диярлек шул эш артындан йөриләр иде. Шунда да без үзебезнең эшебезгә керешдек. Ибраһим Биккол Әбүбәкер Терегуловка китде. Аны өендә очрату яки очратмавындан миңа телефон бирергә булды. Мин икенче докторларны эзләргә китдем. Өйгә кереб Фатих Мөхәммәдияровка телефон белән: «Үзеңнең Наркомздрав карамагындагы иң якшы профессорларыңдан берәресен шушы сәгатьдүк Фатих Әмирханга җибәрә күр, ул хәзер үпкә шеше белән бик авыр хәлдә ята, ничек булса да үлемдән алыб калырга кирәк», – диб әйтдем. Аннары Мөхәммәдияровның

*8 бит*

киңәше буенча әлеге Лобачевскийның юбилейсе була торган фән ияләре клубына китдем. Анда әле берәү дә килеб җитмәгән, бары тик бер генә доктор бар иде. Ул миңа эчке авыруларны карауда мәшһүр булган доктор Якимовны күрсәтде. Аңарга бардым. Өендә очрамады. Шуңар күрә Наркомздрав Мөхәммәдияров исемендән сөйләб: «Татарларның зур әдибе Әмирхан авыр хәлдә ята, кайткач да шунда килсен», – диб кушыб калдырдым. Анардан кайткач, яңадан Мөхәммәдияровдан профессор сорадым. Ул озакламыйча берничә доктор җибәрергә вәгъдә итде. Бер сәгать чамасы үткәч, Ибраһим Биккол белән безнең артдан озак та тормадылар: 1) Терегулов, 2) Якимов, 3) Шварцман дигән докторлар килделәр. Шулар өстенә авыруны ничек табканлыгын, ничек дарулаганлыгын сөйләтер өчен доктор Дезидериевне дә чакыртдык. Шул вакыт Гыйльми һәм Рәхимә Шәрәфләр хәл белә килделәр.

Докторлар җыйнаулашыб карадылар. Фатихнең хәле авыр булса да, кәефе якшы иде. Шуңар күрә ул докторлар белән ачык сөйләшде. Миңа: «Кәрим, син ник болай дөнья кубтарыб йөрисең? Минем хәлем алай ук куркынычлы авыр түгел ич әле. Кешеләрне борчымаска кирәк иде. Синең шул медицина булыр инде», – диде. Шуңар каршы Әбүбәкер Терегулов: «Фатих, бер дә борчылма, без сине карарга тиеш. Авыруың куркынычлы түгел шул. Үпкә шеше авыруы гына нәрсә булган ул. Аны гына төзәтә алырбыз әле», – диде.

Фатих (медицинага бөтенләй үк ышаныб бетмәгәнлеген аңлатыб):

*9 бит*

«Караб карыйк инде», – диде. Моңарга Әбүбәкер: «Юк, Фатих, мин бит сине бер тапкыр плевритләрдән алыб калган идем. Ул чагында да шулай әйткән идең дә, однако, төзәлгән идең», – диб илзам[10] кылды.

Докторлар авыруны бик ныклаб тикшергәндән соң, күрше зал бүлмәсенә чыгыб һәм яңыз үзләре генә калыб, бер сәгать чамасы киңәшделәр. Нәтиҗәсендә һәммәсе дә бер төсле фикергә килгәнлекләрен безне чакырыб әйтделәр. Дезидериевнең дарулау тәртибен дөрест диб табтылар һәм мондан соң даими рәвешдә йөрүне аңарга табшырдылар. Һәммәсенең имзалары белән берничә төрле рецептлар яздылар. Шварцманга иртәгә Наркомздрав белән аңлашыб, Казанның иң яхшы профессорларындан консилиум ясату эшен табшырдылар.

Докторлар киткәндән соң, Фатих абый миңа янәдән: «Кәрим, син нигә анда докторларны ду китереб, дөнья кубтарыб йөрисең? Синең медицинага бик исең китә шул. Караб карыйк инде, нишләрләр икән докторларың! Карасынлар! Төзәтергә, терелтергә кулларындан килсә, моны эшләсенләр. Әгәр дә булдыра алмасалар, медицинага төкерегез[11]. Әле бит моның расходлары да бардыр. Булмаса мин сиңа акча биреб куим әле», – диде. Мин: «Фатих абый, анысы өчен кайгырма әле. Аны үзебез карарбыз. Безгә синең сәламәтләнүең генә кирәк», – дидем. Ул «Алай булса, Кәрим, миндән сиңа йөз сумга чаклы расход тотарга рөхсәт, соңындан исәбләшербез», – диде.

[9] Тәклиф – көчләп кушу, боеру.

[10] Илзам – бәхәстә җиңеп чыгу.

[11] Бу сүзләрне ул берничә көнләр үткәч янында булган башка кешеләргә дә кат-кат әйтә башлады. (Автор искәрмәсе).

*10 бит*

Докторлар киткәндән соң, Ибраһим Биккол һәм Гомәр Әмирхан белән өчәүләб, Фатих абыйны карар өчен үзебезгә һәм аның башка якынларына, дустларына кизү төзедек. Бүген төнлә саклауны фельдшер Габдерахман Моратов белән Габдулла мулла Әмирхан икәүсе үз өстләренә алдылар һәм шулай итделәр.

## Фатихне карар өчен төзелгән кизүлек

Монда күрсәтелгән кешеләр һәммәсе дә кизүдә тордылар. Бары тик көнләрдә һәм алмашынуларда гына үзгәрешләр булды.

Февраль 26 җомга төнлә белән – Габдерахман Моратов, Габдулла мулла Әмирхани, 27 шинбә көндез – Гомәр Әмирхан, Ибраһим Биккол, төнлә – Кәрим Сәгыйд, Габдерахман Моратов, 28 якшәнбе көндез – Гомәр, Биккол, Кәрим Сәгыйд, төнлә – Һарун Максудов, Садри Җәлал, 1 март дүшәнбе көндез – Гомәр Әмирхан, Хәсән Исхаков, төнлә – Бәдри Максудов, Вафа Бәхтияров, 2 сишәнбе көндез – Гомәр Әмирхан, Кәрим Сәгыйд, төнлә – Фатима Максудова, Кадыйр Хуҗаев, 3 чәршәнбе көндез – Гомәр Әмирхан, Хәсән Иҗаков, Кәрим Сәгыйд, төнлә – Габдерахман Моратов, М.Гали, 4 кече атна көндез – Гомәр, Гәрәй Хәсәни, төнлә – Нәфисә Ваһапова, Разия Әмирхан.

*11 бит*

Март 5 җомга көндез – Гомәр, Зыя Ваһапов, төнлә – Салих Корбангалиев, Сафа Хафизов, 6 шинбә көндез – Гомәр, Биккол, төнлә – Сара Касыймова, Рәүф Шахмәмитов, Шиһаб Әхмеров, 7 якшәнбе көндез – Кәрим Сәгыйд, Ибраһим Биккол, төнлә – Рәбига Дивиниева, Габдерахман Моратов, Габдулла мулла һәм Каюм Мостакай, 8 дүшәнбе көндез – Гомәр, Биккол, кичен – Кәрим Сәгыйд, төнлә – Фәйзуллин, Рәхимә Мөхтиева, Габдулла мулла, 9 сишәнбе иртә белән – Габдулла мулла, Кәрим Сәгыйд.

27 нче февральдә кичә бирелгән карар буенча Казанның иң атаклы профессор һәм докторларындан консилиум ясалды. Монда 1) профессор Лурия, 2) профессор Зимницки, 3) доктор Терегулов, 4) доктор Шварцман һәм 5) Наркомздрав Фатих Мөхәммәдияровлар булдылар. Болар Фатихнең хәле бик авыр; үпкә һәм бил туберкулезалары да, шулар өстенә пешеккән үпкә шеше – катаральное воспаление легких[12] авыруы да тагын да көчәя төшкән, ләкин шулай да әле терелүе өмидсез түгел – небезнадежно, диделәр һәм медицинаның иң соңгы чараларыннан дарулар, киңәшләр бирделәр.

*12 бит*

Шушы сәгатьдән башлаб, Фатихне карау, аны дарулау һәм һәрбер кирәкләре өчен хәзер торулар һәр якдан мөкаммәл[13] рәвешдә җитешдерелде. Доктор Дезидериев һәр көн ике килә. Кирәк булыб чакырылса, төнлә дә килә. Башка докторлар да әледән-әле хәл белә торалар. Шәфкать туташы яки фельдшер һәрвакыт бар. Яшь татар врачлары үзләре теләб, төнләрен кизү торалар. Шуның өстенә якын дустларыннан, мөхлисләрендән һәм, гомумән, укымышлылардан биглеләнгән югарыгы җәдвәлдәге[14] кешеләр алмаштилмәш кизүләб, көнләрен-төнләрен берөзлексез саклыйлар, саклыйбыз. Доктор биреб киткән тәгълимат дикъкать белән сәгатендә, минутында үтәлеб тора.

Яшь татар врачларының үзләре куйган кизүләре

28 февраль – Һарун Максудов, 1 март – Бәдри Максудов, 2 март – Фатима Максудова, 3 март – Сара Касыймова, 4 март – Рабига Дивиева, 5 март – Рәхимә Мөхтиева, 6 март – Рәүф Шахмәмитов, 7 март – Салих Корбангалиев, 8 март – Фәйзуллин, 9 март – Барый Биккинин.

Бу тәртиб шушы көенчә үтәлмәсә дә, болар һәммәсе дә килделәр һәм кизү торыб Фатих Әмирханны карадылар, сакладылар.

*13 бит*

Шушы 27 нче февральдә шинбә көн кич белән безнең чакыруыбыз буенча Фатихнең якын дустларындан һәм аны ихтирам итүче укымышлылардан Кәрим Сәгыйд фатирында кечкенә генә бер җыелыш ясалды. Чакырылган кешеләрдән: 1)

[12] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[13] Мөкәммәл – камил.
[14] Җәдвәлдәге – исемлектәге.

Фатих Мөхәммәдияров, 2) Ибраһим Биккол, 3) Кәрим Сәгыйд, 4) Гыйльми Шәрәф, 5) Гомәр Бикбулатов, 6) Ибраһим Аитов, 7) Шиһаб Әхмирев, 8) Гомәр Әмирхан, 9) Бениамин Әхтәмов һәм 10) Хәсән Исхаковлар хәзер булдылар.

Куелган мәсьәләләр: 1) Фатих Әмирханны якшылаб тәрбияләү, дарулау өчен бер үзәк төзү. 2) Терелгәндән соң, Кырымга җибәрү чарасын күрү.

Беренче мәсьәлә тикшерелгәндә, Фатих Мөхәммәдияровдан авыруның дәрәҗәсе һәм терелү өмиде барлыгы турында сорашкандан соң һәрбер йомышларны үтәб бару, шулай ук информация өчен үзәк итдерелеб өчле комиссия төзелде. Болар: 1) Фатих Мөхәммәдияров, 2) Ибраһим Биккол, 3) Кәрим Сәгыйдләр булдылар. Шулар арасындан Кәрим Сәгыйдкә авыру өчен кирәк булачак расходларны тоту эше йөкләтелде.

Икенче мәсьәләдә Фатихнең материальный яклары тикшерелгәч, терелгәндән соң, Кырымга җибәрергә булыр, әгәр дә үлеб китсә, дәфенләре[15] өчен тотылыр диб, иң азында биш йөз сум акча җыярга карар бирелде, һәм бу акчаны Печән базары сәүдәгәрләрендән җыймыйча, яңыз Фатихне якын күргән берничә кешеләрдән генә алырга карар ителде. Шуның өстенә әгәр дә партиясез укымышлылар үзләре теләб бирсәләр, алардан да биргәнләре чаклы

*14 бит*

алынырга булынды. Бу эш Гыйльми Шәрәф, Шиһаб Әхмирев һәм Ибраһим Аитевләргә табшырылды. Утырышдан соң, Биккол, Әхмирев һәм мин өчәүләб, Фатихнең хәлен белергә кердек. Башкалар кайтыб китделәр. Мин фельдшер Габдерахман Моратов белән икәүләб, төн буенча сакларга калдым.

Төнлә Фатихнең хәле җиңеләймәде. Ләкин кәефе ачык булды. Бары тик йоклый алмавындан гына зарланды. Шушы төнне ул миңа: «Кәрим син ник төнлә белән монда йөрисең? Әллә синең мине карый торган чиратыңмы? Әле сез шулай организоваться[16] итеб алыб, мине чиратлаб керешдегезмени? Минем тик шул фактны белеб торасым һәм шуны констатировать итәсем генә килә», – диде. Мин моңар каршы аңарга дару эчердем. Шуның белән сүз озаймады. Ул да бераз тынычланыб калды.

28 февраль бер килеш үтде. Кизү куелган килеш барды. 1, 2, 3нче март көнләре дә бер килеш үтделәр. Кизү торулар, дарулаулар, караулар мөкаммәл рәвешдә барды. Авыруның хәле көндән-көн якшырды. Ул инде хәзер бары тик камфара җибәргән урынларның авыртуындан гына зарлана башлады. Докторлар үпкә шеше авыруының төзәлә башлавыннан хәбәр бирделәр. Шуңар күрә камфара җибәрүне дә азайтдылар. Хәтта «Фатих котылды» дигән шадлыклы өмид һәркемдә ныгый башлады. Шуңар күрә аны апрель башларындан калдырмыйча, Кырымга җибәрү мәсьәләсе безнең арада бик нык сөйләнеб, шуңарга планлар корылды. Ләкин 4 нче мартка каршы төнлә белән Фатихнең хәле көтелмәгәндән янә начарланыб китде.

*15 бит*

Бу төнне кизүдә торучы Нәфисә Ваһапова төнге сәгать 3дә миңа килеб кереб: «Кәрим, нишлик инде? Фатихнең сидеге тукталды, тышка чыга алмый. Үлеб китмәсә ярар иде диб куркабыз», – диб, бер сөаль[17] куйды. Бик кыска гына уйлашкандан соң, телефон белән «ашыгыч тыйбби ярдәм станция»сендән бер врач чакырдык. Шуның өстенә Дезидериевне алырга китделәр. Ярты сәгатьдән соң һәммәсе дә авыру янына килделәр. Катетер куеб карадылар. Ләкин сидек чыкмады. Доктор нервлар авыруы башланган һәм шуның беренче бәрелүе сидек юлына тугъры килгән, диб табды. Яңадан консилиум ясаб, нервлар авыруын карарга кирәк булачак, иртәгә шуны җыярбыз диб, берничә киңәшләр биреб кайтыб китде.

4нче март иртә белән сидек юлларында, почкада[18] авыру юклыгы мәгълүм булды. Шул көндүк яңадан консилиум ясалды. Бусында Фатих Мөхәммәдияров, Терегулов, Дезидериев, доктор Варашилов һәм Зимницкийлар катнашдылар. Болар: «Үпкә шеше авыруы тәмам бетеб бара икән дә, ләкин туберкулеза палочкалары фронтны кисеб чыгыб, карынга, эчәкләргә һөҗүм иткәнләр. Шул сәбәбле эчәк һәм

[15] Дәфенләре – күмүләре.
[16] Организоваться – оешып.
[17] Сөаль – сорау.
[18] Почкада – бөердә.

карын шеше (воспаление брюш. кишки[19] ) авырулары килеб чыккан. Бусы инде теге авыруларына караганда, бик күб куркынычлы», – диделәр. Терелү өмиде барлыгын әйтмәделәр.

Шунда да әле Фатих бу зур куркынычлы авыру белән дә ныклаб көрәшергә, медицина биргән кораллар белән авыруына каршы бик ныклаб сугышырга керешде.

*16 бит*

Никадәр авыр азабланса да, һәммәсен дә эчендән тына, йөзенә чыгармый, кәефен һаман да якшы күрсәтә иде. Камфара, морфий кебек дарулар җибәргәндән соң берәр сәгать чамасы мәлҗерәб ятыб, андары кәефе ачылгач, ара-тирә үткен сүзләр яки кыска гына мәзәкләр әйтеб сала иде. Үзен кадерләб караганга бик шадлана, үлемдән һичбер курыкмыйча, аны көлә-көлә каршы алырга хәзер булуы белән бергә «Инде якшылаб карагач тереләм» диб өмид итә иде. Шушы көнләрдә ул: «Татарстанның мәгариф һәм матбугат эшләрендәге егетләре мине татар театрының 20 еллык юбилейсы булган көндә, күңел хатирәсе өчен генә дә бер кисәк кәгазь җибәреб чакырмаганлар да, хәтта шуның танта[на]лы мәҗлесендә мине һәм татар театрының нигезен салучы, аны гражданлык хокукын алырлык дәрәҗәгә күтәрүче Габдулла Кариевне сүккәнләр иде. Моны миңа «Таз» эшләде. Ләкин менә хәзер минем авыру чагымда миңа никадәр докторлар киләләр. Һәммәсе дә мине юаталар. Бу хезмәтне коммунистлар түгел, минем дустларым гына эшлиләр. Әгәр дә Наркомздравда Фатих Мөхәммәдияров булмыйча, анда да бер коммунист утырса, бу докторлар да, бу дарулар да килмәсләр иде», – диб сөйләде.

Кизүдә торучы яшь врач Рәбига Дивиевага минем алдымда: «Әгәр дә миңа мондан егерме еллар элек син татарның зур мөхәррире булырсың, кулында реальный көч булган бер партия синең кешелек кадереңне төшереб изәргә тырышса да, каты авырган чагыңда сине олуглаб бик күб татар партиясез врачлары кизү торыб карарлар диб әйтсәләр, бу хәлнең булуына һичбер ышана алмас идем. Ләкин Ходай миңа шуны күрергә насыйб итде. Менә күрәсеңме, Рәбига, татарның хәяте нинди уңышлы

*17 бит*

производительно[20] бара. Шуны уйлагач, ирексез тереләсем килә», – диде. Шуны сөйләгәч, мәлҗерәб арыб китде.

Докторлар Фатихнең тереләчәген өмидсез күрсәткәч, мин, Биккол, Нуркин өчәүләб минем өйдә утырыб, үлә калса, ничек итдереб күмү турыларында киңәшдек. Олуглаб, ихтирам белән күмү планларын, тәртибләрен чамалаб карадык. Күмү комиссияләре проектын төзедек. Аңарга дуст, якын таныш һәм мөхлис булган интеллигенцияне тикшереб, кемләрнең нинди эшләргә кирәкле, файдалы булачагын күздән үткәрдек.

Габдулла мулла Әмирхани белән Гомәр Әмирханлар ни өчендер Фатихнең каты авыруы турында үзләренең читдәге кардәшләрендән Ибраһим Әмирхан һәм Мәхмүд Әмирханларга хәбәр бирергә ашыкмадылар. Бары тик без кат-кат басыб әйкәндән соң гына, 27-28 февральләрдә Гомәр Мәскәүгә Мәхмүд Әмирханга хат язды һәм Җиддәдәге[21] Ибраһимгә: «Фатих үпкә шеше белән каты авырый, карау якшы куелды, авыруның кидешендән киләчәктә хәбәр бирербез», – дигән мәфһүмдә[22] телеграмм бирде. Фатихнең авыруы көчәйгәч тагын хәбәр җибәрергә әйтдек. Ләкин һаман да «әһәмияте юк» диб кичекдерделәр. Шунда Мәхмүдкә телеграм бирделәр. Ибраһим Әмирхан авыруның барышындан һаман хәбәрсез калды. Аңарга үлгәндән соң гына телеграм бирелде. Үзендән үлгән көндә хәле ничек, диб соралган телеграм килде.

*18 бит*

5 нче мартда кич белән Фатихне саклаб утырган чагында хәл белә килүчеләрдән Шиһаб Әхмирев, Зыя Ваһапов, Исхак Карташов, Ибраһим Аитовларны алыб калыб, шулар янына Габдулла мулла белән Гомәр Әмирханны да чакырыб, шул ук фатирның урта бүлмәсендә янә бер кат киңәшдек. Монда югарыда сөйләнгән Биккол һәм Нуркинлар белән өчәүләб хәзерләгән күмү проектларын сөйләб күрсәтдек. Яңа кешеләр

[19] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[20] Производительно – житеш, үсештә. Кирилл хәрефләре белән язылган.
[21] 1924-26 елларда Фатих Әмирханның энесе Ибраһим Әмирхан Согуд Гарәбстанында Совет илчелегенең сәркятибе һәм тәрҗемәчесе вазыйфаларын башкара.
[22] Мәфһүмдә – эчтәлектә.

проектка үзгәреш кертмәделәр, мәгъкульләделәр[23]. Аннары Фатихнең «Шәфигулла абзый»сы, мемуарлары, хатлары турында да сөйләшдек. «Шәфигулла абзый»ны күчерергә, башка кулъязмаларына акт язарга булдык. Ләкин бу нәрсәләрнең һәммәсе дә Фатихнең кровате янындагы сандыкда булганга, ул сандыкны үзе авырса да, һаман караб ятканга, алыб чыгу мөмкин булмаганлыкдан һәм шалтыратыб ачыб алу да бик уңайсыз табылганлыкдан, бу эшләрнең һәммәсе дә кичекдерелде[24].

6 нчы март шинбә көн авыру тагын да көчәйде. Бу көн көндез без хезмәтдә чагында доктор Терегулов килеб караб киткән һәм Ибраһим Бикколовны очратыб: «Инде хәзер күмәргә хәзерләнергә кирәк, дүшәнбе көн иртә беләндән дә соңга калмас өзелер диб уйлыйм», – дигән. Доктор Дезидериев: «Инде безнең хәлдән килерлек түгел. Якшәнбе көн кичдән дә калмас, өзелер, үләр диб уйлыйм», – дигән.

Безне соңга таба үләр алдындан иң күб борчыган нәрсә Фатихнең кулы белән язган васыяте бармы, юкмы икәнлеген белү булды.

*19 бит*

Докторлар аның үләчәген тәмам кисеб, вәгъдәләб куеб киткәч, бу мәсьәлә безне тагын да борчыды. Мондый васыятьнең барлыгын яки юклыгын үзенең якын кардәшләрендән һичберсе өзеб әйтә алмады. Кырымга китәр алдыннан бары тик Ибраһим Бикколовка телдән генә: «Әгәр дә үлә калсам, мине Ислам дине кушканча, ләкин бидгатьсез[25] без обрядов[26], ягъни фидия[27], дәүр[28], яллаб Коръән чыгарту, җидемне уздыру кебек эшләрнең – җолаларның берсен дә үтәмичә күмәрсез. Шулай ук минем җеназама чәчәк һәм ленталар да куйдырмазсыз. Васыйларым – Галимҗан Шәрәф, син һәм җизни, өчәү булырсыз», диб әйткән булган. Башкаларын шушылары белән бергә Кырымдан әйләнеб кайткач, үзем язармын әле, дигән[29].

Шушы 6 нчы мартда кичен гадәтдәгечә камфа[ра]лар тәэсире белән Фатихнең кәефе ачылыб китә. Гадәтдәгечә сөйләшеб ята башлый. Шул араларда Ибраһим Биккол Фатихнең үзендән сораб, үз кулы белән язган васыятенең юклыгын белә. Ләкин язарга тәклиф[30] итми һәм васыятьләреңне әйтеб калдыр, диб әйтергә дә базмый[31]. Биккол миңа моны шул сәгатьдүк хәбәр итде. Яңадан бер кат уйлашыб карадык. Ләкин һичбер төрле юл таба алмадык. Хәле авыр булган Фатихне васыятьләр турында сүз кузгатыб борчырга батырчылык итә алмадык. Чөнки аны сөйләшдерү аңарга зарар булыб төшәчәк иде. Шуңар күрә без аны үзебез карый башлагандан бирле мөмкин кадәр сөйләшдермәскә һәм аны үзебезнең сөальләргә[32] җаваб бирдерү мәҗбүриятенә төшермәскә тырышдык. Үзенең иң кирәкле сүзләрен генә тотыб, авыруына бәйләнеше булмаган сүзләрен сөйләшдермәс өчен мөмкин кадәр җавабсыз калдыра идек. Докторлар да шулай кушалар, шуны бик нык

*20 бит*

тотарга әмер итәләр иде. Хәтта хәл белә килүчеләрнең кайсыберләрен,

---

[23] Мәгъкульләделәр – аңлаешлы, дөрес дип таптылар.

[24] Хакыйкатьтә бу эш берникадәр соңрак башкарылган. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендәге Ф.Әмирхан фондында әдипнең васыйлары Галимҗан Шәрәф һәм Ибраһим Бикколов тарафыннан 1926 елның 17 октябрьендә төзелгән Актның төп нөсхәсе саклана (Ф. 16, тасвир. 1, С.б. 47). Биредә Фатих Әмирханның вафатыннан соң бүлмәсендә калган кулъязмалары, китаплары, документлары, шәхси әйберләре һ.б. исәпкә алынган.

[25] Бидгатьсез – йолаларсыз.

[26] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[27] Фидия – үлгән кешенең гөнаһларын ярлыкауны сорап биргән мал, йолым.

[28] Дәүр – үлгән кешенең гөнаһларын ярлыкауны сорап үткәрелгән дини йола.

[29] Кулъязманың 18 б битендә карандаш белән түбәндәге текст бирелгән:
–Нихәл, Ибрай, эш минем начар бит.
–Начар түгел әле, профессорлар, өмид бар әле, дияләр.
–Алар әйтерләр инде.
Янә дәвам итеб.
–Син, Ибрай, беләсең инде, син, җизни, Галимҗан Шәрәф – васыйлар.
–Синең бит Фатих язган васыятең бардыр.
«Язган васыятем юк», – диде. «Күмүне инде Ислам дине буенча, без обрядов», диде.
–Соң алай булгач Фатих син аны шаһидләр алдында әйтер идең, яки языб калдырыр идең.
«Ярар, шаһидләр алдында да әйтермен һәм хәлем якшыргач язармын» диде.
Разия һәм Гомәр Әмирханлар шул вакыт сүз уртасында килеб керделәр.

[30] Тәклиф – көчләп кушу, боеру.

[31] Бу җөмлә карандаш белән сызылган.

[32] Сөальләргә – сорауларга.

сөйләшдерүләрендән куркыб, аның янына кертмичә, үзебез генә кабул итәдер идек.

Шулай да булса җиденче мартда бугай, Габдулла мулла Әмирхани бер уңаен табыб, Фатихнең телендән васыятьләренең кайберләрен әйтдергән һәм шуны языб кайтадан үзенә укыб күрсәткән. Фатих һәммәсен дә мәгъкуль[33] табыб, бераз кәефе күтәрелсә, имза итәргә дә булган. Ләкин ул инде шундан соң имза итәрлек хәлгә килә алмады. Габдулла мулла язган васыять шул көенчә имзасыз хәлдә аның кулында калды. Бу васыятьне Габдулла мулла безгә дә күрсәтде. Биккол белән икәүләб укыдык. Монда ул Ибраһим Бикколга әйткән васыятьләре өстенә: 1) үзенең туганы Ибраһим Әмирханга биш мең сум чамасы бирәчәге барлыгын, артдырыб шуны үзендән калган суммалардан бирергә кушкан; 2) үземне күмү расходларындан калган суммадан якынларымны укытырсыз, дигән. Башка сүзләр артдырмаган[34].

Шул рәвешчә, Фатих Әмирханның үз кулы белән язган васыяте калмады. Ләкин моның ул чаклы зур әһәмияте дә юк. Чөнки аның телдән әйткән васыятьләре үзе исән чагында ышанычлы рәвешдә исбат ителенде.

*21 бит*

Фатихнең тәрбиясен, әхлакын, фикерен, игътикадын[35], карашларын, әсәрләрен белгән кешеләр өчен аның шул телдән генә әйткән сүзләре дә инанырлык һәм игътикадына муафикъ[36] булганлыгы күренеб тора.

7-8 нче мартлар һәм 9 нчы мартка каршы төн, 9 нчы мартның иртәсе – Фатихнең иң авыр рәвешдә иң куркынычлы авыруларга каршы көрәшкән көнләре. Бу көнләрдә аның күз нурлары байтка сүнде, күз пәрдәләре томанланды, сакалы үсеб китде. Үзе бик нык ябыкды. Ләкин анарда искиткеч чыдамлык булган икән. Ул һичбер вакыт һәм үлгән көнләрендә дә кычкырыб ыңгырашмады, ай-вайламады. Һәммәсен эчендән тынды. Мин аның унике көн рәтдән бик күб вакыт янында булсам да, бер генә табкыр да кычкырыб ыңгырашканын да ишетмәдем. Ул иң авыр минутларында да, үләренә тәмам 10-15 минут калганчага чаклы үзенең аңын югалтмады. Хәл белә килгән яки үзен кизүләб карый торган кешеләрнең һәммәсен дә таныб, һәркайсы белән берәр генә сүз булса да сөйләшеб ятды. Иртәгә үләчәк булган 8 нче март кичендә без Рәхимә Мөхитова белән икәү аның янында саклаб утыра идек. Шул вакыт кулын Рәхимәнең итәгенә куеб, Рәхимәнең кулын кысмакчы булды. Ләкин бармакларда көч юк иде. Моңар каршы Рәхимә:

*22 бит*

«Фатих абзый, көчеңез азрак шул», – дигәч, «Юк, миндә анлык кына көч бар әле», – диб җавабланды, көлдерде. Андан соң бераз торгач: «Рәхимә, беләсеңме, без бит синең белән син кечкенә чагында бер вакыт пароходда очрашкан идек. Син әле ул чагында 14-15ләрдә генә булгансың. Менә инде хәзер ничек дәү үсеб киткәнсең. Мин сине шундан бирле күргәнем юк иде. Инде доктор да булгансың икән», – диб, Рәхимәне таң гаҗәбкә калдырды. Исән булган Рәхимә Фатихнең шулчаклы авыр хәлдә дә шул вакыйганы исенә төшерә алуына тәмам абтыраб калды.

Шул сүзләрендән соң мин чыгыб китдем. Рәхимә белән Габдулла мулла төнен утырыб сакларга калдылар. Аларга төнлә белән сүз араларында үзенең иртәгә (9 нчы март була) сәгать 8-9 араларында үләчәген әйткән. «Иртә белән сәгать 8-9 араларында китәрбез инде, ахыры», – дигән.

Мине 9 нчы март иртә белән сәгать алтыда Фатих начарланды диб чакырдылар. «Фатих абый хәлең ничек?» – диб сорагач: «Кәрим, син икәнсең, әлегә ничава, шулай ятабыз менә», – диде дә изерәп китде. Шулчаклы аңы булганга, янындагы кешеләрнең һичберсе аны бөтенләй өмидсез диб табмады. Көндезен бәлки рәтләнеб дә китәр әле диб уйлаган булдык. Чөнки докторларның аңарга үләргә куйган сроклары да үтеб киткән иде инде. Шулай да булса мин бик тиз генә

*23 бит*

Биккол белән Нуркинны һәм Гомәр Әмирханны, Фатих Мөхәммәдияровны

[33] Мәгкуль – акылга ярашлы.
[34] Ибраһим Бикколовка әйткәненчә өч васый күрсәткән һәм җизнәсе Габдулла мулла Әмирхани белән Галимҗан Шәрәф, Ибраһим Бикколовларны атаган. (Автор искәрмәсе).
[35] Игътикаден – ышануын.
[36] Муафикъ – ярашлы, туры килгән.

өйләрендән чакырыб китердем. Фатих аларны да таныды. Шуңар күрә Биккол белән Нуркин бераздан үзләренең хезмәтләренә китделәр. Рәхимә Мөхитованы шәфкать туташы (Серова) алмашдырды. Шулай итеб, без берничә кеше Фатих янында калдык. Сәгать тугызынчы яртыда тагын начарланды. Шулвакыт университетның медицина факультетының соңгы курсында укучы Фәхретдинов дигән студент килде. Алар шәфкать туташы белән икәүләб камфара, морфий җибәрделәр. Аннары кокаин җибәрделәр. Һәммәсе дә доктор кушканча эшләнде. Ләкин инде болар да тәэсир итми башладылар. Габдулла мулла ясин укыб чыкды. Минут саен хәле авырая барды. Минут саен диярлек үзен әйләндерергә кушды. Бераз саташкалады. Ләкин әле һаман да аңында иде. Сәгать нәкъ ун тулганда: «Әйдә, китдек инде булмаса, күңелем рәхәтләнсен бер, менә шулай, менә шулай», – диде. Шул вакыт Фатих Мөхәммәдияров килде.

Шушы сүзләре аның актык сүзләре булды. Шундан соң һичбер сүз әйтмәде. Пульсы тәртибсезләнде. Кан тибү сирәкләнде. Сулу алуы да тирәнәйде. Берничә минутлар бик эчдән сулады. Аннары күкрәкдән, аннары бугаздан гына сулу ала башлады. Сулу бугазга күчкән чагында тәмам соңгы сулуына чаклы сәгатемдән караб тордым. Сулуы соңга таба шул дәрәҗәдә сирәкләнде, хәтта ярты минутка бер генә калды. Габдулла мулла ясин укуда дәвам итде. Яңа Бистәдән килгән Рокыя апалары Фатихнең колагына «Аллаһ», «Аллаһ» диб торды.

Күңел сизүе белән төнлә әйткән сүзендә күб ялгышмады. Иртә белән сәгать ун тулыб нәкъ 10 минут киткәндә актык сулуын алды. Җан бирде. Үзе әйткәнчә күңелен рәхәтләндереб, Аллага табшырылды. Бездән аерылды. «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун»[37] дидек.

*24 бит*

Фатихнең җан биргән минутларында өстендә караб торучылар: 1) Габдулла мулла Әмирхани, 2) Гомәр Әмирхани, 3) Кәрим Сәгыйд, 4) Фатих Мөхәммәдияров, 5) Разия Әмирхан, 6) Газизә Яушева, 7) Нәфисә Ваһапова, 8) Рокыя апалары, 9) студент Фәхретдинов, 10) шәфкать туташы Серова.

Фатих үлгәндән ун минут чамасы үткәч, Исхак Карташев килде. Мин аны Фатихнең хәле авырайгач да чакырткан идем, ләкин үлгәнче килеб җитә алмады. Мөхәммәдияров белән шәфкать туташы китделәр. Без шунда калган кешеләр Фатихнең гәүдәсен урыныннан алыб караватын чистартдык. Бүлмәсен юдыртдык. Бераз гына дезинфекция ясадык. Астындагы көрпәләрен алыб, пакь простыня җәеб, кыйблага аяклары белән яңадан караватына салдык. Аяклары элекдән катып калганга, үлгәч дә тез турындан бөтенләй тураеб бетмәделәр. Ярты җәя рәвешендә калдылар. Шуның соңында телефон белән үзенең якын күргән дустларына, танышларына, нәселдәшләренә, үзе белән мәдрәсәдә укыган ибдәшләренә һәм аны сөюче-ихтирам итүчеләргә, гәзит идарәләренә бер сәгать чамасы берәм-берәм әйтеб, хәбәр биреб чыкдык. Кайберләренә кеше җибәреб әйтдердек. Күб дә үтмәде, бу кешеләрнең һәммәсе дә берәм-берәм Фатихне тәне суынмаган актык мәртәбә күреб калырга агыла башладылар. Елашулар, сыкранулар китде. Бераздан күмү киңәшләре башланды. Бусы турында алдагырак битләргә кара.

*25 бит*

**Фатих Әмирхан авырган чагында хәл белә килүчеләр**

*26.02*

Ибраһим Биккол, Кәрим Сәгыйд, Гыйльми һәм Рәхимә Шәрәфләр, Ә[б]үбәкер Терегулов, Габдерахман Моратов.

*27.02*

Касыйм хәзрәт, Гәрәй Хәсәни, Садри Җәлал, Зыя Ваһапов, Фатима Апакова, Ибраһим Кули, Кәрим Тинчурин, Хәдичә Хуҗаханова, Кәрим Сәгыйд, Халисә Сәгыйд, Г. Моратов, Ә[б]үбәкер Терегулов, Фатих Мөхәммәдияров, Сафа Хафизов.

*28.02*

Г.Кәрәм, Ә. Хәсәни, Хәсән Исхаков, Зәйнәб Хәсәни, Шәһәр Шәрәф, М.Гали, Юсупов, Һарун Максудов, Әхмәдҗан Мостафа, Исхак Карташ, Ибраһим Аит, Разия

[37] Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун – Хакыйкатьтә без Аллаһныкы һәм Аңа әйләнеп кайтачакбыз.

Садыкова, Хәдичә Хуҗаханова, Шиһаб Әхмирев, Кәрим Сәгыйд, Г.Байки, Г.Моратов, Ибраһим Биккол.

*1.03*

Ибраһим Биккол, Кәрим Сәгыйд, Гәрәй Хәсәни, Таһир Ильяс, Йосыф Яушев, Ә.Терегулов, Б.Максудов, Хәдичә Хуҗаханова белән Суфия, Газизә Баттал, Г. Байки, Ибраһим Аит, Шиһаб Әхмирев, Вафа Бәхтияров, Г.Моратов, Исхак Карташ, Җамал Вәлиди.

*26 бит*

*2.03.*

Нәфисә Ваһапова, Кәрим Сәгыйд, Ибраһим Биккол, Борһан Шәрәф, Халисә Сәгыйд, Фатима Бәхти, Гәрәй Хәсәни, Шиһаб Әхмирев, Г.Моратов, Гаяс Байки, Шәфика Аитова, Кадир Хуҗаев, Зыя Ваһапов, Һарун Максудов.

*3.03*

Хәсән Исхаков, Йосыф Яушев, Каюм Мостакай, Фатиха Аитова, Зәйнәб Хәсәни, Ибраһим Биккол, Кадир Хуҗаев, Фатих Мөхәммәдияров, Нәфисә Ваһапова, Халисә Сәгыйд, Фатима Апакова, Кәрим Сәгыйд, (Танылмады), Садри Җәлал, Гомәр Бикбулатов, Фәтхи Борнаш.

*4.03.*

Нәфисә Ваһапова, Фатима Бәхти, Кадир Хуҗаев, Б. Максудов, Г. Моратов, Сибгать Ягуш, Шиһаб Әхмирев, М. Бөдәйли, Мәрьям Мөштәри, Хәмид Мөштәри, Ибраһим Биккол, Кәрим Сәгыйд, Зыя Ваһапов, Фатих Мөхәммәдияров.

*27 бит*

*5.03.*

Кәрим Сәгыйд, Каюм Мостакай, Ибраһим Биккол, Гәрәй Хәсәни, (Танылмады), Заһид Нуркин, Хәдичә Карташ, Ш. Байчура, Г. Моратов, Сафа Хафиз, Шәфика Аитова, Ибраһим Аит, Хәдичә Хуҗаханова, Хәсән Исхаков, Садри Җәлал, Ильяс Әхмирев.

*6.03.*

Габдулла Агишев, Ибраһим Биккол, Фатима Бәхти, Ш.Мостакай, Йосыф Яушев, Маһисәрвәр Мәрҗания, М.Гали, Ә.Хәсәни, Хәдичә Хуҗаханова, Зәйнәб Хәсәни, Х.Апаков, Исхак Карташ, Кәрим Сәгыйд, Ибраһим Кули, Нәфисә Ваһапова, Ә.Терегулов, Халисә Сәгыйд, Ибраһим Аит, Шиһаб Әхмирев, Ильяс Әхмирев, Г.Байки, Зыя Ваһапов, Фатима Апакова, Рәбига Дивиева, Г. Моратов, Гыйльми Шәрәф, Рәхимә Шәрәф, Исхак Карташ, Ә[б]үбәкер Терегулов, Г.Аитов.

*28 бит*

*7.03.*

Кәрим Сәгыйд, Ибраһим Биккол, Г.Кәрәм, М.Туминов, Әфтәх Тәрҗемани, Садыйк Иманколый, Ибраһим Аит, Рауза Апак, Шәмсевәли Тимергали, Заһид Нуркин, Сөләйман Яналиев, Шахмамитов, Касыйм хәзрәт, Бинеямин Әхтәмов, Гыйльми Шәрәф, Сара Касыймова, Халисә Сәгыйд, Зәйнәб Хәсәни, Гәрәй Хәсәни, Шәһәр Шәрәф, Хәдичә Танач, Вәлидхан Танач, Каюм Мостакай, Х.Зәбири, Нәфисә Ваһапова, Г.Моратов.

*8.03.*

Ибраһим Биккол, Кәрим Сәгыйд, Х.Зәбири, Гәрәй Хәсәни, Касыйм мөәззин, Вафа Бәхтияр, Фатима Бәхти, Нәфисә Ваһапова, Һади Максудов, Исхак Карташ, Кадир Хуҗаев, Фатима Апакова, Заһид Нуркин, Шиһаб Әхмирев, Зыя Ваһапов, Сафа Рәйми, Фатих Мөхәммәдияров, Сафа Хафиз, Ильяс Әхмирев, Ибраһим Кули, Хәдичә Хуҗаханова, Фазыл Локманов, Рәхимә Мөхитова, Хәсән Исхаков, М.Гали.

*9.03.*

Кәрим Сәгыйд, Ибраһим Биккол, Заһид Нуркин, Исмәгыйль Кугушев, Касыйм Фәхретдинов, Нәфисә Ваһапова, Ибраһим Кули, Касыйм мөәззин, Ибраһим Аит, Исхак Карташ.

**Кәрим СӘГЫЙД**

*(Ахыры киләсе санда)*

# БАКЫЙ УРМАНЧЕ МУЗЕЕНА 20 ЕЛ

*...Мин туган могҗизалар өчен.*
*Күңелемдә дәрт вә дәрман тулы.*
Бакый Урманче

Бакый Урманче музее 1999 елда ачылды. Шушы 20 ел дәвамында әлеге музей – татар мәдәниятенең күренекле шәхесен күз алдына китерергә мөмкинлек бирүче мемориаль комплекс. Ул сәнгати күргәзмә принципларын берләштерә һәм аның тарафыннан иҗат ителгән иң яхшы әсәрләрне колачлый. Музей экспозициясе нәкыш, скульптура, графика, гамәли бизәлеш сәнгатенә караган 60тан артык әсәрне, Бакый Урманченың архив документларын, шәхси әйберләрен, фоторәсемнәрен берләштерә.

Бакый Урманче (1897-1990) – рәссам һәм сынчы, музыкант һәм шагыйрь, укытучы, сәнгать белгече, гарәп һәм төрки телләрне камил белгән, француз һәм инглиз телләрендә иркен аралашкан, фәлсәфә һәм тарих фәннәрен җитди үзләштергән күпкырлы шәхес.

Ул 1897 елның 22 февралендә Татарстанның хәзерге Буа районы Күл Черкене авылында указлы мулла Идрис хәзрәт белән Мәгъҗүбә абыстайның тугыз балалы зур гаиләсендә дүртенче бала булып туган. Авыл малае Бакый гомерен сәнгатькә багышлый һәм югары һөнәри белем алган беренче татар рәссамы булуга ирешә. 1920-1926 елларда ул ВХУТЕМАСта – илнең беренче сәнгать уку йортында белем ала. Берьюлы рәсем һәм сынлы сәнгать факультетларында укый. Остазлары А.Шевченко, С.Герасимов, А.Голубкина була. Урманче Мәскәү мәктәбе рухын үзенә сеңдерә, аның иҗаты – татар импрессионизмының беренче үрнәге.

1926 елда белем алуын тәмамлап, Бакый Урманче Казан сәнгать техникумына (хәзерге вакытта Н.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы) укытырга кайта. Ул биредә декоратив-гамәли сәнгать факультеты ача. Милли сәнгатьне формалаштыруга хезмәт итүне үзенең төп бурычы итеп саный.

Сталинга гарәп әлифбасын сакларга өндәп язылган «82 кеше хаты»на кул куйганы өчен аны Соловкига сөргенгә җибәрәләр, ул анда 1929 елдан 1933 елга кадәр була. Азат ителгәч, башта Мәскәүдә эшли, 1941 елда Алма-Атага чакырылып, 14 ел буе Казакъстан һәм Урта Азия мәдәниятен күтәрә, сәнгать белемен үстерә. Казанга ул бары тик 1958 елны 61 яшендә генә кайта. Бакый Урманче гомеренең соңгы елларына кадәр үзенең иң күренекле, иң дәртле әсәрләрен нәкъ менә Казаныбызда иҗат итә. Бүген аның шушы чорда иҗат ителгән күп әсәрләре музеенда даими экспозициядә тора.

70 елдан артык вакыт эчендә сәнгатькә фидакарьләрчә хезмәт итеп, ул 400гә якын нәкыш әсәре, 150дән артык скульптура һәм кәгазь битләрендә меңнәрчә график әсәрләр иҗат итә. Бакый Урманче РСФСРның һәм ТАССРның халык рәссамы, Казакъстан ССРның атказанган рәссамы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты исемнәренә лаек була. Бакый Урманче иҗаты – татар сәнгате хәзинәсенең иң төп сәхифәләренең берсе һәм аның исеме халык мәдәнияте тарихында мәңге сакланачак.

Бакый Урманче калдырган масштаблы һәм уникаль мирасны халыкка җиткерү өчен экскурсияләрдән кала, музей хезмәткәрләре тарафыннан күп төрле чаралар оештырыла: Бакый Урманченың туганнары, шәкертләре һәм замандашлары белән очрашулар, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә.

**Гөлгенә АБИЛОВА,**
*музей хезмәткәре.*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Алмаз ГЫЙМАДИЕВ**

## «Күпмесен кире бирим?»

«Биш татар»ның гөрләгән чагы: Равил Шәрәфи, Рәшит Шамкай, Рәшит Сабиров, Хәлим Җәләй, Алмаз Хәмзин шәһәрләрдә, районнарда бик еш гастрольләрдә йөри. Гонорарны көнендә үк бирмиләр. Бригаданың җитәкчесе Хәмзин акчаны бераз соңрак, егетләрнең эш урынына – Камал театрына алып килә. 90нчы еллар – акчаның миллионнар белән исәпләнгән чагы бу.

Килеп керә Хәмзин Шәрәфинең грим бүлмәсенә. Бер төркем артистлар карта уйнап утыра. «О-о-о, шеф килде! Акча килде! Акча килде! Как раз кәрт сугарга акча беткән иде», – дип каршы ала аны Шәрәфи, сөенеп. Хәмзин һәммәсенең күз алдында кыштырдатып, акча санарга тотына: «Бер мең, ике мең, өч мең, дүрт...» Миллионга якынлашканда, сулышы каба монын, тирләп-пешеп чыга. Тирә-юньдәгеләрнең исә күзе түгәрәкләнә бара. Бер айлык хезмәт хаклары ич бу аларның!

Ниһаять, миллион! Бер төргәк акчаны Шәрәфинең кулына тоттыргач, Хәмзин саубуллашып, ишеккә юнәлә. «Тукта, озатыйм үзеңне», – дип, тегесе дә аның артыннан кузгала. Коридорга чыккач, Шәрәфи пышылдап сорый: «Күпмесен кире бирәсе?» «700 меңен», – ди Хәмзин дә, пышылдап кына.

Шушы ук хәл Хәлим Җәләй бүлмәсендә дә кабатлана. Аңлагансыздыр, чынлыкта гонорар ул кадәр үк зур түгел, Камал артистларын котырту өчен юри шулай эшли инде болар.

Чиратта – Шамкай бүлмәсе. Монда да кәрт сугалар. Тагын теге сценарий. Әлеге тамашадан өнсез калган Әзһәр Шакирның күзләре дымлана: «Алмаз, «Биш татар»да безгә дә бирәр эш юкмы соң анда? – ди ул үзенә генә хас тонык тавышы белән. – Алайса, йөрибез монда өч тиен зарплатага селкенеп...»

Шамкай исә кашларын сикертә-сикертә Хәмзинне озата чыга. Коридорда шул ук пышылдау: «Күпмесен кире бирим?»

## Шартлау

Газета-журналлар нәшер ителүче 14 катлы бина соңгы елларда зур үзгәрешләр кичерде. Затлы итеп ремонт ясалды, бүлмәләрне кондиционерлар, компьютерлар белән тутырдылар, электрон ачкычлы, тычкан да үтеп керә алмаслык заманча ишекләр куелды.

Беренче катта – буфет, брифинг-зал, тагын әллә ниләр... Әлеге үзгәрешләр биредә эшләүчеләргә тагын да тырышырга, бай эчтәлекле, матур газета-журналлар чыгарырга бер стимул булды.

Идәндә – затлы кафель. Аның пычрак вакытын һич күрмәссең – ун минут саен сөртеп торалар, күзләр чагыла.

Бинага кешеләрне энә күзеннән үткәреп, бик нык тикшереп кертәләр. Дөньяда еш кабатланып торучы терактлар шулай эшләргә мәҗбүр итә.

Көннәрдән бер көнне «Чаян» журналында эшләүче Хәмзин бер кат кына югарыда

утыручы «Казан утлары»ндагы дусларына карлыган кайнатмасы алып килергә вәгъдә бирә. «Өйдә ашаучы юк, дүрт-биш банка утыра, сыйлыйм әле үзегезне», – ди. Бер пакетка тутыра да кайнатмаларны эшкә юнәлә.

Ул көнне ниндидер зур җитәкче килергә тиеш булган, ахры – ишек төбендәге сак хезмәте егетләре галстук таккан, кафельләр тагын да тырышыбрак юылган.

Чамаламыйрак тутырган, күрәсең, гөнаһ шомлыгына каршы, кереп барганда, теге пакет шартлап өзелә бит! Өч литрлы банкалардагы дүрт варенье кафельгә төшеп чәлпәрәмә килә! Шартлау тавышын ишетеп, хезмәткәрләр йөгерешә башлый. Кемдер хәтта МЧСка шалтыратырга өлгерә. «Террорист»ның Хәмзин икәнен күргәч кенә тынычланалар.

## «Депутат син түгелмени?»

Сайлаулар чоры якынлашуга Разил Вәлиев һәрвакыт авылдашы, классташы, дусты Алмаз Хәмзингә шалтырата. Халык белән очрашуларга йөрү өчен. Билгеле инде, кешеләрне җыярга теләсәң, Хәмзиннән дә кулае юк – үзе җырлый, үзе сөйли, үзе көлдерә дигәндәй.

Икәүләшеп авылларда йөри болар. Разил Вәлиев сайлау алды программасы белән таныштыра, Хәмзин концерт куя. Рәхәтләнә генә авыл халкы бушка концерт карап. Саубуллашыр чак җиткәч, Хәмзин аларга мөрәҗәгать итә: «Шулай итеп, мөхтәрәм язучыбыз, шагыйрь Разил Вәлиевне сайларсыз дип ышанып калам!» Шулчак әби-апалар аптырашып кала: «Бәрәч, ике сәгать буе тырышып җырладың, сөйләдең... Без бит депутатлыкка сине сайлыйбыз дип торабыз...»

## Тирес

Шул ук 90нчы еллар. Алмаз Хәмзин туган ягы – Түбән Кама районы Ташлык авылыннан Казанга кайтып килә. Үзенең «буханка» «УАЗ»игында. Машинаның салонында – тирес. Капчыкларда.

Шәһәрдә бөтен нәрсә дефицит, бөтен нәрсә кыйбат. Шәһәр халкы яшелчә, җиләк-җимешне дачасында, бакчада үстерә. Хәмзин да үзләренең Казандагы бакчаларын әнә шулай Түбән Кама тиресе белән туендыра.

Капчык тирәсен чебеннәр сырып алган. Алар да Казанга кайта. «Буханка»ның шофёр ягы тирес исе һәм чебеннәр комачауламасын өчен яхшылап томаланган.

Мамадыш күперен чыгуга бер гаишник туктата моны. Йөзенең һәр күзәнәгеннән татар икәне кычкырып торган егет честь биреп, үтә дә эре кыяфәт белән Хәмзингә эндәшә:

– Сиржант Хәмидуллин! Ышту визём?

– Б..! – ди Хәмзин, тиресне авылчарак, кыскачарак, өч хәреф белән генә әйтеп.

Егетнең кашлары җыерыла:

– Я не шущу!!! Ышту ыв салоне?

– Энекәш, – ди Хәмзин саф татарча. – Әйттем бит инде, б.. дидем...

– Аткруй салун! – дип боера тегесе.

Хокук сакчыларына буйсынмый чараң юк – ачып җибәрә Хәмзин машинаның ян ишеген. Ә анда чыдап булмаслык ис! Ул гына түгел, саф һавага чыгуга аңгырайган чебеннәр, күккә күтәреләсе урында, сержантның авыз-борын тирәсенә юл тота.

– Тьфу! Тьфу! – дип чебеннәрне төкерә сержант һәм каты гына итеп сүгенеп, ишекне ябып куя. – Фәләненңне... Бар, абзый, бар, юлыңда бул! Ычкын моннан!!!

Саф татарча әйтә ул бу сүзләрне.

## Протез

Алмаз Хәмзиннең әтисе Наил абый сугыштан аяксыз кайта. Әмма ул үзенең гариплеген беркайчан да сиздерми. Алмазның Казанда укып йөргән студент чаклары. Әтисе аңа протез заводына кереп, «аяк запасы» алып кайтырга куша.

Бара Алмаз протезга. Утыра чиратта. Янәшәдә җыен аксак-туксак җыелган.

Бүлмәгә берәм-берәм чакырып кертәләр. Менә берзаман «Хәмзин!» дип кычкыралар. Керә. «Утыр!» – диләр. Утыра. Алмазга күтәрелеп караучы да юк. «Чишен!» – диләр. Трусикка хәтле чишенә. «Примеряйте!» – дип, әтисенә дигән протезны китереп тоттыралар. «Ничек?» – ди Хәмзин, аптырап. Шулвакыт бүлмәдәгеләр гаҗәпләнүле карашларын Алмазга төби: «Хәмзинме?» «Хәмзин!» «Откуда у тебя нога?» «Своя, – ди Алмаз. – Я же за отца пришёл!»

Заказны калын кәгазьгә төреп биреп җибәрәләр. Казан трамвайларында кайта-кайта кәгазьләр ертылып бетә, протез аякның балтыры белән табаны күренә башлый. Кешеләрнең күзләре шунда. Уңайсызланмый Алмаз, чөнки ул сугыш каһарманы – әтисе өчен аяк алып кайта!

## «Мине тотып калырсың»

Алмаз Хәмзингә алтмыш яшь тулган көннәр. Филармония администраторы Фердинанд Хафизов әйтә моңа: «Алмаз абый, әйдә, юбилееңны Чаллыда да үткәрик әле», – ди.

Китәләр. Иң әүвәл билет тарату эшен хәл итәргә, залны халык белән тутырырга кирәк бит әле. Чаллыдагы бер бай гына оешма җитәкчесенә керергә булалар. «Кереп тә тормагыз, – ди аны якыннан белүчеләр. – Бик яман сүгенә, чыдар хәл юк. Сез олы кеше, рәнҗерсез...»

Әмма Хәмзин бик кызыксынучан бит – тегенең ничек сүгенүен беләсе килә. Фердинандка әйтә бу: «Акча бирергә хәлебез юк, дисә, мин ава башлармын, син тотып калырсың».

Кереп тә җитмиләр, тотына теге аты-юлы белән сүгенергә! Үзе күтәрелеп тә карамый: «Халыкка хезмәт хакы түләргә акча юк, җитмәсә, сез йөрисез, ни бетмәгән хәерче артист...»

Шуннан, алдан килешенгәнчә, Хәмзин ава башлый. Ә Фердинанд каушавыннан аны тотып калырга кирәклеген оныта. «Лап» итеп идәнгә барып төшә Хәмзин.

Җитәкче шундук торып баса: «Ай, Алмаз абый, берәр җирегез авыртмадымы, нәрсә булды? – дия-дия күтәреп ала. – Күпме бирик?» «Бер 50 билет алсагыз, әйбәт булыр иде», – ди Хәмзин, көчкә сулаган кыяфәт чыгарып. «Ничәшәр сумнан?» «500!» Теге кабат сүгенә башлый, ләкин: «Ярар, синең хакка алырбыз инде», – дип, мәсьәләне уңай хәл итә.

## «Газинур что ли?»

Бервакыт җырчы Газинур Фарукшин Самарада концерт кую өчен артистлардан төркем җыя. Хәмзин да шулар арасына эләгә. Китәләр. Рульдә – Газинур үзе.

«ГАЗел»енең урындыкларын алып, артистларны шунда төйи – берничә урындыкны алсаң, «В» категориясенә туры килә икән, дигән сүзне ишеткән булган, күрәсең.

Әмма Самарага җитәргә 50-60 чакрым калганда, гаишниклар туктата машинаны. «Есть у тебя категория «Д»?» – дип сорыйлар шофёрдан. «Нет.» «Давай, штраф!»

Газинур, бичара, нишләсен, штраф түли инде.

Ярар, барып җитәләр, концертны куялар. Гөнаһ шомлыгы, халык аз була. Әлләни акча эшли алмыйлар.

Кире кайтып баралар, шул ук чатта кабат гаишниклар тагын туктата: «Газинур что ли?» «Да.» «Категория «Д» есть?»

Кая барсын, түли штрафны...

50-60 чакрымлап кына китәләр – тагын гаишниклар!

Боларга тегеләре шалтыратып, хәбәр итеп куйганнар, махсус көтеп торганнар. Кабинадан чыгуы була: «Газинур что ли?» – дип, янә килеп басалар. Тагын штраф!

Шулай итеп, бөтен эшләгән акчаны Самара гаишникларына биреп кайта болар.

# İctimağí-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## WORLDSKILLS KAZAN 2019

Казанда WorldSkills Kazan 2019 эшче һөнәрләре буенча дөнья чемпионаты булып узды. Казанга 63 илдән эшче һөнәрләренең осталары килде.

Чемпионатның ачылыш тантанасында халыкны РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев, WorldSkills президенты Саймон Бартли сәламләде. Ярышларны ябу бәйрәмендә РФ Президенты Владимир Путин чыгыш ясады. Тантаналарның икесендә дә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Дөньякүләм WorldSkills Kazan 2019 чемпионаты барган көннәрдә Казанда илледән артык мәдәни һәм күңел ачу чарасы уздырылды. Театрларда иң яхшы спектакльләр, С.Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында IX халыкара «Казанская осень» опера фестивале кысаларында концертлар күрсәтелде, фестивальләр, ярминкәләр, күргәзмәләр оештырылды, мастер-класслар үткәрелде, бию остаханәләре эшләде, Кремльдә җирле һәм классик сәнгать үрнәкләре тәкъдим ителде.

## САЙЛАУ

8 сентябрьгә билгеләнгән алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советына сайлауларга җиде сәяси партия кертелде. 100 депутат мандаты (50се – партия исемлекләре, 50се бер мандатлы сайлау округы буенча) өчен көрәш барды. Республика иҗтимагый палатасы тарафыннан 2811 сайлау участогына күзәтүчеләр билгеләнде. Сайлауларга әзерлек чорында «Бердәм Россия» партиясе аеруча активлык күрсәтте: «Мобиль кабул итү» проекты гамәлгә ашырылды, республикабыз шәһәрләре һәм районнары буйлап «Минем депутат» дигән язулы автобуслар йөрде. Халык әлеге автобусларга кереп, үзенең үтенеч-гозерләрен әйтә алды.

## РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ ЮБИЛЕЕ ЯКЫНЛАША

Татарстан АССРның бер гасырлык юбилее якынлаша. Әлеге бәйрәмне билгеләп үтү турында указ 2015 елда имзаланган иде. Казан ратушасында Россия Федерациясе хөкүмәте Рәисе урынбасары Виталий Мутко катнашында утырыш булды. В.Мутко сүзләренә караганда, ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итү – федераль масштабтагы вакыйга. Олы юбилейның оештырылуы Татарстанның икътисад, мәдәният, спорт, фән һәм мәгарифне үстерүгә керткән өлешен, республика казанышларын күрсәтергә мөмкинлек бирәчәк. Әлеге вакыйганың планы 75 чарадан тора. Казанда БДБ уеннары, «Россия-Ислам дөньясы» халыкара саммиты, федераль Сабантуй, халыкара музей форумы, татар театрларының чит төбәкләргә гастрольләре, төрле күргәзмәләр, конкурслар һ.б. – барысы да шушы юбилей кысаларында узачак.

Утырышта чыгыш ясаган ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов та бу бәйрәмнең федераль статус алуын әйтте. Тантаналы чараларның Казаннан тыш Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, башка төбәкләрдә һәм чит илләрдә узачагын хәбәр итте.

## АВГУСТ КИҢӘШМӘСЕ

«Казан Экспо» күргәзмәләр комплексында Татарстан мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең «Тәрбия – белем бирү сыйфатын күтәрү факторы» темасына багышланган август киңәшмәсе булып узды. Анда Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов доклад белән чыкты. Киңәшмәдә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов чыгыш ясады. Ул иҗтимагый үсешнең катлаулы процесслары шартларында үсеп килүче буынны тәрбияләүнең актуаль була баруын әйтте. Укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә республикабыз мәгариф хезмәткәрләре алдында яңа бурычлар куйды. Әлеге чарада ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

## РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ КИТАП ҺӘМ ЯЗУЧЫЛАР ТУРЫНДА

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов бер төркем массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләре белән очрашты. Әлеге сөйләшүдә ул үзенең китапка һәм язучыларга карата фикерен дә җиткерде:

– Яңалыкны, теге яки бу әсәрне Интернеттан укуга караганда, китаптан уку уңайлырак. Шуңа күрә без барыбер тора-бара кәгазьдән укуга күчәрбез, дип уйлыйм. Икенчедән, язучыларыбызга бәя бирәсем килми, әмма аларның әсәрләре укучы өчен кызык булырга

тиеш... Хәзер без элекке «Казан» милли мәдәният үзәген китапханә итеп үзгәртәбез. Анда яңа технологияләр кулланылачак. Ягъни бу мәсьәләгә бик зур игътибар бирәчәкбез. Яңа язучыларыбызның гына түгел, күренекле язучыларыбызның да бик кызыклы әсәрләре бар. Ә балалар аларны белми. Бәлки, бу әсәрләр буенча фильмнар төшерергәдер. Фильмны караган балада китабын да уку теләге уяначак. Мәктәптәге китапханә – китап саклагыч түгел. Ниндидер мастер-класслар, очрашулар үткәрелергә тиешле урын бу.

Рөстәм Миңнеханов язучыларга активрак булу, укучылар белән ешрак очрашу зарурлыгын да искәртте.

### ЮБИЛЕЙ

Казан телевидение студиясенең 60 еллыгына багышланган тантана булып узды. Анда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның әлеге вакыйга уңаеннан котлавы яңгырады. Аны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров ирештерде. «Барлык коллегаларга һәм ветераннарга Татарстан өчен бәяләп бетергесез булган мәгълүмати эшчәнлекләре өчен рәхмәтемне белдерәм! Алга таба да яңа иҗади уңышлар, күпсанлы тугры тамашачылар булуын теләп калам!» диелә әлеге котлауда. Ә.Сәфәров телевидение ветераннарын һәм хезмәткәрләрен үз исеменнән дә котлады, аларның «иң-иңнәре»нә Мактау дипломнары тапшырды, студиянең дистә еллар дәвамында туган телдә сөйләүче бердәнбер канал булуын искәртеп узды. «Хөрмәтле милләттәшләр, дөнья белән мәгълүмат идарә иткән заманда сезгә тугрылык саклап, үз профессиональ йөзегезне югалтмыйча, Казан телевидениесе традицияләрен дәвам итүегезне телим», – диде ул үзенең чыгышында.

### ХАЛЫКАРА ФЕСТИВАЛЬ

Алабугада X Халыкара мәктәп укытучылары фестивале булып узды. Әлеге форумга 500дән артык укытучы килде. Аны ачу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты һәм лекция укыды. Ул барлык укытучыларга балаларны, ягъни киләчәгебезне кайгыртулары өчен рәхмәт белдерде, бу фестивальне киләчәктә дә дәвам итү кирәклегенә басым ясады. Тантанада катнашучыларны ТР Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов сәламләде.

Әлеге форумның темасы – «Үзгәрешләр мәктәбе». Анда ачык мәгълүмат гасырында укытучының роле, ничек үзгәрергә тиешлеге, төрле илләрдәге мәктәп белеме бирүнең традицион һәм яңа форматларының нәтиҗәлелеге турында зур сөйләшү булды, дискуссион мәйданчыкларда һәм мастер-классларда укытуның полилингваль киңлеген булдыру, цифрлы белем бирү технологияләрен куллану, укучының сәләтен үстерү, аңа ярдәм итү, инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыру, хәзерге заман укытучысының имиджы кебек проблемалы чыгышлар тыңланды.

### ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

Казандагы 1 Май мәйданында моннан 75 ел элек фашист төрмәсендә җәзалап үтерелгән Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләрен искә алу мәрәсиме булып узды. Анда язучылар, галимнәр, Казан театрлары актёрлары, театр училищесы студентлары, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе җырчылары, музыкантлар, «Хәтер дозоры» яшьләр хәрәкәте (ТР Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге, Татар китабы йорты тарафыннан оештырылды) вәкилләре катнашты. Искә алу мәрәсименә Мәскәүдән каһарман шагыйрьнең кызы Чулпан Җәлилова да кайткан иде.

### УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Татарстан язучылары республикабызның район һәм шәһәрләрендә укучылар белән очрашуларда катнаштылар. Мондый чаралар Арча, Биектау, Кукмара, Әлмәт, Тукай, Буа, Мөслим, Балык Бистәсе, Чистай, Кайбыч, Лаеш, Алексеевск, Аксубай, Ютазы һ.б. районнарда, Чаллыда үткәрелде.

### БОЛГАРГА СӘФӘР

Татарстан язучылары (30лап каләм иясе) Болгар тарихи-архитектура музей-тыюлыгына сәяхәт кылды. Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов җитәкчелегендә делегация юл уңаенда каһарман-язучы Абдулла Алишның туган авылы Көеккә кереп, әдипнең бюстына чәчәкләр салды, аның рухына дога багышлады. Каләм ияләре Болгар цивилизациясе музеен, иң зур Коръән сакланган «Истәлек бинасы»н карадылар, Россия Ислам академиясендә, Ак мәчеттә булдылар.

### ӘБҮНӘЧЕЛӘРГӘ – БҮЛӘКЛӘР

2019 елның икенче яртысына «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте нәшер иткән өч яки аннан артыграк басмага язылып үз квитанцияләрен җибәргән әбүнәчеләр арасында телевизор уйнатылды. Бәйгедә 178 кеше катнашты. Телевизорны Әтнә районыннан Рафаэль Мөхәммәтҗанов отты. Телевизордан тыш, 12 комплект йон юрган, мультиварка, электр иттарткычы, блендер уйнатылды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман-элегия К.КАРИМОВА «Письмо без адресата», повесть А.САФИУЛЛИНА «Гайфулла из Китая», десять притч «Ногайский дом» Л.ЗУЛЬКАРНАЯ, рассказ Ф.САДРИЕВА «Возвращение в Алмалы-куль», рассказ Г.ХАСАНОВОЙ «Судьба»; стихи Г.БАТТАЛОВОЙ, Ш.ГАДЕЛШИ, рубаи Ф.ДАВЛЕТБАЕВА.*
*«Из литературы родственных народов»: стихи Ш.АБДИКАРИМОВА.*
*«Новые имена»: стихи А.ВАХИТОВА и М.ГАФУРОВОЙ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*Конкурс «Исцеляющие руки»: повесть С.САУБАНОВОЙ «Диагноз».*
*«Татарстан. История. Личности»: очерки Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ и Р.ГИЛЕМХАНОВА.*
*«85 лет со дня образования Союза писателей Татарстана»: статья Л.ХАМИДУЛЛИНА; фотоархив, посвящённый юбилею Союза писателей РТ .*
*«Тукай и татарская литература»: статья Р.РАХМАН.*
*«Книжное обозрение»: И.ГИЛЯЗОВ. «Новая научная работа о Казанском ханстве».*
*«Тюркские литературы и современнось»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Бриллианты эпохи»: Дневник К.САГИДОВА «Болезнь, смерть, церемония захоронения известного татарского писателя Фатиха Амирхана» (с предисловием И.ГУМЕРОВА).*
*«Наши музеи»: Г.АБИЛОВА. «20-летие музея Б.Урманче».*
*«Страницы юмора»: подготовил А.ГИМАДИЕВ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: музей Баки Урманче в г.Казани. Фото Т.Абдуллина; литературный критик Рамиль Ханнанов.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel-elegy by K.KARIMOV «A letter without an addressee», novel by A.SAFIULLIN «Gayfulla from China», ten parables «The Nogai House» by L.ZULKARNAY, story by F.SADRIEV «Return to Almaly-kul», story by G.KHASANOVA «Fate»; poems by G.BATTALOVA, SH.GADELSHA, rubaiyat by F.DAWLETBAEV.*
*«From the literature of related peoples»: poems by SH.ABDIKARIMOV.*
*«New Names»: poems by A.VAKHITOV and M.GAFUROVA.*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*Competition «Healing hands»: novel by S.SAUBANOVA «Diagnosis».*
*«Tatarstan. History. Persons»: essays by F. ZAMALETDINOVA and R.GILEMKHANOV.*
*«85 years since the foundation of the Union of Writers of Tatarstan»: article by L.KHAMIDULLIN.*
*85th anniversary of the Union of Writers of the Republic of Tatarstan: photo archive.*
*«Tukay and Tatar literature»: article by R.RAKHMAN.*
*«Book Review»: I.GILYAZOV. «New scientific work about the Kazan Khanate».*
*«Turkic literature and modernity»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Diamonds of the era»: Diary of K.SAGIDOV. «Disease, death, burial ceremony of the famous Tatar writer Fatih Amirkhan» (with a preface by I.GUMEROV).*
*«Our museums»: G.ABILOVA. «The 20th anniversary of the B.Urmanche Museum».*
*«Pages of humor»: produced by A.GIMADIEV.*
*Diary of social and cultural life.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Бакый Урманче музее. *Т.Абдуллин фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* әдәби тәнкыйтьче Рамил Ханнанов.